# Казан утлары

10
ОКТЯБРЬ • 1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**10**

ОКТЯБРЬ
1977

## Бу санда

И. ЮЗЕЕВ. Өзелмәс кыллар. Поэма . . . . . 3
Ә. ГАФФАР. Кашан җыры. Повесть . . . . . . 13
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Казан — күңелем һәйкәлләре
иле. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 71
М. ХУҖИН. Өч хикәя . . . . . . . . . . . 75
Р. ХӘЛИУЛЛИНА. Каенана. Поэма . . . . . . 90
В. ИСХАКОВ. Карт һәм чәчәкләр. Новелла . . . 94

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Х. ХӘЙРУЛЛИН. Бригадир Зөфәр. Очерк . . . 99
В. БЕЛОКОПЫТОВ. Яшәү хакына . . . . . . . 105
Ә. ГАЛИЕВ. Давыллы еллар аша . . . . . . . 112

ОКТЯБРЬ ТУДЫРГАН ӘДИПЛӘР

М. ГАЙНУЛЛИН. Укыдык, укыттык, эшләдек, эшлибез . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Р. ИШМОРАТ. Изге көн, изге ел... . . . . . . 121
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Юл күрсәтүче йолдыз . . . . 123
А. РАСИХ. Өч фарыз . . . . . . . . . . . 126
Р. ГАМЗАТОВ. Беренче номерлы пост . . . . 128

ҮЗЕШЧӘН СӘНГАТЬ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ ӨЧЕН

С. ШӘКҮРОВ. Кыз бирү. Пьеса . . . . . . . 132

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. Ф. ВӘЛИЕВ. Якты маяк . . . . . . . . . 163

ПУБЛИЦИСТИКА

Р. МОСТАФИН. Фән-техника революциясе һәм милли әдәбиятлар үсеше . . . . . . . . . 169

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ


**Ш. САДРЕТДИНОВ.** Мәгърифәтчелек дәвере әдәбиятын өйрәнү юлында . . . . . . . . . 174
**Ф. УРМАНЧЕЕВ, Р. ӘХМӘТҖАНОВ.** Җырлагыз, дуслар, җырлагыз... . . . . . . . . . . . 178


ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...


Әпкәли язмалары . . . . . . . . . . . . . 183
**Г. НӘБИУЛЛИН.** Мин һәм Салман. Шигырь . . 186


БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ


**Ә. САБИРОВА.** Шиһап Рамазанов . . . . . . 187
**Ш. РАМИЛ.** Китапханәгә 70 ел . . . . . . . 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190



Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.



Баш редактор: **Зәки Нури**
Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 4/VII-1977 ел. Басарга кул куелды 13/IX-1977 ел. ПФ 09034. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж экз.
Заказ Б-281. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1977 ел.

## Илдар Юзеев

# ӘЗЕЛМӘС КЫЛЛАР

### Кереш

Биек таудан аска төшеп барам,
Туктап карыйм гомерем кыясын,
Сирәк чәчләремне җемелдәтеп,
Баеп бара инде кояшым.
Күнеккәнсең, йөрәк, тынлыкка да,
Һәм ят түгел сиңа шаулар да,
Калды инде, калды еракларда
Йөгереп менгән чагым тауларга.
Актык көчем җыеп тауга мендем:
Ниндидер бер нечкә кыл тартты...
Туктагыз да, яшьләр, тыңлагыз сез
Скрипка тоткан чал картны.
Вакыт җитеп килә бу дөньядан
Үз көеңне уйнап китәргә,
Безгә — аманәтләр калдырырга,
Сезгә — безне дәвам итәргә.
Тормыш мәгънәле һәм дәртле була
Таба белсәң иң төп кылларын,
Кабатланмас моңлы бер көй булып,
Сызылып калды узган елларым...
Үзем уйнар көйне яшьлегемдә
Җиңел табармын дип уйладым,
«Гомер» дигән көйне мин бары тик
Гомерем баешында уйнадым.
Үз көем ул минем... Аерып булыр...
Күммәс башка көйләр дулкыны.
Мең һәм миллион кыллы зур тормышның
Көйләр сезгә бары дүрт кылы...

### Беренче кыл

#### ӨМЕТ КЫЛЫ

Вилдан истәлеге, изге ядкарь
Яуда йөргән егет чаклардан...
Кыл өстендә йөрсәк йөрдек, әмма
Егылып төшмәдек без атлардан.

...Бер чак шулай чолганышта калдык,
Ахыр чиккә кадәр түзелде,
Алда, артта — дошман, —
Юл киселде, өмет өзелде.
Скрипкасын алды кулларына:
— Их, бер уйныйк әле, егетләр!
Сездәй кыю җаннар бар чагында,
Юк, өзелмәс юллар, өметләр!
Кайдан соң бу гаҗәп тылсымлы көй?—
Кылларыннан Йолдыз кашканың...
Болай оста, болай таң калдырып
Уйнаганын белмим башканың.
Әллә нинди җанга якын көчләр
Тартты безне Вилдан артыннан.
Без камаудан чыктык. Качты дошман,
Танып алып кашка атыннан.
Ул үзе дә серле бер көй иде, —
Дәвер көе нәкъ шул булгандыр.
Кызыл гаскәр узган олы юлда
Ишетәм сыман сүзен Вилданның:
«Җанга керим дисәң, нык тарттырма,
Бушатма да — тап кыл уртасын,
Шул чагында табарсың син көйнең
Илаһи бер бөек ноктасын»...
Төшмәде ул соңгы сулышкача
Шул илаһи бөек ноктадан.
Иярендә килеш алга барган,
Туктамаган!.. — Йөрәк туктаган...
Кемнәр әйтә: «Герой — корычтандыр,
Батырлыкны шуңа кылгандыр».
Ихтыяры корыч булса булыр,
Ә күңеле — нечкә кылдандыр,
Иң-иң нечкә күңелләрнең берсе —
Җанның көен тапкан Вилдандыр.
Корбан бирә-бирә, яклавык без
Илебезнең һәрбер карышын.
Туган җирдә туфрак булганнарга
Сәлам биреп төшеп барышым.
Тау башында гына кабере аның...
Аннан башка күпме ел үткән...
Сез яшәгән тормыш күтәрелде
Вилдан саклап калган Өметтән.
Түзәлмәслек өметсезлек кайчак
Юлдаш булса барыр юлымда,
Бөтен күңелем биреп уйнадым мин
Менә шушы Өмет кылында.
Каһарманнар туктап калган җирдән
Алга киттек Хыял артыннан,
Җаннар — Җирнең даһи көен тапкан
Ленин Өметенә тартылган.
Йөрәгенә якын шушы көйне
Халкым ничә гасыр эзләгән,
Тукай кебек нечкә кыл тудырган,
Әмма Өмет кылын өзмәгән.
Бер мәкер дә тартып өзәлмәсне
Күп дошманнар инде аңлады,
Җәлилләрнең башын чабып өзде, —

Өмет кылын өзә алмады!
...Җирдә әле күпме өметсезлек...
Ачлык... Сугыш... Коллык чылбыры...
Юк! Халыклар, Ирек көен табып,
Зур Өметкә —
Тынычлыкка таба йөз борыр!
Вилданнардан калган шушы кылны
Саклагыз сез, яшьләр, өзмәгез,
Югалтсагыз әгәр, фидакарьләр
Туктап калган җирдән эзләгез!..
Безнең көйләр бик үк булмаса да
Бер үк тембр, бер үк дулкында,
Уйлый-уйлый сез уйнарга тиеш
Вилданнардан калган шул кылда...

## Икенче кыл

### мәхәббәт кылы

Бик сак кына кагылам мин бу кылга:
Аннан нәзакәтле кыл юктыр...
Сорадым мин яшьли язмышымнан:
«Мәхәббәткә мине юлыктыр».
Дездемона, Зөләйхалар түгел,
Студент кыз Диләиде ул,
Узган-барганнарны «ах!» иттереп,
Урамнардан килә иде ул.
Шушыдыр ла җирнең идеалы,
Камиллеге, рухи пакьлыгы,
Күтәрелде җаным бөеклеккә...
Юктыр матди дөнья ваклыгы.
Диләуйный, гүя табигатьнең
Һәр табылган көе кушылыр,
Мәхәббәтнең башка көе юктыр,
Мәхәббәтнең көе шушыдыр...
Ул яр иде — «сакласана!» диеп
Табигатьтән ярдәм сорарлык,
Ул яр иде — асыл бер яр иде
Сөенечтән кочып еларлык!
Кочып та мин елый алмыйм хәзер...
Мин югалттым аны... Ник? Нигә?
Ничә еллар йөрәк сорау биреп
Газап чигә... Ник? Нигә?
«Мин бары тик сине сөям!» диде.
Сүзгә ышанмадым... Көнләдем...
Отеллодай шаштым, үзем качтым,
Газапландым көнен-төннәрен.
«Дилә, Дилә, мин ышанмыйм сиңа,
Нигә күпләр сиңа күз ата?
Егетләрнең комсыз карашлары
Каршы ала сине, озата...»
... Бер чакны мин авыр хәлдә калдым...
Гөнаһсызга бәла тактылар...
Хәтта дус дип йөргән кайберәүләр
Баш тарттылар...

Күз алдымда таныш ихлас йөзләр:
Гаебем юк, нишлим, туганнар?
«Иң-иң авыр хәлдә калганда да
Хаклык җиңә!» — диде Вилданнар.
Тикшерделәр. Акладылар. Чыктым.
Бик сагындым. Эзлим Диләне.
Җилләр телеграмм кылларында
Коточкыч бер хәбәр көйләде:
— Ул юк!
— Ул юк?!
Күзалларым — томан,
Кап-карадыр
Декабрьның салкын ак кары.
Дус кызлары скрипкасын суза:
— Менә... соңгы ядкаре.
Диләбары сине генә сөйде,
Тик мәхәббәт бәхете тимәде,
Табалмассың инде дөньяларда
Андый ярны, андый Диләне...
Скрипка кылы... Тартылудан
Ул да җуя, ахры, түземне.
Бәгыремнән сызып үткән чакта,
Мәхәббәтем кылы өзелде.
... Барган. Әйткән: «Мин ышанам аңа!
Ул — ярым да минем, дусым да...
Мин бары тик аны гына сөям,
Җан яраткан кайда, мин шунда!»
Кавышулар көен уйнамадым,
Аерылу көен уйнадым,
Мин эзләдем. Таптым. Соң иде шул...
Каберен генә таптым мин аның...
Ул нурлана минем күз алдымда
Төньяктагы балкыш шикелле,
Ярын җуйгач, кинәт җиргә төшеп,
Җанын биргән аккош шикелле.
Мәхәббәтем кылы гомерем буе
Үкенечле бер көй көйләде:
«Табалмассың, йөрәк, дөньяларда
Андый ярны, андый Диләне».
... Сез тыңлагыз менә шушы кылны,
Әрнү ишетелсә аңардан,
Белегез сез, бик нык тартылган да,
Ул, өзелеп, кабат ялганган...
Югалтсам да аны, мин үземне
Мескен дәрвиш итеп тоймадым,
Мәхәббәтем кылын эзләп таптым,
Мәңге тынмас көен уйнадым.
Ул көй моңлы итте гомеремне,
Сабыйланып аштым күкләргә.
Сөю бәхетен тоеп калды йөрәк, —
Ә ул... насыйп булмый күпләргә.
Бер чак җирдә ике йөрәк типкән...
Адәм эзләп тапкан Һавасын,
Миллион-миллиардларның арасыннан
Үз Һаваңны табып кара син!..
Күпме әле Сөю дигән хиснең
Ни икәнен белми киткәннәр,

Ярын табалмыйча тилмергәннәр,
Зар булганнар, газап чиккәннәр,
Мәхәббәт дип уйлап алданганнар,
Бер куышта гомер иткәннәр!..
Сызыл, кылым, бәлки берәүләргә
Бу көй инде күптән таныштыр.
Сызыл, кылым, сызыл, көйсезләрне,
Ярсызларны табып кавыштыр!..
Юк, яшермим татлы яшьләремне,
Никадәре түзем булсам да,
Мәхәббәтем калыр, кылым калыр,
Көем калыр... үзем тынсам да.

## Өченче кыл

### НӘФРӘТ КЫЛЫ

Өмет һәм Мәхәббәт көен уйнап,
Алсу иртәләрем сызылган...
Диң-даң!
Диң-даң!
Июнь балкышына бомба куеп,
Дошман килә... Көйләр өзелгән.
Бу кылны мин чиртәм мәҗбүр булып:
Уян, Нәфрәт!
Уян, Вөҗдан!
Диң-даң!
Диң-даң!
Концерт залы — концлагерь,
Консерватория — зиндан!
Көй уйнаган куллар — курокта,
Ярын кочкан куллар — курокта.
Диң-даң!
Диң-даң!
Уян, Нәфрәт!
Уян, Вөҗдан!
Өмет, Мәхәббәткә мылтык терәп,
Фашист уйный «үлем биюе»н,
Кетә Азатлыкның баш июен...
Диң-даң!
Диң-даң!
Уян, Нәфрәт!
Уян, Вөҗдан!
... Хәйдәр якташ белән, яраланып,
Әсир булдык фашист кулында.
Ат кылыннан ясап, скрипканың
Уйнады ул тик бер кылында.
Дусларымның күзләрендә — нәфрәт!
Йомшаклыктан түгел күздә яшь...
Нинди генә дошман кагылса да,
Өзелмәде ул кыл, өзелмәс!
Шушы бер кыл, нәфрәт көен уйнап,
Ирек өчен яуга әйдәгән,
Шушы бер кыл, аерылмаслык итеп,
Туган җиребезгә бәйләгән.

Белмәделәр дуслар: ә бит ул кыл
Немец чаптарыннан алынган,
Һәркем көен нәкъ үзенчә сыза —
Килгән сыман туган ягыннан.

Көйнең, телнең, гореф-гадәтләрнең
Бар үз моңы, бар үз хисләре...

Ә табигать, нәфрәт, мәхәббәтнең
Юк һәм булмас милли чикләре!
Әллә бу көй Зөя буйларының
Сәламнәрен алып килгәнме?
Телгәләнгән җанны сөеп уза.
Нинди көй бу? Әллә Вилданмы?..

Күтәрдек без башны югарыга,
Кем баш ия — тик шул кол иде,
Хәйдәр якташ булып, үз артыннан
Ияртүче тик бер кыл иде!
Күрер күзгә күренмәслек кылны
Дошманнар да, ахры, сизделәр:
Күз алдында Хәйдәр дус гәүдәсен
Танклары тартып өзделәр.

Дусларымның күзләрендә — нәфрәт,
Йомшаклыктан түгел, күздә яшь!
Нинди генә дошман кагылса да,
Өзелмәде ул кыл, өзелмәс!
Нинди көч тә туктатырлык түгел, —
Ыргылдык без ачу-нәфрәттән,
Азат иттек үзебезне, илне
Һәм дөньяны бәла-афәттән.
Скрипкамны алам кулларыма,
Хәйдәр якташымны сагынсам,
Үзәкләрем хәзер өзеләдер
Менә шушы кылга кагылсам.

Хәйдәр көен уйнап бирсәм генә,
Сезгә әйтер сүзем хакланыр.
Гомерем кылы өзелгәнгә кадәр
Күкрәгемдә нәфрәт сакланыр...
Диң-даң!
Диң-даң!
Бу көй йөрәгемә тирән кайгы,
Нәләт-каргыш белән сызылган.
Диң-даң!
Диң-даң!
Миллион гомерләрне биреп алган
Ирекккә — дан!
Инде чынбарлыкка әверелгән
Өметкә дан!
Җир әйләнеп кайткан Егеткә дан!
Сафлардан-саф Өмет-Хаклыкка дан!
Аны яулап алган Халыкка дан!
Диң-даң!
Диң-даң!
Гашыйкларга —
Таһир-Зөһрәләргә,
Ләйлә-Мәҗнүннәргә дан!
Диң-даң!
Диң-даң!

Җаннар, каннар, саннар хисабына
Яулап алынган дан!
Диң-даң!
Диң-даң!
Сизгер бул, Җан!
Онытма, Җиһан:
Җир үзенә миллионнарның
Нәфрәтен җыйган.

Диң-даң!
Диң-даң!
Кабатла, Җан,
Кабатла, Җиһан:

Вөҗдансызларга,
Имансызларга —
Нәфрәт! Нәфрәт! Нәфрәт!
Җансызларга,

Кансызларга,
Сансызларга —
Нәфрәт! Нәфрәт! Нәфрәт!
Хаиннарга,
Җәлладләргә —
Нәфрәт! Нәфрәт! Нәфрәт!

Үлгәннәрнең нәфрәте дә
Җир карынында ятмасын:
Кара ниятнең юлында
Бомба булып шартласын!

Тынычлана күрмә уйлап:
«Сугыш инде узган...»

Уяу бул, Нәфрәт,
Йоклама, Вөҗдан!
Диң-даң!
Диң-даң!
Әнә анда Золым
Баш калкыта кабат!
Ирек куйсаң — бик тиз
Алыр Җирне камап!

Диң-даң!
Диң-даң!
Уяу бул, Нәфрәт!
Уяу бул, Вөҗдан!
Нәфрәт — явыз көчкә:

Дарга, свастикага,
Гильотинага,
Бомбаларга — нәфрәт!

Вәхшилеккә, дошманлыкка
Һәм коллыкка — н ә ф р ә т!
Н ә ф р ә т! Н ә ф р ә т! Н ә ф р ә т!
Чор катлаулы: тик көрәштә туа
Мәхәббәт тә, Хыял-Өмет тә...

Мәҗбүр булып без уйнаган көйне —
Нәфрәт хисен сакла, киметмә!
Диң-даң!
Диң-даң!
Уяу бул, Нәфрәт!
Йоклама, Вөҗдан!

# Дүртенче кыл

ИҖАТ КЫЛЫ

Тормыш дигән бер көй туа башлар
Өмет, Мәхәббәт һәм Нәфрәттән,
Ул көй булыр безне җилкендергән,
Ул көй булыр безне яшәткән...
Уйламагыз: «Камил көй табылыр
Бу дүртенче кылдан башка да»...
Мондый кылда, тиңсез илһам белән,
Зур осталар гына башкара.
Кара алтын табу остасы ул, —
Мәшһүр артист булу уе юк.
Ә тормышның шул остадан башка
Алга барышы һәм көе юк.
Чал чәчләре тузган, уйга чумган,
Көен эзли Шамун кылларда:
«Ничек табигатьнең кылын өзми,
Байлык-хәзинәсен юлларга?
Скрипкада — кеше уе тапкан,
Машинада туган кыллар бар,
Табигатьнең үзе кебек гүзәл,
Моңлы, садә... димәк, юллар бар!»
Туа иҗат чиксез газапларда...
Бар аң, бар җан аңа тартылган.
Кая чакырса да, егетләре
Иярергә әзер артыннан.
Без аны гел алдыбызда күрдек,
Эссе җәйме, зәһәр кыштамы...
Җырның көен белгән,
Җирнең көен белгән,
Җанның көен белгән останы.
Әкияттәге пәһлевандай итеп
Тоя идек аның янында,
Скрипканың бердәм кылларыдай,
Бер көй идек эштә, табында.
Ниләр кылдык, ниләр эшләдек без
Ул уйнаган көйгә кушарлык?
Күбебездә кими бара иде
Тупаслык һәм явыз усаллык.
Шамун абый яраттыра белде
Җирнең гөлен, кошын, кураен,
Кешелеклек булса җаныбызда, —
Шуннан киләдер ул, мөгаен.
Остазымның көен уйныйм хәзер,
Иң шәп көй дип уйлыйм мин аны:
«Җирнең табигатен югалтмыйча,
Көйле итик көйсез дөньяны».
Табигатьнең һәм без иҗат иткән
Машинаның камил аһәңе
Табылырмы?.. Шушы Өметенә
Җитәм-җитәм диеп яшәде.
Шамун абый йөрде дәртләндереп,
Мең яшәргә килгән шикелле.

...Авария булып, ауды кырда,
Тамырын кискән имән шикелле.
**Таныш көй бу... Кайда иштгем мин:**
«Кеше күңеле нечкә кылдан да...»
Өзелмәсме?

... Юк! Юк! Һич өзелмәс!
Көйнең башлангычы — Вилданда!
Шамун абый үзе бирде миңа:
Истәлеккә шушы кыл калды,
Тирәкләрдә сайрап кошлар калды,
Аккаенлы асфальт юл калды.

...Һай, ул уйнауларың скрипканы,
Күңелләргә тирән үткәреп...
Шамун абый, иңбашыма салып,
Китәр идем хәзер күтәреп.
Ниләр кылдык, ниләр эшләдек без
Ул уйнаган көйгә кушарлык?!

Бар әле, бар теңкәләргә тигән
Явызлык һәм мәкер, усаллык...
Йөри бирә безнең арабызда
Яшәү көен боза торганнар:

Матди туклар, рухи хәерчеләр,
Тимер җаннар, салам-торханнар...
Гомум иҗат — Байлык, Матурлыкка
Сузылмасын әрсез Озын кул, —
Туң йөрәкләр аша яндырып уз,
Сызыл, Кыл!
Диң-даң!
Диң-даң!
Шамуннарны өзелеп сагынганда,
Дорфа көчләр кылга кагылганда,
Өзелмә, Кыл,
Өзелмә, Җан!

... Дүртенче кыл килеп кушылмаса,
Көй тараер иде өч кылдан,
Яна-яна туды илаһи көй
Шамуннардан калган очкыннан!
Гомеремнең янар дәверләрен
Шушы дүрт кыл сөйләр шикелле...
Сезгә кала бар да, язылган һәм
Язылачы көйләр шикелле.
Кызлар, уллар... Сезгә кала бар да:
Без йөргән һәм йөрелмәгән Юллар,
Уйналган һәм уйналмаган Кыллар,
Уйланган һәм уйланмаган Уйлар,
Табылган һәм табылмаган Серләр,
Кичергән һәм кичермәгән Хисләр,
Башланган һәм башланмаган Эшләр,
Без җиткән һәм җиталмәгән Өмет —
Сезгә кала бар да...
Кала бар табигать, иркен һава,
Тәс тә, тәм дә, ямь дә, җир-су да...
Иҗатыбыз булып каласыз с е з —
Өметем дә минем, борчу да...
Мин ышанам акыл кодрәтенә,
Йөрәгем дә әйтә: «Бул тыныч!..»

... Тормыш көен бозып, усал янап,
Ракеталар карый... Куркыныч...
Күпме гасыр Кеше иҗат иткән
Байлык-хәзинәләр беркөнне
Юк булмасмы, һичбер җан иясе
Җирдә яшәмәгән шикелле?!

## Финал

Адәм үтәлмәслек упкыннардан
Кыл аркылы үткән чагым бар.
Һич өзелмәс кыллар булды юлда
Вилдан, Хәйдәр, Дилә, Шамуннар...
Кайда гына, нинди генә дошман
Күпме генә җанга сукмады!
Күңелемнең нечкә кылларыннан
Өметсезлек көе чыкмады!
Яшьләр алсын диеп кулларына,
Көйләп бирәм сезгә кылларын,
Безне искә алып бер уйнарсыз, —
Сау булыгыз, кыз һәм улларым!
Борчу яна минем күкрәгемдә:
Уйнарсыз сез нинди кылларда?
Өзелмәсме алар?
Юк! Өзелмәс!
Көйнең башлангычы — Вилданда!
Карыйм, күрәм, тоям:
Сез — янымда!
Димәк, өзелмәслек кыл тартты!
Биек тауга йөгереп менгән чакта,
Кыл тартты да сезне туктатты,
Тирән уйга калып тыңлыйсыз сез
Соңгы аккорд сызган чал картны...
Тынмас йөрәк гел тауларга тарта,
Һич кенә дә белми туктасын...
Табыгыз сез тормыш тауларының
Илаһи бер бөек ноктасын!
Хәерле юл!
Зур өметләр баглыйм.
Онытмагыз, яме, хушыгыз!
Киләчәкнең туар Көйләренә
Кылларымның моңын кушыгыз!

1977

Әхәт Гаффар

# КАШАН ҖЫРЫ


ПОВЕСТЬ

Җыр язмышы — кош язмышы кебек,
Бер тирәдән үтә юллары.
Җыр да кайчак егылып төшә җиргә,
Күтәрелә аннан югары.

С. Хәким.

## Унның берсе

### 1



Авыл читеннән узган автобустан ун кеше төшеп калды. Алар, сынаган сыманрак, бер мәл авыл ягына, кырларга карап тордылар.

Эсселек басыла төшкән иде. Якты август көне кичкә авышкан чак. Үткән атнада гына тоташлый яуган яңгырлар җирнең бар тузанын юган. Бөтен җир чиста, саф. Күз күреме җитәрлек һәр тараф ап-ачык. Офык читенә болытлар тавы орынып тора. Авыл шул якка таба күтәрелә барган үргә урнашкан. Өйләрнең кызыл, яшел, ак түбәләре тау битендәге чәчәкләр кебек күренә.

Авылның урта бер җирендә — бакчалар артындагы ындыр табагына кырларның бу ягыннан да, теге ягыннан да машиналар очып килә дә очып китә. Ерактан алар ояларына ширбәт ташыган бал кортларына охшый. Ындыр табагындагы аксыл-соры көшелләр тәлинкә тутырып салган алтын балны хәтерләтә.

Автобустан төшеп калган кызлар һәм егетләр — студентлар иде.

— Зур авыл икән, — диде аларның берсе.
— Бай күренә. Тамак тук булачак, — диде икенчесе.
— Синең тамагың кайгысын көтеп яталар ди!
— Исе белән дә тук мин авылның!
— Сиңа исе, миңа ите, алайса.

Олы юлның ташын чыгырдата-чыгырдата, мәңгелек мәшәкать йомгагын сүтеп яткан авылга таба атлап киттеләр. Аларны, чемченүеннән туктап, тирән ерганак белән юл арасындагы бушлыкка арканланган ялгыз бозау озатып калды. Олы юлдан өзлексез агылган машиналар, дулкын булып, каядыр артка чигенде дә студентларны әрем, ак мәтрүшкә исе, каты билчән кыштырдавы, тавыклар кытаклавы, шомыртлар каралыгы, алмалар алсулыгы белән тулы утрауга кагып калдырды сыман.

Иң элек егетләрнең озын чәчләренә, ә кызларның чалбардан булу-

ларына күзләре төшкән авыл кешеләре аларны кала артистларыдыр дип уйлады. Колхоз идарәсенең, авыл советының кайсы якта икәнлеген сораштырулары бу уйны куәтли төште.

Тын авыл урамын шаярышу, көлешү авазына күмгән бу яшьләр арасында куе кашлы, кара мыеклы, озынчарак борынлы Бәхтияр дә бар. Күз кабагы күз алмасының яртысын диярлек томалап торганга күрә, йөзе ачулы һәм серле тоела. Яше белән ул студентлардан өлкәнрәк. Арткы кесәсенә дага белән ат башы рәсеме ябыштырылган чалбарын киң каеш белән буган, чәчәкле күлмәк кигән. Нәкъ студентларча. Сүзгә катнашмыйча бер-ике адым читтәнрәк атлап бара. Күзәтүчән кеше аның бу төркемгә кагылышы юклыгын чамалар иде. Дөрестән дә, ул студентларга бүген генә килеп кушылды. Ләкин тегеләре аның кем икәнлеген белми әле. Сорашсалар әйтер иде. Сорашмадылар.

Ул тыныч йөз белән авылны күзәтеп килә.

Өйләр, каралты-куралар таза, ямьле. Агачлар күп: тупыллар, шомырт, чияләр! Сулавы җиңел. Койма, рәшәткә араларыннан, качып кына егетләр күзәткән, тик әле алар күзе төшәрлек булып өлгереп җитмәгән кызлар сыман, битләренә кояш кунган алмалар күренеп кала. Алмалы авыл — нурлы авыл.

Шаулы төркемдәгеләр авыл җитәкчеләренә үзләренең артист түгел, бәлки студент икәнлекләрен әйткән чакта да Бәхтияр, аларга катнашы булмаган кыяфәт белән, ләкин җитәкчеләргә үзенең студентларга кагылышы юклыгын сиздермәскә тырышып, читтәрәк тора бирде.

— Театр килгән дип торабыз тагын, — диде үзен «колхоз председателе Кәбир Шаһгалиев» дип таныштырган кеше. Аның ян-якларына кызарып пешкән кабартма ябыштырып куелгандай дәү битендә кеп-кечкенә күз караеп тора. Ул, күзе кечкенәлегеннән йөзенең көләчлегеннән дип белсеннәр дигән шикелле, гел елмаеп сөйләшә. Тирәсендәгеләр дә елмаймый булдыра алмый. Ул елмаю, ирексездән, Бәхтиярнең калын иреннәре читенә дә елышкан иде.

— Ә без сезнең артистларны тыңларга килдек, Кәбир абый.

Чәчен үрми-бәйләми иңбашына салган озын буйлы, тулы гәүдәле кызның председательгә җавабын уенга алдылар.

— Элгәре үзегезне күрсәтегез әле.

— Бурычлы калынмас, — диде кыз, йөзен каплаган чәчен озын тырнаклы бармаклары белән колак артына сыпырып.— Ә бәлкем сезнең дә бардыр берәр такмак. Җырларсыз...

— У-у, рәхәтләнеп! — Председатель кычкырып көлеп куйды. — Чынлапмы? — дип, аптырабрак калган кызга текәлде.

— Чынлап... Без — университеттан. Халык иҗаты — җыр, бәетләр җыеп йөрибез.

— Ә-ә! Менә ничек!.. Озаккамы?

— Дүрт-биш көнгә, — диде баян кабына утырып сигарета көйрәткән сакал-мыеклы егет. Шаһгалиев сагая калды.

— Дүрт-биш көнгә? Урып-җыю кызган чак... Ара тар — мәшәкать күп. Сезне кайгыртып булыр микән?

Председательнең кәефе үзгәреп китте.

Моны күреп, аның белән баскычта басып торган идарә кешеләре эчкә кереп китте. Төркемдәгеләрнең моңарчы сүзгә катышмаган өлкәнрәк яшьтәгесе алга чыкты. Бәхтияр аның студентлар җитәкчесе икәнлеген автобуста белгән иде инде.

— Дөресен әйткәндә, иптәш председатель, безнең шөгыль дә үзенә күрә урып-җыю... Гафу итегез... — Ул ярты йөзен диярлек томалап торган кара күзлеген салды. — Гафу итегез, — дип кабатлады да кулын сузды. — Хәбир Миңлеханов мин... Без дә бит, сезнең кебек үк, урып-җыюда. Безнең вакыт та урам тузаны түгел. Рухи азык җыеп йөрибез, фольклор...

— Ярар, — диде председатель, идарә ишегенә таба борылып аваз салды. — Нәгыймә!

Чәчен толымлап аркасына салган бер кыз күренде.

— Студентларны кунак йортына озат әле, сеңелем. Хөснижиһан апаң ашатсын-эчертсен. Сөт-катык кына түгел. Ите дә мул булсын... Кызык, — диде ул. Юан, кыска бармаклы кулын Хәбир Миңлехановның иңбашына салды. — Нәрсә, аңламас дип шүрләдегезме? Аңлыйбыз, агай-эне. Тик уңарсыз микән? Күптән ташып бетергәннәрдер инде ул җырларны Казан калаларына.

— Калгандыр әле бер-икесе. Халык җанының төбе юк аның — кое шикелле гел тулып тора.

— Һәр кешенең үз җыры була. Табылыр, — дип, Бәхтияр дә сүзгә кушылды. Егетләр-кызлар да, Кәбир Шаһгалиев тә аның кем булуы белән кызыксынмады. Председательгә ул студентларның берсе булып калды. Студентларга — әлегә беркем дә түгел...

— Сезнекеләр сакаллы да мыеклы икән,— диде председатель, аңа күз ташлап.

Кунак йортына урнашырга киткәндә, колонкага иелеп, Бәхтияр су эчте. Башта тәмле тоелган су, ком белән ышкыгандай, тамагын әчеттереп калдырды. Ниндидер тәмсез, каты...

## 2

— Рөхсәт итсәгез, мин дә шушы бүлмәгә урнашыр идем.

Бүлмәдә өч караватч. Өстәл, кечкенә шкафлар — һәммәсе ялтыраган. Идәндә келәм, тәрәзә пәрдәләре затлы тукымадан.

Миңлеханов аңа читләбрәк карады.

— Теге бүлмәләрнең түшәме буялган, ә монда табигый... Чын авыл өе. Һавасы шәп, — дип аңлатты Бәхтияр.

— Ярар.... Безгә барыбер, — диде Миңлеханов.

Миңлеханов, муенын сузып, түшәмгә карады. Такталары киң, түшәм дә, стена да — яңгырап торган нараттан. Берничә урынга сагызы саркып, тамчыланып каткан. Нарат исе.

— Кем буласыз соң? — диде аңа Миңлеханов, урнашу ыгы-зыгысы сүрелгәннән соң караватына сузылып яткач.

«Тагын бер кат сорасын әле».

— Гафу итәсез... күршене белеп торганың яхшы дигәннән кызыксынуым.

— Бәхтияр.

— Юк, мин кем диюем, — дип ычкындырды ялгыш Миңлеханов. — Гафу итегез... — Ул, кара күзлеген салып, кулын сузды. — Хәбир Миңлеханов, студентлар белән.

— Беләм бераз.

Бәхтияр канәгать. Миңлеханов аның кем булуын, ник, каян килүен сорарга уңайсызланып калды. Күренеп тора: яхшы күңелле кеше булырга тиеш.

— Кайдадыр күргән дә кук...— диде Миңлеханов.— Казандамы, кайда, хәтерләмим.

— Күпләр мине кайдадыр күргән кук. Йөз шундый, күрәсең. Корреспондент мин.

## 3

Бәхтиярнең үз коллекциясенә берәр яңа җыр өстисе килгән иде. Студентларга ул шуның өчен ияреп китте дә.

Кызыксынган кешегә — җырлар бихисап. Ләкин Бәхтиярга һәр бирмеш көн диярлек дөньяга килеп торган чуар җырларның кыйммәте дә

бер генә көнлек. Аңа бүтәне, халык җырлары кирәк — болын чәчкәләре. Алардан ул җаны теләгән такыя үрә, бәйләм ясый, зиһенен баета.

Ул үз коллекциясенә андый-мондый җиңел, зәвыксыз такмакларны кертми. Куе үлән арасындагы кызыл җиләк ишеләрен генә җыя. Тыңлый да — шул җиләкләрне авыз итә күк.

Ул үзе эзләп тапкан, үзе генә белгән җырларны җыя. Аларның да халык тарихының текә борылышлар ясаган зур вакыйгалар, дөньяның бөтен давылларын, җирнең бөтен дулкыннарын үзенә сыйдырып, кадерләп саклаганнарын.

Халык тәненнән аккан кан — су булган, җаныннан аккан моң — җыр, җырдан аккан мәгънә — ил... Бәхтияргә шундыйлары кирәк.

Әүвәлрәк ул ни ишетсә, шуны язып бара иде. Әмма соңга таба язганнарын төрле китапларда очрата башлады. Баксаң, күбесе аңа хәтле үк теркәлгән икән. Җыр саны, такмак, куплет төрлелеге гаҗәпсендерсә дә, галимнәр җыр түгел, хәтта чебен санына хәтле белеп тора икән лә! Бер пар чебеннән бер җәйдә ике миллион токым тарала, ди, әйтик.

Җырларның күбесе төрле халыкта да кабатлануын белгәч, Бәхтиярнең сөмсере коелган иде.

Аларның таралу сәбәбен ул озак эзләде. Һәм тапты.

Бер заман, студент чагында, әнкәсенә бәрәңге-яшелчә утыртышырга кайтканда ул чәчәк орлыклары алган иде. Алар авылында моңарчы күренмәгән чәчәк. Шул матур чәчәкне утыртуын үзенчә яңа җыр чыгару сымаграк тойган иде. Әнкәсе аның орлыкларын күрше-күләнгә өләшеп бетергән. Матур чәчәкләрнең шулай таралуы кешеләрнең бер-берсенә матур җыр җырлавына тиң. Димәк, җырларның да шатлык белдергәннәре күбрәк тарала икән! Менә шуңа җирдә шатлык җырлары күбрәк, ә кабатланмастайлары зуррак кичерешле була икән. Менә шуннан Бәхтияр кайгылы хәл, канлы вакыйгаларга багышланган җырлар белән генә кызыксына башлады. Беренче табышы нииндидер камыш шавы турында әнкәсе чыгарган сагышлы җыр булды.

Яшь бер кыз, җәй көне салкын күл суында бот тиңентен йөреп, терлек азыгына камыш ура, шуннан гомерлек зәхмәтле сырхау ала...

Йөрдем көмеш күлнең, ай, буеннан,
Камышларын урдым муеннан;
Селәүсеннән куркып саргаймадым,
Мин саргайдым дөнья уеннан.

Урак ургаң гына ла тавышка
Тәкърлекләр кача камышка;
Йөзкәемә сары нур ябышты
Әчкенәем тулы сагышка.

Кара да гына елан, ай, туз башлы,
Йөри көмеш камыш буенча.
Кара да камыш, ялгыз башым
Йөридер лә язмыш буенча...

Ниндидер камыш урудан төпсез бер моң... Каян килә?

Җирдә бала табулар, кабер казулар барында җыр чишмәләре ургыйи да ургыйдыр. Дөньяга яңа килгәннәр, ана сөте белән бергә, шул чишмә суларын эчә. Караңгы дөньяга китеп барыр алдыннан кеше күңеле кабатланмас үз җыры белән тула. Чөнки: моңлана белгән кеше генә — кеше. Җырлый, җырлана торган ил генә — ил. Иле бар кеше генә — кеше.

Шушы нәрсә хәрәкәттә чакта яшәү дә мәңгелек хәрәкәттә.

Бәхтияр үзен бишектә яткан ярдәмчесез сабый итеп тә, соңгы сулышын алыр өчен, хәлсез терсәкләренә таянып мендәреннән калкынган карт итеп тә тойганы бар. Ә аның каршысында микрофон, каләм белән дәфтәр тоткан студент басып тора, имеш. Бер куркынды, бер дулкынлан-

ды. Ахыргы сулышын алып өлгермичә тынсыз булыр да көнелендәге соңгы моңын аларга җиткерми калыр күк. Ул вакытта бишектәге бала нишләр?

Диңгез буендагы санаторийга бару ниятеннән ваз кичеп, тотты да университетка шалтыратты:

— Сездән быел фольклор җыярга чыктылармы әле?

— Августта чыгачаклар.

— Кай якка?

— Быел тәҗрибә кебек бер нәрсә — Казаннан ерак түгел.

Сәбәбен сорашмады: якын арада да әлегә билгесез җырлар барлыгын-юклыгын сынап карамакчылардыр.

— Юлга — кайсы көнне?

Әйттеләр.

— Карагыз әле, кем сорый? Кем сорый дим, алло? Алло?

## Үрмәкүч

### I

Килгән көнне студентлар ял итте. Яздыру, язу әйберләрен җайладылар. Өч төркемгә бүленделәр. Көтүләре белән йөрмәсләр бит инде. Әзерләнеп беткәнгә хисаплап, бер чандыры сумкасыннан тасма алды да магнитофонын эшләтеп карады.

Карты каршында да җырламаган карчыклар яисә аек килеш күршесе алдында да көйләмәгән картлар яшьләргә, җитмәсә магнитофонга, җыр әйтеп утырырмы икән? Әйткән шаттә дә ни генә әйтерләр?

Моны Бәхтияр студент чагында ук татыды. Студентлар җәтмәсенә күбрәк такмак-мәзәк, табышмак-әйтем генә эләгү — шуңа. Бәхтияр хәзер алай итми. Чын коллекционер аучы шикеллерәк ул. Аңа бераз үрмәкүч сыман була белү кирәк. Әйе, үрмәкүч. Кеше күңелендәге иң матур, иң яшертен җырга ия булыйм дисәң, ялгыз йөре. Яңа җыр — су төбендәге балык. Аны ятьмәгә эләктерү — үзе бер сәнгать. Һәр кешенең күңеле үзенчә көйли. Һәрберсе өчен аерым ятьмә кирәк. Кемнең күргәне бар үрмәкүчнең икәүләп яисә анда бишәүләп пәрәвез үргәнен? Гел ялгызы... Бу аның үз табышын икенчесе белән бүләргә теләмәү инстинктыннанмы? Юк, әлбәттә. Комсызлыгыннанмы? Һич. Шулай ышанычлырак. Ризыкка иң тиз, иң якын юл салыр өчен үрмәкүч ничәмә метр пәрәвез җебен ялгызы гына эрли, ябыштыра, үрә. Кайчагында бердәнбер чебен яки анда черки-мазар өчен.

Кайбер җырларын Бәхтияр ялгызы гына йөрүе, кеше күңелен ача белүе аркасында тапты.

Ә Хәбир Миңлеханов студентлары карт-коры белән ничегрәк сөйләшергә кирәклеген әле алай ук белеп бетерми. Килделе-киттеле рәвештә җыйналышалар да юлга ашкыналар. Өйрәтелми җигелгән атның дилбегәсен ычкындырган сымаграк. Җилдерәләр генә! Кая анда юл читенә үк елышып үскән сусыл җиләкләрдәй, үзләре синең күңелеңә керәм дип торган җырларны күрү?! Фольклорчы өчен ашыкмау — иң төп кагыйдә.

Менә бу гамьсез егет-кызлар иртәгә нишли инде? Әйтик, ничәседер бер йортка килеп керерләр. Бер абзый ишегалды себереп йөрер.

«Исәнмесез, — диярләр студентлар. — Рөхсәттер ич?»

«Шөкер генә. Әйдәгез, әйдә, узыгыз».

«Без — студентлар. Фольклор җыеп йөрибез».

«Фул-клур? Бездә андый нәрсә югые шул. Чүпрәк-чапраклар бирдек. Бирдек иске китаплар... Фул-клур — юк».

Фул-клурның фольклор икәнлеген абзыйга аңлату артык кыен булмаса да, бу чит сүз уяткан шөбһәне аның күңеленнән җиллэтеп бетерү өчен шактый вакыт кирәк.

«Мәнә шул инде, борынгы җыр-бәет җыябыз, әкият-мәзәк».

— Ә-ә-ә, — дип сузар агай. — Мин онытып бетергән инде. Сез, лучше, бүтәннәргә керегез. Хирыслыгым булмады андыйга».

«Бәлкем, апа бардыр...»

Эх, бардыр дию — зур гөнаһ! Шундый алсу, җыерчыгы да беленмәгән йөзле абзыйның «апасы» барлыгына шик белдерергә ярыймы соң? Кыска гына калдырылып киселгән сакалына чал йөгерсә дә, бетәшкән дип уйларлыкмы әллә әле ул?

«Бар, бар... ыһым, — дияр карт себерке сабы тотасы кулына төкерә-төкерә.— Өйдә. Оялыр ла ул. Мәҗлестә дә кыюсыз».

Барысы да өйгә кереп китәрләр. Юк, берәрсенә абзыйны сөйләштереп каласы, югыйсә.

«Җыру? И-и-и, булмаганны-ы... Кеше көләр Галимә җыру әйтеп утыра дип. Җәш чак булсае...»

Алай да әбиләр күңеленә ачкыч таба студентлар. Экспедиция ахырына тикшереп карасаң, күп нәрсәләре әби-карчыклар авызыннан.

Әби чәй эчәргә кыстар.

«Юк, юк, әбкәй, мәшәкатьләнмәгез. Ашыгабыз. Әле тагын җиде авылга өлгерәсе...»

Бусы да зур ялгыш. Соң, әбиләр теләнә ачкыч — чәй ләбаса. Ихластан кыстый бит! Аның чәен эчәргә риза булып, абзыйны да дәшсәләр...

«Соң, ашыгыч икән — бусагага аркылы ятмаган. Җиде авылда житмеш карчык очрар әле, миннән генә бөтәймәссез», — дип уйлар әби. Һәм, микрофонга сак караш ташлап, алмагачларның майның унбишендә чәчәк атуын искә алыр, дус-ишләренең алмагач чәчәкләре күклеге дә хәтерендә икән әле...

Шуны җырлар да тынлык урнашыр, магнитофон тасмасы чыжылдый башлар.

«Рәхмәт, әби».

«Үзегезгә рәхмәт, оланнар. Изге юлда икәнсез».

«Сау булыгыз, абзый».

«Хуш иттек, хуш. Бигайбә инде, ара тар чак. Югыйсә».

Сизәсезме? Агайның җаны кытыклана. Ул үпкәли кала...

Аннары соң түрдәге комод өстендә кемнең тальян гармуны тора иде соң әле?

Капка келәсе шыкылдар, канәгатьсез йөзле студентлар, бер-берсенә карарга уңайсызланып, күрше яисә каршы йортка юнәлер.

Андамы, җиденче, унынчы өйдәме аларга:

«Кәҗә Нуруллаларына керәсегез калган. Мәнә кемдә ул җыруга һәвәслек!» — диярләр.

«Кайда торганнарын әйтмәссез микән?»

«Әнә теге яктан. Уники өй аша».

Санап карыйлар: ишегалды себереп йөргән абзыйларга туры килә. Әйләнеп керү уңайсыз шикелле...

## 2

Көн сүрелә. Бәхтияр, пәрдәләрне кайтарып, тәрәзәне ачып җибәрде. Каршы яктагы өйнең бер тәрәзә өлгесендә суга җәелгән бензин шикелле аллы-гөлле бизәк чагыла. Күзгегә кунган күбәләкмени! Әллә кайчангы пыяла бугай. Үз вакыты килгәч, хәтта пыяла да чәчәк ата мәллә?

Кунак йорты текә ярлы инеш буенда. Калкулыкка салынган. Тәрәзәсеннән аргы яктагы яшел, урыны-урыны белән кояш көйдергән уйсулык күренеп тора. Таллыклар, аксыргаклар. Мөгаен, һәр иртәдә ул уйсулыкны язгы җепшек кар кебек итеп учта йомарларлык куе томан тотырадыр. Ә хәзер анда авыл көтүе. Сыерлар утлый, сарыклар чемченә.

Ярда кәҗәләр. Тау-таш арасында кыр кәҗәләре дә шулай ышкынып йөридер. Моннан йөз ел элек тә утлагандыр ул көтү. Йөз ел элек... Әйтүе нинди ансат! Ә йөз елдан соң? Үткәннәргә ара шундый якын! Чөнки аның һәр мизгеле синең каныңда, аңыңда эрегән. Шул синең гомерең. Ә киләчәк — ул инде син түгел, ул — бүтән. Әнә шул томан, шул көтү. Йөз елдан соң да шулай тыныч һәм гамьсез көтү йөрер микән монда? Бүлмәне чит, тамак төбе белән җырлаган тавыш тутырып тора. Җирән чәчле егет магнитофонын әйләндерә.

Уйсулыкның теге ягында үр. Кырлар, болыннар, авыл арасында сәгать угы кебек туктаусыз әйләнеп йөргән көтү үрнең астыннан түбәсенә кадәр дулкын-дулкын баскычлар уйган. Бик күп дистә даганы өсте-өстенә тезгәннәр сыман. Юк, баскыч түгел. Бу борынгы җиргә аларны көтү дә уймаган. Вакыт уйган аларны. Кеше маңгаендагы җыерчыклар кебек алар.

— Тиздән көтү кайта, — диде Бәхтияр.

Миңлеханов, ачык ишек яңагына таянып, күрше бүлмәдәгеләргә эндәште.

— Фәгыйлә, Билал!

— Әү? — диде бер кыз.

— Кирәгез әле. — Фәгыйлә дигәне председатель Кәбир белән сөйләшкәне икән — ул керде. Аның артыннан — баянчы Билал. — Ничек, урнаштыгызмы?

— Җәннәт! — диде Фәгыйлә.

— Җәннәтнең кошлары гына юк, — диде Билал.

— Ә сез кем? — диде Фәгыйлә. Ул буяган кебек озын, чынга охшамаган керфекләрен йомып-йомып ала. Үзе янәшә, ә шул керфекләре, тузгып торган чәче арасында тагын да аграк тоелган муены, калынча иреннәренә карап, Бәхтияр аны театр сәхнәсе түрендә итеп күрде.

— Армадыгызмы? — дип сорады Миңлеханов.

— Җитмеш чакрым юл үтепме?

— Җитмеш чакрымны якын итеп без, бер күрер өчен килдек б-е-ез,— дип көйләде аның артыннан Билал.

— Нитик, алайса, концерт куйыйк бүген. Халыкка ничек белдерик икән? — диде Миңлеханов.

— Тәвәккәллик, Хәбир абый. Урак өсте. Халык сусагандыр җырга.

— Без кызганмасак, үзләре дә кызганмас иртәгә җырларын.

— Тукта әле, Билал. Урак өстендә җыр кайгысымыни? Кич кенә кем белеп бетерсен дә кем генә җыелсын икән? — Бәхтиярләр бүлмәсендә чебен кунмасын дип битен газета белән каплап яткан җирән чәчле егет тә сүзгә кушылды.

— Тиз генә игълан язып эләргә кирәк берничә урынга, — диде Миңлеханов.

— Ә сез белдерү-фәләнсез генә, — диде Бәхтияр. — Радиодан әйттерергә кирәк. Беләсезме, әгәр болай итсәгез...

Ул портфелен кул астындагы кечкенә шкафка куйды. Студентларга аркан иде, аның нишләгәнен күрмәделәр. Борылды да магнитофон тасмасы сузды.

— Магнитофон ала барып, башта әйләндерегез әле шушыны. Монда бер карт белән бер карчык җырлый. Бергә җырлыйлар.

Студентлар ана гаҗәпсенгәндәй карап торалар иде. Миңлеханов күзләгән салды, кысасы очыннан тотып, биш-алты кат әйләндергәләп алды.

— Сез кем соң? — дип сорады Фәгыйлә.

— Без сезнең кебек халык арасында йөргән идек бер җәйне. Шуннан калган нәрсә, — диде ул тасмага ымлап. — Без дә концерт куя идек алдан. Шулай иткәч, халык иләшә. Кызыксыну арта.

Кухняда бая ак җәймәләр өләшкән, аларны урнаштырган яшь хатын күренде. Ул инде ни ара газ кабызырга өлгергән, чыжлатып коймак пе-

шерергә керешкән. Саллы гәүдәсе җиңел һәм шома уйнаклап тора. Ул яктан кызган май, әче камыр исе бөркелде.

— Безгә мәллә бу, Хөснижиһан апа? — дип сорады Фәгыйлә.

— Аш пешкәнче тамак ялгарыгызга.

— Кая, нәрсә ул сезнең? — диде Миңлеханов һәм, тасманы алып, җирән чәчле егеткә сузды.— Куй әле, Хәмит.

Хәмит, торып, тасманы магнитофонга куйды. Хәзер инде колакны чит музыка тырнамый. Сәер бер тамак кыру, ниндидер пышылдау: «Йә инде, йә, бабай...» Тоныкы кына итеп әтәч кычкыра, урындык кузгала...

«Мин туксан өченче сәнәдә дөньяга килгән бала, — дип әйләнә магнитофон тасмасы.— Җәшләй тегү тектем, читләргә йөрдем. Бер җылны җәштәш җегетләрем Донбасс шахтыларыннан кайтканые. Шулардан отып калган бер җыруымны җырлыйм. «Бәдрәм-бәдрәм» атала».

Егетләр дә, кызлар да кайсы-кая утырышты. Күрше бүлмәләрдән дә кереп тулдылар.

Пешеренүен куеп, Хөснижиһан да, суыктан кергәч җылы мичкә сарылгандай итеп, күкрәге белән ишек яңагына сыенды.

Бүлмәгә шәүлә инде — үткәннәр шәүләсе. Үзе индеме, бәреп кердеме? Күңел әллә тетрәнә, әллә дулкынлана... Ниндидер моңсулык. Бәхтияр инде ничәнче кат дәшә үз-үзенә: «Нигә — бала? Инде исәнме-юкмы икәне билгесез ул картның теләге микән бу, әллә үкенече микән? Җитмеш алты ел гомер иткән бала... Үзен мәңгелек итеп күрәсе килгәннән әйткәндер ул «бала» дигәнне».

Ул яздырып алганда бабайга җитмеш алты иде. Ә тавышы көр, моңлы. «Бәдрәм-бәдрәм». Шундый чәчәк бар: ул тәбәнәк кенә, сабагында икеме, өчме көл төсендәге йөнтәс шар. Дөньяның бар гөнаһсызлыгы шул чәчәктә кебек — йомшак. Кулга алдың исә: «Син миңа тимисең бит, абый?» — дигәне ишетелә сыман.

Картның да тавышы — шул чәчәк күк: саф, тылсымлы.

«Җәшләй, җәштәш, җыру җырлыйм...» Ак кылганнар шулай кыштырдыймы? Әллә көзге яланда дөньяның бар авыртуын, нахак каһәрен бер үзенә җыеп утырган каты билчәнме?

Нибары бер минутлык җыр. Ә шулай да гасыр белән гасыр арасын тоташтырып куя. Ике тормыш уртасында — магнитофон. Шул магнитофон, көйле бишек булып, сине үткәннәр моңына тирбәтә. Юатамы, әллә сине гасырлар давылының мәхшәре белән очраштырамы? Ничәмә буынның бөтен моң-зарын, кабер ташлары чылаткан иртәнге чык сыман, күңелгә яга мәллә?

Егерменче гасырның күзе тулы — мөлдерәмә яшь. Ничә сугыш, ничә киселгән язмыш, күпме өзелгән моң, тәсбих төймәләре булып тезелгән хәсрәт. Үткәннәрнең кое кебек тирән, караңгы салкын куеныннан шушы җыр булып кысылып чыга алар.

Бәдрәм-бәдрәм, бәдрәм-бәдрәм...
...Ә-ә-әй!
Бәдрәм-бәдрәм искән, ай, җилләрдә
Бәдрәм-бәдрәм тузан таралды-ый;
Маңгайларга язган хак язмыштан
Бәдрәм-бәдрәм чәчем агарды-ый.

Бәдрәм-бәдрәм ак мамык очыра
Кара сазда үскән ак җикән;
Мөлдер-мөлдер чылый көмеш шөлдер,—
Күзләремнән чыккан яшь микән?

«Тын бетә бит, оланнар».
«Тагын берне, бабай, берне генә...»

Күпме кыстасалар да, җырламый карт.

Аннан соң яңгыравык, нечкә тавыш белән бер әби башлый:

Түбәтәй генәемнең, ай, түбәсе,
Түбәсендә көмеш түмәсе;
Тел очкайларына бадьян кабып,
Тик сынамак өчен үбәсе.

Миңлехановң белән Билал, Бәхтияр тасмасын да алып, радиоузелга дип киткән, кызлар Хөснижиһанга бәрәңге әрчешә. Ә Бәхтиярнең күз алдында — күл, күңелендә — камыш шавы, шул камышны, кыштырдата-кыштырдата, әнисе урып йөри. Үзе ура, авызында бер җыр: бөдрәм-бөдрәм, бөдрәм-бөдрәм...



## Киек каз юлыннан

### I

Студентлар концертына барып йөрмәде Бәхтияр. Ятты да йоклады. Хөснижиһан уятты. Икенче якка әйләнгән хәйлә белән Бәхтияр аңа борылып ятты: белештерми әле, янәсе. Кырын яткан җирдән күз кырые белән генә чамаласа — кухнядагы ут кына яна, мәгәр якты. Аның караваты янында — Хөснижиһан. Кыска җиңле аксыл күлмәктән. Юудан утырганмы, тегелеше шулаймы — кысан, ахры: җиң кайтармасы беләгенә батыбрак тора. Ашыккан булса кирәк: еш-еш тын ала. Бармаклары белән Бәхтиярнең иңбашына сак кына орынгандай:

— Йоклыйсыңмы соң? — ди.

Учы кием аркылы да кайнар кебек.

— Карале дим, концерттан килешем, кайтырларына дип сөт кайнатырга куйган идем. Карый тор әле...

Бәхтиярнең бер кулы күкрәк турысында: Хөснижиһан кулы якынлашканда, искәрмәстән, беләгеннән электерде:

— Фәгыйлә, синме? — диде ул юри.

Хөснижиһан төкреген йота-йота бер кавым ни әйтергә белми торды.

— И-и-и, шәрык гәләе, — дип, күкрәгеген кыскан тынын чыгарды ул, ниһаять.— Фәгыйлә, Фәгыйлә... Затсыз!

— Каян белим, апа җаным. Билләһи, гөнаһсыз.

— Һы, гөнаһсыздыр, кагылган берәү Фәгыйләгә калгач.

— Әллә көнлисең инде, апа? Ә? — Бәхтияр маңгаена шуышкан ялыгын төзәткән хатынга бармак изәде.— Яшьләрдән көнләү гөнаһ, апа җаным.

— И, энем, кайгым шул гына булса иде...

Бәхтияр аның әле генә агарынган йөзенә кисәк кан йөгерүен, борын тирәсендә тир бөртекләре җемелдәшүен чамалап алды. Күзе кырыеннан сизелер-сизелмәс өчәр җыерчык таралды. Кухня ишегеннән туры төшкән ут битенең һәр хәрәкәтен, сырын тирәнәйтә, баета, серле итә...

— Ә ирең, апа?

Хатынның күзендә ташып торган очкын сүрелде китте. Иреннән — елмаю, күзеннән көлемсерәү качты. Бүрәнкәгә салган сөтнең агып бетүе күк булды.

— Вафат булды ирем. Шофер иде. Сорочый тавыннан төшкәндә тормозы тотмаган...

Җиңел әйтте: тавышында сыкрау чыкмады.

— Алайса, апа, үпкәләмә инде, гафу...

— И-и-и, энем, уйлама. «Уф» дигән тыннарым белән тартып алып булмый бит. Дөньяга кыз баласы булып килгәнмен, бәхеткәйгә тиң итмәгәч соң...

— Кыз баласы? Мондый сүзне беренче ишетүем.

— Кешедән кеше ким түгел дә бит, бәхеткәйләре тиң түгел, — дип сузды хатын. Бәхтиярнең кайтарып соравын әллә ишетмәде, әллә инде ишетеп тә искә-өнгә алмады.

— Ярар, энем, концерт бетте, кайтырлар. Бии калганнар иде. Сөт кайнатырга куйыйм дип кереш кенә, син карарга күнмәссең микән дигән уй белән уятуым булды...

Үрдәк сыманрак вак-вак атлап, Хөснижиһан кухня ягына ашыкты. Аягы әлеге куркудан хәлсезләнгәнме, урындык читенә генә эләгеп утырганга талган микән?

«И бу хатын-кыз! Бөтенесенә уртак газап — бала табу. Шулай булмаган җир кайда бар?»

«Дөньяга кыз баласы булып килгәнмен».

Бәхтияр төшенде, ахрысы.

Шаулашып, көлешә-көлешә студентлар кайтты. Фәгыйлә иңендә — Билалның күн пинжәге.

Ут кабынды. Табынга җыелдылар. Ә Бәхтияр болдырга чыкты да култыксага таянды. Хөснижиһан әле эчтә. «Ярар инде, беренче көнегез, ияләшкәнче», — дип, кул югычка су җылытып салды, плитәгә чәй куйды. Шул суы, шул чәе кебек, ахры, ул, күңеле җылы.

Салкынча. Айның тулып килгән чагы. Караңгыда кара-шомлы күренгән сирәк-мирәк болытлар көтүе шәйләнә. Киек каз юлының кара ат сыртындагы шләя тәңкәләре булып ялтыраган эре йолдызлары. Болар авылның төнге күген якынайтып күрсәтә. Ат тугаргандагыча, шул Киек каз юлын дөнья сыртыннан кайтарып салдырып булырдыр шикелле. Кемнәр адашыр икән аннары? Кошлармы? Кешеләр дәме? Авыл өйләренең төнге утлары — кара бүрек эчендә йокымсыраган сары чебешләр.

Авыл йокламый әле. Машина уза, ындыр табагында эш тукталмаган, ыгы-зыгы тынмаган.

— Бәхтияр...

«Фәгыйлә».

Фәгыйлә, шалтыратмаска тырышып, юынгычта кул юа:

— Әйдә, кер, нәүмиз булып каласың ич.

Ачык ишектән егетләрнең Хөснижиһанны кыстаганы ишетелә:

— И, апа гынам! Бу бит — нәрсә генә инде бу?

— Йокы даруы, й-йокы...

— Мин кем сезгә, каныктыгыз. Әнә, кызларыгызны кадерләгез. Үпкәли күрмәсеннәр. Көнләштерерсез ялгыш.

— Көнләсен, кем, Хөснижиһан, — Миңлеханов кыяр чәйни. — Хаталанмыйммдыр? Чамага караганда бер тирәдәрәк бугай без. Кырык берләрме?

— Үпкәләтәсез апагызны. Утыз икенче генә.

— Мин елын, туган елын әйтәм.

— Ә-ә...

Ул турыда төпченмәделәр, Билал кыстый:

— Бит иннеге генә бу, күңел сөрмәсе.

— Дару, дару...

Түзмәде, ахрысы, Хөснижиһан: өй тутырып хуплап тордылар.

— Әттәгенәсе!

— Бәхтияр кайда, егетләр?

Фәгыйлә аның янына басып кулын сөртә:

— Әйдә, керик.

Кашы сирәк, керфекләре озын Фәгыйләнең. Нинди бизәге соң аны матур иткән? Тешләреме, сипкелеме, бите түгәрәклегеме? Чигә чәчләренең дулкынлыдыр бәлки. Ихтимал, кулының ныклыгы, бармакларының озынлыгыдыр.

Бәхтияр Фәгыйләгә җавап кайтармады. Ул Хөснижиһанны уйлый. Фәгыйләнең нигәдер ирене турсайды. Кунакханәгә уздылар.

«Кайда йөрисез?» — дип, Хәмит ана стакан сузды. Кыстатмады. Бөтенләйгә тыны җитмәде, яртысы кадәресен генә эчә алды.

Егетләр-кызлар көлешә. Чандыр Хәмит кызларча киенеп иннек-кершән сөрткән дә тәбәнәк буйлы Ислам белән җырлаган икән. Тәнәфестә бер егет Исламнан сораштырган, имеш: кем дә кем соң ул — озаткан шәттә сүз уңарлыкмы да санга сугарлыкмы? Шуннан көлүләре икән.

Хөснижиһан китте.

Бәхтияр аның артыннан кузгалырга яхшысынмады. Өстәлдән чүмеч алды. Кухняда салкын су эчә, имеш. Ишек ачык. Югалуын сизәрләрме икән? Берәр ничек аңлатыр әле.

Кунак йортының ишегалды бик зур. Ике капкалы. Чәчәк түтәлләре сузылган. Бер якта алма агачлары. Хөснижиһан кайсы капкадан чыгып, кай якка китте икән? Барыбер ич, урамга чыга. Табуы мөмкин әле. Әһә, сул якта кемнеңдер эте чәбәләнеп өрә. Хөснижиһанга өрүедер. Шунда таба ашыкты. Дөрестән дә, тәрәзәдән төшкән ут белән рәшәткә сырлаган турыны берәүнең шәүләсе кисеп үтте.

Урам Киек каз юлы буйлап сузылган иде. «Адаштырмас микән бу юл?» — дип уйлады ул.

## 2

... Студентларны кичә радиодан күпләр тыңлаган бугай. Өйдән-өйгә йөрибез дигәннәрен күп кеше ишеткән. Кайсы бер өйләрдә килүләрен көтеп торганнар хәтта. Керүгә чәйгә кыстыйлар. Аскы урамны тиз генә йөреп чыгарлар кебек иде. Насыйп булмады. Әллә көннең кызулыгы тәэсире дә бар шунда. Сүлпәнлек басты.

— Бүгенгә җитте мәллә соң? — диде Фәгыйлә.

Аның сүзен Билал хуплады:

— Әйе, кичен күрше авылда концерт куясы.

— Бе-еренче көнгә җ-җитәр...

Миңлеханов каршы төште:

— Ширияздан дигәннәренә кермичә дәме? И, түзем сездә! Ничә кеше шул бабайга керегез диде бит. Тикмәгә әйтмәсләрдер.

Урамга буйлый салган йортка җиткәндә, кызлар әлсерәп төште, егетләрнең сөмсере коелыр чиктә иде.

Миңлеханов төркемендә — Фәгыйлә, Билал, Хәмит. Бәхтияр дә алар белән.

Ширияздан картларга керер алдыннан студентларның һәммәсе бергә җыйналды. Миңлеханов шулай теләде. Аларга ничә карт-карчык:

— Шириязданны калдырмагыз, — дигән киңәшен җиткерде. Йорт-җире шушы урамда икән. Менә инде капкасын кагалар. Аның чираты. Һәвәслеге нидә икән? Авыл кешеләре сөйләвенә караганда, данлы бер җыр белә, имеш.

Ширияздан дигәннәре, кояш шактый кыздырса да, киез итектән, башында — колакчыны күтәрелмәле бүрек.

Алар капканы ачып кергәндә, ул кое чиләгеннән җиргә шарлатып су агыза иде.

Кергән чакта берсе дә капка астыннан башланган кечкенә ермак күрмәде. Читтәрәк үрдәкләр быкырдаган былчырак күләвек тә бар.

Картның сәламгә каршы җавабы саран булды:

— Шөкер әле.

Хәл-әхвәл белешеп, йомыш әйтелгәч, озын-озын төкле калын кашын җыерды:

— Кая инде, балалар! Кем коткысы? Хәзер зиһен тарау ла. Биш-ун җыл әүвәлтенрәк әмәле чыгарые.

Кыяфәте ачулы картның. Шул ачуны очлы сакалы, киң яңаклары, өшетерлек дәрәҗәдә чәнчеп карый торган гаҗәеп кара күзе көчәйтә. Тавышы коры, чатнап тора: ташка таш бәреләмени. «Балалар» диешеннән генә күңеленең ерак бер төшендә җылы урын барлыгын чамаларлык.

— Капка төбендәге тактамның бер-икесен алып киткәннәр, хәерсезләр. Мунча түбәсенә дип хәстәрләнгән ием. Сез утырышыгыз.

Үзе балта белән ботак-сатак чабарга кереште. Балтасын кыска селтәнә, каты итеп чаба, тамак төбе сызгырып куя.

«Гайрәтле. Мондыйныңмы зиһене тарау?» — дип уйлый Бәхтияр.

Ишегалды киң, чиста. Капкага каршы якта такта түбәле келәт, өчме-дүртме торыклы абзар. Ян якта — алма бакчасы. Койма башыннан куш йодрык шәйле алмалар балкып тора.

— У-у, бабай, бакчаң шәп икән!

— Җәшлегендә теләге шәп булганга, кызым. Керегез, ашагыз — күңелегезгә хуш икән. Ә җыр әйтергә чама җук.

Студентлар картның карышуына аптырамады. Күпме кеше шулай алар йомышын кире кага. Картлар күңеле серле йозак, ашыгып бер бәйләм ачкыч шалтыратырга керешмә. Сөйми алар кабалануны. Ясаган чәйләрен кыстатмый гына эч, күңел йозакларына орынырга ашыкмый тор. Алдан нәкъ тиешле ачкыч табу мәгъкуль. Бер мәлне үзләре келт итә алар. Картның киреләнүен дә шулай юрадылар. Өметләре киселмәде әле.

— Ашагыз, мул анда.

Карт бүленгән эшен дәвам иттерде. Чаба торган агачлар арасында корыган, кипкән алмагач ботаклары бар. Бәхтияр белә: алар кипкәч — имәннән каты. Мәгәр картның балтасы шәп чаба.

— Каяле, агай, үзем.

— Ә?

Балтасын китереп чапкан мәлдә әйткәнгә, картның күкрәге «Әһ-һ?!» дип сулкылдап куйды.

— Сулу ал дим, агай!

— Син ник бакчада түгел? Ә, өлкәнрәк чамадасың икән.

Картның кулыннан балтасын алып, Бәхтияр бар җәһәтлеге һәм ярсулы гайрәте белән ботак чабарга кереште.

— Тотнагың бүтән. Җаның сабыр...

— Каян, агай.

— Күңелең китек калмасын, әйтим. Әнә, күрәмсең, ишләрең алма ашый. Җыенысы бер агачтан. Иң асылы — шул. Алмасы дәү. Тапканнар тәки. Кызгануым түгел, бик хуп.

— Корт яхшыга куна.

— Хак сүз. Тик ул агачның соңгы җылы быел.

Эшләми эшләгәнгәме — Бәхтиярнең сулуы капты. Карттан бераз гына уңайсыз булса да, тын алырга чама итеп, бүкәнгә чүкте.

— Ничек — соңгы?

— Соңгы. Язын чәчәккә бөреләнгәндә корый язды. Чак апкалдым. Бөреләнгәндә авырган агач җәй күрмәс. Иптәшләрең моны белми ләсә... Олан, ә олан, бәлкем минем дә, шул алмагачныкы күк, соңгы җәемдер? Мисалга, ул алманың бер-икесе калырга тиешме?.. Кашан алмасы бит ул! Кеше алмагачмы — соңгы җырын да өзәргә...

Картның күңел төбе Бәхтиярга шулай ачыла башлады. Укыганы бар: асыл энҗенең кабырчыгы затсыз. Картның кырыс йөзе бай зиһенен томалап торыр өчен генә мәллә?

— Әле дә ярый тандың. Кешенең үзе белән ләхеткә иңәсе соңгы җырын алма, олан. Җан җырусыз кеше... Корыган кашан алмасы, корыган. Ихластыр.

Бәхтияр көлеп җибәрми түзә алмады:

— Кәмит кеше син, агай. Юк нәрсәне күпертәсең.

— Күпертәм? Кеше жыры бакчамдагы кашан алмасы диюемме күпертү?

— Казан алмасы диюеңдер, агай.

— Кашан диюем, Кашан... ш белән әйт, ш белән.

— Андый сортны ишеткәнем юк.

— Жуктыр, жуктыр. Бу актыккысы. Ахыргы баг алмасые.

— Кашан, баг,— дип кабатлады Бәхтияр. Аның әнисе шулай матур, билгесез сүзләр кушып сөйләшкәли иде. Ул уенда тагын камыш шавы ишетә дә, нечкә билле житү кыз баланың, күлмәк итәген билендәге путасына кыстырган килеш, урак белән камыш уруын төсмерли.

— Аталышы нигә Кашан соң аның? Хикмәте ни?

— Кашан тавында үскәнгә. Шуннан күчерелгән.

— Соң, тагын күчер бирәрне. Яшерәген. Бардыр әле.

— Бетте, олан. Тракторлар белән йолкып-йолкып аттылар. Кама жарыннан түбәнгә очты, акты-китте баг алмалары. Урынында Масланың алма бакчасы хәзер.

— Анда бетсә, бүтән жирдә бардыр.

— Моның ишесе жук, олан. Алмасы башта әче булса да, бер араны чат бал белән тула ул. Татып карамадың аны. Ул бит болгар бабайлардан калган агач, болгарлардан хәтле калган!

Портфель тоткан, нигәдер чалбар балакларын сызганган Миңлехановкүренде. Аның артыннан — бүтән студентлар.

Бәхтияр сүзнең табышмаклы урында бүленүенә түземсезләнеп көенде.

— У-у, рәхмәт яусын, бабай! — диде кызларның берсе.

— Минә бу алмаң тәмле икән, агай! Үзе кечкенә, әче чат ярма. Бал инде менә,— диде Фәгыйлә.

Ул, төсе белән дә, зурлыгы белән дә йомырка сарысы ише булган бер алманы чертләтеп тешләп ала да «нәм-нәм» дия-дия чәйнәргә керешә. Авыз тирәсенә алма суы чәчри.

— Житте, жәмәгать! Эшкә башлыйбыз. — Миңлеханов Ширияздан карт утырган бүрәнәгә утырды.

— Абзый, сез карулашмагыз инде, зинһар, кирәк бит. Өлкәннәр китә, жырлары калсын дип йөрибез лә.

— Үзләре калып, жырлары үлгәннәр дә була, агай-эне. Жан асрамак — жыр асрамак бер түгел. Гаепкә алма, кем...

— Һәй лә, бабай! — дип кычкырды Билал. — Шаулатып утын кисәсең әле, сөбханалла диген!

— Кисәсең кирәккәч. Кирәккәч кенә жырлый алсаең, сез әйткәнди.

Карт, алла билем дип, урынынннан кузгалды, биленә арттан кулын салган килеш, кое авызына иелде. Бер мәл нидер чамалап торды.

— Болай булгач, булмады әле бу, жәмәгать. Ышаныч баглаган идем, югыйсә. Әллә ничә кеше әйтте ич Ширияздангарга сугыла үтегез дип.

— Безгә дә бер әби шуны искәртте...

— Тикмәгә түгел, димәк. Нихәл итәсең. Әйдәгез, жәмәгать. Әбәт житеп узды.

Студентлар чыгып китте. Бәхтияр дә. Бүленеп каласы килмәде. Миңлехановка кызык эстәгәндәй генә ияргән иде ул.

Иртән, ашап-эчкәч, Миңлеханов аннан:

— Ә сез нишләп йөрисез? — дип сорады.

— Нишләп?.. Урып-жыю турында язасы иде. Яңа керешкәннәр. Язарлык әллә ни юк әле.

— Соң, әйдәгез безнең белән. Кызык нәрсә ул фольклор.

Бәхтияр Ширияздан карт ишегалдыннан урамга чыкты. Аркасы буйлап кайнарлык ташкыны йөгерде — Хөснижиһан килә иде.

... Кичә ул аны искәрмәстән куып җитәргә базмады. Нигә? Ни сәбәп белән? Үзеннән биш яшьләргә өлкән хатын. Авыл хатыны өчен биш яшь аерма — үзе бер гомер. Ни уйламас та, ни дип сукмас. Уйлавы бер хәер, эт итеп сүксә мена... Җир ярылса сикерер хәлгә тарырсың. Тыныч башка бәла өстәп... әллә бәла, әллә ни тагын.

Икеләнә-икеләнә араны кыскартты. Тәвәккәл...

«Нәрсә, тәвәккәл? — дип эндәште ул үз-үзенә. — Тәвәккәл таш ярамы? Таш кынамы?»

«Ә үз башың ярылса?»

«Эх, кайда соң ул «Кочагында үлсәм дә шат» дип җыр чыгарган әүвәлге тезгенсезләр?!»

Ул оялып китте. Шып туктады. Алда ниндидер ир заты:

— Хөснижиһан! — дип аваз салды. — Хөснижиһан!

— Кара мәче булма, Ногман, бүлмә минем юлымны. Туйдырдың тәмам.

— Туктале, тыңла...

— Өстерәлмә тирәмдә дим.

— Куенында таш йөретмәле, Хөснижиһан! Балаларым хакына...

— Балаларың сиңа, шул нәрсәм! Кемгә алмаштың, Ногман! Яшь башкайларымны никләргә генә хурладың? Мин хурлансам, син түгел күзем төшкән таш янар...

— Изге шул син...

Бәхтияр, урамның икенче ягына чыгып, басынкы авазларга якынаярак төште. Хөснижиһаннар өе турысы, ахрысы. Хатын, ап-ак булып, багана башындагы ут яктырткан төштә басып тора. Әйтерсең яктыга елышкан күбәләк. Утка тиеп канатын көйдергән күбәләк сыман, аның да күңел канатлары янганмы, хәзер дә янамы әллә?.. Я булмаса, үзе яктырткыч бөҗәк, ә аның каршысындагы аваз иясе шуны аулаган төнге кошмы? Ә бит ул кош кайчандыр бер Хөснижиһанның пар канаты булганга охшый.

«Вафат дигән иде ич!» — дип уйлый Бәхтияр.

— Соң, минем хатын лабаса син!

— Яна гаиләң югалткандыр, Ногман. Авыру тилгән бер тотып ычкындырган кошны минеке дими. Әй лә, син исерек белән авыз чайкаган мин гәләй!.. Китсәнә юлдан, вөҗданыңнан ваз кичкән нәмәрсә!..

Хөснижиһан зәһәрләнеп караңгыга атлады да шапылдатып капкасын ябып кереп китте.

Ир заты очкылык тота-тота китеп барды.

«Үлмәгән ич. Аерылганнар!»

Көтеп торса, Хөснижиһанның йокларга ятуы бар.

Шакыды. Әкрен генә итеп тә, катырак та. Ишеттеләр.

— Әле югалмадыңмыни, денсез! — дип сүгенә-сүгенә Хөснижиһан аваз салды. Каты кычкырмый, якыннан ишетелерлек дәрәҗәдә генә. Күрәсең, күршеләр, үткән-барган ишетүеннән яхшысынмый.

Бәхтияр аны капкага аркылы тыккан агачны шудыра дип тора иде, кече капканы үзе сыярлык кына ачкан хатын кулында көрәк шәйләп алды. Өлгермәде, исенә килгәнче, янбашына сугудан артка атылып китте дә, ташка абынып, чалкан барып төште. Аякка басам дип янгарак борылган иде, аркасына да сукты. Хөснижиһан кулында агач көрәк икән.

— Җитте сиңа, оятсыз. Иртәгүк сәвиткә барам, бел аны, иманыңнан түнгән нәрсә. Кем дип белдең, кем?

Көлсенме Бәхтияр, еласынмы, дәшми-тынмый качсынмы? Танытмыйча. Якты җирдән үтәсе бар шул. Кемлеген тәгаен танымаса да, студент кына иде дип, иртәгесен дөнья кубаруы бик ихтимал.

— Апа жаным... тагын мин лә бу...

Кызган хатын туктамады. Тәрткәләүдән туктамады. Бәхтияр, чарасы калмагач, сикереп торып аның кәрәгенә ябышты.

— Апа жаным, тагын мин лә бу!.. — дип пышылдады.

— Аб-бау, хәерсез!.. Ычкын җәтрәк кеше күргәнче...

Көлкегә калды шул. Көлкегә генәме? Иртән, Хөснижиһан ашарга пешереп киткәнче, йоклаганга сабышты. Хәзер инде нинди күз белән күренсен? Жир бит түгел лә ул көпә-көндез аның күзенә чалынырга. Бер-бер юне табылыр, шәят, онытылыр.

... Студентлардан аерылып калып, Шириәздан картларга кереп качудан битәр әмәле булмады.

## Кашан каласы

### 1

Бәхтияр төшлеккә кунак йортына кайтып тормады. Шириәздан карт янында калды. Инде менә аның гомерендә башына килмәс соравы бар:

— Нинди тау ул — Кашан тавы? Кай төштә?

— Кама буенда. Борын заманда ул тауның текә ярында Кашан каласы торган. Болгар шәһәре...

Бәхтиярнең күңел төбе кытыклана. Башында уйлар учагы кабына да сүнә, кабына да сүнә.

— Кем әйтте?

«Уңдүртенче гасыр...» — дип хәтерләде Бәхтияр. Белә ул бу кала хакында. Болгарга караган китаплардан бу хакта укыганы бар. Кайберсенең ул беренче укучысы да булган иде... Юка гына зәңгәр тышлы китап хәтерендә. Аңа кадәр кеше кулына эләкмәгән. Бәлки эләккән дә булгандыр, әмма ачып укылмаган. Ул аның әле киселмәгән битләрен тарагы белән ертып укыды.

«Кашан, Кашан, — дип кабатлады ул күңеленнән. — Җукәтау, Кирмәнчек... — дип саный китте. — Болгар шәһәрләре...» Ләкин хәзер ул бер нәрсәне дә белмәгән атлы кыланды. Сөйләсен карт, сөйләсен.

— Кем әйтсен — ата-баба хәтере әйтә. Ата-баба хәтере — ил хәтере ул. — Карт сүзеннән туктады да карлыгач кәтүен күзәтә башлады. — Яңгыр явасы... кызуга китте.

«Әйе, хәтер чишмәсе тарих тавы түреннән агып чыга,— дип уйлады Бәхтияр. — Әгәр туып үскән оясын тапкан карлыгач хәтеренең серенә төшенә алсаң, карт сүзенә гаҗәпләнмәс тә идең. Жиде баба хәтере... Карлыгачлар дөньяга килгән ояларын ничек шулай онытмый да, аларның бу гаҗәп хәтере йомыркадан чыккан балаларына ничек итеп күчә икән? Ә безнең, безнең нигезләр кайда, таныйбызмы без аларны?..»

— Кайда соң ул тау?

— Жырак түгел. Дүрт-биш чакрым моннан, Шуран авылыннан Кама буйлый бер чакрым хәтле өстәрәк. Шунда як-ягыннан ике ерганак белән чикле бер үр булыр.

— Без бит инде әзме-күпме укыган, агай, тарихны да белмибез түгел, син әйткән хак микән? — дип сораган булды.

Йөзе җил-су ашаган ташлы кыяны хәтерләткән карт аңа авыр һәм салкын итеп карап куйды. Бәхтияр, куып чыгара хәзер бу дип, шүрли калды хәтта.

Картның карашы, чыннан да, күңелгә пошаман салырлык. Кыска аксыл чәче һәм ак кашы астындагы чем-кара күзе белән ул тау бөркетен хәтерләтә. Әйтерсең кояш яктырткан текә ак кыяда караеп торган ике керәшә оясы...

— Мин укытучы түгел, кем, Бәхтияр... Белмәгән өчен җәза итеп икеле куймыйм адәм баласына.

Бәхтияр төшенеп җитә алмады. Теләсәң ышан, теләмәсәң ирексезләмим, кеше үз ихтыярында диюеме?

— Хәзер анда нәрсә... Мин барсам, таба аламмы ул төшне? Берәр эзе калганмы соң аның?

Күзен кыса төшеп, карт көлемсерәп куйды:

— Бабаңның бабасы димим... бабаңның атасы каберен эзли керешсәң, таба алырсың микән?

— Юктыр, ихтимал. Ул бит кабер. Шәһәр булып шәһәр...

Картның сөйләшүе кызык: Бәхтиярне бер мәртәбә дә сүзеннән бүлгәне юк әле. Тыңламаган да кебек үзе. Хәтта кәрҗин үрергә кереште. Җаваплары төгәл: Бәхтияр зиһенендәге уйны, бодай арасыннан чүп аралаган шикелле, капшап, эзләп ала.

— Әй-й, олан! Күпме кала ята димсең җир астында?! Бу дөньяның без белмәгән күпме зираты бар!.. Тагын күпмесе булыр әле... Ә? Иң хәтәре — хәтер зираты... Хәтерең күмелсә — рухың күмелү белән бер.

«Әйе, — ди Бәхтияр килешеп. — Калаларның калалары, бабаларның бабалары... Зиратларда һәммәсе тигез».

Бәхтияр үзенең ни өчен килгәнлеген дә онытып торды. Ул картка кәрҗин үрешә — чыбык юныша. Тыныч эш. Картның куллары бер көйгә очкан кош канатларымыни: бер күтәрелә, бер төшә, аннары, әйләнеп, тагын күтәрелә...

## 2

Әле яңа гына Ширияздан картның бер борчуы кимеде. Идарәдән күпме сорап йөдәткәч, утын китереп ташладылар. Бая көпчәкле трактор килеп туктау Бәхтиярне кунак йортына кайтып торудан коткарды. Хәснниҗиһан Ширияздан карт өе турыннан узып китүгә, шул утынны бушатышырга кереште. Юан нарат утыны. Дөрес, төп буеның үзәге черегән, алай да утынга таза. Кипкәч күкерт булып кабынырлык.

Утын бушатылгач, аны китергән кешеләр карттан бер литрлык акча дәгъваладылар.

— Юграк чак бит, оланнар, пенси килмәгән,— диде карт.— Шушыңа канәгать калсагыз... — Ул тракторчыга өчлек сузды.

— Бурычка алып торсаң?

— Түлисе бит барыбер. Карт кешегә рәнҗемә инде, Мәрданша энем.

Сүзгә Бәхтияр дә кушылды:

— Сезгә бит моның өчен колхоз түли. Урак вакытында берәү сезне изге эшкә юллаган, сез калым теләнәсез. Килешми.

— Тәртибе шул... — Тракторчы егет карашы белән аны баштанаяк, аяктан-баш сөзеп чыкты. Тәне көчле, кояшта янган ялангач беләкләренә кара көмеш йөгертелгәнмени — елкылдап тора. Бәхтияр аның кулы йодрыклануын күрә.

— Син кысылма, студин, — диде өлкәнрәк яшьтәге йөкче. Анысының карашы елгыр, сынап карый.

— Соң, братлар, бу картка сәдака гына бирерлек. Сез аныкына мохтаҗмыни? Идарәгә җиткерсәм, рәхмәт әйтмәсләр.

— Дәшмәсәнә! Нинди брат ди без сиңа, көлчә!

Тракторчы да, йөкче үзе дә көлчә дигәннән шырык-шырык көлешеп алдылар.

— Ярар, Ширияздан абзый, бигайбә, алайса.

— Ихластыр, оланнар, рәнҗемәгез инде.

— Ярар, калмаган. Ә син, студин, клубка чык бүген, хе-хе. Кытыклы уйнарбыз, эхе-хе-хе...

Бәхтияр кызмый. Сабыр булырга күнеккән. Низаглар — юл пычрагы, алар аша сикереп үтә белә. Булдыра алганча... Бераз уңайсыз, билгеле,

горурлык дулый, кайчак, түзәр әмәл тапмыйча, бүртенә. Кайчак әшәке кеше ояласы урынга, үзең кызарасың. Усаллыкка юл кую бетеп житмәгән шул әле...

### 3

Хәзер инде Бәхтияргә үзенең бу авылга эләккәненә гомер буе үкенмәстер кебек тоелды. Билгеле, аның ялы — көньякта ял итәм дип кыш, яз буе ымсынган теләге — Шириаздан картның ишегалды белән, бакчасының утыртмалы читәне белән чикләнде. Әйе, кайдадыр ярларында пальмалар үсеп утырган шау диңгезләр бар, сыннарын сикертә-сикертә модалы биюләр биергә һәвәс кызлар бар. Кайдадыр Кырымнар, Парижлар, Алтын комнар — зур дөньяның рәхәтлек мәккәләре бар. Кемнәр өчен соң алар? Шул тикле даннары булган диңгезләрнең, ерак илләрнең Бәхтиярне рәхәтлеге белән ымсындыра алмаулары — ни соң ул?

Ә бит әле Парижлар яңа оеша башлап, урамнары кояш төшмәс тар булган чакта, түбәсе зәңгәр ташлы Болгар сарайлары, Биләр һәм менә — Кашаннар чәчәк аткан лабаса! Ни аерма ул замандагы бер француз Болгарга омтылмавы белән Бәхтиярнең бүген Парижлар белән кызыкмавы арасында?..

Карт җайлап кына кәрҗин үрде үрде дә, аннары, торып, коесыннан ике чиләк су алды, аны бура сәкесенә беркетелгән авыш улакка салды. Шарлап аккан су улак төбендәге озынча ләгәнгә тулды. «Маллары көтүдән кайтуга җылынып торсын өчендер», — дип уйлады Бәхтияр.

Чиләген өченче тапкыр кое төбенә төшерә карт. Бер тыңлаганда чыгыр шыгырдый күк, икенче колак салганда — Шириаздан картның буыннарыдыр сыман.

Ул тагын су чыгара. Бусы ләгәннән артып ташый, капка астыннан урамга ага.

— Ләгәнең тулды инде, Шириаздан абзый!

— Беләм...

«Белә торып?.. Акылына зыян килгән дисәң...»

— Урамдагы каз-үрдәк өчен мәллә соң ул?

Карт эндәшми. Кое тирән түгел, чыгыр тоткасын карт җиде-сигез генә кат әйләндердеме — сулы чиләк менеп тә житә. Һәм менә тагын бер чиләк су авыш улак буйлап сай канаудагы болганчыкка кушыла.

— Ник түгәсең аны, агай?

Карт тамагын кырды, күзен ачарак төшеп коега пышылдады:

— Әһә, бүгенгә житкән.

Аның мыек очларына тир кунган, аскы иренен бүлтәйтеп, аларга тын өрә: кф-фф...

Әйтерсең лә, серле дога әйтеп, шул коены өшкерә. Аннары, шөгыленнән арынып, бил тирәсен угалагач кына ул Бәхтиярга борылды:

— Суы тәмсезләнә шулай итеп тормасаң. Билгеле бер турыны үтә дә... Сасы тәм сеңә. Ни хикмәттер... Хикмәте шул: бераз казыгач, йомшак бер катлам бар күк ие. Әллә турфы? Шуның аркасында мелләлә.

— Шулай тоела гынадыр ул. Җыела төшкәч, суы җылымсаланадыр.

— Кайнаткач та чит тәм кала. Ниткәндер саз тәме.

— Аннан эчмәскә кирәк, алай булгач.

— Ә каян аласың бүтәнен? Чишмәгә хәтле бер чакрым. Калунканыкы хәтсез каты, бу җылыда өч сәгатьтән зәңгәрләнә ул. Авызга алгысызга әйләнә. Анысы да якын түгел аның... Ун өй аша... Үзеңнекеннән калдырмасын диген.

— Шулай гел түгеп торасыңмы?

— Чарасыз булгач, нихәл итмәк кирәк?

— Минут саен кое чыгыры әйләндерү буламы? Чишмәгә бер бару хәерлерәктер, минемчә.

— Күп тими ул... Көнгә дистә ярым чиләк түгәсе... Сыер заты булгач, аңа каян төткәзәсең читтән ташып? Җәен рәхәт. Суганга сибәсең, кыярга, алмагачка... Кышын бөтенләй әз, су килү кими.

— Шайтан белсен тагын! Син, агай, ел тәүлеге кое төбе сакларга мәҗбүр икән ич! — Эченнән ул: «Кое колы!» — дип аптырашта калды.

Шириязданн карт тагын кәрҗин үрергә тотына.

— Ниткән мәҗбүр! Гомер итү мәҗбүр нәрсә димени?

«Чынлап та. Су агызу — дөнья итүнең гамәле бит инде, картның көндәлек тормышы. Ел тәүлеге бер төрле эш эшләп без үзебез дә тормыш коесын бер халәттә тотабыз түгелме соң? Гаҗәбе бу түгел. Хикмәт карт коесының суы тәмсезләнүендә. Ник? Тын торгангамы? Әмма кое суы... Аның тәме — хәрәкәттә».

Бәхтияр кызыксынуын баса алмады, торып, коены карап килде. Искитәрдәй әллә ние юк. Гадәти бер кое. Карт өчен эче пошуы тиккә генә. Су агарга тиеш икән, аны агызу кирәктер инде. Безнең гомер үтү белән вакыт агышы су агуга тиңләнә. Ләкин бу юлы Бәхтияргә вакытны алга үрмәләгән арба итеп түгел, кирегә тәгәрәгән тәгәрмәчкә тиңләү уе килде. Һәм менә ул, зиһенендә ничә гасырны үтте дә, Кашан хакындагы уйга килеп җитте. Кем белә, картның сүзләре берәр риваять белән очраштырмасмы. Риваять булган җирдә җыр да йөри. Ниндидер җыры бар диделәр ич.

Ләкин сораштырырга өлгерми калды: студентлар тагын килеп җитте. Бу юлы дүртәү: Миңлеханов үзе, Билал, Фәгыйлә, чандыр Хәмит. Хәмит белән Билал авыр магнитофоннарын күтәреп килгән — тирләп-пешкәннәр.

— Менә кайда икән әле син. Анда эзли чыга яздык,— диделәр.

— Агайга утын китерделәр дә... тоткарланылды. Кайтып тормадым инде.

— Анда Хөсниҗиһан апа да... ач кала бирәвегез дип...

Керү белән, иңенә аскан фотоаппаратының ат күзе төсендәге шәмәхә пыялалы объективын Билал картка таба төбәде. Карт, әүвәлгечә, аларга исе китми генә кәрҗинен үрә.

Билал уйлана-уйлана, ашыкмый гына йөри. Картны әле кое чыгыры астыннан төшерә, әле кул арбасы көпчәгенең тырнаклары арасыннан, әле лапаска сөялеп куелган баскычка менгән җиреннән. Картның бер ягына кояшта ялтырап яткан дәү җиз табак куйды, анысы эченә ак калайдан эшләнгән комган утыртты.

— Истәлеккә, истәлеккә, бабай!

Алай да түгел, Фәгыйләгә, калын табанлы туфлиләре рәсемдә чәчрәп торырлык итеп, өйалды баскычына утырырга кушты. Үзе туктаусыз сүз чәчте:

— Гасыр белән гасыр очрашу, ә, егетләр? Хәзер ни, Фәгыйлә, микрофонны бабай авызына якынрак китер.

— Микрофон алынмаган ич әле.

— Соң, Хәмит, авызыңны ачып торма инде, чыгар, ходла микрофонны. Монда берәү тарихи рәсем төшереп ята... Әһә, менә, шәп! Каплама, комганны, комганны! Булды... Нит, туфлиеңне кәрҗингә терә. Яхшы. Юк, юк, аягыңны аера төш... Гасыр белән гасыр...

Фәгыйлә курчак кебек. Ничек кушса, кул-аягын шулай йөртте: күтәрде, төшерде, ерагайтты, якынайтты.

— Безне дә онытма инде, Билал, — диде Миңлеханов.

— Хәзер, хәзер. Тагын бер кадр гына. Ни, Хәмит, анау букәнне дә куй әле. Әйе, артка... күләгәгәрәк. Балтасын каптыр. Һоп! — рәхмәт, бабай.

Шириязданн карт, каршы яктырткан кояшка күзе чагылудан ике учын да маңгаена китереп һәм күзен кысып, Билалны күзәтте. Хәзер аның

бите Бәхтияргә такталары араланган түбә кыегы, ә күзе — чарлакка якты төшсенгә ярым ай итеп уелган ике тишек булып күренде.

— Ни нәрсәгә ул? — диде карт.

— У-у, бабай! Бер егерме еллардан бу рәсемнәр!.. Менә боларның берсе дә калмагачмы? — Билал, кулларын җәеп, бөтен ишегалдына ишарәләде. Каршысында ни бар — һәммәсен, кирәкмәс, чит нәрсәдәй, үзеннән читкә этәргән сыман булды. — Бу рәсемнәрнең һәммәсен дә акчага әйләндерәм мин бер заманны!

Фәгыйлә, иңбашын җыерып, бармак очлары белән авызын томалады. Дәшмә, янәсе. Аннан телгә килде:

— Син ул сөлгеләрне, әбиләрнең җеп эрләвен, кәләпүшле бабайларның ишегалды себерүләрен шуның өчен төшерәсеңмени, Билал?

— Тарихка калсын, тарихка! Боларның эзе дә булмый монда бер егерме-утыз елдан. Эзе дә! Таш йортлар, и ул техника...

Бәхтияр, сизмәстән, бер генә мәлгә күзен йомып алды. Яшел җирлектә — чылатып киптерелгән киндер өеме... талкы... сүс һәм әнкәсенең кул сырты белән маңгаеннан тир сөртүе. Сөртелгән маңгае тир тамчылары чылатудан ялтырап тора. Бер читтәрәк — шушы күренешкә туп көпшәсе кебек итеп кара объективлы фотоаппаратын төбәгән Билал. Күлмәгендәге уч төбе хәтле сары значоктан чагылган нур күзне авырттыра.

— Бүкәнне урынына куегыз, балалар, — диде карт, тавышы үзгәрүен йөткерәсе килүдән күреп, тамагын кыргалады. — Комганны да... Калмый кая китәр алар? Калган ич моңынчы. Сез чыгып киткәч тә торырлар, бүтәннәр килсә дә.

Билал бәхәскә кушылырга җитешмәгән Миңлеханов белән Хәмиткә эндәште:

— Төшерәм. Сез дә басыгыз, Бәхтияр. Фәгыйлә... Бабайны капламагыз тик.

Күзен фотоаппаратка якынайткач, ул аптырап китте. Бәхтиярнең ачулы, хәтта кызарып ук чыккан йөзен күреп алды.

«Минем әнинең камыш, я арыш уруын да шулай ваемсыз елмаеп төшерер иде микән бу?» — дип уйлады Бәхтияр.

— Ашыгасың син, Билалетдин брат! Тереләрне, үлмәскә килгәннәрне күмәргә аш-шыгасың, — диде Бәхтияр тешләрен кысып.

Ул Билал алдында бигрәк тәбәнәк күренә. Ләкин Билал аның киң күкрәге каршысында куркып калудан озынайган кебек.

Яманлык сизеп, Миңлеханов алар арасына басты.

Йодрыкланган кулын күтәргән иде Бәхтияр. Кире төшерде. Бары тик тотлыгудан көчкә:

— Бүкән белән... балтаны... урынына куй, — дип пышылдады. — Аннары соң сыз моннан... фольклорчы...

## Һәрнәрсәнең ахыры бар

### 1

Утын җиңел киселә иде. Бар тарафка нарат чәере исе таралды. Бәхтиярнең дә, Фәгыйләнең дә куллары сагызга буялган, шуңа тузан, пычкы чүбе ябышып беткән...

Студентлар дәшми-саубуллашмый гына чыгып китте. Хәбир Миңлеханов карттан гафу үтенде, беркемгә дә ишарәләмәстән:

— Киттек, — диде.

Фәгыйлә дә киткән иде, бераздан кире борылып керде.

Хәзер ул Бәхтияр белән утын кисеп азаплана. Юан гына бер нарат-ка керешкәннәр иде, карт пычкыларын бүтәнчә куйдырды:

— Тар ягыннан кисегез, шулай көйле, — диде ул.

Чынлап та, агач түгәрәк түгел, бер якка юкарак. Аны шулайга җайлагач, пычкы җиңел йөри башлады.

Карт, селкенмәсен өчен, агачны тотып тора.

— Юкка кыздың ул балага, — диде ул. — Рәнҗемәдем мин. Яшь әле ул, аңлар... Нәстә аны, — диде ул тыныч кына.

Бәхтиярнең әнкәсе дә шулай, кайткан саен, үләсе ди. Сизә Бәхтияр: ул моны һич теләми. Шуңа күрә Бәхтияр аның алдында үлем-китем турында ялгыш сөйләп ычкындырудан бик саклана иде.

Картка да ни дисең? Кирегә үгетләсенме? Үзен-үзе корбан кылырга җыенганнарга гына биреп буладыр үлмә дигән үгет-нәсихәтне. Картлар нәрсә: иелеп йөри-йөри иң күп күргәннәре — җир: кеше, көнен кичергән саен, җиргә якыная ич.

Сүзне икенчегә борасы килде. Картны шул уенда калдырсынмыни?

— Яңа киселгән, ахрысы, бу агач,— диде.

— Яңадыр. Пенсиядәгеләргә корысы тәтиме? Бүтәннәргә әле бусы да юк.

— Урман якын бугай ич. Әнә генә. — Бәхтияр ияге белән урман ягына ымлады.

— И-и, аны да урман дисәң... Сирәгәйгән инде ул, үтә күренә. Чат иләк.

— Алай булгач, бу ерактандыр. Бу тирәләрдә нарат үсми бугай.

Бәхтиярнең бу районга бер-ике килгәне бар. Бу авыл да хәтерендә. Бу тирәдә нарат-чыршы үсмәгәне аңа яхшы билгеле.

— Юк ла, урак өстендә ерактан китереп йөрми инде. Моннан гына. Кашан тавыннан. Безнең тирәдә бер җирдә дә нарат үсми, ә анда үсә. Изге урын булгач, кисмиләр ие, корыса гына мәчеткә апкайтып кискәннәре хәтердә. Әтинең атасы Бикбулат бабай да әйтә торганые: әүвәл заманнарны Сабакайдыр, Кызыл-Юлгадыр, безнең авылдыр халкы җәй көне ел саен шунда йөри, дога кыла торган булганнар дип, хәзер анда иң күбендә ике дистәләп агач калгандыр инде. Әүвәле күп ие.

— Ә ник кисәләр икән соң аны әз генә калгач?

— Кисә инде, нишләтәсең... Болары иген арасында булгандыр, күрәмсең...

Инде өч торык кистеләр, Фәгыйлә арыды. Аның белән кисү җайсыз. Бәхтияргә пычкыны тартасы гына түгел, этәсе дә. Әле ярый, картның пычкысы көйләнгән: үтә, ипле.

Хәл алырга туктадылар. Фәгыйләнең бите алсуланган, тирләгән уч төбен ботына сыланып торган кысан, ләкин киң балаклы чалбарына сөртә, бармак очлары белән күлмәк изүен эләктереп, тәненә һава җилпетә. Аннары, биленә таянып, матур итеп кирелә дә бүрәнәгә, Бәхтияр янәшәсенә утыра. Якын утыра, орынып диярлек. Бәхтияргә уңайсызрак. Моны Фәгыйләгә сиздерсә, ул уңайсызлануы көчәячәк кенә. Башына бер кайнар уй килә дә, балавыздай эреп, бөтен тәненә тарала: «Нәрсә шушы кызны үз итәр егет түгел мәллә?» Кочаклар иде. Тегесе карышмас та бәлки. Янда күзен кысып әллә кая карап торган ап-ак чәчле карт бар. Фәгыйләдән тир исе килә. Шул искә нарат сагызы исе дә кушылгач...

Моның ише кичереш аның өчен яңа түгел. И Фәгыйлә кебек бер-ике сылуы белән очраштырганы бар дөньяның! Аларны бераз вакыттан кабат очратыр күк булган иде. Юк икән. Һәрнәрсәнең башлангычы — аның ахыры да икән...

— Ә син ник иптәшләрең белән түгел, Фәгыйлә?

— Әй лә! Билалның баягы кыланышы ачуымны китерде.

— Ник инде? Дусларсыз бугай.

— Дуслар?.. — Фәгыйләнең уң яңагы тартышып куйды. — Ялгызлык куркыта мине... Бер айга да түзем җитми,— диде ул. Җиңел әйтте. Ләкин Бәхтияр мәгънәсенә төшенеп җитә алмады, картны күзәтә иде. Ул

исә уйлары авырлыгыннан басылып, бөкрәеп утырган да, башын артка ташлап, дөньяда гаме булмаган адәм шикелле, каршы өйнең телевизор антеннасына текәлгән.

«Җанында нинди җыр бар икән бу бабайның?» дип уйлый Бәхтияр.

Карт тезенә таянып баса да кереп китә. Бәхтияр йомычка белән тырнагын чистартып азапланган Фәгыйләнең кулына кагыла. Фәгыйлә моңа илтифат итмәстән, эшен дәвам итә. Бары тик «җылы», я булмаса «каты» дип әйткәндәгедәй, тыныч кына:

— Ялгышасың... — ди.

Әле генә сез дип эндәшә иде Фәгыйлә. Бер кагылу белән Бәхтияр үзен «син» түбәнлегенә куйды. Әллә «син» якынлыгынамы?

— Кисик мәллә? — ди Бәхтияр.

— Әйдә.

## 2

Утын кискәч, ял иткән арада картның бакчасында йөреп алганнар иде.

— Бая беткәнче ашаган икән сез Кашан алмасын.

— Кем алмасын?

— Шундый сорт икән. — Бәхтияр карттан ишеткәнен кабатлап тормады. — Ашап бетергәнсез диюем.

— Бабай үзе кыстады ич. Иң тәмле алмасы шул булгач... Ач кешегә аш пешертмә, ялан тәнгә күлмәк кистермә ди. Безгә җитә калгандыр.

Фәгыйлә сабагында утырган дәү табактан көнбагыш чемченә.

— Ә бу агач быел корый язган инде... Соңгы елын алма бирүе. Беркесеннән калдырасы калган картка да.

— Белмәдек ич.

— Белсәгез әгәр?

— Өзмәс идек ул тиклем. Соңына хәтле.

— Ә бит өзәсез.

Фәгыйлә, Бәхтияргә карап, иңбашын җыерды.

— Көнбагышнымы? Монда күп ич. Әнә күпме! Табак-табак.

— Җыр җыюгызны әйтәм мин. Карт-коры сезгә бәлки соңгы җырларын җырлый торгандыр. Соңгы елны... Алар да бит — карт кешеләрнең соңгы алмалары. Җырлар диюем. Бәлки сезгә җырлаган кешеләрнең кайсыберсен, икенче кат килсәгез, очрату насыйп та булмас...

— Аңа карап җыймаска мәллә? Кирәкмәсә йөрмәс идек. Аннары — җырлаган кеше соңгысын җырлыйм димәс. Җырларның очы-кырые юк бит... Алма ашалып бетә ул аңысы, ә җыр җырланып бетмәстер.

Фәгыйлә сүзләре Бәхтиярне бераз гаҗәпсендерде. Фикер яңалыгы белән түгел. Бәхтияр үзенең ялын кайда үткәрәсен әйткән бердәнбер кешенең фикере сүзгә-сүз Фәгыйләнеке шикелле үк булуы белән.

Бәхтияр үз уйларын аңа гына ышана иде. Ул кызның үе-сүзе генә түгел, күзе дә дөреслек белән тулган кебек. Ә йөзе, шул күзләре сыман, гел якты, салкын су белән югандай саф. Ул кыз — бер заводның комсомол секретаре. Үз вазифасына тирән бирелгән.

Бәхтияр иң яшертен серләрен дә аңа житкерүдән курыкмый — әйтә дә, ниндидер сейфка бикләп куйган сыман, үз уйларының ышанычлы җиргә урнашуына шикләнми.

Шулай, ул кыз Бәхтияргә:

— Җүләрләнгәнсең дисәм, дорфа булыр — ир кеше җыр җыеп йөриме инде? Ярый ла эшең белән бәйле булса. Син фольклорчы түгел бит! — дигән иде.

— Минем язган нәрсәләрдә — гел фольклор гына, ник бәйле булмасын! Ни язсам да халыктан. Мин — плагиат. Мәкаләләремдә халыктан чыккан әзер мәгънәләрне үземнеке итеп кулланам мин...

— Артык гадиләштерәсең...

Бәхтиярнең бу әңгәмәдәше филология белемле. Һәм аның белән сүз көрәштерү секретарь кызга ләззәт биргәнен Бәхтияр яхшы белә иде. Икәү генә калсалар исә, Бәхтияр белән секретарьның телендә әдәбият та мәдәният. Бу, ахыр чиктә, Бәхтиярне күптән туйдырды. Инде берберсенә карата хисләре дә сүрелмәде түгел бугай.

— Җырсыз кеше юк, — диде кыз, сүзен дәвам итеп, — һәркемнең үзенеке генә булган моңы-зары бар. Ишеткән берсен, сөйләм калыбына салып, язуында кулланасың икән — бу әле плагиатлык түгел. Син кешенең бердәнбер җырын куллансаң, башка мәсьәлә, — дигән иде.

Дөресен әйткәндә, аның болай галимчә сөйләмен Бәхтияр өнәми. Мәгәр ике елга якын сузылган танышлыктан бүген кер эзләү беркатлы ваклык булыр иде.

— Синең дә бармы ул — үзеңнеке генә исәпләнгән җыр? — дип төрттереп сораган иде Бәхтияр. Чибәрлеккә бай-мул секретарь кызның җыр көйләү, биер һәвәслеге чамалы. Әмма хатын-кыз назлылыгы, вакыты уза барган кыз хәйләлеге бар. Хәер, анысы да сизелер-сизелмәс кенә, нечкә.

— Бар, — ди ул.

— Соң, тыңлат бер. Ишеттергәнең юк моңынчы.

— Син — минем җыр, — дигән җавап ишетә Бәхтияр. Кызның үз күкрәгендә яткан башы янга шуыша да, аның сулышыннан Бәхтиярнең култык асты кытыклана.— Беренчесе. Бәлки соңгысыдыр...

Бәхтияр аны кызгана.

Әһә, бардыр ул һәммә кешенең үзенеке генә булган җыры.

Кем белә: берәүгә — Фәгыйләдер...

— Бер үлгәч, кешене үлем бүтән куркыта алмыйдыр инде... Картлар соңгы сүзләрен җәлләми,— ди Фәгыйлә, читән казыгына элеп куелган ат башы сөяген кулына ала. Сары сөяк инә очыдай нечкә генә сызыклар белән чуарланып беткән: күзәнәкле, җип-җиңел.

— Ярар, килешәм, — диде Бәхтияр. Казан кызын уйлап, ул Фәгыйлә белән сөйләшүнең очын югалткан иде инде. Мондый очракта теләсә ни белән килешергә туры килә.

— Алма да ашамыйсың, көнбагышыңны да ташладың, — диде Бәхтияр сүзе беткәнгә эче пошып.

— Алмадан туйган, көнбагыш өлгермәгән әле... Бу сөяк нәрсәгә икән?

Бәхтияр ул сөякнең нәрсәгә икәнен белә иде. Үзе дә, кызыксынган булып, Фәгыйлә белән янәшә басты. Кара, нәкъ аның буе икән. Ялан аягында калын табанлы туфли — шуңа. Шәһәрдәге секретарь кыз моннан тәбәнәгрәк. Тәне дә какча. Фәгыйлә кай ягы беләндер күтәрә алмастай матур герне күз алдына китерергә мәҗбүр итә. Ә бит, читтән күзәткәндә, теләсә нинди герне күтәреп булыр кук...

— Сөякме? Күрәсең, Шириаздан карт әүвәле умарта асраган.

Сөякне алган булып, Бәхтияр Фәгыйләнең кулына кагылды. Ул моны ялгышлык белән эшләгәндәй кыланган иде дә, кыз алай кабул итмәде: кулын кабаланып тартып алды.

Ә бакча капкасын эз генә ача төшебрәк үзләрен күзәткән Хөснижиһанны алар шәйләмәделәр. Аның карашы сөяккә төбәлгән. Юк, аңа түгел. Бер мәлгә берсенә-берсе орынган кулларга бугай. Ул нидер әйтергә талпынган иде, күрәсең, тынды, карашын капка күгәненә күчерде. Кулында кызыл бер нәрсә.

Бәхтияр, күзенә төшкән чәчен аралаганда, иң әүвәл шул кызыл нәрсәне күрде. Чәч күзне томалаганда, ерак әйберләр якын булып күренә. Кызыл нәрсә — кызыл алмамы? Хөснижиһан капканы ябып өлгерде.

«Чү, минем удостоверение ич. Кичә төшеп калган, димәк. Ә ни калган аңа монда?»

— Безнекеләр әзерләнәдер инде, — диде Фәгыйлә.
— Кая?
— Күрше авылга ди бүген. Әллә бармыйсы? — Кыз кырын басты да инбашы аркылы аңа карады.
«Минем белән калыр өченме?» Бу уен Бәхтияр чак теленә күчерми калды:
— Минем белән... минем белән монда аерылып калма тагын. Эзләр.
— Эзләр? Кем?
— Кем? Билал.
— Ә-ә! Эзләр шул, — диде Фәгыйлә. Кырт борылып, бакчадан чыгып китте.



### 3

Ишегалдында Хөснижиһанның ни өчендер тонықланган тавышы ишетелде. «Ә, коены карыйдыр», — дип уйлады Бәхтияр. Тагын коемы? Аңа бу авылдагы бөтен кеше дә Ширияздан картлар ишегалдына кое карар өчен генә килә торгандыр сыман иде инде.
— Ә, Фәгыйлә! Нишләп берүзең?
— Түгел. Бәхтияр дә бар. Бакчада.
— Ул нишли тагын?
— Ә кунак йортында ни калган аңа?..
— Мәйтәм, монда ничек килеп эләккән?
— Безнең жыр жыеп йөрүгә иярөп.
— Ул да жыямыни?
— Юк, болай гына. Гәжит кешесе ул. Кызыксына, болай гына иярде.— Ә син нишлисең монда, Хөснижиһан апа?
— Әтигә булышырга килдем.
«Нинди атасына? Ә кыз баласы диюе ни?»
Кое чылбыры чылтырады. Бакча капкасын пычак йөзе генә сыярлык итеп ачкан Бәхтияр коедан сулы чиләк алырга киерелеп иелгән Хөснижиһанның аркасын күрде.
— Нигә ул су? — дип түземсезләнеп сорады Бәхтияр. Капканы сәер итеп ачкан жирдән эндәшүе хатынны кисәк шикләндерде, ахрысы, үрелеп чиләк алганда жыерыла төшкән итәкләрен ашыгыч сыйпап алды.
— Маллар кайта, шуларга.
— Соң, сулары бар ла.
— Коя҆шта артык жылымсаланган анысы. Кое суының тәме китә жылымсаланса.
— Атаң кая? — Бәхтияр ишегалдына үтте. Соравының, янәсе болай гына әйтелүен сиздерер өчен, кое каршындагы бүрәнәгә утырды.
— Йоклый әле әти. Бакчы ике кәржин үргән. Бәрәңге алырга әзерләнә. Әнәтерә, утын кисеп ташлаган кем беләндер.
— Бергә турадык. Ә син кичә кыз баласы дип... Ә хәзер — әти.
— Тиз шикләнәсең икән. Белеп бетер, наный, кыз баласының да атасы була. Юкса — ничек?
— Була. Тик...
«Дөрестән дә, кемнең атасы юк? Яки булмаган?..»
— Нәрсә «тик?»
— Юк, мин болай гына...
Бәхтияр капка ярыгы аша төшкән кичке кояш нурыннан күзен кыса. Кичәге төннән соң бу хатынның берни булмагандай сөйләшүе оялта аны. Иңбашы авыртуы үзен сиздерә әле. Кайтып китсә ни була? Кунак йорты буштыр инде, тегеләр киткәндер. Ләкин, кирәкмәс кешедәй, ялгызы каласы килмәде.

Хөснижиһан тал чыбыгы калдыклары, йомычка жыя. Кара толымнары иелгәндә җиргә тия, очларына йомычка, чүп эләккән. Кулыннан тотасы иде хәзер аның.

— Хөснижиһан... апа... син ни, кичәге өчен битәрләмә инде. Билләһи, әллә нишләп шунда... Авыл дип, мажара эзләнгәнгәме инде...

Уйламады да Хөснижиһан. Чыбык-чабыкны тал кабыгы белән көлтәләп бакчага чыгарып куйды, яфракларын кәрҗингә тутырып, абзарга кереп китте — тиреслеккәдер.

Аннан чыккач, мунчала юешләп, баскычны сөртә башлады.

— И, наный! Хәсрәтең биш тиен бакыр икән. Яшь чак җүләр чак димәсләрие аны. Син инде каргама тагын. Теге тәре дип орылган ласа.

— Иренме?

— Шул.

— Үлгән дигән идең ич кичә кичен.

— Шулай итеп башны ташка орды шул ходай! Югыйсә, берәүдән жәбер алып яшәр идеммени?.. Бусы икенчесе...

— Ә-ә...

— «Ә-ә» генә түгел шул. Тарихы кан-яшьле. Язмышыңа җен төкергәч соң... — дип, хатын сүзен кырт кисте дә өйалдына кереп китте. — Нимә дип йоклап ята соң әле бу эти? Авыру нярган мәллә тагын...

Бәхтияр аның артыннан:

— Аргандыр, — дип калды.

— Гомергә булмаганны.

Бәхтияр үз күңеленең ничектер төссезләнеп бушаюын тоя. Аны Хөснижиһанның беләгеннән тотасы килдергән хис биләми инде. Кичтән берәр туйда-мазар утырганнан соң, иртән, баш авыртуга түзә алмыйча, бүтән эчмәскә үз-үзенә вәгъдә ташкыны яудырган кеше шикелләрәк.

Хөснижиһанның язмышыннан зарлануы Бәхтиярнең кайнар уйларын суынган мунча ташына әйләндерде. Инде кич, урам ягы көтүдән кайткан мал, аны каршылаган кешеләр авазы белән тулы. Тагын бер төн якынлаша. Хөснижиһан язмышыннан сукрана икән, моны ишеткән кешенең бурычы — ул сукрануны оныттыру түгелмени? Ләкин ничек итеп?..

Карт уянган, ахры — йөткергәне ишетелде. Нидер әйткәнме, Хөснижиһан:

— И, эти, оят инде, билләһи! Рәхмәт юк тагын, — дия-дия, кызарып өйалдыннан чыкты.

— Ә минем ниемә хәҗәт синең кызгануың! Мохтаҗ түгел, шөкер!

— Мохтаҗ чакта гына соң була ул.

— Кирәкми, синең хәләл көчкә калмаган! Син үзеңне кайгырт.

Шириаздан карт та күренде. Күзе кысык, яз чирәме күк тырпайган ак чәченә мамык кунып беткән — нәкъ тузганак.

— У-у, син мондамыни әле? Һы, чат сазлык сөлеге икәнсең! — диде ул Бәхтияргә.

— Хәзер китәм.

— Кууым түгел, түземлегеңә ис китүем.

Карт абзарга таба атлады.

Хөснижиһан баскычтагы комганнан су агызып кулын юды да алъяпкычына сөртте.

— Килеп булышкан ярамый. Янәсе, үзем... Мин йөргән булам тагын үз өемдә эш калдырып.

— Кунак йортына барасыңмы, Хөснижиһан апа?

— Юк инде. Тегеләр китте. Кайткач, үзләре карар. Иләшкәннәрдер.

— Алай булгач ни... Минем кичәгенәк анда... бер-бер нәрсә төшеп калмагандыр ич?

— Нинди бер-бер нәрсә?

— Кызыл тышлы кенәгә бер.

— Ә-ә! Тапкан идем дә бер әйбер иртәнчек көтү куганда.
Бәхтияр сиздерми генә Хөснижиһанның кулын кузәтә. Хатын кесәсендәге таныкнамәне капшап карамый булдыра алмады.
— Ала килмәссең микән?
— Килмәссеңме дип... ни, килеп ал соң, ашыгыч икән.
— Түгел түгелен. Хәзер барсам ярармы?..
— Монда йомышың бетсә әгәренки. Бераздан, кайтышлый, яме? Минем әле барып киләсе җирем бар.
— Ярар, кайтышлый, Хөснижиһан... апа. Кайтышлый.

## Кыз баласы

Болгар дигән зур каланың
Урамнары бигрәк төз булган;
Бәхетле кызлар бик күп түгел,
Бармы икән меңнән бер уңган?

### 1

— Каян белдегез наратларның ярамаган җирдән киселгәнен?
— Шириязлан абзый әйтте.
— Ул әйтсә генә инде... Кистереп әйтә. Үзәккә үткәзеп.
Председатель баштарак Бәхтияр белән сөйләшеп торыр кебек түгел иде. Каядыр ашыга, машинасының ачык ишегенә кереп китәм-кереп китәм дип кенә тора:
— Кискәннәр икән, ябыштырып булмастыр ич инде, — дип каядыр кузгалырга чамалаган иде.
Бәхтияр:
— Мин өлкә газетасыннан, — дигәч кенә, авыш галстугын рәтләп, чәчен сыйпап куйды.
— Ник моңарчы әйтмәдегез аны?
— Эшегездән бүлдерәсем килмәде,— диде Бәхтияр, акланган-дай итеп.
— Кем кисте икән аларны?
— Тракторчысы Мәрданша атлы.
— Бәрдемша икән... — диде председатель Кәбир.
— Кем-кем? Бәрдем...
— ...ша. Холкы бәрдем-суктымлырак. Мәсьәлә анда түгел... Фольклор җыеламы?
«Фольклор җыеламы?» Председательнең бу хакта кызыксыну сүзләре Бәхтияргә кипкән елга комы кыштырдавы булып кына ишетелде. Болай гына соравы. Ышанмый.
— Барып килик әле шул җиргә, Кәбир абый, шул наратлар үскән җиргә.
— Бәлки, соңрак барырбыз?
— Ашыгыч түгел.
— Сез озаккамы соң, нинди мәсьәлә белән?
— Күзәтим әле, күңел нигә тукталыр.
— Шәп инде ул, күңел кушканны гына эшләп йөрү...
— Шәп дип... эш-эш инде, Кәбир абый.
Председатель, машинасын кабызгач, янә дәште:
— Мин тиз...

Бәхтияр студентларга иярмәде. Миңлеханов та кыстамады. Һәм Бәхтияр: «Кичкә хәтле!» — дип ялгызы гына идарә ягына атлады.
Ул инде җыр эзенә төшүенә шикләнми. Студентлар да җыяр җыр чәчәкләрен, шиксез. Экспериментлары уңарга охшый болай. Казан тө-бендәге авыл булса да, билгесез җыр-такмаклары фольклорчылар киш-

тәсенә менеп бетмәгән бугай. Миңлеханов шулай юанып торды кичә. Дөрестән дә: кайсыбер диңгез гәрәбәле, бүтәне мәрҗәнле. Һәр авыл үзе бер җыр диңгезе, күрәсең. Ләкин һәр диңгез дә үз гәрәбәсен яр кырыена кагып чыгармый. Энҗе теләгәннәргә су төбенә чумарга кирәк.

Студентлар арасында Бәхтияр шул җыр диңгезенә иң тирән чумганы булмас микән? Әлеге «кыз баласы» дигән нәрсә... Хөснижиһанның колакка ят яңгыраган сүзенең төбе хикмәтле. Берәүнең кыз килеш тапкан баласы, кеше теленә гайбәт сазы булып түгел, киресенчә, матур бер сүз булып кергән — «кыз баласы»... Көтмәгән сүз. Аның ишеткәне юк. Һәрхәлдә.

Кыз баласы. Бәхтияр белә инде: алты гасыр элеккеге бер дастанның шушы авылда бер күңелдә сакланган ике генә сүзе бу. Башка җирдә «җилдән туган» диләр. Монда: «кыз баласы!»

Хөснижиһан диңгез дулкыны кебек киң итеп бер уфтанган иде кичә: «Кашан каласы — кызлар баласы». Әйтерсең лә җансыз тарихның яшел болынында хәтер байрагы әләр манара тергезде Бәхтияр — Кашан каласы.

Һәм менә ул председательне көтә...

Озак көттермәде.

— Вакланмыйк мәллә соң? — диде председатель. — Бәлки, әнә, комбайнчы Ядегәрне язаргадыр. Пәһлевандай эшли.

— Эшлидер дә... Ял итәренә агач күләгәсе калганмы соң?

— Күләгә эзләр чакмы, күләгә!.. Иген диңгезе бит! Һәр минуты исәптә.

— Диңгездә утрау булу да кирәктер. Хәзер инде эшләү минуты гына түгел, ял итү минуты да кадерле.

— Кадерлибез дә! Әнә культура сарае! Авылың белән җыел — колачы иркен.

— Җир кешесенең чын ялы җир матурлыгы да түгел микән? Сәхнәдә авыз җырлый, табигатьтә — җан. Ялгыз агачлар киселә икән, җан еларга тиеш, — диде Бәхтияр.

— Хак сүз. Ярар, кузгалдык,— диде колхоз башлыгы.

Машинада бөркү. Тән су сорый.

— Инешегез авылның бер очыннан икенче очына. Буагыз — уртада.

— Өстә көтүлеккә су суыргыч машина бар безнең. Астан ук бусаң, су менеп җитми. Шуңа күрә урта бер җирдән буарга туры килә.

— Анысы шулай инде. Производство — буа гына түгел. Тегеннән буылса, моннан акмый... Утын китертү дә: ерактан китерелсә, трактор бүленә, шулай ич?

— Ул агачларны мин кушып кистерткән димисеңдер бит, иптәш Шәйморатов?

— Кисүчеләре вакытында кисәтелми икән...

— Кисәтелгән, энем, борчылма. Без булмасак, мелиораторлар күптән төбе-тамыры белән йолкып аткан булыр иде инде. Әнә кара, күрәсеңме иген арасында берәр куак я агач? — Председатель уфылдап куйды. Капрон эшләпәсен арткы утыргычка атты. Бәхтияр аның колагыннан өстәрәк кенә пеләш төш шәйләде. Чәче кара председательнең, дулкын-дулкын. Ә бу җире — дулкын какканда батып-калкып торган кебек күренгән дәү таш: сулык-сулык килеп тора — яра эзе. «Ике йөрәкле», дигән уй килде. (Күкрәгендәге йөрәге дә, шушы ярасы да председательнең җан җире бит.)

Бәхтияр:

— Авыртамы? — димичә түзә алмады.

Күрәсең, Бәхтияр ишеләрең кызыксынуы председатель өчен яңалык түгел. Туры әйтте:

— Синең кебекләр артыграк каныкса — авырта. Ә берәүләр күз алдында золымлык кылса — сызлый ук. — Бәхтияргә алда, нәкъ юл турысында эленеп торган кояшның кайнарлыгы, шарлама булып, менә-менә бодай басуына ургылып төшәр күк тоелды. — Син нәрсә, иптәш корреспондент, өчәр-дүртәр йөз еллык наратларны кисү мине сызландырмый дип беләсенме? Бәлки картраклардыр да әле. Кинәнеп Казаннан туристлар ташырлык. Күрсеннәр әйдә!

Бәхтиярне машина түгел, бер хис дулкыны тирбәтә.

Горурлыкмы? Тик кем өчен? Үзе өченме, председатель өченме?

— Сызлый, энекәш... Йөрәк тамыры өстендә бит ул җәрәхәт. Ә йөрәк — җир өстендә инде безнен. Шулай булгач, тән ярасы җир ярасына сизгер ул.

— Гафу итәсез... — диде Бәхтияр. Нигәдер, үз авылында яшәгән зәгыйфь акыллы Миңлехарисны хәтерләде. Шуны бер кыерсыткан иде малай чакта. Аннан, җәлләп, атасыннан калган кечкенә шөшлене чыгарып биргән иде. Председательдән гафу соравы, шул шөшлене биргәндәге кебек, күңеленнән юшкын юды.

— Нәрсә — «гафу»... Эш тыгыз... Тик бер белер идем кем кискәнне. Табар идем! Шул җәрәхәт сызлавына дару итеп. Тапкан идем бер. Бу тирәдәге бердәнбер калган ләкләк оя корган наратны кисеп сата берәү. Торф отряды шоферы, игелексез. Үз кулын кискере нәрсә. Караңгыда ләкләкне күрмәгән, янәсе. Калтырый ук башлыйсың кайбер ябалак намуслылар эшен күреп.

— Дөрес әйтәсез.

— Начарлык турында башкача ничек әйтәсең?

Машина, кисәктән, югарыга таба юл алды. Ләкин үр күтәрелә барган саен, юл, дуга ясап, түбәнгә авыша башлаган сыман тоела. Шулай итеп, юл үзе гел өскә күтәрелсә дә, машина гел бер биеклектән бара шикелле. Үр маңгаенда нарат башлары күренә. Әмма машина тирә-юньгә караганда югарырак үрләсә дә, арыш кырына сирәк-мирәк сибелгән наратлар, артмый-кимеми генә, алга барган шәпкә әйләнәләр генә. Ярым түгәрәк үр, биек булмаса да, әллә кайсы төшләр дә учтагыдай күренеп тора.

Кашка менеп җитәбез дигәндә генә, машинага ун метр чамасы киңлектәге бер биеклекне үтәргә туры килде. «Өйгә керер алдыннан бусагa аша үткәндәге кебегрәк»,— дип уйлап куйды Бәхтияр. Шушы «бусага» үр сыртын мичкә кыршавы булып иңләп торкан, ул булмаса, түгәрәк үр, ком таучыгыдай басылып, ишелеп төшәр иде сыман.

— Кашан тавы бу, — дип, председатель Бәхтиярнең күзәтеп баруына аңлатма биргәндәй итте. — Бу сикәлтәсе шул тауны саклаган балчык вал булган.

Алда үр итәген кисеп үткән ерым күренде. Шунда житәр алдыннан, ерымны уң якта калдырып, юл яссы муентыкка килеп керде һәм кисәк каерылды да, инде сулда калдырып, тагын бер ерым башыннан узып китте. Ике ерым арасы йөз метрлар чамасы иде. Юл дугаланып арттa калды, күренмәс булды, ә үр кетмәгәндә артка чигенеп, машина яссы таштай тип-тигез мәйданга килеп чыкты. Шундый тәэсир: әйтерсен лә машина тупка әйләнгән дә җирдән сикереп өстәлгә килеп төшкән. Өстән караганда бу урын бәрхет түбәтәйгә охшаган икән. Әйе, бәрхет түбәтәйгә. Бәхтиярнең күз алдында, ирексездән, Шишкинның арыш кырындагы наратлары һәм шул наратлар арасына атлы юл төшерелгән рәсем яңарды. Өстә, бодай арасында, әле анда, әле монда наратлар үсеп утыра.

Үрдә бодай кыры. Өлгереп җиткән бугай инде.

— Менә, Кашан тавы дип атала инде бу төш, — диде Кәбир кабат-

лап. Машинасын туктатты, чөнки юл бодай басуына барып тәрәлеп, кинәт юкка чыккан иде.

— Тау ук түгел бугай ич, — диде Бәхтияр, артка таба борылып, ерак кырларны күзеннән кичерде.

— Ә син тегендә кара әнә, — диде председатель. — Кама!

Бәхтияр яр читенә үк йөгереп килде. Кискен җил исте дә аның сулышын бүлде һәм ул текә яр читеннән чигенергә мәҗбүр булды. Ярның биеклегенә сокланырга гына өлгерде ул. Тауның Камага караган кашыннан текә ак кыя башланган, сөзәгрәк урыннары гына үлән-куак белән капланган.

— Шәп урын бит, ә? — диде аның янәшәсенә сиздерми килеп баскан председатель.— Кала торган диләр монда... Кашан каласы.

— Шушындамыни инде ул? — дип сорады Бәхтияр.

— Син беләсеңмени? — дип гаҗәпләнде председатель.

— Искә кереп калган шунда, — диде Бәхтияр. — Университетта укып үткән идек. Шушы дип кем белгән?

Ул председательдә кызыксыну, шуңа өстәп горурлык хисе уятуына исәпләп ялгышмады.

— Моны университетта үтәләрмени?

— Шушындый тарихи җирнең наратларын кисәрлекме соң! — диде Бәхтияр. — Үзегез әйткәндәй, туристлар ташырлык монда. Тик Казаннан гына түгел... Анау наратларны кисәләр, алайса...

— Дөресен әйткәндә, миндә дә хата бар, — диде председатель. — Мин әнә теге ике корыганын аударырга әйткән идем, читтәгеләрен. Алар, күрәсең, авырыксынган корыны кисәргә... Ни бит, Ширияздан картны әйтәм, тынгысыз бик. Бир дә бир аңа, урак өсте, транспорт юк димә.

— Кашан каласы — кызлар баласы,— диде Бәхтияр йөзен председательгә таба борды да әле үкчәсенә, әле аяк очына басып чайкалып торды.

Кәбир сөйләвеннән кырт киселде. Күзен кысып наратларны күзәтте.

— Бусын да университетта укып үткән идегезме? — дип сорады ул. Тавышын әкренәйтте, кашлары өскә күтәрелде.

— Бусын башка төштә ишеткән идем, — диде Бәхтияр, уе белән үз янына Хөснижиһанны дәшеп алды да аның кичә сөйләгәннәрен хәтеренә йөгертте. «Кызлар баласы... моны Кәбир абый да белә, димәк».

## 2

Әллә риваять, әллә чын — Хөснижиһан кичә Бәхтияргә бер хикәят сөйләгән иде. Кызганыч та, шатлыклы да хикәят.

... Шәмсенурны төнлә, кичке бакча эскәмиясендә айга карап утырган җиреннән урладылар. Кулын каерып тоттылар да яулыгын йомарлап авызына тутырдылар. Аннан алма агачлары астыннан иелә-бөгелә инеш ягына күтәреп алып киттеләр, каерылган койма тактасы арасыннан чыккач, арбага күтәреп салдылар. Койма ярыкларыннан атасы ишан хәзрәтнең нараттан буратылган ике йортындагы утлар гына җемелдәп калды. Ишан хәзрәт сәдакага килгән һәр әйберне, көмеш тә мәрҗән, атлас та ефәк, кыйммәтле тире дә савыт-сабага әйләндереп, кызы Шәмсенурга бирнәгә салган иде — алар да калды.

Хәзрәт исенә килеп, бөтен йорт, бөтен авыл Шәмсенурны эзли купканда, төн уртасы житкән иде инде. Ә бу вакыт Шәмсенур, хәзрәтнең иң ихлас мөриденең чибәр төпчек улы өенә төшкән, ә Башкорт җиреннән мәхәллә эше белән килгән яшь бай мулла аларга таң алдыннан никах та укып өлгергән иде инде.

Беренче баласын табудан ук вафат булган Шәмсенур, гомере кисе-

лугә сәбәпче баласының да үз язмышын кабатлыйсын белсә, тырышыр-тырмашыр, бер-бер чарасын күрми калмас иде бәлки.

Язмыш дигәнең биш бармаклы кул түгел шул: ничек кирәксә шулай бөгеп, нәрсәгә кирәксә — шуңа ябышып булмый.

Төн күбәләкләре, яктылык эзләп, айга юл алыр иде алай булса, җирдәге утларга кунып, үз-үзләрен харап итмәсләр иде. Язмыштан узмыш, чыннан да, юк шул.

Шәмсенурның кызы Гөлҗиһан да, шул күбәләкләр сыман, ялгыш үз бәхете канатын көйдерә.

Колхозда җитен игүчеләр башлыгы иде.

Җитен йолкып сугылган, көлтәләре Мунчала күленә чылатылырга салган урыннан алынып, чәчеләрдә киптерелгән, инде иртәдән караңгыга хәтле талкырга да керешкәннәр иде.

Менә шунда, көзге бер кичне, гөнаһ шомлыгына каршы, ничектер үзе генә соңлаган җиреннән, аны бөтен авылга бер тракторчы Ишморатка урлаганнар. Урлаучыларның берсе Җангәрәй, икенчесе Шириязадан, Ширияздан — Ишморатның тугрылыклы җан дусты.

Чыланган җитен исе, талкынган сүс исеннән аерып, Гөлҗиһанны да арбага салганнар. Карышмаган ул, кычкырмаган, чәбәләнмәгән. Ишморат дип башына да килми, карышыр иде — үз күңеленең әүвәлгедән Җангәрәйдә булуы сукырайткан. Ялгышмас та иде. Җангәрәй аңа күз атып, сүз җиткереп торган егет. Мунчала күленең җитен чылатканнан каралган суы ник пышылдамаган Гөлҗиһанга Җангәрәйнең аның бүтәнгә алып китүен?

Пар ат тирләп чыкты. Авылны читләтеп, бакча башларыннан гына бу очтан аргы очка юырттылар.

«Тракторда эшләгәч, икмәк күп тиде Ишморатка, — ди Җангәрәй. — Туйны мулдан итмәкче».

«Балны да ун чиләк салдым ди».

«Ясый инде туйны! Исәбе зиһен чүпләп бетерәлмәслек».

Шириаздан Гөлҗиһанга ымлый:

«Районга дан җитен кызын ала кочакка».

«Җәл түгел. Үзе дә бит МТСта атаклысы».

Пар ат — тирләп чыга, арбаның кадак-шөрепләре нык кагылган, нык тартылган, арба төбенә салсаң, су торыр, күчәр дегете лыч лычкылдаган — тавышсыз җилдерәләр генә. Кыр буш, болыт юк, ай яңа калкып килгән чак.

Ярты юлны тын килгән җитен кызы Гөлҗиһан, егетләрнең ниятенә төшенгәч, Җангәрәйгә сүз әйтмәк булып, туктарга куша.

«Тр-р-р! Уңайсыз мәллә, чибәрем?» — ди Җангәрәй.

«Берәмтекләп җитен йолыкканга түзгән кыз арба катылыгына гына чыдамасмыни? Якты булса, күз яшьләремне күрер идең. Үзеңә генә әйтәсе сүзем бар, Җангәрәй!» — дип өзгәләнә Гөлҗиһан.

«Ишморатка калдыр сүзеңне, чибәрем. Төннәр озыная...»

«Ялынып сорыйм, тыңла мине!»

«Ялынып?... Шириаздан, ншетмә!»

Шириаздан, арбадан төшеп, читкәрәк киткәч, Гөлҗиһан Җангәрәйгә күңелен ача:

«Ялынып дип... Чаршау артындагы караватымнан сора, колагыңны куеп, йөрәгемне тыңла, Җангәрәй, Ишморатка барырга теләмим мин. Үз очыңа аптөш, үз ояңа!.. Үзебездә дә, күрше авылдан да егетләргә күпме кыз урлашканыңны беләм.. Үзең өчен дә берне урла әле бүген, егет булсаң! Үкенмәссең. Мин сине... яратып йөргән идем».

«Минеме?! Синме? Күптәннәнме?..»

«Былтыргыдан булса ни дә, кичәгедән ни... Менә хәзергедән булса да барыбер түгелмени синең ише егеткә!»

Шулай дигәч, сикереп кузгалган пар аттан Гөлҗиһанның сүс тузаны сеңгән яулыгы гына төшеп кала юлга. Ширияздан ни икәнен белештерми, арттан чапкан да була, чабата бавы чишелеп, шуңа абынып кала.

Шул калудан кала. Ишморатны әйт. Соң инде кыз урларга читләрне яллап җибәрәме егет кеше! Дуслыкның үз урыны бар, иптәш дип алтын ышандырырга мөмкин кешегә. Мәгәр вәгъдәләшмәгән кызны түгел.

Ишморатка ни кала? Ни булганын гарьлегеннән өй борынча сөйләп йөрсенмени? Ә Ширияздан? Кичтән дуамалланган башны иртән ташка орудан ни мәгънә?

Бер елдан соң, фин сугышына китәргә дип аркасына биштәр аскан җиреннән, Җангәрәй генә, әнкәсе карчыкны ялгыз калдырганына үкенеп: «Кайтмам, ахры, әни, көтмә син: берәүне рәнҗеттем, бөтен токымыбызга җитәр каргышы. Юлымда очраган чишмәгә кара төкерек төкердем бит, әй!» — дип, җитен исе белән дөнья тулган шул кич вакыйгасын сөйләп киткән ди. Ә авылны чыккан чакта Шириязданнарга сугылган һәм ак кәҗә бәрәне белән уйнап йөргән бер кызчыкның башыннан сыйпаган да: «Кем баласы икән син, ә, кем баласы?» — дия-дия күзен сөрткәләгән, имеш.

Үзе киткән, Хөснижиһан атлы шушы балага, чәчәк авыруының кеше битенә шадра уеп калдырганы кебек, кыз баласы дигән ым салып киткән. Кайтмый калгач, улы истәлеге итеп, әнкәсе өч дусның Гөлҗиһанны урлау тарихын ахирәте колагына пышылдаган. Бер төймәдән дисбе булмый. Ахирәтенең ахирәте юкмыни?..

Ишморатларга барып, Җангәрәй белән Гөлҗиһанның эзсез югалуына аптыраган Ширияздан кире китә Җангәрәйләргә. Алар өе — тегермән буасы буенда. Бер якта буа яры белән чикләнгән зират, бирерәк — алма бакчалары.

Җангәрәйләр тыкрыгында аңа сулык-сулык елаган Гөлҗиһан очрый.

«Чү! Адаштың мәллә монда?! Кайда Җангәрәй?»

«Җансыз Гәрәй... Сазлык бакасы... Ашадыгыз башымны, и хараплар иттегез!..»

«Син аңлатып сөйлә әле...»

Гөлҗиһанның әүвәл җырлап торган тавышы кипкән камыш сабагы кебек ватылып, таушалып чыга:

«Аңлатыр идем — дөнья кошларсыз хәзер минем өчен... Һәрнәрсәдә — чыланган җитен сасысы, җитен сасысы... Җитен итеп талкыдыгыз, җитен итеп...»

Гөлҗиһанның җитен сүсе булып тузгыган күңеле шул төнне тормыш дигән нәрсәнең авыр талкысы арасына салына. Җангәрәй талкысы да, Ширияздан талкысы.

... Ширияздан Гөлҗиһанны үзенә алып кайта. Җангәрәй мыскыл иткән җитен кызын.

— Шуннан менә — мин. Хөснижиһан дигән исем кушканнар. Кыз баласы, — дигән иде Хөснижиһан кичә.

Дөньяга канатсыз килгән кош бүтән кошлар канатын күреп торудан гына оча алмый. Бәбкә чакта канатсыз икәнен тоймаса да, күзе ачылгач, аннан ни яшерәсең?..

Хөснижиһанның канаты гына кем менә?!

Аның бер канаты булып Карелия сазлыгында Җангәрәй каерылып калган. Икенче канаты Шириязданга бөтен бу як Европаны айкап-иңләп, себереп-тазартып кайтырга көч биргән.

Кешенең канаты кем икәне белән кызыксыныр вакыт булганмы соң?

Ә бит теге чакның җитен исле бер төнендә өч егет «урларлык» кызның чибәрлеге нинди дан булмагандыр?..

Шуңа күрә бу тарих гайбәткә түгел, хәтта гыйбрәткә дә сөйләнми. Ул бөтен авылга бер җыр — кыз баласы...

Җангәрәйнең әнкәсе сугыш елларында орден алган Гөлҗиһанның йөзек кашын — Хөснижиһанын Җангәрәем куеп китте, дип сөйләнгән, имеш.

Хөснижиһан боларны кичә сөйләгән иде. Бәхтиярне кунак итәсе килеп, почмак яктан алып чыккан шәрабтән ярты стакан чамасы авыз иткәч, ояларыннан чәчәк балы җыярга очкан бал кортлары кебек, сүзләре берөзлексез безелдәп кенә торды. Шул сүзләре, кәрәзгә җыелган бал булып, Бәхтияр зиһененә җыелып калды.

Хөснижиһан көтмәгәндә:

— Ә менә мин бүген бәхетле әле, калганнары чукынып китсен! — дип әйтеп ташлады. Башын чайкап, күзен каплый төшкән чәч тотамын артка сирпеде. Кемгәдер каршы йөгергәндәгедәй, кулын җәеп җибәрде.— Улымнан телеграмма килеп төште бүген. Икенче бишлесен алган. Универси-тет-ка керә, — диде ул. — Керер. Шундый җирләргә кергәненә атасына куану гына насыйп булмаган. Аракыга сатты шул башын. Язмыш диген, — диде ул калтыранган тавыш белән.

Бәхтияр аның үзенә сәеррәк, таркаурак карап сөйләвенә игътибар итте. Ниндидер сырхаулы, күңеле боек кешеләр шулай сөйләшә. Яки бүтәннәрдән яшертен уе булган кешеләр. Бәхтияргә кинәт кенә монда, балаларын кече яктан йоклатып, үз моңыннан бушанып утырган ялгыз хатын янында түгел, әнкәсе янында утырадыр кебек булып китте. Ул Хөснижиһан йөзендә әнисе йөзе чалымын күргәндәй булды. Ул чалым нидә дисә — әнә шул күз карашында икән. Бәхетләре үткән гомерләрендә яки киләчәк хыялларында булган, ләкин менә бүгенге көнендә аннан мәхрүм кешеләр шундый карашлы.

Хөснижиһан шул карашы белән Бәхтияргә әнкәсе кебек якынга, кирәклегә әйләнде дә куйды! Кулын иягенә таянып сөйләнгән дә сөйләнгән хатын аның өчен тагын да матураеп китте. Ялгызлыкка дучар, үз бәхете булмаган шушы чибәр Хөснижиһан менә хәзер үк аңа ниндидер бәхет бирер кебек сәер бер хис биләде Бәхтиярне.

— Тагын ике генә сынавы калган улымның. Бәхетләре булып, керсен генә иде. Бүтәннәргә эләккән ата кырыслыгы, тәрбиясе тимәде шул аңа — йомшак үсте. Кыюлыгы җитәрме? Мин дә йомшак...

Хөснижиһан еламсырап сөйли. Аны юатыр берәр сүз булса икән! Ә ник юатырга? Бераз иркенрәк халат кигәнгә, озын, ак муены тагын да озынаебрак, аграк күренгән бу хатын кызганыч кебек. Ләкин Бәхтиярнең аны кызганасы килми. Кимсетү булыр кук. Ялгызы гына кырда шау чәчәктә утырган шомыртны бераздан чәчәкләре коела бит инде дип кызганырлыкмыни? Аңа иркәләнәсе, рәхәтлек өчен бер-ике тәлгәшен үзеңнеке генә итәсе килә...

Бәхтиярнең Хөснижиһанны уйлап киңәйгән күңеленә дә әллә нәрсәләр сыеп бетәр сыман. Һич югында, менә шушы — Хөснижиһанлы, йоклап яткан ике балалы, самаварлы, сөтле өйрәле, табак-савытлы, кашага-чаршаулы өй...

— Мин дә йомшак... Таптый-таптый, дөнья йомшартып бетергән.

— Улыңны әйтәм, керер... Хөснижиһан... керер. Бер бишле түгел бит, ике бишле... — Ул апа дип эндәшсә, әле генә уйлаган шомырт чәчәкләре салкын кар белән алышыныр сыман тоелды. — Ни, бу балаларың белән малаеңның арасы... артык күп түгелме соң?

— Аларның бары тик кечесе минеке. Олылары хәзерге премнекеләр лә... Балалары йөзен күрмәгере!

— Ә аналары? — диде Бәхтияр пышылдап.

— Аналары — мин... — Бәхтияр стенага эленгән чигү бизәген карап тора иде, капыл аңа борылды. — Аңламассың шул, наный. Аналары вафат, минем апам иде. Апамның ире булганга, җәлләп, шушы балаларына... балаларыма ана булыйм дип, бик гозерләгәчтен... Ә ул, бәрәңге йөрәк!.. И-и, наный, начар уйлама тагын, кай төшемне шул Маһирәгә

алыштырды икән — шуны әйтә алмассыңмы, ичмаса?.. Белмәссең, белмәссең, наный, үзем дә белмим, шуңа җавап тапсам, кертер идем өемә, гаебем булса төзәтер идем, ышаныр идем антларына. Тәүбәгә килгән бугай. Инде күңелем төбе дә тишек, кем нәрсә белән тутыра алыр икән?.. Гүрләргә дә сыймаслык дәү иде бит минем күңел, и-и-и...

Кайда ишеткәне бар иде Бәхтиярнең мондый сүзләрне, кемнән? Ә-ә, әнкәсеннән бит! Ул бит шулай урак белән арыш уруларын, сыер җигеп урманган утынга барганнарын, язгы суларны сагына. Сагынмас иде — һәрберсендә Бәхтиярләрнең атасы янәшә булган яшьлеге. Коелган яфракларда, аккан суларда, очкан кошларда...

Хәзер инде Хөснижиһанга апа дими чарасы юк.

— Хөснижиһан апа, әңгер-меңгер төште инде, теге минем таныкламаны бир дә, кузгалыйм.

— И наным, онытканмын бакчы! Хәзер, хәзер...

Аннан да, моннан да эзли башлады Хөснижиһан. Ашыга-ашыга, ләкин тын гына, басынкы гына. Мәчесенә сөт тә салып алды. Бушаган шешәне каядыр яшерергә өлгерде. Бәхтияргә нигәдер Хөснижиһанның шәүләсе юктыр булып тоелды.

— Халат кесәңдә кенәгә, Хөснижиһан апа.

— Хәтер чуалмый иде алай, Бәхтияр энем. Әллә генә нишләдем шунда! Кичә сине ялгыш кыйнап...

— Хәтерне юк-бар белән чуплэмик инде. Кичә кыйналган, бүген сыйланган — нәрсә аны. Рәхмәт!

— Кузгаласың дамыни?

## 3

— Нишлибез инде хәзер. Бер кискән агач кире ябышмый, — диде председатель Кәбир.

Тын иде. Иген кырындагы вак-төяк кош аваз сала. Һава, чикерткә тавышы сыман, тынлыктан зыңлап тора.

Трактор эзе белән барып, яңа киселгән нарат төпләрен таптылар. Сусыл йомычкалар исе өлгереп килгән бодай, җир, су исләрен күмеп киткән. Йомычкалардан мул сагыз саркып чыккан — гәрәбәгә әйләнгән күз яшьләре. Сагыз тамчылары гүя тере. Эчендә ниндидер асылташ катып калган да, башны әз генә авыштырсаң да, шул таш әле җете яшел, әле җете сары, әле җете кызыл, әле ал нур сирпи.

— Дөнья кешедән, агачтан, җәнлек-җанвардан, су белән һавадан тора дибез бит. Әнә, Кашан туфрагы ишетсен: шәрә ич бу яклар хәзер. Безнең токымнар, шушында ук басып, сукмәсләрме безне?.. — диде Бәхтияр.

— Ул хәтлесен кем белгән? Без ул эшне калдырмыйк әле оныкларга. Безне гайбәт итеп сөйләрлек булмасын, ә? — Председатель көлеп җибәрде. Көлеп кенә түгел, биеп тә җибәрде шикелле: бөтен төше калтырый, бизгәк тота диярсең. — Без әрләмибез ич, анау калку... күрәсеңме, бодай арасындагы буш җирне... Әнә шул калку урындагы кабер ташы астында яткан гүр иясен...— Аннары ул җитдиләнде.— Иптәшләр суды жыярбыз. Сабак булыр. Бүген үк, Бәхтияр иптәш... Мин бит корыганнарын кисегез дип җибәргән идем аларны. Тыңламаганнар, — дип кабатлады.— Баксаң, ул агачларның берсенә тагын ләкләк оя корган икән. Әнә! — дип күрсәтте.— Ел саен килә ул безгә, бичара.

Кояшка каршы иде, Бәхтияр нарат очындагы дәү ояны авырлык белән генә шәйләде.

Мотор тавышы ишетелде. Председатель машинасы янына, кинәт калкып, көпчәкле трактор килеп туктады да тынды.

— Кем булыр бу? — диде председатель.

— Шириздан абзыйларга утын китергән трактор. Номеры шул.
— Шул,— дип раслады Кәбир.— Бәрдемша... Гафу итәсең, Мәрданша.
Тракторны кабыздылар. Ул машинаны әйләнеп кире борылмакчы иде, Кәбир туктап торырга кушып кул изәде.
— Исәннәрме? — диде җиргә сикереп төшкән Мәрданша. Күн итектән. — Безнең, Кәбир абый, сезнең йомышны үтәп йөрү иде. — Ул тракторда калган кешегә ишарәләде. Бәхтияргә күз атты.
— Мин оныткан да инде.
— Ике нарат дип кичә...
— Ул бит кичә. Бүген — бүген.
— Кичә өлгерелмәгән иде безнең. Ашлык ташудаек. Өстә калмасын инде дип килгән җирдән. — Ул, башын янтайта төшеп һәм бер күзен йомып, кояш ягында торган Бәхтияргә сынагандай карап тора.
— «Өлгерелмәгән»!.. Ә минем сүзне икеләтә арттырып үтәргә җыенасыз икән.
Мәрданша сизмәстән:
— Һәр вакыттагыча! — дип ычкындырды.
— «Һәр вакыттагы»ракка киткән шул, энекәш... Намус дигәнегезгә көч килә башлаган. Кичә бер булгансыз лабаса инде!
Мәрданша аңлады:
— Үзебез өчен түгел бит, Кәбир абый. Карт-корыга.
— Юк, үзебез өчен. Менә шушы кырны игүчеләр өчен ул наратлар, энем.
— Безгә нәрсә — кушылгач. Эшлисең, эшлисең...
— Эш түгел сезнең эш, Мәрданша. Этнең мәче кууы бу эш! Гел шул эчү артыннан... Бүген дә, корыганнарын запаска калдырып, яшелләрен кисәсе идегезме?
— Бүген корыганнарын. — Мәрданша борынын тартып куя, кепкасын маңгаена шудырып, башын кашый.
— Сатарга исәпләп инде, ә?.. Менә нәрсә... Хәзер кая кушылган, шунда эшлисез, кич белән бүтәнчә сөйләшербез.
— Өз дә кис инде аны, Кәбир абый, кич сөт илтәсе миңа. Ара булмас.
— Сиңа тереләмәгән. Илтүче табылыр.
— Табылса, әзләгез, алайса! Миңа нәрсә — кул-аяк тышауланмаган. Әнә генә Чаллы! Киттем-бардым булыр!
— Эх, энекәш! Ә карт атаң-әнкәңне кемгә калдырам дисең? Алар корыган нарат кына түгел шул! Сатып булмый... вөҗдан шикелле.
— Нигә кирәк алар?
— Кем? Атаң-әнкәңме?
— Наратлар дим. Бет кән ич инде барыбер.
— Соңгы телем ипи кадерле, Мәрданша. Син менә бакча артыгыздагы талларны кисәргә ябышып кара! Атаң, Биккол карт, әүвәл кулын кистерергә бирә сиңа.
— Безнең вакыт юк бит, Кәбир абый, синең вәгазеңне тыңлап торырга. Комбайннар чыга хәзер. — Мәрданша тракторының ачык ишеге тоткасына барып ябышты да эчкә сузылды.
— Вәгазь дигәнең — бабаң васыяте ул.
Трактор морҗасыннан кара төтен ургып чыкты. Тизлек күчергече кытырдады. Председатель, авыр гәүдәсен алпан-тилпән китереп, урыныннан кузгалган зәңгәр трактор каршысына чыгып басты да, кулын җәйде:
— Тукта! Кая?
— Ашлык ташырга, кая! Ашлык! — дип кычкырды Мәрданша. Бәхтияргә ул шулай итеп тракторын председательгә өстерә шикелле тоелды.

— Туктат дим, әй!

Трактор, теше ыржайган җанвар булып, Кәбиргә якынлашты, тормозы белән ыңгырашты да, аягын терәп туктаган ат кебек, туктап калды.

— Юк инде. Рас килгәнсез икән, буш киту юк. Тракторны алты чакрымга бушка куар идегез, ә? Кырык ат көчле тракторны. Кырык ат ич ул! Кырык!! Әби патша да унике генә атлы арбада йөргән. Сез инде үзегезгә-үзегез патша булып бетмәгез әледән. Кисәсез корыган агачның берсен. Галимә әбигә кертерсез. Карагыз аны, әнә теге, ләкләк оялаганын кисәсе түгел. Берсен генә. Кич белән иптәшләр судында үзем дә булам. Сорармын.

— Нинди суд тагын, Кәбир абый?

— Үз судың. Вөҗданың сукыр икән, иптәшләрең ачар күзеңне, Мәрданша!

— Ә төкергән без аңа! Бурлыкта тоттыгыз мәллә?! Юл бир, Кәбир абый!

— Ялгышма, Мәрданша! Әйткәнне тыңла син. Күрәләтә кеше ялгышуына юл бирмим мин. Ун ел инде председатель, хаталана күрмә коры нотык сөйли бу дип. Борыл!

Корыган нарат очыннан дәү бер кош күтәрелде.

— Япа-ялгыз, — диде председатель. Машинасына кергәндә бер генә мәлгә тукталып торды. Бармаклары дерелдәвеннән Бәхтияр аның дулкынлануын сизде.

Председательнең: — Әнә теге кабер ташы кебек ялгыз кош, — дип кабатлавы аны Ширияздан карт турында уйларга мәҗбүр итте.

Ул да япа-ялгыз гомер сөреп ята. Аның хәтере очына да, шушы корыган наратта оя тапкан ялгыз ләкләк булып, бу дөньяның югала барган бер җыры кунган булырга тиеш. Ничек кузгатырга ул җырны? Наратлар да мәңгелек түгел бит. Алар киселеп беткәч, ләкләкләр, торналар, бака челәннәре кая кунар? Ата-бабалар җыры кемнәрнең хәтер очына күчәр? Шул җырга нинди дер Мәрданшалар балта белән кизәнмәсме?

Кизәнмәс. Куллары корыр. Чөнки кешеләр хәтере — Җир кояшы. Кешеләр хәтере — киләчәкнең әнкәсе.

Борынгылар белән киләчәк арасында Кәбир абыйлар тору шәп.

Югыйсә, Билал ишеләр, бүгенгене киләчәкнең кабере итеп күрүчеләр дә бар ич, тере мәетләр.

Үткәннәргә таш атарлыкмы? Ул чагында киләчәкнең ашы нинди булыр?..

## Карлыгач сере

Карлыгачкай кара, муены ала,
Ник моңая икән бу бала?!

### I

— Ну, студин син диделәр. Үз башыңа ашыккансың, көлчә!

Фәгыйлә белән талгын гына биегән Бәхтияр янында Мәрданша шулай дип, зәһәр пышылдап, ышкылып узды. Мәрданша биергә чакырган кызын биленнән кысып тоткан. Кызы исә терсәкләрен аның киң күкрәгенә терәгән.

— Нәрсә ди ул?

Фәгыйләнең болай да зур күзе нидер сораганда яки гаҗәпләнгәндә тагын да матуррак ачыла. Хәтта ачудан зәһәрләнеп кысылган чагында

да матур аның күзе. Муенына ураган куе кәрән ефәк яулыгы күзен тагын да дәү итеп күрсәтә.

Үткән атнада яуган яңгырлардан гөмбә күп булырга тиеш дип, студентлар урманга барып кайткан иде. Юллары унды. Шуларны чистартып ятканда матур, тыгыз тәнле, кечкенә бер гөмбәне тоткан Фәгыйлә:

— Кара, кара, үзе кеп-кечкенә булса да, кортларга өлгергән! — диде.

Билал аның әйткәнен кискен генә:

— Кайбер кызлар да шулай: үзләре ябь-яшь... — дип эләп алды.

— Шуннан? — диде Фәгыйлә.

— Шуннан... син әйткән гөмбә күк инде, бактың исә...

— Бактың исә? — диде Фәгыйлә. Кинәт кызарып китте. Өстәл аркылы үрелеп, кечкенә генә кулы белән Билалның яңагына сугып җибәрде. Билалның таза бите тартылып, көчле ияге дерелдәп куйды. — Мин сиңа бу хакта ымларлык бирәр сәбәп биргәнме әллә?

— Җәмәгать, җәмәгать, җәмәгать! Шаштыгыз мәллә шул кадәре? Әхлаксызлык бит ул сугышу! Кызлар егетләр белән... И-и-и, замана! — Миңлеханов Билалга якын ук килде дә текәлеп-текәлеп аның битен тикшереп чыкты. — Җавап бир аннары сезнең өчен...

Билал йодрык белән алдындагы гөмбә өеменә китереп сукты.

— Менә шул, бактың исә. Каракның бүреге яна, күрәсең,— диде ул.

— Кемнең яңагы яна әле анда?! — дип көлде кызларның берсе.

Хәмит Фәгыйләгә бәйләнде:

— Син нәрсә? Тик торганда. Сиңа әйтүе мәллә?!

— Кем әйтә әле миңа дип? Кызлар турында әйтә. Безнең турыда. Димәк, миңа да!

Юк, Бәхтияр Билал белән Фәгыйлә арасындагы бәрелешнең тикмәгә түгеллеген сизенә. Тышкы хәрәкәт — күңел көзгесе. Сүз әрләше — эчке ызгыш, Фәгыйлә белән Билал арасындагы соңгы җепнең өзелүедер бу.

Матур иде Фәгыйләнең шул чакта күзе. Нәфрәт белән зәһәрләнүнең дә матур чагы бар икән...

Мәрданша тагын аларга якынлашты.

— Шулай итеп, председатель белән морадыгызга ирештегез тәки, ә? Ул ун тәңкә ыштрафны чәйним, чәйним, чәйним дә битегезгә төкерәм мин!

— Ник бәйләнә ул? — диде Фәгыйлә.

— Шириздан абзыйга без турашкан агачны тиешсез җирдән кисеп алып кайткан ул. Кашан тавыннан.

— Нинди Кашан соң ул һаман?! Әле алма, әле тау.

— Кала торган ул тауда. Кашан каласы. Сөйләсәң, озын. Ләкин кызык. Үтмәдегез мәллә?

— Кем хәтерләгән инде бөтенесен?

— Үз халкы тарихын белмәгән кеше — Ватансыз кеше.

— Бер фактны белмәү — халык тарихын белмәү дигән сүз түгел бит әле.

— Мин гомумән әйтәм.

Баянчы үйнавыннан туктап, биючеләр кырыйга елышкач та шул турыда сөйләштеләр. Фәгыйләнең кәефе шәп, күп елмая. Бәхтиярнең күзенә туры карап рәхәтләнеп сөйләшә. Биегәндә гел Бәхтияр иркендә, карышмый.

— Аксак Тимер бөек Болгар каласын алган чагында Габдулла хан хатыннары һәм берничә баласы белән хөкем палатасына кереп кача, — дип сөйли Бәхтияр әллә кайчан бер китаптан укыганын. — Аксак Тимер ул бинаны бүрәнәләр белән уратып алдырган да ут төрттерткән. Хан

үзе дә, янындагы кешеләр дә янып үлгән. Үтә матурлыгы өчен Болгарда хур кызы дип даны чыккан, акыллы, киң күңеллелеге белән изге саналган кызы гына исән калган. Кызны ут алмаган. Тимер сугышчылары аны ак киемдә утырган килеш әлеге йортның түбәсеннән табып алганнар. Могҗизага исе киткән Тимер, аны тагын бер агай-энесе белән Сәмәркандка алып киткән.

Ләкин, Аксак Тимер үлгәч, ул кыз белән малай әсирлектән качып котылган. Башта алар Кашанда куыш тапкан, аннары, Габдулла ханның котылып калган һәм Казан шәһәренә нигез салган тагын ике улы — Алтынбәк белән Галимбәк дигән туганнары янына күчеп киткән...

Утта янмас хан кызы турындагы риваятьне Фәгыйлә йотылып тыңлый.

— Каян беләсең боларны? — дип сорый ул. Тагын бию башлана, Бәхтияр аның беләгенә кагылыр-кагылмас кына:

— Биибезме? — ди.

Фәгыйлә бөтен хәрәкәте белән Бәхтияр иркендә. Аның якынлыгыннан Бәхтиярнең аңы томаланып-томаланып ала. Мөгаен, Кант белән Лаплас әйткәнчә, дөнья томаннан барлыкка килгәндер. Менә Бәхтияр дә — бүтән дөньяда. Ул дөньяның йолдызлары — Фәгыйлә күзе, кояшы — Фәгыйлә елмаюы.

Шунысы бар ләкин: боларның һәммәсе Бәхтияр дөньясыннан хәтәр ерак, чиксезлектә, бүтән — чит вакыт эчендә һәм моның белән килешү, бәрәңгеләр алынып беткән көзге көн кебек, сагышка бирелдерә.

Ләкин ул сагыш Бәхтияргә Мәрданшаның, ике егет белән үзенә яшертен караш ташлый-ташлый, нидер сөйләп ятуын күреп торырга комачауламый. Серләшсеннәр соң! Ун тәнкәләрен чәйнәп, аның битенә төкерергә җыенуларыдыр. Мәрданшаның бу сүзләре ни аңлатканын белә Бәхтияр. Үзе дә авылда егет булып үскән кеше. Әмма бу куркыныч түгел. Авыл җирендә бу эшне кешелеклерәк эшлиләр. Куркыту итеп кенә. «Нахакка» кыерсытылган күңелләрен басар өчен генә...

Фәгыйлә белән ул бүтән дөньяда. Мөгаен, бүтән дөньядан караганда, җирдәге пышым-пышым явыз ният корулар тагын да кешелексезрәк булып күренәдер. Бүген моны Бәхтияр шулай кабул итә. Пышылдашсыннар соң. Бәхтияр бүген Фәгыйлә дөньясын саклап теләсә нинди көчкә каршы көрәшергә әзер.

— Кашан каласын, Шәһребану атлы бугай, хан кызы салган, дип сөйли риваятьләр. Күп шәһәрлекләр, ныгытмалар корып, ул атасына каршы сугышып йөргән. Ярамаган эш, әйеме, Фәгыйлә? — ди Бәхтияр.

— Ярамаган эш, — дип килешә Фәгыйлә.

— Шуңа күрә ул хан кызы салдырган һәр нәрсәгә кызлар баласы дигән яманат кушканнар. Кашан каласы — кызлар баласы — аңладыңмы?

— Юк.

— Атага каршы ачу тоткан кызның кала, ныгытмалар салуын... беләсеңме... законсыз эш күреп шулай атаганнар — кызлар баласы. Аңлашыламы? — ди Бәхтияр.

— Каян беләсең боларның һәммәсен? Һәм кем соң син? — диде Фәгыйлә, бию беткәч, культура йортыннан кунак йортына таба кайтышлый.

— Ә мин — Шәһребануның улы.

— Рәхим итегез, Шәһребану кыз баласы Бәхтияр Шәйморатов.— дип шаярта Фәгыйлә. — Таныш булыгыз.

2

— Әйдәгез соң, таныш булыйк... кем әле... Шаһирбану кыз баласы Бәхтияр Шәйморатов... («Мәрданша», дип уйлый Бәхтияр). Ә мине Бәр-

демша диләр. Бер бәрдем — ша! Бар иде, юк булды дигән сүз, ягъни мәсәлән.

Бәхтияр белән Фәгыйлә студентлардан бераз арткарак калганнар иде. Икәве генә. Студентлар ун, юк, инде унбиш адымнардыр алда, урам тутырып көлешә-көлешә кайта. Алар арасында Билал белән Хәмит кенә юк. Бәхтияр аларның үзләреннән арттарак калып килүләрен абайлап алган иде. Алар якынрак.

Ә Мәрданшаның нияте ачык.

— Ә сез кем? — дип, йөзе белән Фәгыйлә йөзенә орына язып сорый ул. — Танышырга рөхсәттер ич? Курыкмагыз, егетләр кулы.

«Кешедән дә матур нәрсә юк. Ә үзенең кеше икәнлеген онытып торган кешедән ямьсез нәрсә бармы икән?» дип уйлый Бәхтияр.

Мәрданша, Фәгыйләнең яулыгын тартып алып, үз муенына бәйләп куя:

— Истәлеккә. Төсең итеп сакламармын. Аб-бау, җаным, шаккатты. Карасана күзләрен, — дип көлде ул иптәшләренә Фәгыйлә ягына ишарәләп. Аннары Бәхтияргә таба борылды: — Шул хәтле дә гашыйк мәче булып карап тормасаң соң. Танымыйсыңмы әллә, студин?

— Танышыйк соң. Шикләнмә. Чиста. Бу кул белән әле бер генә карттан да сәдака алмаган, — диде Бәхтияр.

Шуннан соң ни булганын Бәхтияр ачык хәтерләми. Ул бары авызын ачып калган Мәрданшаның алдагы тешләренең тимер икәнен генә күреп калды. Фәгыйләнең яулыгын аннан алу омтылышы аны сукырайткан иде инде.

Ул борын яфракларының, һава җитмәгәндәге шикелле, ярсудан калтырана башлавын тоя. Багана башындагы кечкенә лампочка сипкән тонык яктылыкта моны беркем күрми күрүен. Ләкин ул үзе моның шулай икәнен яхшы белә. Дулкынланса, аның борын яфраклары һәм аягы кызышырга, калтырарга керешә. Бармаклары дерелди. Хәзер төнге күк йөзе, кошлар тавышы, дулкын кагуы, дуслары көлүе — һәммәсенең Мәрданша муенына күчкән яулыкны кире йолкып алу белән генә кире яуланачагын аңлый Бәхтияр.

— Бир яулыкны! — Аның бар нәфрәте киерелгән иреннәреннән ташып чыга.

Беренче булып аңа Мәрданша сукты:

— Мә соң! Ун тәңкәнең бер тәңкәсе,— диде ул сукканда.

— Икенчесе, — диде ул ияртеп килгән егетләрнең берсе. Артка чигенеп өлгергән Мәрданша Бәхтиярнең эченә кизәнде. Бәхтияр сыгылып килде, ләкин тураеп борылды да яндагы Мәрданшаның иягенә орды:

— Сдачасы. Сана, дөресме?

Фәгыйләнең кычкырганын ишетә Бәхтияр. Ләкин аның тавышына йөгереп килгән Билалның:

— Була да бетә моның чше ыгы-зыгы. Ә минем сугышып йөргән дип университеттан сөреләсем килми, — дигәнен хәтерләми. Ул шулай ук Хәмитнең, иң элек Мәрданшага каршы басар алдыннан, әйдә дип, Фәгыйләнең култыгына орынган Билалга сукканлыгын белмәгән иде. Ә менә егылган чакта кулына таш туры килеп, шуны эләктергәне һәм Мәрданша каршына туры басып:

— Бир яулыкны! — дип пышылдаганы исендә аның. Арттан сукмасыннар өчендер инде, койма ягына баскан Мәрданшаның Бәхтияр кизәнеп өлгергәнче качып котыла алмасын сизеп:

— Мәсәнә, бәхетсез псих, — дип, бөтен нәрсәне уенга борырга маташканы күз алдында тора.

Ә ул арада йөгерешеп килгән студентлар арасындагы Миңлехановның:

— И җир бит, тәрбиясез! Үз авылыгыз кызлары беткән мәллә? — дип

Мәрданшага бармак янап калганын иртәгесен көлеп Бәхтиярга Фәгыйлә сөйләде.

— Әнкәсенә барып әйтегез сез ул Мәрданшаны, Хәбир абый, почмакка бастырсын,— дип көлгән Фәгыйлә.— Кычыткан белән кайбер жирен чәбәкләсен, ә!

— Жыен әхлаксыз эш сезнең зат аркасында, Фәгыйлә Юлдашева.

— Почмакка бастырырсызмы, Хәбир абый?

— Теленә тилчә чыксын иде, сеңелем... Инде авыл малайларына да житештеңмени? Билалың кайда, хәерсез?

— Башы ике бармагым арасында, калганы кайдадыр Билалымның, Хәбир абый жаным! Мин тилгән булып, ул чебеш булса да, мин аны ашамас идем.

— Ник тагын?

— Ите телгә йокмас, аның каравы, батып үләрлек итеп буяп бетерер иде ул.

— Затсыз син, Юлдашева. Кыз башың белән...

— Ә бит Билалың, Хәбир абый жаным, егет башы белән кызлар артына посты. Урыны шунда аның.

Бәхтияр боларны яхшы хәтерли. Ул Фәгыйләнең акылына сокланган иде.

Кинәт кенә ул туган иленда кыш үзганны сизеп, үз оясына кайтырга чыккан карлыгач серен тойды кебек. Менә шушы — чәч шарламасын озын муены өстеннән жилкәсенә таратып жибәргән, күрер күзгә эре сөякле, ләкин нечкә билле кыз мине адаштырмас шул сер мәллә соң? Аңа юнәлеш алып очыйм мәллә соң күңелем дәрьясы аша? Эч кенә авырта менә... Катырак сукканнардыр. Авыртсын сәнә! Канаты каерылган кош та очарга талпына. Ә Фәгыйлә... шундый якында ул.

— Кайсыгызның сәдәбе, мәгез,— ди Миңлеханов. Иелә дә жирдән бер сәдәп табып ала. Ничек күреп алгандыр. Багана башындагы ут сүрән, юкса.— Жиңегезнеке, ахрысы.— Табышын башта Хәмиткә суза, аның свитер кигәнен абайлагач, Бәхтияр жиңенә карап ала.

— Минеке түгел, рәхмәт, — ди Бәхтияр.

— Ташлагыз, Хәбир абый, — ди Фәгыйлә. — Бүтән жирдән төшкән төймә ул.

Студентлар белән бергә, бик уңайсызлап авырткан эчен тотып, Бәхтияр дә сулкылдый-сулкылдый көлде. Нишләрен белми аптырап калган Миңлеханов төймәне акча чөйгәндәгедәй чиртеп очырды да нәзегрәк тавышы белән аларга кушылды.

Кузгалып киттеләр.

— Юкка көләбез, — диде ул бераздан тыелгач.

— Еларгамыни? — диде Хәмит.

— Шушы кечкенә авылга да сыймый сугышасыз бит, хәерсезләр. Зуп-дур дөньяда ни булмас?

— Төймә булмас, — диде кайсыдыр.

— Булмас иде шул, әгәренки бер урамга сыеша алсагыз.

— Нишлисең соң... явызлык белән тар урамда да, киң дөньяда да сыеша алмагач! Ярый ла, аннан сәдәп кенә төшеп кала торган булса... Бухенвальдлар кала. Жиңеп кайткан әтиләрнең вакытсыз каберләре кала, — диде Бәхтияр.

«Троялар, Карфагеннар, Кашаннар кала»,— дип өстәде ул күңеленнән.

### 3

Эче авырта. Кунак йортына житәрәк, бер чокырга басып, аягын кайшалдырды. Шул аягына кабат басканда авыртуга түзмәде, янәшәсендә атлаган Фәгыйләнең иңбашына таянды. Фәгыйлә моны үзенчә аңлады: йөзен кисәк аңа борды, тукталып калды.

— Кайтыйк мәллә? — дип пышылдады.

— Йөрик әле, — диде Бәхтияр. Бераз сөйләшер өчен Фәгыйләгә нинди тәкъдим әйтерен белми бара иде. — Ялгыш басып, аяк кайшылды, ахрысы. Кан утырмасын.

— Кайтыйк, салкын суга тыгып торырсың.

— Әйтәм бит Билалга, — дип кычкырды Хәмит.

Фәгыйләнең ачуы чыкты:

— Бер ат солы боткасы ашаганда бүтән атларга карарга оялам дип әйткән, имеш, — диде ул.

— Аңламадым, — диде Бәхтияр.

— Кызларга тук нәрсә ул. Мин булсам ни аңа, бүтән булды ни. Ат уенда солы булган шикелле... уйлаганы бер аның... Аңа бар нәрсә — корт төшкән гөмбә...

Кунак йортына житәрәк, тар бер тыкрыкка борылдылар. Бакчалар ягыннан алма, чык исе аңкый.

Фәгыйләнең тавышы тын. Ул тавышны учка алып, бит белән шуңа назланып буладыр сыман. Назланып... Ә нигә назлап түгел? Ник әле без гел үзебезгә, үзебезгә... Секретарем минем. Сиңа минем наз тимәгән икән бит? Мин генә назланган. Бәлки синең мин теләмәгәндә дә минем белән бергә буласың килгәндер. Бу хакта уй төшмәгән — димәк, яратмаганмын. Ә Фәгыйлә...

Ә ул:

— Авыртамы? Ныграк таян миңа... авыртса, — ди. «Ныграк таян»...

Ничек бу кадәр дә тирән мәгънәле соң бу хатын-кыз күңеле? Аның бит назланасы килүе белән назлыйсы килүе бергә: «таян миңа»...

— Фәгыйлә...

— Әү, Бәхтияр?

— Тамыры шактый ук тартылган, ахрысы, монын.

— Таян дим ич.

— Көчең житәрме соң?

— Житәр. Көчле мин — спортчы. Ишкәк ишәбез.

Тыкрык башына житеп уздылар. Алма исе артта кала. Басу ягыннан салам, кибәк исе килә. «Барасы да барасы иде, барасы да барасы шулай, — дип уйлый Бәхтияр. — Бүген генәме, әллә гомер буенамы?»

— Бәхтияр, кем син?

— Телисеңме, икебез дә булам? Хәер, теләмәсәң дә булганмын инде, ахрысы.

— Ничек инде?..

— Миндә син дә бар кебек хәзер. Миннән сине алгач — мин калам. Менә мин кем.

Фәгыйлә гажәпсенеп караган күзен зур ачып аңа текәлә. Ләкин Бәхтияр ул күздә кайсыдыр бер йолдыз чаткысын гына күрә. Шушы чаткы нәкъ менә шушы бер мизгелдә Фәгыйлә күзендә чагылып китәр өчен күпме очты икән жиргә табан? дип уйлый ул.

— Бу төн — төш кебек, — диде Бәхтияр.

— Төш?.. Ә-ә! Ямьсез килеп чыкты шул. Сугышудан да ямьсез нәрсә юк.

— Анысы аның — өн.

— Мәгънәсез өн. Дөресен әйткәндә, мин синең аны жиңәчәгеңне шундук тоеп алдым.

— Ник?

— Белмим. Шулай теләгәнмендер.

— Теләгәнгә... Миңа аның шушысы төш — шулай теләвең... — Ул тотлыгып калды. Учы белән каты итеп маңгаен ышкып алды. — Бу йолдызлар, бу ай, бу...

— Бу алма, салам исе! — дип куәтләде Фәгыйлә аның сүзен. Сөрлегеп китккәндә тотып калдымыни!

— Сиңа рәхәтме монда?
— Авылдамы?
— Авылда... Монда... — Бәхтияр аска, тыныч кына сулап яткан авылга таба кул изәп күрсәтмәкче иде, ялгыш Фәгыйләнең иңбашына орынды. Ләкин шул орынудан ул аны якын һәм ачык итеп, Фәгыйлә йөзендәге һәр сызыгы, гәүдәсендәге һәр хәрәкәте белән тоеп калды. Әле генә салкынча тоелган төн һавасы буйлап җылы бер җил дулкыны йөгерде. Фәгыйләнең кайнар сулышы шулай бөтен басуга таралды мәллә? Бәхтиярнең тыны берара киселеп торды, аннары ул тирән итеп сулыш алды.
— Рәхәт монда, — дип пышылдады Фәгыйлә.
Аның тавышын, аның сулышын Бәхтияр каяндыр үз эченнән ишетә иде. Фәгыйлә аңа буй һәм караш җитмәслек ераклыктан, миллион еллар очкан нурларның теге ягыннан карап тора сыман.
— Чыннан да төш... — Бәхтияр, үз күңеленең читенә үк кереп посхан кыюлыгын туплап, каршысындагы иң ерак йолдызга табан кул сузды. — Йолдызларның иң якыны ничек аталганын беләсеңме? — дип сорады ул үз алдындагы аклыктан.
— Сириус,— дип пышылдады Фәгыйлә. Учын чак селкетеп, ул күкнең кайсыдыр билгесез бер ягына изәде. — Сириус.
— Юк. Иң якын йолдыз... синдер дип, мин беркайчан да әйтә алмас идем, әгәр бу дөньяда... Фәгыйлә атлы кыз булмаса.
Җаннарыннан чиксез ераклыкта аларның куллары очраштыы. Башта бармак битләре белән генә. Аннары җир тирәнлегенә омтылган имән тамырлары кебек, аларның бармаклары бармакка тоташты. Бәхтияр үзен Фәгыйләнең бер бармагы итеп кенә тойды. Аның учына сыеп бетәсе, шунда, Фәгыйләнең озын, көчле бармаклары арасында адашып каласы килде.
Фәгыйләгә Бәхтиярнең үзе турында уйлавын сизү чиксез рәхәт иде. Бүтән беркем турында түгел, үзе турында гына! Аның каршысындагы егет күңелендә тагын бер Фәгыйлә бар — хыял һәм теләк дөньясында яшәгән Фәгыйлә. Ул, шул кыз белән кушылырга теләгән төсле, аңа сыенарак төште. Аның ышанычына, шаулап торган йөрәгенә якынрак, түгәрәк, озаккарак...
— Мондый төш була димени, җуләр... җуләрем минем. Төш итеп әрәм итәрлекме соң моны? Сине, — диде ул тыела алмыйча.
Аңа хәзер Фәгыйлә ни сөйләсә дә барыбер. Сөйләсен генә, туктамасын. Пышылдасын. Пышылдавына чәче кыштырдавы кушылсын. Кушылсын — йолдыз нурлары белән сәлам исләре аларның бармаклары төсле бер-берсенә тамыр җәеп кушылсын.
Бәхтиярнең шушы уй белән сулкылдаган йөрәге тибешен, яшен чаткысы итеп, җир үз тирәнлегенә үткәрде. Кешеләрнең хыяллары, тормышлары алма исенә дә, салам кыштырдавына да, җир җылысына да сыя.
— Кызык, син нигәдер дәвәеп калдың, — диде Бәхтияр.
— Сигаретың бармы синең?
Һич көтелмәгән сораудан Бәхтиярнең аңы уянып китте. Бармаклары үзеннән-үзе бушады. Йозак ычкындымыни. Хәтта буыны да шыртлап куйды. Фәгыйләнең кулы мамык кына мәллә — авыртмаган. Шул кысуга соң. Ул, кабаланып, күнеккән хәрәкәт белән кесәсеннән сигарет чыгарды да Фәгыйләгә сузды. Шырпы ялкыны, дөнья караңгылыгыннан аерып, Фәгыйләнең йөзен яктыртты. Ә шул ут читендә — терекөмеш төсле күз яше. Эреде һәм, шәмдәй ак йөз буенча тәгәрәп төшкәч, ирен читендә туктап калды.
— Ник елыйсың, Фәгыйлә?
— Елыйм?.. Күзгә тәмәке төтене кергәндер.

— Әй, еласаң иде син бер, Фәгыйлә! Җырдагыча.
— Җырдагыча?
— Әйтимме?
— Я. — Гаҗәеп канатлары белән серле бер дөньяга очыртып алып китәрдәй могҗиза көтеп, ул, күзләрен зур ачып, Бәхтияргә текәлде.

Бәхтияр көйләмичә генә, шигырь сөйләгән сыман, түбәнгә, авылга карап:

Ике дә генәй түгел, ай, өч фонарь,
Фонарьлары саен шәм янар;
Ике каш арасында сиксән керфек —
Керфекләрен саен яшь тамар,—

дип пышылдады. Кайсыдыр бер тыкрыкта эт улап җибәрде. Тынлап торган да, түзә алмыйча, елап җибәргән диярсең. Бераздан туктады һәм ник, ичмаса, берәр чикерткә аваз салсын — зыңгылдап торган тынлык! Бары тик басу өстендә җәймә булып җәелгән яңа ашлык, чык, су исләре генә бу дөньяның сулаганын, җирнең, арып йоклаган анадай, иртә таңнан уяныргә әзерләнеп ятканын искәртеп тора сыман иде.

— Яшь тамар?
— Куркасыңмыни яшьтән?
— Нинди кызны куркытмыйдыр ул. Фр-р! — диде Фәгыйлә, иңбашын җыерып башын селкә-селкә.
— Шатлык яше булса дамы?
— Нәкъ шунысы кирәкмәс тә!
— Ник?
— Андые аның бер мизгеллек... Бер бөртек.
— Ташыганы язсын, алайса.
— Анысы нинди?
— Хәсрәтләре белән көйдерә торганы.
— Чү! — диде кыз, бармаклары белән аның авызын каплады.
— Әйе. Күз яшенең шундые татлы. Сөю, ярату дигән хәсрәт китергәне... Бусы гомергә бер генә. Иң бәхетлесе — шул.
— Кем соң син, кем? — Фәгыйлә һич көтмәгәндә, тартынусыз-нисез, Бәхтиярнең күкрәгенә капланды. — Каян алдың соң син бу ихласлыкны, Бәхтияр абый? — дип әллә көлә, әллә үкси иде ул. Бәхтияр, нишләргә белмичә, тораташтай тынсыз калды.
— Синнән, Фәгыйлә.— Кайдадыр, икенче бер томанлы дөньяда калган, үзен беренче мәртәбә атландырып йөрткән ат искә төште. Җирән иде ул байтал, нәкъ җиз самавар инде менә! Кояшка каршы чыгып карасаң, йоннары алтын нурлар булып сирпелә дә кала иде. Менә шул байталның озын ялы белән күзен сөртә-сөртә елаганы хәтерендә Бәхтиярнең. Җитәкләшеп йөргән күрше кызы, ул җыеп биргән чынаяк китекләрен алмыйча, селтәп торып тегермән суына ыргытканнан соң. Дегет исе, әнкәсе урган камышны арбага төяп кайткан атасының тирләгән кулмәге исе белән бала чагы. Бәхтияр, нәкъ шул вакыттагыча, Фәгыйләнең куе, каты чәченә битен яшерде. Монда аны бернинди рәнҗү табып алмас шикелле. Әгәр дә ул шушы кызга гомерен бирсә, ул аны, чынаяк китекләре итеп, вакыт тегермәненең заяга әйләнгән ике ташы арасына илтеп ташламас микән?
— Кечкенә чакта мин атланып йөргән атның ялы җилдә шулай кыштырдый иде, — диде ул, аның чәчен бармаклары белән аралый-аралый. — Әле кайчан гына, кайчан гына!

Фәгыйләнең дә үзен аның бала чагында янәшә күрәсе килде. Алар ниндидер бер ат каршысында. Аның кулында эре тоз сибелгән ипи. Юеш иреннәрен шапылдатып, ат шуңа үрелә. Сулышы кайнар, каты төкләре белән учны кытыклый... Бу — Бәхтияр икән. Иелеп, аның учын үбә.

Иреннәре чак кына кыймылдап тора. Кыз аларның вак дерелдәвен сизә. Мыегы кытыклауга түзмичә, кулы тартылып-тартылып китә. Кытыклану түгелдер бу, бәлки йөрәгенең шашып тибүедер, җанының сулкылдавыдыр. Ишетсен бу егет ул шашуны, тойсын ул сулкылдауны — Фәгыйлә, күзен йомып һәм башын артка ташлап, Бәхтияр аның — Фәгыйләнең кулын үбүенә бүтән карышмады.

— Кадерлем, — диде Бәхтияр үзе дә сизмәстән.

Дөнья чиксез тарайды, салкынайды кебек. Икесенә дә кысан булып китте. Бу кысанлыктан качарга, котылырга теләгәндәй, алар берберсенә елышты.

— Җырым буласың киләме, Фәгыйлә?

— Син көлмә, яме. Көлмә генә!

— Нидән, нидән?

— Ни әйтсәң дә, дөньядагы иң матур, иң мәгънәле җыр — кеше генә... Син генә, — дип өстәде Фәгыйлә бераздан кыюсыз, нечкә тавыш белән.— Тик көлмә минем сүзләремнән. Бәлки юкка сөйләмимдер.

— Юкка түгел... Юкка түгелдер.

Бу борынгы җирдә аткан яңа хис чәчәге аларныкы иде. Шунда, бакчалар артында, алма исе белән кичә урылган арыш исе уртасында икәве басып калдылар.

Тупыллар арасында өйләрнең соры шәүләләре төсмерләнә иде инде. Инештән бөдрә бу күтәрелә, һәм ул, суырып алгандай, көндез кетү йөргән уйсулыктагы томан диңгезенә агыла. Ул җирләр, чыннан да, диңгез култыгы булып күренә, үзенә әйдәп тора.

Башта Фәгыйлә, аннары Бәхтияр кунак йорты ягына, әнә шул томан диңгезенә таба атлап киттеләр. Чыклы үләндә эзләре генә каралып калды.

## Кое

Иске кое... Көч һәм газап белән
Ыңгыраша чыгыр,
Ычкыныр да чыгыр, өзелер күк
Үткән еллар — чылбыр...

С. Хәким.

### 1

Ширияздан картның урынга авуына бишенче көн инде.

Бәхтияр аны борчырга кыймый әле. Көтә. Түземлек кирәк. Студентлар киткәннән бирле ул картның үз өенә күчте. Хәснижиһан килеп йөри, хәл белешә.

Бәхтиярнең күз төбендәге шеше кайтты. Хәзер инде күзе ат күзе хәтле булып тоелмый. Әрем яфраклары пешекләп каплауның әзме-күпме сихәте тиде бугай: тамыры тартылган аягы сызламый. Хәснижиһанга рәхмәт. Югыйсә, аягы гына түгел, аяк астында җир сызлаган кебек иде башта.

Эчендәге авыртуы гына әз-мәз сизелә әле. Төн уртасында айга карап улаган эт сыман, бер көйгә җанны тырнап тора. Вакыт-вакыт ул эт бөтен чылбырлары белән тартылып ыргыла.

Авыртуын ул уй белән басарга тырыша. Гомумән, кирәкме-юкмы, кеше һәрчак уйлап йөрсә яхшы. Зиһеннең бар истәлеге янып бетеп, көле генә калса да, кеше уйларга тиеш. Уйлаудан туктаган кеше — һавага килеп кергән метеор: янып бетә. Кешегә исә үз омтылышына җит-

мичә янып бетү һич ярамый. Уй юк урында берни юк. Кешеләр, әйберләр, ахыр килеп, дөнья үзе. Һәр кеше — дөнья умырткасы. Бәхтияр уйсыз калсын ди. Ул чагында җан ачыйгысы белән камыш урган хатынның җырын Шириаздан карт күңелендәге тирән яшерелгән җырны кем бергә тоташтырыр? Өченче елгы һава торышын быелгы белән кем чагыштырыр? Ниндидер яхшылыкларны, кемнәрнеңдер кабахәтлеген кем хәтерендә тотар — әгәр кеше уйлар мәшәкатеннән туйса? Кеше шул уйда гына чын, шул уйда гына яши ләбаса? Хәтердә... Әйтик, Фәгыйлә...

Көн аеруча якты бүген, әссе. Югары урам бакчалары артындагы кукуруз басуы эчендә торып калган җил тегермәне шәүләсен рәшә тирбәтә. Инеш аръягындагы тугайда биш ат утлап йөри. Тугайны кыйгач кисеп, бер төркем малай инешнең түбән ягына балыкка бара. Берсе җәтмә тоткан, һәм ул Бәхтияргә малайларга ияргән дәү күбәләк булып тоелды.

Авылны ике тигез кисәккә бүлеп куйган юлдан машиналар уза. Баштарак, бу авылга килеп төшкәннең беренче көннәрендә, ул машиналарны үзләре туздырган тузан куып җитә алмый иде. Ул чагында тузаны да әз иде — шуңа булгандыр. Хәзер җирне яңадан тузан басты. Машина авырайды инде: район үзәге ягына ашлык ташыйлар. Машиналар акыл иңгән, үзләренең дөнья тоткасы икәнлеген тойган ирләр сымаграк салмакланды. Аларга каршы килгән бушлары сәлам биреп үткән яшь җилкенчәк кебек үтеп китә.

Бәхтияр дә кинәт кенә үзен әнә шул үзләре туздырган тузанны куып җиткән саллы машиналар хәлендә итеп тойды. Аның да әлек җилбәзәгрәк, җиңелрәк һәм үзен иреклерәк тоткан күңеленә олы бер йөк — сөю йөге килмәде микән? Ачык белми әле бу хакта, белми. Менә кайтыр Казанга, очратыр Фәгыйләне дә ачыклар.

## 2

Китәр алдыннан ул Бәхтиярне эзләп тапты. Җитди иде, сүзе салмак иде. Кичәге шаянлыгы күзендә генә чалымлана. Ләкин аңа җитдиләнү килешми бугай. Кояш нурында яктырып яткан шома ташны мүк басып киткән күк. Йөрсен шунда елмаеп: шаян булсын, җитез, ул шулай матур.

— Сау бул хәзергә, — диде Фәгыйлә. — Әле кайтып китмисеңмени?

— Бу күз беләнме?

— Шул күз белән. Мин сиңа кара күзлек бирәм менә, күренмәс.

— Эштә нишләрмен?

Фәгыйлә:

— Ә син эзләрсеңме мине? Килерсеңме? Бер атнадан, тагын ике авылны әйләнгәч, кайтабыз инде без, — дип сорады.

Фәгыйлә соравына туры җавап бирә алмады. Ашыкмый гына, озын міегын ирене өстенә сыпыра-сыпыра һәм тирә-юньне күзәтә-күзәтә:

— Мин дә кайтам ике-өч көннән, — диде Бәхтияр.

— Шалтыратсам ярар микән?

— Менә инде!.. Фәгыйлә...

— Әү?

— Табармын.

Табигать буш, сагышлы: электр чыбыгына ник бер карлыгач кунсын, су буенда ник бер керәшә уйнасын, күктә ник бер карга күренсен. Тугай өстендә тилгән генә әйләнә — йомран эзләведер.

Табигать киң, электр чыбыклары буш. Аның каравы, Бәхтияр шат — күңел җепләрендә, сәйләң булып, Фәгыйләгә әйтергә теләгән, ләкин әйтми калган, ләкин тәгаен әйтәсе сүзләре тезелешеп тора.

## 3

Студентлар күрше районның зур бер авылына китеп барды.

Ә Ширияздан абзый терелмәгән әле.

— Түз инде бер-ике көн, искә төшеп бетми бит каһәр жыр,— дип уфтанды ул.

Ничәнче көн инде Ширияздан карт коесыннан беркем су тукми. Дөрес икән: суы дүрт-биш сөям кадәр күтәрелгәч, тәме әллә нишләде. Чәй кайнатырга дигән суны Хөснижиһан чишмәдән китерә. Анысының суы тәмле: ниндидер баллы, йомшак.

Ә менә кичә Хөснижиһан килмәде. Кисмәктәге су бетте. Төбендә калганы жылымсаланган, тәмсез.

Ярар ла дип, чүмечен чумылдырып кое суын алды. Тәмен сынап карады. Шикләнердәй гаеп тапмады. Артык сусаганга күрәдер дип уйлады.

Түгел икән. Тагын эчте. Шул ук. Саз тәме килми. Газга куеп кайнатты. Картка чәй ясап бирде. Ул да аны-моны әйтмәде...

Тагын өч сөямнәр хәтле күтәрелгәч, коедагы су бүтән артмады. Суы әүвәлгедән күпкә чистарак. Күрәсең, көн саен түгеп, болгатып тормагангадыр.

Бәхтиярне башта гадәти, аннары саз тәме сеңгән суның инде менә яңадан тәмлеләнү сере уйландыра. Суның тәмсезләнүе мүкле, гөмбәле бура агачларының аста калуы белән аз-маз аңлатырлык үзе. Әмма яңадан тәмлеләнгән чагында да шундый ук бүрәнәләр күмелде ич? Ә су тәмле...

Бәхтияр дулкынлана ук башлады. Шушы сергә төшенсә, картка тәмсезләнү чигенә якынлашкан суны түгеп мәшәкатьләнәсе калмый.

«Тукта, тәмсезләнү чиге?» — дип сагайды ул. Тәмсезләнү чиге... Болай булгач, тәмләнү чиге дә булырга тиеш бит. Коеның сере — әнә шул ике чик арасындадыр.

Димәк, күтәрелгән чагында кое суы ике чик үтә.

Тәмсезләнү. Моңа гөмбәләр, мүк белән капланып беткән, почмаклары чери башлаган бура ярыкларыннан саркып, су жир дымы белән кушыла торгандыр. Дымлы, юеш катламдагы матдәләр, су күтәрелгәч, эридер, таркаладыр. Ул гына да түгел. Катлам чылангач, шунда жир асты суы тупланадыр. Кое казыганда, беренче су чыккан урынны узып, икенче су катламына төшеп житәргә тырышалар. Тирәндәге су йомшаграк була. Ширияздан картның коесы да шундыйдыр.

Ә бер тәмсезләнгән су, тагын күпмедер жыелгач, яңадан ничек тәмлеләнә икән соң? Торф катламы турысында гына тәмсез тормый микән ул? Күрәсең, Ширияздан карт аны әлеге торф катламына житкерми тоткан, шуннан узгач, тәме әүвәлгечә калуын белмәгән.

Бәхтияр шушы уйлары белән кое караңгылыгындагы күренмәс йозакны ача алуына горурланды. Ул гүя әле генә тирән чокырда ятып, дөньяны күрер рәхәтлектән мәхрүм торган да инде менә ул дөньяны биек манара башыннан күздән кичерү, танып-белү бәхетенә иреште. Бөтен нәрсә ачык. Иң кимендә менә шушы кое.

Ә бит тормыш — шул ук кое. Һәр тормышның чиста суны тәмсезләп тора торган катламы бар. Ул катламны яңа бура белән каплап куярга, күмдереп аста калдырырга кирәк. Чисталык, сафлык тәме биеккәрәк күтәрелсен!

Гасырларның сазлы катламнарыннан саркып чыккан халык жырлары — әнә шул су.

... Бер Мисыр пирамидасында үзенең төсен жуймаган чәчәк бәйләме табыла. «Бу чәчәкләр меңнәрчә елларның бер мизгел генә икәнлегенә шаһит» дип язганны укыганы бар иде Бәхтиярнең. Ширияздан карт күңелендәге дастан да шул чәчәк кебек. Менә сөйләтер, язып алыр да гасырларның мәңгелек хөкеменә тапшырыр....

# Соңгы җыру

Кемдә моң бар, кемдә хис бар —
Җыр серен шул аңласын.

## 1

Йокыдан яңа уянып килгән көннең битен таң белән яңгыр юып китте.

Аннары соң авыл өстеннән берара болытлар кабарып узды. Әйтерсең лә ниндидер булдыклы хатын мамык мендәрләрен кипсен дип күк гөмбәзенә элеп куйган да, тузгыта-тузгыта җил аларны читкә алып китеп бара.

Авыл өстеннән мендәрләр, түшәкләр, ястыклар оча. Сүрүләре актан гына.

Әллә соң мендәрләр акмыйча, зәңгәр даладагы кар көртләре ышыгында ак сарыклар көтүе утлап йөриме?

Нәрсә генә булып күренсәләр дә, алар бары тик кояш нурлары белән каймаланган ак болытлар гына. Җил аларны теләсә ничек укмаштыра, тарката, бөтенесен бергә куып китереп, яшен камчысы белән кыйный-кыйный елата да, юаш ак бәрәннәр итеп, бүтән илләргә куып китә. Ак болытлар мәңгелек хәрәкәттә. Кешелек хәтерендәге җырлар кебек.

Болытлар үзгәрә, мендәрләр... сарыкларга әйләнә. Ә җырлар — җилдән җитез елларның туры һәм тугры атлары алар: бөтен рухлары, теләсә кемне әсир итәрлек кыңгыраулары белән киләчәккә таба ыргылалар.

Бәхтияр капка төбендәге эскәмиягә, Шириязддан карт янәшәсенә утыра. Алар койманың тузган рәшәткәләрен алыштырдылар. Хәзер ял итүләре.

Болытларны күздән кичергәч, Бәхтияр карашын аргы яктагы кырларга күчерде. Каршы якта — үрле басу. Арышын суктыргач, саламын җыеп, инде сөрергә дә керешкәннәр. Гайрәтле «К-700» тракторы басуның калку маңгаена кара буразналар сыза.

Кеше маңгаен еллар да шундый ук тирән сырлар белән челтәрли. Шириязддан картныкы, мәсәлән. Инде аның йөзенә пәрәвездәй нечкә эзләргә дә урын калмаган. Озынча борынына хәтле челтәрләнеп беткән. Бар җирен үткән гомеренең сары сукасы сукалап ташлаган. Тик бит очларындагы бармак башы хәтле урын гына кагылгысыз калган. Алсуланып тора хәтта. Аннан өстәрәк — чем-кара күз — төбендә ак болытлар чагылган ике кое. Бүген алар Бәхтиярга буш булып күренә. Әле кичә генә алар төпсез мәгънә белән тулган шикелле иде. Инде — буш сыман. Ул кое төбендәге алтын мәгънәне хәтер чылбыры белән суырып чыгарып, тамчысын да түкмичә, Бәхтияр үз хәтеренә салып куйды...

Бәхтияр таң беленер-беленмәстә сусап уянып китте. Өйалдында йоклый иде. Тәрәзәгә күз салды. Караңгы, йолдызлар күренми. Өстендәге тунны ачуга, тәненә чирканчык энәләре чәнечте. Тун астына кире чумарга уйлады. Тик үз-үзен сынатасы килмәде. Кармаланып өйалды ишеген ачты, болдырга чыкты. Стенага эленгән чүмечне капшанып тапты да савыттан чумырып су алды. Су тәмле иде. Балланган диярсең. Аннан, сизелер-сизелмәс кенә итеп, кар исе килә кебек.

— Чык монда!..

Бу тавышка сискәнеп китте. Күрмәгән иде — болдыр ишеге ачык тора икән. Ул үзе дә, ник икәнен белмичә, аяк очларына гына басып, ишек янагына барып сөялде: гүя тавыш күбәләк тә шуны куркытасы килмәде. Ишегалды караңгы иде әле. Һәм башта бернәрсә дә шәйләмәгәнгә, буш күренде. Кайдадыр ниндидер тамчы тама. Бүтән тавыш юк.

«Чык монда!..»

«Кем булыр икән бу? — дип уйлады Бәхтияр.— Карт авырып ята ич».

Айны болытлар каплаган. Аларның ертык урыннарыннан тулып, җиз кебек кызарып ай күренгәндә, бөтен ишегалды калтырап торган зәңгәрсу шәүләләр белән тулды. Шушы минутта ук ул кое чыгыры астыннан Ширияздан картның соры-зәңгәр йөзен шәйләп алды. «Айдан төшкән мәллә бу? — дип уйлады ул.— Әллә коесыннан чыгып килә́ме?»

Уеннан шомлана калды. «Карт, чыннан да, авырып ята ич?!.»

Ул, өйалдына кире керергә дип борылырга теләсә дә, әле кабынып, әле сүнеп торган сары йөздән күзен ала алмыйча, сак кына итеп бер баскыч түбән төште. Карт, бөтенләй бөрешеп, кое артындагы бүкәнгә утырган, ахры. Чыгыр баганалары һәм чыгыр үзе аның йөзен рам белән чикләгән. «Улмы соң бу?» — дип уйлады ул һәм, түзә алмыйча, караңгылыкка:

— Нәрсәгә мин сиңа? — дип кычкырды.

«Әгәр дәшсә, бу — ул».

— Йокың бик басса, кыстамыйм, — диде карт.

— Ник анда утырасың, Ширияздан абзый?

— Җан сызлаганда күз йокламый, олан.

Тагын ай калтыранып алды. Аның яктысы бу юлы бар нәрсәне яңадан өн итте. Бәхтияр картны кызганып куйды. Аны юатасы, җыен мәгънәсез сүзләр сөйләшеп утырасы килде.

— Әллә берәр тол хатынны уятып килдең инде шунда? — дип шаяртты, аягына ниндидер галуш элеп, аның каршына килеп басты. Карт тәмәке тартып утыра иде.

— Үземнең тол җанны уяттылар әле монда... Кылыч тавышларын ишетәм.

Бәхтияр сагая калды.

Ай югалды. Кайдадыр читтә утлы канатлары белән аҗаган кагынып алды. Шуның бер чите Бәхтияр күңеленә тиеп китте: картның сүзе серле тоела иде. Ул тирән итеп иснәде дә, җылы төренеп, кое сәкесенә, картка кырын утырды. Йокысы килә иде.

— Син авырыйсың ич, Ширияздан агай, мә, тун бөркән.

— Аугa алып барган этка борынчак киертәләрмени?

— Нәрсә, нәрсә?

— Мин сиңа кызлар баласын сөйләргә җыенам... син миңа тун ябасың... Безгә тун — тиздән җир... Җиңелчәдән җөреп калырга кирәк...

Карт урынында кымшанып куйды. Бәхтияр хәзер генә аның иңенә чуклы калын шәл ябылганын күреп калды. Карт тирән итеп тәмәке суырды. Болытлар белән күмелгән ай кебек, тәмәке яктысыннан йөзе калтыранып куйды.

Бәхтияр йокы белән тартышканын аңлады һәм, куркыныч төштән арынырга теләгәндәй, күзен зур ачып картка каршы борылды.

— Мин бит язып бара алмыйм.

— Борчылма җукка. Үзем язып барам.

— Үзем? — Бәхтияр аптырады.

— Зиһенеңә язам... Кылычларның ничек чыңлаганын ишеткәнең бармы?

— Ә синең?

— Төркестанда минем ротаны бакыр җыланнар өере диләр ие.

— Кем?

— Басмачылар.

— Ә бакыр елан?

— Ни нәрсәме?.. Ул, олан, үкчәң белән бассаң, колагыңнан чыга торган җылан. Менә ник алар без килеп чыккан тирәдән үкчәләрен җиргә тигезмичә кача ые... Бусы аның әкият түгел... Безне сөйләргә... әкият итеп... җырак әле... Кызлар баласы әкиятеннән дә җырак.

— Бусы якынракмыни?
— Каршында.
Карт, тәмәкесен соңгы кат суырды да, калкынып, төпчеген ләгәнгә ыргытты.

2

— Алар бер кыз, ике ир туган булганнар, — диде карлыккан, тонык тавыш белән.
— Кемнәр? — дип сорады Бәхтияр. Тәнендә кайнар дулкын уйнаклаnып алды: «Шушы»! — дип уйлады ул.
— Кызны, Шаһирбануны, атасы гел үзе белән бергә болан ауларга алып йөри икән.
— Аталары кем?
— Шаһ. Хатыйп шаһ... Бервакытны шулай, җиде үзән, җиде үр кичеп, ике улын алып, Шаһирбануны ияртеп, шаһ елга ярына килеп чыга. Күрәләр — алар куып килгән болан таш кыя очына менеп баскан. Кичке кояшта боланның мөгезләре алтын булып яна, кояш нурын кырыкка телеп, кырык тарафка чәчә, тоягы белән типкән җирдән утлы ташлар чәчрәп оча.
«Бу — синеке! — ди Хатыйп шаһ кызына. — Атып төшерә алсаң, ике каламның икенчесен сиңа бирәм».
«Ә миңа ничә кала?» — дип сорый төпчек улы. Җанына курку йөгерә.
«Сиңа беренчесе».
«Ә миңа ничә? — ди өлкән улы. — Минем калага минем тәнем белән башымны аерган арадан гына үтәрсез! — дип, булат кылычын суырып чыгара да: — Синең шикелле әткә кала биргәнче, эт күк каберсез булыйм», — дип агай-энесенә ташлана.
«Үз каныңны үзеңә эчертми торып, сиңа кала калдырмыйм!» — дип, анысы да алмаз очлы сөңгесен абыйсына каршы бора.
Һәм агай-эне, атларын күз ачып йомганчы бер-берсенә каршы бастырып, сөңгеләрен сөңгегә, кылычларын кылычка тери. Яңгыр катыш боз өермәсенә охшап, бер-берсе белән аталары үлгәч мирас булачак калалары өчен сугыша да башлыйлар.
Эчләренә шайтан өермәсе оялаган шикелле, араларына беркем керә торган булмый. Миләш саплы сөңгеләре бер-берсенең калканнарына бәрелеп сынгач, бер-берсенең кылычларын җиде җирдән тураклагач, атларыннан төшеп, хәнҗәрләргә ябышалар. Алар сугышкан җирдә үлән көя, туфрак, кан белән тугланып, сазлыкка әйләнә. Сазлык аларны баштa тездән, аннан кендектән, аннан күкрәктән, аннан муеннан күмә. Болар, тешләрен бер-берсенең муеныннан ычкындырмый, атлары-ниләре белән үз каннарында үзләре тончыгып үләләр, үз каннары белән кушылган җирдә зыярат табалар. Иң соңыннан иң олысының гына башы калкып кала.
«Миңа ник кала калдырмадың?» — дип сорый ул, һәм аның соңгы тамчы каны күз яше булып сазлыкка тама.
«Ә мин сине җиде калага бер баш итмәкче идем», — ди дә шаһ булат кылычы белән аның башын кисеп тә ата.
Уллары өчен оялып, ул Шаһирбануның күзенә туры карарга да кыймый.
«Ике калам бер кызыма насыйп икән», — ди.
«Ә тидерә алмасам?» — ди кыз һәм алтын мөгезле боланга алтын очлы угын төзи. Йөрәгенә ир туганнары өчен әрнеп үпкә каны сава, иртәнге ай төсле ак бите буйлап энҗе-энҗе яшь тәгәри. Ә үзе, Чакмар аты биеп торса да, сөлектәй сынын, җәясе шикелле артка таба каерып, ут

тояклы боланның ярсу күкрәгенә төбәп ук ата. Ук оча тора, ә Хатыйп шаһ кызына:

«Атып төшерсәң, шул кыя башына кирмәнчек салып бирәм», — ди.

Әйтеп тә өлгерми, алтын ук боланга барып та житә. Тик боланның янбаш сөягенә генә барып кадала: яраланган җәнлек, мөгезләре белән кояшка җитәрдәй булып бер омтыла да, үткән яшьлек, аккан гомер сыман, мәңгегә югала.

«Хәзер нишлисең?» — дип сорый Шаһирбану атасыннан.

«Кыя башына кирмәнчек салам, — ди шаһ. — Кылыч тотарга, ук тәбәргә шушында өйрәнерсең, кирмәнчектә торырсың. Хәзер минем меңбашым син», — ди. Шулай дип, атын җиде чуклы камчысы белән көйдереп ала да җиде тау, җиде үзән аша баш шәһәренә оча.

Таш кыя башына шаһ кырык көн эчендә кырык тәрәзәле кирмәнчек салдыра. Шаһирбану урманнарда кылыч белән агач кыеп, далаларда сөңге белән киек куып, елгаларда ук белән балык аулап гаскәри һөнәргә өйрәнә. Үзе белән бергә килгән җиде ахирәт кызын да өйрәтә. Кырык көн, кырык төн кылыч кайрап, сөңге очлап, ук телеп кырыгышар айлык атлар белән дөнья айкагач, кайтыр юлга чыгалар.

Шаһирбану Чакмары өстендә алдан оча. Ахирәтләре аның артыннан көчкә өлгерә. Беренче торакка җиткәч үк, йорт башларына эленгән юкә пумалалар күрәләр. Сак манарасы башындагысын сумалалап яндырганнар — сабы гына көйри.

«Аһ» итә Шаһирбану. Илләренә яу килгән!

Шуннан туктамыйлар. Баш кала утырган тауга күтәрелүгә, барчасы беравыздан еларга, сыкрарга керешә. Шаһирбану чулпыларын чишә, ачы җилдә ургып-ургып чәче җилпенә. Еламый. Кырык көн, кырык төн кылыч айкаган кулы хәлсез кала. Үзе, тау түбәсеннән ишелгән кар йомгагы булып, ак Чакмары ияреннән кара көйгән җиргә сыгылып төшә. Суынган күмерләрне тырный-тырный, ул да елый башлый. Яу килеп, баш каланы хәрабә кылган. Җан әсәрен калдырмаган, кол иткән. Кояш кара, һава кызыл, елга канлы. Кызлар туган өйләрен, җимелгән илләрен кызганып ыңгыраша. Ә Шаһирбану, елау-сыкраудан туктап, кинәт җил өргән утлы күмер шикелле ялкынланып киткән күзе белән дошман атлары, куылган коллар эзе сузылган юлга текәлә. Тузанлы җил ул яктан әсирләрнең:

Үзәннәр, урләр, сезләрне
Безгә бүтән күрү юк.
Бәхетлеләрнең йөрәген
Кылыч кискән, тишкән ук, —

дигән үксүле зарын китерә.

Шаһирбану:

«Кыз батырлар! — ди. — Кичә акчарлаклар идек, бүген бөркетләргә әйләник! Бүреләр өере белән алышып, көч-сәләтебезне сынар чак житте. Ил күзе безгә текәлгән. Күзе яшьле батыр булмый. Әйдәгез, җилдән узып, дошман артыннан!

Халык өчен үлгән батыр мәңге үлемсез ятыр,
Халык өчен җиңгән батыр яшәргә диеп кайтыр.

Ә хәзер, этләр белән бүреләр туена ризык булмас өчен, туганнарыбызны җирлик!» Җирне мамык итеп, үтерелгәннәр ята. Һаваны даган итеп, асылганнар чайкала. Кызларның йөзенә сагыш төне куна, йөрәкләрен үч сусавы көйдерә.

Алтын кадаклар белән кагылган итеге, франк сукносыннан тегелгән чикмәне, бакыр җөббәсе, алтын укалы кеш бүрегеннән Татагайрәш батыр ята. Шаһирбануның сөйгәне. Күкрәгенә тәңкә хәтле генә булып каткан кан табы уртасындагы дошман угын җил калтырата...

Үлем тынлыгында бер яралы сугышчының соңгы сүзләрен ишетә Шаһирбану:

Кылыч алмый суырып
Дошманны кыраем дип,
Шаһ тез чүкте кол булып,
Сөңгемне куяем дип.
Аның каны булып безнең кан акты,
Аны җаны булып безнең җан чыкты.
Мирасы аның сиңа — кара бәхет,
Хода сиңа риза кыла канлы тәхет...

Шаһирбану бу сүзләрдән, киек тәненә кадалган ук шикелле, калтырап китә. Тәне калтырый, җаны тетрәнә, ә күзләре нәфрәтеннән утлы күмер булып йөри. Сөйгәне Татагайрәш күкрәгендәге укны суырып чыгара да иярендәге укчасына яшереп куя. «Илне саткан атам йөрәгенә», — дип ант итә ул. Ә кызларга карап болай ди:

Атам булды йөрәгемнең ярасы,
Кызыл кандыр күзләремнең карасы.
Еглан йөрткән күңелендә — хыянәт,
Ошбу уктыр — минем атама кыямәт!..

...Сәгать унберләр. Аръяктагы тракторларның берсе, ватылыптыр, ахры, туктап калды. Ширияздан карт та, нәкъ шулай, дастанын сөйләгән җиреннән кырт киселгән иде. Аны коры ютәл басты. Ул буыла, җиргә кадәр диярлек бөкрәеп йөткерә. Күрәсең, августның таң алды салкыны куырып алган аны. Култык астыннан кочаклап, урынына кертеп яткырганда, картның бөтен тәне, тегермән кәүшәсе кебек, вак калтырау белән дерелди, тәне кызу, тирләп чыккан иде.

— Алдадым... бугай сине,— диде ул. Теше-тешкә тими иде. — Ымсындырдым... — Бәхтияр аның өстенә юрган япты. — Тагын яп, салкын,— диде карт. Иңеннән алып тунын да япты.— Син бар инде... ят...

— Сиңа чәй кирәк,— диде Бәхтияр. Бөтен күңеле белән картны кызгана башлады. «Мескенгә чәй ясаучы кеше дә юк икән авыра-нитә калса»,— дип уйлады.

— Бар, ят. — Карт башыннан ук бөркәнгән. Тавышы баздан чыккан сыман тонык, көчсез.— Мин күнеккән... Япан кырда буран чыкмаса, суык кына... адаштырмый...

Бәхтияр газ өстендә су кайнатып чәй ясады, салып бирде. Карт, тимер караватына утырган килеш кенә, өрә-өрә чәй эчте, шикәр капмады.

— Үпкәләмә инде... олан,— диде ул Бәхтияргә, каш астыннан гаепле караш ташлап. — Тик ул тәки атасын үтерә бит... Үз юлында гаскәр җыеп, дошман явын куып җитеп туздыра да, атасын тотып, таш кыядагы кирмәнчеккә томалап куя. Чишендереп, тере килеш... Ни ашарына... ни корал... Оныткан атлы кыланып, Татагайрәш аркасыннан алган укны гына төшереп калдыра. Шаһ шул укны үз йөрәгенә чәнчи...

Чәй эчкәч, карт тынып, җиңеләеп киткән сыман булды. Урынга ятты. Күзе йомык. Йөткергәч, хәл алгандай, тирән-тирән итеп сулый башлады. Аннары тәрәзәгә борылды. Йөзе ап-ак, кипшенгән иреннәре юка, зәңгәрсу. Күзендә, мәңге китмәс шикелле булып, ниндидер үкенеч, сагыш мөлдери.

— Таң ата... Тик бу яктылык, кем... Бәхтияр олан... кое төбеннән. Балыкны коега салсалар, сукыраюына ул гаепле ме?

Карт саташа башлаган иде. Бәхтияр, кулъяулыгын салкын суга манчып, аның маңгаена куйды. Бары тик шуннан соң гына ул аңга килгәндәй ачык итеп:

— Иртәгә сөйләп бетерермен... Син инде... бигайбә... савык чак булсае...— диде дә йоклап китте.

Аның янында бераз утыргач, утны сүндермичә генә, Бәхтияр өйалдындагы урынына чыгып ятты. Ләкин күзен йокы алмады. Тышта шыбырдап кына яңгыр ява. Тәрәзә өлгеләрен зәңгәр ялкын белән сыйпап яшен калтырый. Бәхтиярнең уенда, яшен чаткысы булып, шаһ йөрәгенә төбәлгән ук калтыранды...

Ә калай түбәне янгыр шавы дөбердәтми мәллә? Әллә соң анда, Шаһирбану гаскәрләреннән миһербан-шәфкать сорап, дошман явы чәбәләнәме?

Таң ата. Бәхтиярне йокы баса. Бер генә тәрәзәле караңгы өйалды чиксез озын туннель итеп тоемлана. Менә ул, кулын сузып, алда төсмерләнгән яктылыкка карап бара. Яктылык та аңа каршы килә, ә ул Фәгыйлә йөзе икән. Ябык, ак яңагы юка кара чәч белән каймаланган, борын сызыгы, сизелер-сизелмәс башланып, текә дугаланган сирәк каш булып китә, озын керфекләреннән күз төпләренә күләгә кунган, маңгае киң. Аннары соң караңгылыкны, Фәгыйлә сурәте белән бергә, яңа яшьнәгән яшен чәчрәтеп вата...

Уянып күзен ачканда, өйалды яп-якты иде. Төнге аҗаганнар стенага ябышып калган күк. Бөтен җирне кояш нуры яктырта.

Торып чыкса — ишегалдында гадәти кыяфәте белән Ширияздан карт йөри. Бакчадан ярты чиләк кыяр, помидор җыеп кергән, шуларны юып маташа иде.

Көн эссе, аяз, саф.

«Аның кичәге әкияте төш кенә булмады микән? — дип уйланды Бәхтияр. Аннары үзен: — Бүгенге әкияте»,— дип дөресләде.

— Тордыңмы? — диде карт, берни булмагандай елмаеп. — Әйдә, ашыйбыз тозлап монауларны... Хөснижиһан иртән сыер савып киткән... Сөте тәмле минем сыерның.

Картның борын очына, иягенә чиләктән чәчрәгән су тамчылары кунган, ә аларда кояш нуры чагыла иде. Моның белән ул балага охшап калган. Кичәгене һич искә алмады, әйтерсең берни булмаган. Сүзсез генә ашадылар, чәй эчтеләр.

— Инде дә бер эш барые, олан... миннән җимерек калмасын — каршы рәшәткәнең черегән җепсәләрен алыштырыйк әле. Син дә авырыксынма, зинһар. Миннән җимерек калмасын.

## 3

Бәхтияр Ширияздан карт янында утырганда, трактор тавышы ишетелде. Бераздан ул үзе дә күренде. Мәрдәнша. Арбада, алгы такталарга тотынып, Хөснижиһан баскан. Капка каршысында трактор туктап калды. Хөснижиһан, теге як борттан төшеп, аларга якынлашты. Кулында төенчеге бар иде.

— Менә, әти, алма бөккәне пешергән идем, коймак.

— Нәрсә җөрисең инде мәшәкатьләнеп. Ач түгел лә. Җитмәсә, трактор куып.

— Безнең комбайнчыларга аш илтү, әти. Юл ыңгаеннан сугылу.

— Инде дә эшең... Чегән күк бер җирдән икенчесенә... Хәтә... Үз җиреңдә аягың басмаган җир калдырмыйча җөреп калу үзе бер бәхет инде ул. Картаелды менә. Икенче кат басып чыгаргае җылы җиргә. Иң киме — карап...

— Әйдә соң,— диде Хөснижиһан.— Җил өрдереп кайт безнең белән бер.

— Кайлардан урыйсың?

— Йортөстеннән, Күкертлектән... Ядегәре тагын — Кашан кырынук барып чыккан эш ясап. Берүзе... Әйдә.

— Җир җылысын җылы тән белән тою мәслихәт инде анысы. —

Карт сораулы караш белән Бәхтияргә карап куйды. — Карап калу да үзе бер гомер, ә?

— Ияребез мәллә? — диде Бәхтияр.

— Үкенечкә калмасын соң!..

Һәм менә алар трактор арбасында. Шириаздан карт Бәхтияр белән Хөснижиһан арасына басты. Күзе җанланып, каршы җилдәнме, дулкынлануданмы йөзе кызарып китте. Түземсезләнеп, башын як-якка боргалап кына тора.

Хөснижиһан җил тузгыткан чәчен җыйный.

— Малаең кергәнме соң, Хөснижиһан апа?

Ялгышмады Бәхтияр. Хөснижиһан өчен шуннан кызык сүз булмаслыгын дөрес чамалады.

— Кайтты, кайтты! Сынауларын биргән, тик билгеле түгел ди әле. Конкурс үтәсе калдымы ди шунда... Дүрт тә бишкә биргән, дүрт тә бишкә!

— Әйткән идем бит мин.

— Ә нәрсә диган идең?

— Яхшыдан начар булмый дидемме әле?

— Истә дә түгел инде.

— Ә нәрсә истә? — диде Бәхтияр.

Хөснижиһан йөзен читкә борды.

— Мин, тишек авыз, артыграк сөйләшеп ташлаган ул көнне.

— Иртәгә китәм, Хөснижиһан апа.

— Аңламадым да, Бәхтияр... Безнең авылда нинди йомышың төшкән иде соң синең? Терелдең дә бугай инде, ә үзең гел монда әле.

— Күзнең шеше кайтсын дип көтү иде дә... Озакланды.

— Эч авырта диган идең, беттеме, ничек?

— Бетте. Китәм иртәгә.

Беравык сүзсез бардылар.

— Соң... килеп кит кичен.

— Килеп дип... Беркөн дә мәшәкатьләп...

— И-и-и... Сөйләшеп утырырсыз шунда. Болай сүзгә начар кеше түгел ул. Кеше ярата.

— Кем, малаеңмы?

— Ә ул китә инде төштән соңгы автобус белән. Алсалар укырмын, алмасалар, шул китүдән КамАЗга китәм ди... Иремне әйтүем әле, Ногманны!

— Әле бер көн генә...

— Әле бер көн генә аны... ачу бер килсә. Керттем инде, нишлисең. Язган булгач... Әлек болай ук түгел иде... Тәүбәләргә килдем дигән булды инде. Нишләр менә. Кайтканнан биртен авызына аны-моны алганы сизелми әле сизелүен. Бик тәүфыйклы.

— Кабат башлар дип курыкмыйсыңмы соң?

— Куркамрак шул! Ялгыз баш та читен... Ялгызлык ул, наным, хатыннар башына түгел, эт башына төшеп тә ябагаларын койдырта. Күрми дә каласың икән ич ул гомер дигәнне!.. Шуңа керттем Ногманны да. Тәүбәләре белән башларымны ашамаса инде... Кызгандым чукынчыкны.

Тормышның үз шәригате бар шул. Һәм, Хөснижиһан кебек, шундый җаннар бар — эчләре тулы иман! Иллешәр сажиннан бәреп чыккан чишмә сыман, тормыш кайберәүләргә авырлык өстенә авырлык өя тора. Әллә соң, суы сыгып чыгарылган алма шикелле, Хөснижиһанның яхшылыкларын бәхетсезлек шулай мул итеп кысып чыгара микән?

Юл кисеп үткән тирәнрәк ерганакларга сулар җыелып калган иде. Трактор аларны чәчрәтә-чәчрәтә чаба. Каршыга ашлык төягән маши-

налар очрый, арттан бушлары узып китә. Кырда тик машина гөрелтесе генә. Югыйсә, табигать тын. Дүрт урында сигез комбайнчы, әллә ничә шофер ашаткач, соңгы җир итеп, Кашан ягына юл алдылар.

Кашан үре. Мәрданша тракторы, күтәрелә барган самолет сыман, үргә үрмәли. Һәм менә күтәрелеп бетә дә, бинокльнең юан башыннан карагандагыча ерагаеп, басу күренә. Аның түрендә — комбайн, туктаса да, эшләп тора. Бодай арасындагы карт наратлардан кыска-кыска күләгәләр төшкән.

— Бункеры тулган,— диде Хөснижиһан.— Я безне көтәләр. Карыннары ачкандыр мескенкәйләремнең.

Шул мәлдә Бәхтиярләрне машина әйләнеп узды.

— Бункерлары да тулган икән. Нәкъ вакытында килгәнбез.

Ширияздан карт зур кызыксыну белән, хәтта кабаланып һәм нәрсәдәндер оялган кебек, тирә-юньне күзәтеп барды. Егылмас өчен ул аягын киң аерып, бөкрәя төшеп баскан, борт тактасына чытырдап ябышкан.

— Әүвәле... Ә-әнә тегендә...— Ул ияге белән каядыр алга ишарәләп күрсәтте.— Әнә тегендә... Безнең... минем ызаные.— Карт Кашан кырына түгел, моннан күренеп торган икенче бер үргә ымлый булып чыкты. — Ә бу җиргә без алма җыя киләдериек. Кыраулар бер куыргач... и-и-их!..— Ул авызларын ук чәпелдәтеп куйды.

Аларны узып киткән машина комбайн янына түгел, киң елга яры буена табан китте. Бер мәл тукталып, аның шоферы кабинасыннан чыкты да, кулын йөзгәндәгечә кыландырып, Мәрданшаны да чакырып карады: су коенабыз, янәсе.

Мәрданша тракторын комбайн каршына китереп туктатты да сүндерде. Берәм-берәм җиргә коелыштылар. Хөснижиһан да авыр гәүдәсе белән сикереп төште. Басып кала алмады, артын-артын чигенеп, салам чүмәләсенә барып терәлеп калды. Ширияздан карт әле тегеләй, әле болай итеп карады, ләкин Бәхтияр кочагын җәеп торса да, борт аша атлап чыгарга кыймады. Ниһаять, ул да җирдә.

— Кырда булмаганга ни гомер икән инде... — дип, ул, нидер эзләгән шикелле, аяк асларына карана-карана йөренергә керешге.

— Кайда соң бу? Әй, Ядегәр! — дип кычкырды Хөснижиһан.

— Су коена киткәндер,— диде Мәрдәнша, арба ышыгына килеп утырды.

— Комбайнын эшләтеп калдырыпмы?

— Җә җоклап ятадыр,— диде Ширияздан карт. — Бу эсседә... Ә бит җангырга, җангырга бөркү. Әнә, тургай әсәре юк.

Комбайнның салам җыйдыргычы артыннан комбайнчы күренде.

— Эше комбайн сүндереп торырлык булмаган икән,— дип көлде Мәрдәнша.

— Шул телең булмаса... — Хөснижиһан кулы белән эчен тоткан Ядегәрдән тизрәк читкә борылды. — Кая утырасың, Ядегәр? Аш суынды инде. Иң актык кеше — син.

Хөснижиһан Мәрдәнша алып төшеп саламга утырткан термосны ачты, сумкасыннан ашъяулык, тәлинкә-кашык, ипи чыгарып урнаштырды:

— Әти, аша әйдә син дә.

— Кая...монда ашау... — Ширияздан карт, куркынып әле Ядегәргә, әле Хөснижиһанга каранды. — Нишләгән ул, оланнар?

Барысы да Ядегәргә текәлде. Ә аның йөзе ап-ак, аскы иренен тешләгән, чәче чуалып, тирле маңгаена ябышкан. Ул бер-ике адым атлады да җиргә сыгылып төште.

— Сук-кыр эчәк... имансыз... Шартламагае... икенчесе, егетләр...

Мәрдәнша, сикереп торып, тракторына менеп утырды, инде тар гына калган бодайны кистереп, су буена, рәшәдә калтыранган машина

ягына юл алды. Ядегәр, кырын яткан килеш, тезен эченә терәп куырылып килде.
Тормозларын чыгырдатып, машина килеп туктады.
— Өлгерсәң, җарты сәгать сина, Сәет эне,— диде Шириязданкарт.
— Беләм, бабай.
Сәет билгә кадәр ялангач, ялан аяк. Бәхтияр белән икәүләп, Ядегәрне кабинага кертеп утырттылар. Ширияздан карт читтән булышкалап йөрде.
— Кабаланмагыз, оланнар. Бу кырлар авыру гына түгел, бала табулар да күрде... Үлгәнне дә... Бодаен урып бетереп киләдерне икән. Бүленде.
Машина киткәч, Мәрданша комбайнны сүндереп төште.
— Ярдәмчесе кая киткән соң моның?
— Үз малае иде,— диде Хөснижиһан.
— Бүген көтү чираты җитте аларның. Шунда киткән,— диде Мәрданша.— Әйдә, утырышыгыз. Бүген бу кырны бетерәм дип чыгып киткән иде... бетерде пычагым... Дөнья гел син дигәнчә генә түгел шул ул.
Хөснижиһан тәлинкәдәге ашны нишләтим икән дип уйлап торды да кире термоска бушатты.
— Ядегәргә язмаган икән... малга бирермен.
Ашъяулыгын җыйнап, кашык, тәлинкәне сумкасына салды.
— Булдыгызмы? — дип кычкырды Мәрданша.
Бәхтияр трактор ишегенә барып тотынды:
— Буш кайтмыйк инде. Әйдә, бушат бункерын арбага.
— Ничек инде, хуҗасыз... Хәзер малаена җиткерерләр Ядегәр абыйның, килер, бушатыр.
«Ник мондый бу? — дип уйлады Бәхтияр. — Нинди көч шулай кире итә икән аны?!»
Һәм ул, катгый карарга килеп, баскычтан югары үрмәләде, стартерга һәм газга басып, комбайнны кабызды.
— Куй арбаны бункер астына! — дип кычкырды ул, ике мотор тавышын уздырып. — Җиргә түгәм, югыйсә!
Ул бункер көрәгечләрен хәрәкәткә китерде, җиргә берничә уч бодай түгеп күрсәтте.
— Төш аннан, естудин! Менеп сугып төшерәм хәзер... Ватасың ич!
Мәрданша чәчрәп җиргә сикереп төшкән иде дә, биленә таянып, каршысына Хөснижиһан килеп басты. Кулын бутый-бутый нидер кычкырды да ахырында аны эткәли-төрткәли кире куып менгерде. Мәрданша аның төрткәләүләреннән чыдый алмый көлде:
— Кытык... килә ич, кит моннан,— дип шыркылдады ул. Тик, әйләнеп килеп, арбасын бункер ягыннан комбайнга янәшә куйды. Буылып торган суны ерып җибәргәндәй, арбага ишелеп-ишелеп бодай ташкыны агылды.
Шуннан Бәхтияр төшмәде. Ул, куллары калтыравуын да сизмичә, тизлек күчергечне алга этәрде, әкрен-әкрен генә, әйтерсең лә динамит төялгән машинага утырган кебек, муфта аергыч педальне ычкындырды. Алдагы һәм арттагы һәрнәрсә хәрәкәткә килеп, күзенә бер чүп килеп кунды. Күзеннән әллә шул чүп, әллә башка нәрсә аркасында яшь саркып чыкты. Җиңелчә калтырану белән кузгалып киткән комбайн, сал шикелле тирбәтеп кенә, аны инде киңрәк елга хәтле генә сузылып яткан бодай кырына алып кереп китте. Аягына басып һәм бөтен буена сузылып, ул бункер авызының читеннән күренеп торган бодай агымын күрде. Гүя анда, ургып-ургып, алтын шарлама кайнап тора иде.
Комбайн яныннан, кулларын болгый-болгый, Мәрданша йөгерә.
— Туктат! Башың ике мәллә... туктат! Естудин!..
Бәхтияр аңа ак кепкасын болгап көлә.

— Тагын кил, Мәрдан!.. Күрсәтик әле бер!..

Дугаланып кергән җирдән борылганда ул артка борылып карый. Анда, кулын каш өстенә куеп, Ширияздан карт карап тора. Ул көчле җил сындырган, ләкин тамыры белән туфрагына нык береккән таза нарат шикелле генә күренеп калды.

Хедер канатлары астында бодай чәбәләнә. Комбайн, Бәхтиярнең үткән гомер секундларын санагандай, бөртекләп ашлык җыя. Әле кайчан гына соң, менә шушылай, Бәхтияр комбайнда эшли иде. Кичә генә кебек. Менә бункер яңа бөртекләр белән тулар, ә алар санынча булып җыелган минутлар аның унбишенче яшенең комбайнлы җәен кире кайтарыр да, алтын башаклы кечкенә генә басу итеп, алдына җәеп салыр кебек. Бәхтияр уе белән ул басуның алтын парчасын ачып карый. Ә анда... кыш. Атасы үлгәннән соңгы кыш. Әнкәсенең җилпучында тагын бер ипи изәрлек кенә калган он... Һәм менә колхоздан боерык белән алынган бер капчык бодай. Тегермән. Җылы он чишмәсе. Бәхтияр капчык тотып тора, әнкәсе он тутыра. Соңгы учын җыеп салгач, кулына щетка ала да он ящигын ялап алгандай себерә... Җирдә бер башак та калмасын өчен, комбайнны ничек тотасын белә Бәхтияр.

Башка җитеп кире борылгач, бункер тулды. Хөснижиһан Мәрданша белән кайтып киткән. Ширияздан карт Кама ярына барып баскан: канатын җыеп, тау башына кунаклаган тилгәнмени!

Бәхтияр комбайнын туктатты. Хәзер генә эчәсе килгәнен сизде: «Су...» Әнкәсе, камыш уруыннан туктап, әкрен генә аңа борыла.

«Ә-ә, сумыни? — ди ул, елмая һәм урагын иңбашына салып иелә дә читләрендә камыш үскән кулне аңа суза: — Эч, улым!»

Аннары кипкән камыш көлтәләре төялгән йөк артыннан китә. Ат дилбегәсен Бәхтиярнең атасы тоткан. («Әти, син күпме фашист үтерден?» — дип сорый бастырыклап төялгән йөкнең иң өстендәге ике көлтә арасына сузылып яткан кечкенә Бәхтияр. — «Кем санаган инде аны, улым? Булгандыр инде шунда...»)

Кызу. Гүя ул атасы эшләгән тимерчелек миче каршында. Мич өстендә шушы басу өстендәге шикелле үк рәшә... Атасының бер араны тимерчелеген ташлап торганын хәтерли Бәхтияр. «Анда бармыйм бүтән». Ничектер саташып авырган чагы иде. Терелгәч, алачыгына кире кайтты: «Хәтердәге крематорий утын шушы учак кына сүндерсә сүндерә, улым». Шуны сүндерер өчен микән — кышның иң салкын бер мәленә калдырып китте ак дөньяны...

«Җирдә туган, җиргә китәсе кеше шушы кыр алдында әҗәтле кала аламы соң?!» — дип уйлый Бәхтияр. Рәшә дулкыннары чайкалган үр өстенә диңгез эченнән күренгән корабль кебек әкрен-әкрен калка барып, зәңгәр трактор күтәрелеп килә иде. Әнә кемдер кабина тәрәзәсеннән кепка болгый — Мәрданша.

Ул килеп җитә дә, зур түгәрәк ясап, комбайн белән янәшә туктый.

— Ну, естудин... — Мәрданша елмаеп бармак изи. — Кем белгән синең безнең тамырдан икәнне, фәл-лән-төгән...

Ул бодай шарламасы астына кереп баса. Бер генә мизгелгә бодайдан коеп куйган җиз сын булып кала. Аннары, колагына кергән суны чыгарган шикелле, әле бер, әле икенче аягында сикергәли, чәч арасына кергән бодайларын каккалый.

— Әйдә, әйдә, естудин... Күпме духың бар — ку!

Ул елмая. Алдагы ике көмеш тешендә кояш чаткысы уйнаклап ала. Тракторы морҗасыннан кара төтен ургыла — шунда йоклап яткан карганы куып чыгардымыни. Бу минутта үз күңеленнән дә куып чыгарды шикелле ул аны.

...Һәм менә — соңгы өчпочмак та урылып бетте.

Комбайн, ашап туйган кызыл сыерга охшап, кыр уртасында тора. Салам чүмәләләре — каядыр күченергә чыккан дәү әкәм-төкәмнәр кө-

түе кебек. Ни ара үзгәреп өлгергән кырын таный алмыйча шаккаткан йомран, оясыннан перископ кебек сузылып, тирә-юньне күзәтә. Гаҗәпләнүеннәнме, сызгырып та куя хәтта.

Бәхтияр белән Ширияздан карт салкынча җил бәреп торган сөзәк яр буенда утыралар.

Кояш кичке бөтен нуры белән Кама өстенә сузылып яткан. Су коена шикелле. Сак кына хәрәкәтләнеп, яр кырыендагы суны чайкалдыра.

Карт егетләрчә гайрәтле матурлык белән җиргә кырын яткан.

— Ә синең маңгай тиргә мул икән,— ди ул су өстендә алтын каурыйлар булып чайкалган нурларга карап. — Тагын синең күңелең йомшак икән, менә шундый... — Ул, үрелеп, яр кырыеннан бер уч кара туфрак ала да үлән өстенә чәчә. — Синең тир җиргә тамды да сеңде-югалды түгел икән... Ул синең, беләсеңме, монда тамды, ә тегендә ургып чыга икән... Чишмә булып.

— Сөйләшеп тә карыйсың инде, Ширияздан агай!

— Сөйлимрәк шул. Ә син хәтереңә ал... Онытма: синең тир тамудан туктаса, бер җирдә чишмә корый дип бел.

— Ә бит... туктаячак бер...

— Җир зур ул, олан — бөтенебезне сыйдырыр анысы. Вакыт житкәч... Ә кеше, анда кереп ятканчы, шундый итеп яшәсен — тамган тирен җир чистартсын да чишмә итеп чыгарсын, болыт итеп таратсын... Кешедән эшләгән эше генә кала... Бүтән берни дә... берни дә...— Карт аягын җыеп торып утыра, тезен кочаклый.— Менә, тыңла әле...

«Бер аучы яшәгән. Аның җиде улы, бер кызы булган. Кызын Бодаһай дип йөрткәннәр. Сылулыгын әйткән дә юк, күзе төшкәннәр аның акылына хәйран кала икән. Тәне сөттән ак икән дә чәче көн уртасындагы кояштан да сары икән.

Мәгәр Бодаһайның даны бөтен илгә, күршедәге дус яисә дошман җирләренә таралу сере бүтәндә булган. Көлсә, ул басып торган җирдән челтерәп чишмә агып чыга икән дә вак кына саф алтын тешләреннән бөтен дөнья якты нурга күмелә икән. Шуңа күрә аучы белән аның җиде улы йөргән урман киек-кошка мул булган. Алар ачлыкның, бәхетсезлекнең ни икәнен белми гомер сөргән.

Бодаһайның көлүе ерак карурмандагы Каракошлар патшалыгына хәтле ишетелеп, анда чишмәләр чыга, алтын тешләреннән чәчелгән нур аларның күген дә яктылыкка күмә икән. Каракошлар чыккан бер чишмәнең күзен томалап, чәчелгән бер нурны болыт-болыт кара канатлары белән каплап торган...

Ә Бодаһай көлә дә көлә, елмая да елмая икән.

Каракошларның ачуы чыккан. Чөнки аларга карурмандагы киеккошларны сусызлыктан алҗытып, караңгы сукмакларда тотып ашау торган саен кыенлаша барган.

Каракошлар яу булып җыелганнар. Утлы-яшенле кара болытка әйләнеп, Бодаһай иленә ябырылганнар. Иң алдан чал сакаллы Баш Каракош очкан.

Бодаһайны тотып алып, Баш Каракошның колы итәргә килешкән алар.

Ничек икәнен сөйләп тормыйм, тик алтын толымнарыннан эләктергәннәр дә, аучы белән аның җиде улы тиз генә күреп калмасыннар өчен, Бодаһайны караңгы ерганак үзәне буйлап күтәреп киткәннәр.

Бодаһай, туганнары ишетеп Каракошларны куа чыксын өчен, көлгән дә көлгән. Көлгән саен, кара үзән көмеш су белән тула икән. Ә Бодаһай тип-тигез алтын тешләрен берәм-берәм елга ярына ташлый барган — абыйларына эз калдырган.

Елга яры буйлап килгәндә, алар Бодаһайның алтын тешләрен берәмтекләп җыя барганнар. Соңгы теше аларның учына салынуга, көн шикелле якты, кояш шикелле алтын кыз Баш Каракошны тәнендә кал-

ган соңгы кайнарлыгы белән көйдергән дә, җиргә егылып төшеп, кояшка соңгы кат карап көлеп җибәргән. Аның алтын тешсез авызы көмеш сулы коега әверелгән.

Ә ир туганнары Бодаһайның алтын тешләрен алып кайтып, кайгысыннан йөрәге ярылган әтиләренең каберенә чәчкән, ди. Икенче елны кабер өстенә утыз ике үсенте борынлап чыккан. Көзгә алар Бодаһайның толымы күк дүрттән үргән һәм һәркайсы утыз ике бөртекле башак булып җитешкән.

Кешеләр яңа үсемлекләргә Бодаһай истәлегенә богдай дигән исем кушкан.

Ә Каракошлар, болытларга әверелеп, ышнасы-ышнасы белән җәйрәп яткан игеннәргә ябырыла башлаган. Канатлары белән кайнар җилләр җилпегән. Тик башаклар аларга карап, аткан ук шикелле горур кыяфәттә, тартылып үскән көйгә елмайган гына! Каракошлар исә гарьлекләреннән утлап-яшенләп елап китә икән. Аларның күз яшен башаклар эчәр сулары иткән, ә җилләре белән чәчен тараган, бер-берсен сәламләгән.

Менә ни өчен бодайның эче Бодаһай йөзе күк ак, тышы кояш шикелле алтын.

Бодаһайның истәлеге итеп, илнең һәр кешесе үз җиренә бер бөртек бодай алып кайтып чәчкән... Менә шуннан бирле кешеләр җирдә иген игә башлаган.

Берни калмый кешедән. Кача гомер яраланган болан булып... Кеше гомере ул — күпер генә... Бер ягында — анаң кычкыруы белән синең елавың, ә бер ягында — синең кычкырмас булуың белән балаң елавы... Күперенне ничек үтәсең бит — менә нидә төп хикмәт. Берәүләр... ә-әнә анау җомран сымак... үлән арасында кора да оясын... яши аллы-артлы каранып... Ә без... чәчтән сыйпасалар да, күсәк күтәрсәләр дә — йөз белән... каршы... җылмаеп!. Менә шушы Кашаннардан килгән гадәт... фигыль... Тугры булганбыз, хәйләсез. Артыгы белән... Менә бу Кашан җимерелүе. Бабай сөйли ие: киләләр бер заман Кама өсләтеп, көймәләргә төялеп. Ушкуйниклар. Өстән төшәләр. Войкин чокырына житкәч, ярга чыгалар, ә көймәләренә яр буеннан кисеп бүкәннәр утырталар да чикмәннәрен, бүрекләрен кидертәләр. И җибәрәләр көймәләрен түбән табан, агым ыңгаена. Ә үзләре чокыр буйлата посып кына арт яктан төшә. Кашан халкы җылга өсләтә килгән көймәләрне күрә дә, гаскәр дип белеп, олысыннан кечесенә хәтле коралланып, ярга чыга. Ә-әнә тегә борынгадыр. Ә тегеләр арттан каплана боларга да әйдә кисәргә, туракларга... Әнә шул борында кырып салалар да инде безнекеләрне... Без бит хәйлә белән түгел... Без бит бүтәнчә көчле — яшәмчәнлек белән...»

Бәхтияр ялан аяклатып су читенә төшеп басты. Учлап су алды да битенә каплады. Су, йөзендә, нягендә, муенында ак юллар калдырып, түбән ага. Мыегында тамчылары гына кала.

Дөньяның бөтен суы түбән ага.

Моны бары тик корыган агач турысында зур-зур әйләнешләр ясап очкан ялгыз ләкләк кенә белми...

Яр читенә җиңел машина килеп туктый. Председатель Кәбир Шаһгалиевның гөлдерек тавышы. Ә бусы кем?.. Керфекләренә кунган су тамчыларын сыпырып алгач кына таныды Бәхтияр аны: Фәгыйлә. Кулларын, беренче кат очкан кош баласы шикелле, тигезле-тигезсез чайкап йөгерә. Юк, йөгерми: Бодаһай кыз кебек балкып көлүе һәм хыял канатлары аны Бәхтиярга каршы йөгертә иде.

Чү, әллә соң бу ләкләк Шәһребану каһарманмы? Бу җирдәгеләрне ул Кашан дигән каласының үлемсез балалары итеп күрми микән?

...Фәгыйлә Бәхтияргә эндәшми әле. Аның күзе әлегә тик: «Төш түгел бит бу, әме?» — дип кенә карый иде. Ә Бәхтиярнең аңа: «Бу мәңгелек җирдә мәңге бергә булмыйча мөмкинме соң?» — диясе килә.

Әле чигенеп, әле яңадан үрмәләп, дулкын кага; табан астындагы ком ишелеп, кытык килә. Арырак, текә ак кыя читенә елга зур бер агач төбе чыгарып ыргыткан. Аны төркем-төркем булып җыелышкан кара таплы кызыл бөҗәкләр — «фатыймалар» сарган. Шунлыктан ул төпкә кан укмашкан шикелле. Әйтерсең лә елга аны өстәрәк булган Кашан «борыны» ярыннан казып чыгарган. Ә «фатыймалар»... алар Бәхтияргә Шәһребану батырның соңгы көрәштә түккән алсу каны булып күренде. Әнә, кисәк искән җил урыныннан җайсыз кузгалган бер бөҗәкне яшел мүк баскан ташка кагып төшерде... Тамчы булып тамды.

Яндырган да шәмнәр сүнәрме,
Җыр җырламый егет түзәрме?
Җырлар җырлап эчне бушатмаган
Моңлы кеше егылып үләрме?!

Җирне шартлау яңгыратты — зират турысыннан очып барган самолет тавыш киртәсен узды. Хәер итеп, вак акча өләшеп йөргән агайның сөялле куллары калтырап китте, акчалары, тонык чылтырашып, туфрак катыш тапталган үләнгә коелышты.

— Ләхәүлә...

Әле генә өелеп беткән кабер калкулыгының текәрәк урыннарындагы коры балчык, зәгыйфь шыбырдап, аска коелды. Әйтерсең мәңгелеккә киткән гүр иясе ләхет кысанлыгына җайлашып ятты.

— Шириялан абзыйга соңгы залп,— дип куйды артып калган ләхет тактасына чүгәләгән бер ир.

— Ике сугышта тугыз ел йөрдем ди торган иде, мәрхүм.

— Тугыз?!

— Һе! Өч ордены гына бар...

— Күпме җирләгәндер үзе!

— Шушы кабер хәтле күпме окоп казыгандыр.

— Күрә инде адәм башы.

— Боларның бөтенесен алып китте инде ул.

— Апкитсәе, әй, апкитсәе мәрхүмнәр кеше башына төшәсе казаларны! — соңгы тәһлил әйткән агай, ак сакалын сыпырып, тезләрен кагакага урыныннан купты. — Кала шул!

Кузгалыштылар.

Урак өсте булса да, кумүчеләр күп иде.

— Урыны шәп туры килде — кыл урта!

— Иркен төш, тыныч.

— Карчыгы Гөлҗиһан астай белән рәттән...

— Карале, Вилдан, кәнүшнигә төшешли газ балунын калдырып кит әле минем.

— Иртәгә сугылырмын, Моталлап абый.

— Ярар, Вилдан...

— Син хәзер кая?

— Гайни телевизор алган — антеннасын утыртышырга сораганнарые.

Зират капкасына таба кузгалган кешеләр әкренләп үз көйләренә, бу дөнья мәшәкатьләренә күчте. Кайсыдыр күлмәк җиңен кайтарып сәгатенә карап алды. Берсе, әнә, озакламый телевизор антеннасына дип чокыр казый башлар...

Ә сирәк каеннарның чуклары, рәшәткә буйларындагы кычытканы, шайтан таягы, меньяшәр чәчәкләре, әремнәре, чокырлы урыннардагы

кура җиләге белән сагыш көендә җәйрәп яткан зиратта вакыт беркемгә дә кирәкмәс. Монда вакыт юк. Монда вакыт тигез секундлар агышыннан түгел, кеше гомерләре киселүдән җыйнала. Монда мәңгелек кенә бар.

Бәхтияр, зират капкасына таба атлаган күмүчеләр төркеменнән аерылып, яңа кабер янына кире килеп басты. Бөтерчек җил инде кояш җылыта башлаган, ләкин әле дымсу калкулыкка чүп катыш үлән, чәчәк орлыклары сибәләп китте. Бәхтияр, казык төбендә ниндидер түгәрәк орлык шәйләп, кулы белән аның өстенә туфрак иште.

Күк төпсез зәңгәр. Кайнар кояш сиздерми генә Ширияздан карт кабеpенең баш-башындагы казыклардан төшкән күләгәләрне озынайта.

Бурасы тузып ишелгән һәм кәлшә, карт балтырган, тигәнәк арасында күренмәс булган, мөгаен, бүтән беркем дә килеп яңартмаячак кабер янында мәтрүшкә күреп, Бәхтияр аның ябалдашын өзеп алды да, учында угалап, орлыкларын җилгәрде. Борынына татлы ис бөркелде. Туфракны бармагы белән тәрткәләп, орлыкларны берәм-берәм шунда салып чыкты һәм, Ширияздан, инде гүр иясе булган Ширияздан картны тынычсызламыйм дигәндәй, туфракны сак кына сыпырып күмеп куйды. Киләсе елга, кар сулары киткәч, бу калкулык куеныннан кояшка, биеклеккә омтылып, шул орлыклардан тернәкләнгән нәфис шытымнар калкып чыгар. Алар өчен кайда үсү мөһим булмас — әллә кабер, әллә күпме казысаң да берни чыкмас буш җир... Иң мөһиме — дым, яктылык, җылы. Болар — мәтрүшкәләрнең салкын кышлар артындагы киләчәге...

Бәхтияр, карашын кырларга юнәлтеп, тын калды. Кошлар тавышы юк. Гаять зур саргайган яфрак буенча үрмәләгән кызыл бөҗәкләр сыман, еракта комбайннар шуыша, кырмыскалардай өн-тавышсыз гына машиналар йөгерешә. Баскычлы үр белән чикләнгән уйсулыкта бүген ат көтүе утлый. Җир галәмгә офыктан-офыккача сузылган сары кырлары һәм яшел тугайлары — җәйге пәрәнҗәсе аша карап тора. Кояш җирнең алтын табасы булып җәелгән ашлык басуларындагы арыш һәм бодайны туклык нуры белән коендыра.

Ә Ширияздан карт кабере, кайнар кояш һәм киң җирнең мәңгелек сулышында пешеп, зиратның кыл уртасына яңа чыгарып куелган ипи кебек, суынырга әзерләнеп ята иде.

Зират буш һәм ямансу. Чөнки ул бу авылның соңгы сугыштан исәнимин кайткан унөч сугышчысының җиденчесен үз куенына алды бүген. Әгәр дә аның туфрагы ерак җирләрдә ятып калган ике йөз сиксән тугыз улын үзенә кабул иткән булса, ул, ихтимал, бу кадәр дә буш тоелмас иде. Бу борынгы җирнең күпме кешесе һәм җыры үз туфрагында түгел.

Ләкин үз күңелендә, үз хәтерендә. Үлгәннәрнең җыры исәннәргә кала. Моны Бәхтияр бик яхшы белә.

1975—1977.

## Сажидә Сөләйманова

### Казан — күңелем һәйкәлләре иле

Барам әле, Казан, киләм әле
кош юллары буйлап, очынып.
Ай-кояшың, рәхмәт, каршы ала,
Идел яры дәшә юлчыңны.

Сөембикә сыны, ни тылсымы? —
яшерәдер сыман серләрен.
Ерак бабамнарны белгәнме ул,
әбиләрне минем күргәнме? —

Сибелгәннәр урман-далаларга,
күтәргәннәр җирнең чирәмен.
Үткәннәрнең моңын җырга салган
Тукайларны сагынып киләмен —

Бүгенгегә, чорлар чорналышкан
казаныңда, Казан, кайнарга.
Соңгы богауларны өзгәләргә
Мусаларың чыкты мәйданга.

Яшь Ульянов безнең белән уза
йөзьеллыкның соңгы чиреген, —
хәзинәләр яткан илләремдә
киләчәкнең табып җирлеген.

Язмышларның борылышларында
шундый юлдашлары булганда,
мәңгелекнең үзәк юлларында
Җыр һәм Акыл бара иң алда.

Казан — күңелем һәйкәлләре иле!
Кайтавазлар җавап кайтара:
— Без Вакытка хезмәт итсәк кенә,
Вакыт эшли безнең файдага!

## Сүз

Сүз — тормыш, халык гомере.
Ул — борынгыдан мөлкәт.
Үзгәрми йөри телләрдә:
Дус, Дошман, Сөю, Нәфрәт.

Җыенда, эштә, чиратта
кумәк көч заманында
күпләрнең тоям күкрәген
һәм сизәм җаннарын да.

Түбәндә, югарыдамы —
шунсы хак, шунсы дөрес,
гомергә төшми телләрдән:
Сөт, Икмәк, Туфрак, Тирес.

Һәм шулар җирдән аермый,
телләргә кер кундырмый,
тарталар фани дөньяны,
кучәрдән ычкындырмый.

Сүз — икмәк. Шагыйрь икмәге
тәмледер — үреләләр...
Минеке генә түгел ул —
ул — кызларыма мәһәр.

Хөррият, хөрмәт, дәрәҗә
кемгә аз, кемгә күбрәк —
тауларга карап кодрәт ал,
түбәнгә карап — гыйбрәт.

Сүз — җанда. Бәлки ирендә?
Кемгә ук, кемгә кубыз:
Биегез... Кубызлар күп... Тик,
белегез, тормыш кырыс.

Сүз — татлы исерткечләрдән
иң мавыктыргыч хәмер.
Сүз — тамыр. Тамыр корыса —
юк тарих һәм юк гомер.

Сүз — кылыч. Чыгар кыныдан
шөбһәсез — җиңәренә.
Сүз — икмәк. Үсә ул — сөргән
һәм чәчкән җирдә генә.

## Нидер яңа...

Җәйнең соңгы киче. Салкын төшә.
Яшь малайлар учак яндыра.
Салкын кичнең утлы кочагында
Нидер туа, нидер җан бирә.

Хыялларның зәңгәр төтеннәре,
акшарланган авыл мичләре...
Кайда гына безне йөртмәделәр
бала чакның кышкы кичләре! —

Ялкын яллы атлар ак күбектә...
Акылларын җуйган җайдаклар
ут уйнатып, җир тетрәтеп чаба,
ыргылалар алга байраклар.

Үрсәләнә ялкын кочагында
ак каенның зифа кәүсәсе.
Чү... Сузыла кайнар иреннәргә
җиңүченең алтын касәсе...

Ыргый-ыргый кыргый җаннар бии,
карт иманнәр ничек илерә!..
...Мич алдыннан киттек урманнарга,
януларның серен белергә.

Үстерешә безне, саклады ул,
ышыклады яңгыр-бозыннан.
Безне яклар өчен чыршыларның
сөңгеләре күккә сузылган.

Суктырмады безне яшеннәрдән,
үзе янса янды каенлык...
Отты микән заман, оттырдымы
урманнардан безне аерып?

Җәйнең соңгы кичә. Учак яна:
әфлисуннан калган тартмалар,
сикерешә каучук тәгәрмәчләр,
кара төтен, дөрләү, шартлаулар...

Учак яна. Кышкы ак мичләрнең
хатирәсе дәррәү яңара.
Атлар дулый, шәрә сыннар бии.
Нидер яна. Нидер ярала.

## Бәйрәм көнне

*Укытучыга*

Майда кайный чәкчәкләр,
карлы көздә — чәчәкләр...
Гел янында, күз алдында
сабый чаклар, яшь чаклар.

Киләләр теркен-теркен дә
китәләр төркем-төркем.
Дөньяда алар әйтерсең
елгада дулкын-дулкын.

Агыла, күздән югала.
Акчарлак — хатлар кайта.
Юлларын сызып, сызылып,
Маңгайда сырлар арта.

Кечелек, олылык тулы
җаныңда әллә тып-тын?
Дәрьялар төбенә тыңлә,
аһ, укытучы холкын.

Я чәчәк тамырларына...
Корт күче кебек мәктәп!
Яшь балның әчесе белән
табында кайнар чәкчәк.

●

Синдә генә, авылым,
тыңдәшсез дүрт фасыл.
Дулап уза кышың,
балкып килә язың.

Җәйләр — яшел яшен,
көзләр — көмеш яшем —
яшьлегемә дәшә,
ярсып, җирсеп яшим.

Карлы-бозлы таулар
канатыңны сыный.
Аерым узган айлар
яратуны сыный.

Тарлыкларда шаулый
шарлавыклар.
Тарыма син, юлым,
тарлавыкка.

Төннәр чат йолдызлы,
Аең Зөһрә кызлы.
Сихриләнеп сызыла —
шәфәкъ-таңнар кызыл.

Ак каеннар язы,
ачык изүләре.
Табигатьнең сизгер,
изге мәле.

Арулардан арынып,
кайтамын көрт ярып.
Сиңа килеп кушыла
дөньяның дүрт ягы.

Мәгъсүм Хуҗин

# ӨЧ ХИКӘЯ

## ЮЛМӘТИ БӘЙРӘМЕ



Бүген Үр басуда сабан чәчүенә керешәләр.

Морат Юлмәтев иртәдән үк шунда — чәчүчеләр янында кайнашты, агрегатларны көйләштебулышты. Бер уч салам бәйләнгән колганы басуның Коры елгага терәлгән башына үзе кадап менде — беренче эзне туры сызарга маяк бар хәзер. Башлыйлар, димәк. Менә соңгы хәстәрне күрерләр дә кузгалырлар. Һәм Юлмәтев һәр чәчкеч өстенә — маяга — өчәр капчык борчак куйдырды: исәп-чама буенча, әйләнеп чыгарга шушы орлык таман булачак.

Кузгалдылар.

Юлмәтев сәгатенә карады: әһә, шактый юанганнар икән — тугыз тулып килә.

Йөз адымнар узгач, агрегатлар туктады — Моратка орлыкның тигез төшүен һәм күпмегә күмдерелүен тикшерергә кирәк иде. Ул, җир куенына сеңгән орлыкларны урыннарыннан күчермәскә тырышып, туфракны ике бармагы белән генә оазаклап актарды. Бу эшне Морат берәүгә дә ышанмый, чәчкеч артыннан орлыкның туфракта ятышын карау аның өчен бәйрәм башы иде. Юлмәтев, соңгы казыган төшен күмеп, аны учы белән тигезләгәч һәм бармаклары белән тырмалагач, аягүрә басты да тракторчыларга кул изәде:

— Юыртыгыз!

Аннары баш бармагын күрсәтте:

— Күркәм!

Тракторчылар да, чәчүчеләр дә сүзсез әйтелгән бу бәягә елмаеп баш кактылар. Агроном Юлмәтевнең кырда, машиналар гөрелтесе астында, игенчеләр хезмәтенә бирә торган бәяләрен тиз төшенделәр алар. Һәм аның тагын бер бәяләү ысулын онытмыйлар. Монысында Юлмәтев чәнти бармагын бастыра:

— Алама!

Гел шулай — бәя ике генә, урта бәя юк. Механизатор халкы соңгы ишарәдән шүрли. Әмма хезмәтләренә шундый бәя алгач, алар да Юлмәтинең үзенә охшатырга тырышып, салмак кына итеп — әллә инде агрономны яратып шунда! — бер үк сүзләрне кабатлыйлар:

— Бетте газиз башкайлар. Юлмәти иманны укыта болай булгач!

Тик мәсьәлә беркайчан да иман укытуга барып җитмәде. Бергәбергә эшләгән шушы унбиш елда аның белән колхоз кешеләре арасында ялгышып кына да ачуланышу-үчләшү булмады. Сине, шагыйрьне олылагандай, Юлмәти дип торгач, гел шигъри сүзләр генә әйтәсе килеп тора шул. Әмма чәнти бармакның да тырпайган чаклары күргәләделәр колхозчылар һәм хатаны дуслыкка зыян китермичә төзәтергә күнектеләр.

Әле, тракторчыларга кул изәгәч, Юлмәтинең кинәт күңеле тулды: кырда чәчкеч беренче эзне сызды бит! Моңсу булып китте — гомернең яңа елы башланды.

Морат Юлмәтев уйлавынча, игенче җиргә беренче орлык төшкәч, иске ел белән хушлашып, яңа елга керә. Һәм Юлмәти инде ничәмә еллар яңа елны үзенчә бәйрәм итә. Хәтта сугышта йөргән дүрт языньда да ул игенче яңа елын каршыламыйча калмады: җирнең орлык кабул итәргә сусавын күргәч, солдат көрәге белән шул төшне казып, аны бармаклары белән тырмалап йомшартыр иде дә алдан хәстәрен күреп җыйган бөртекләрне җылы бәргән туфракка төртер иде. Йонсыз муенын сузып, кимерчәк томшыгын үзе дәүлеге ачып, оясыннан егылып төшәргә җитеп, энисенең җим китерүен көтүче кош баласы сыман тоела иде аңа шушы урын. Уч төбедәй төшкә генә иген чәчсә дә, бөтен җирне туендырган кебек шатлана иде ул.

Смоленск янында, Жлобинодан ары, Висла ярында һәм Германия түрендә калды шундый чәчүлекләр. Төрлесе — арпа, солы һәм башкасы, хәтта арыш чәчелгән иде ул җирләргә. Ничек үстеләр икән алар? Кемдер, абайламыйча, таптап китмәгәндер, шәт. Юк, шушы кечкенә чәчүлекләрне күреп сокланучылар күп булгандыр! Бер изге җаны, башакларны уып, Моратка рәхмәт укый-укый, яңа уңыштан авыз да иткәндер әле... Тәгаен, шулайдыр.

...Буйны бер әйләнеп чыкканчы, Морат, кулларын артка куеп, чәчүчеләр янәшәсеннән атлады. Ә агрегатларның икенче кат әйләнүен юл читенә басып карап торды. Кинәт күзен кистереп җил исте. Юлмәтев, җилкәләрен уйнатып, телогрейкасы эченә кергән суыкны куды, күлмәк изүе дә ачык икән — төймәләде. Кепкасын басып киде. Аннары аны салып карады — козырекка балчык ябышкан иде. Чистартмакчы булды, әмма ак шакмаклы кепка пычрана гына төште.

— Кепкасы өр-яңа иде, пычрагы да өр-яңа булды әле моның, — дип, үзалдына елмаеп куйды.

Чәчүчеләргә шул кепкасын изәде дә уҗым тырмалаучылар янына — Урман буе басуга китеп барды. Анда да озак юаныргa туры килде — тырмаланган участокны түрдән үк җәяү әйләнде. Тракторчыларны туктатып тормады, аларга баш бармагын бастырып күрсәтте дә юл читендә утлап йөрүче Бурлы бияне үзенә чакырды. Тегесе, ашаудан бүленүенә кәефсезләнмичә, килеп Моратның җилкәсенә башын салды, иреннәре белән аның колагын кытыклады.

— Иркә җан булдың да инде син, әй.— Морат аның тамак астын кашыды.— Сиңа атланырга да җәл.— Ул тезгенне иярга эләктерде, Бурлы бияне, укмашкан ялыннан җитәкләп, тапталырга өлгермәгән язгы юл уртасына чыгарды. — Әйдә, кайт шуннан, янәшәдән.

Алар ашыкмадылар.

— Төшкә иртәрәк, Бурлыкай. Төштән соң бүтән басуларга чыгарбыз, бу якта эшләр күркәм.

Һәм ул, үзе дә сизмәстән, баш бармагын бастырды, кинәт башына бер уй төште — нигә чәчүчеләр янына тагын сугылмаска икән? Бүген әллә әйләнеп була моннан, әллә юк.

Юлмәти иярга җәһәт сикереп менде, атны Үр басу юлына борды.

Бурлы бия сузылып юырта башлады. Моратның йөзенә җил китереп бәрде, сакал-мыек төкләре авырттырып тартеп чыккандай булды. Әйе шул, менә ничек кытыршы, югыйсә, иртән генә шоп-шома итеп кырынган иде.

Чәчү җире башында — Коры елга-үзәнгә катоклар тәгәрәтеп ташланган иде. Тракторчылар, Юлмәтинең очынып килүен күреп, үзләре үк туктадылар һәм аның каршысына чыктылар.

— Алама эш кылгансыз, агайнеләр.

— Безгә председатель кушты, Юлмәти ага.

— Алама!

— Һәм болай тизрәк йөрелә.

— Шәп икән! — Морат ярдән сикереп төште дә Бурлы бияне читкә җибәрде. — Әйдә, бер тракторны ычкындырыгыз, катокларны тагып менәбез.

— Ерак калмады бит, бәлки шунда җиткәч кенә...

— Егетләр, катокларсыз өч адым да китмисез!

— Председатель тагын алдырса?

— Юлмәти кушты диярсез.

— Юаш юанайса, ишеккә сыймас инде ул...

Моның белән генә бетмәде әле — Морат Юлмәтев, чәчү агротехникасын бозу турында акт төзеп, тракторчылардан да, чәчүчеләрдән дә имза салдыртты. Егетләр башта карышмакчы булганнар иде дә, аннары кул селтәделәр. Ахрысы, үзләренә дә кызык булып китте — председатель өстеннән акт төзиләр бит. Алар Юлмәтинең хаклы икәнлеген беләләр. Аның барыбер үз сүзен итәсенә ышаналар. Әле дә истә — быелтыр бер комбайнчы электр баганасы төбендә арышны кыйпылчык калдырып урган иде. Юлмәти теге комбайнчыга урак китереп бирде.

— Чәчкеч узган төшкә комбайн да сыя, егетем, — диде. — Комбайн белән урасың килмәгән икән, менә моның белән ур.

Урды егетең, агрономга карышудан файда юк иде. Әйе, аның сүзеннән чыкмыйлар монда. Һәм менә унбиш ел инде шулай. Хәзер Морат өченче председатель белән эшли. Монысы — Зәер Чураев — шушы авыл егете, зоотехник кеше, институтта колхоз укытты үзен. Әйбәт белгеч, каты куллы — хуҗалык итү өчен шулары кирәк, тик кызу канлылыгы бар. Район киңәшмә-җыелышларында колхоз исемен тискәре яктан телгә алсалар, гарьлегенә сыешмыйча, яхшыртам дип, бөтенесен кырып-сүтеп ташлавы мөмкин.

...Морат колхоз идарәсенә иртәрәк кайтты. Гадәттә, алар кичке алтыда җыелалар иде, бүген алданрак килеп, Зәер белән сөйләшмәкче булды.

— Ялгыша бит егет, — дип уйлады Юлмәти. — Мин дә авызга су кабып йөрсәм, кем киңәш итәр аңа?

Зәер килгәндә, идарә кешеләре җыелып беткән иде һәм алар көнлек эшкә йомгак ясарга председатель бүлмәсенә керделәр — Зәернең ялгызын гына туры китерергә ара тимәде.

Ә киңәшмә беткәч, Морат Юлмәтевкә Зәер үзе калырга кушты. Ул, ачуланышып китәргә уйлапмы, кулын селтәп сөйләмәкче булган иде дә, авызын ачкан килеш тукталып калды — кычкыру белән генә Юлмәтевне өркетеп булмасы исенә төште бугай. Бүлмәдә аңа кысан тоелды — түр тәрәзәне дә, ишекне дә ачып куйды, алгы бүлмәдән графин белән су алып керде. Әмма ачуын барыбер басып бетерә алмады һәм:

— Ни өчен син минем юлыма аркылы төшәсең? — дип башлап китте.

Юлмәтев тыныч кына утыра бирде, күзләренә йокы килгәнгәме, хәтта ул гамьсез күренде. Бераздан соң гына:

— Сиңа һәркем ләббәйкә дип торса, син үз фикереңнең дөреслеген ничек тикшерерсең соң? — дип, председательгә үзе сорау куйды.

— Хаклы булмасам, мин сөйләмим. Әйтик, уҗым туклandырганда бүтән колхозлар самолет чиратына баса. Ә без...— Зәер баядан бирле кулында тоткан графиннан стакан тутырып су эчте. — Ә без синең сүзеңә карап яшибез... Яшәгән булабыз...

— Ә безгә самолет кирәкми. Үз көчебез җитә. Барлык колхозчы иртәнге туң белән басуда була. Таңнан ук басу юлында йөрү матур яшәү инде ул... — Юлмәти креслога аркасын терәп үк утырды.

Зәер әңгәмәнең болай барышын ошатмады, кач-кач уйнауны яратмый иде ул. Һәм ачуын ярып салды.

— Бүген ни өчен мин кушканны үзгәрттең? Минем авторитетны төшерергә теләдеңме? Кем хуҗа монда? Минме, синме?

— Син басуга өр-яңа күлмәкне ертып киерттең бүген, Зәер туган. Үзең алама күлмәк кимисең, пөхтә йөрисең.

— Син дә чиста киясең. Итекләрең күзге шикелле әнә. Пычракка басмас өчен ялтыратасың.

Бу сүзләр Юлмәтине сискәндереп җибәрде, аның кашлары җыерылды, ул Зәергә озак текәлеп карады: әмма сүз дәшмәде, Чураев дәвам итте.

— Каток тагарга кирәклеген әллә мин белмимме?! Чәчүдә иң артта — без! Синең сүзеңне тыңлап иң соңлап керештек. Мине сүгәләр моның өчен! Тизрәк чәчәргә кирәк! Борылыш саен катоклар көйләп күпме вакыт әрәм итәбез.

— Дан артыннан куасың, Чураев. Әмма шуны да аңла. Үз югарылыгыңнан түбән төшеп пычрануны яратмый дан... Яратмый...

— Беләбез! Мин дә үзем өчен тырышмыйм... Әллә син башка колхозларда гел каток тагалар дип уйлыйсыңмы?

Агроном әңгәмәне ташлап китәргә дә ниятләгән һәм урыныннан да кузгала башлаган иде, тик үзенең хаклыгын председательгә төшендереп җиткерәсе килеп, калырга булды.

— Кеше күз алдындагы басуларны гына әйбәтләп эшкәртергә кирәк дип әйтүеңме бу? Ә минем беркайчан да болай уйлаганым юк иде. Җирне рәнҗетәсең син бу сүзләрең белән, Чураев, каты рәнҗетәсең җирне...

Әңгәмә тукталды. Председатель бәхәсне онытты кебек, шариклы ручкасын бер сүтә дә бер җыя. Кызуы сүрелде, эндәшми, әллә инде телен йоткан тагын. Ә, юк, саллырак дәлил эзләгән икән.

— Картая төштең, Морат агай. Картайдың. Пенсиягә кайчан озатабыз әле сине? Киләсе елда бугай?..

Әңгәмә тагын тукталды. Юлмәти бу юлы инде Чураевка күтәрелеп тә карамады, уйга чумды. Шактый вакыт тынып утыргач, кинәт кенә калкынып:

— Дөрес исәпләгәнсең, — диде. — Пенсия яше февральдә җитә... Әйе, саный беләсең син. — Юлмәти, ишек катындагы урындыкка күчеп, сул аягын уң тезенә куйды. — Күзең дә очлы: инде кайткан-да я пычракка басармын... — Ул күн итекләрен салды, ап-ак оекбашларын тартыбрак киде, чолгауларын төрде. Һәм итекләрен, куныч бавыннан эләктереп, селти-селти идарәдән чыгып та китте.

... Мине пенсиягә чыгарырга ишарәләве инде. Картаясың... Бардыр, яшереп булмый, картлык үзе килә ул, карыша алмыйсың. Җирнең дә бит, әгәр аңа картаю сиздертсәң, какшавы тизли, картаюын туктатырга берничек тә көч җитми. Бәлки, председатель хаклыдыр, — китәргә вакыттыр, хәзер югары белемле агрономнар күп. Юлмәтинең урта белеменә Зәер Чураев нигә түзеп утырсын икән? Син, карткай, үзеңне тәҗрибәле санныйсың да, тик чамаңны арттыр-

мыйсыңмы? Белеме зур кешегә акны-караны аеруы җиңелрәк, күп җиңел.

Тиеш икән, кушалар икән — нигә ял итмәскә?! Рәхәтләнеп өйдә утырырмын, түр башында. Аяк бөкләп. Мин лаеклы ялда, китерегез миңа барысын да, мин әзергә — хәзер, диярмен. Ачы бураннарда, котырынган яңгырларда хафаланып йөрисе булмас. Пычракка басмас өчен генә туфли ялтыратып та мәшәкатьләнмәм. Рәхәткә тиенермен...

Рәхәт?! Әллә һәр таңда җир хәлен белү өчен ишекне каерып ачу начар идеме? Җирнең бүгенге халәтен сиңа җил әйтә, һава шул хакта сөйләп сиңа сулыш өрә, кош сайрап хәбәр сала. Аннары басу капкасын ачасың да иген кырларына сәламеңне бирәсең. Җирнең хәлен үзеннән сорашасың. Сиңа рәхәт була. Җир игътибарлы, ихтирамлы, ул синең аягыңа ни киюеңне дә күреп-тоеп кала — һәр чакның үз аяк киеме... Ул синең хәл белүеңне авызын ачкан кош баласыдай көтә. Һәр таңда шулай... Шулай иде. Әйе, күпме заман инде таңнан торылган. Кай төш булды соң әле бу? Үр басу?! Бүген шушыннан чәчә башлаган идек ләбаса, кая килеп чыкканмын, әй...

Кинәт, иртә беләнге сыман, күзне кистереп җил исте. Юлмәти кесәләреннән кульяулык эзләде. Хәтер диген, кульяулыкны пинжәгенең эчке кесәсенә салган икән. Кулына дүрткә бөкләнгән бер кәгазь дә эләкте.

— Акт ич бу! — дип кычкырып куйды ул. — Каһәр икән... Зәердән кул куйдырырга онытылган. Үзе чәчтергән төштә алынмый калган уңыш өчен түләр... Җир каршында без барыбыз да бер тигез. Ә быелгы уңыш өчен башлап торып мин җавап бирәм әле...

Ул кире борылды, караңгылыкны ярып авылга таба атлады.

## ҖИТӘКЛӘШКӘН ТАЛЛАР

Авыл кергәндә дәп-дәү глобуслар сыман ике тал бар. Ябалдашлары җитәкләшкән бу таллар басу капкасы ясап торалар — юл арадан уза. Ике тал төбенә дә тәрәкле эскәмияләр куйганнар.

Зөлфирә сулдагы — елга ягындагы тал төбендә туктады, кояшка каршы утырды. Монда салкынча, күләгә рәхәте. Туфлиларын салды. Эскәмия алды тапталудан такырайган, шул уем төшне урап чирәм үскән — ялан тәпиләрен шуңа тидерде. Җәйге эссе юлда талчыккан аякларына үлән назы берьюлы хәл кертеп җибәргәндәй булды.

Ардырган шул — өченче авылга җитүе бит инде. Монысының да бер башыннан кереп, очраган кешеләргә сәлам өләшеп, кышкы болытлы көндә иңнәренә кайгы күтәреп йөргән абый турында берәүдән дә сорашмыйча, икенче очыннан чыгып китәрме? Шулай булыр инде, бүтән нишләмәк кирәк. Ул абый шушы төбәкнекеме? Бәлки аны белүче дә юктыр монда, Зөлфирә үзе дә аз таныш ич әле аның белән. Бер очрашу да тәрәзә аша кул изәп бер озату... Кем булуын һәм кайсы авылдан икәнлеген сорарга да онытылган. Исем-фамилиясен әйткән иде әйтүен, тик моңа игътибар итәр чак түгел иде, ул да абыйның ашыгуы турында гына уйлады.

Зөлфирәнең хәзер аны эзләп йөрүе дә сәер иде. Иптәш кызларына сөйләсә дә аңламаслар — бер бабайга гыйшкы төшкән, дип көләрләр. Шулай да күңеле гел борчылды аның — нәрсә булган иде икән, бик өзгәләнгән иде ул абый теге чакта. Зөлфирәнең ярдәме кирәкмиме икән аңа... Аннары, әманәтен үтәве турында да абыйның үзенә белгертергә кирәк инде...

Шушы таллар күләгәсендә рәсемгә төшсәң икән, дип, кинәт кенә уйлап куйды Зөлфирә. Көньякка баргач, кипарис-пальмалар янында

рәсемгә төшәләр бит, әллә безнең таллар начармы? Әйе, сиңа төште ди, агач яфракларын аралап узган кичке кояш нурлары йөзне алатилә итәр иде, болай да сипкелле биткә шул гына җитмәгән.

... Өч көн инде һава ачылмый, көн уртасы да эңгер-меңгер кебек. Шәһәрнең биек йортлары ишелергә җиткән болытларны түбәләрендә күтәреп торалар. Ә шәһәр урамнары барыбер гөжли. Бу көннәрдә халыкның иң кайнашкан төше — аэропорт. Монда инә төшәр урын да юк. Тәүлек буена ыгы-зыгы тынмый, кешеләр шундый тыгынлыкта да йөрү әмәлен табалар. Очып китәргә өметләнү йөртәдер инде бәндәне...

Бер мөсафир кассалар төбен дә озаклап саклады, дежур администратор янына да кат-кат керде. Файдасы юк.

— Күрәсез бит, самолетлар бөтенләй очмый. Көн ачылсын — сез дә китәрсез. Һәр пассажир ашыга, ашыгыч булмаса, самолетка билет та алмый инде ул, — дип борып җибәрәләр үзен.

Ә аңа кайтырга кирәк. Һәм болытларны хәтта куллары белән аралап самолетка юл ачар иде ул. Үзе аэропорт хуҗасы булса, шундый кайгыга төшкән кешегә ялгызына бер самолет бирер иде. Әмма синең үтә ашыгыч кайтырга тиешлегеңә кем ышансын соң... Кулыңда шуны раслаган кәгазь кисәге — телеграмма булса бер хәл икән...

Билет алырга да су буе чират торырга кирәк. Әле билетын сатсалар икән, анысы да юк бит. Билетлы кешеләр очып беткәнче тәүлек үтәр. Бигешкә очучылар исәп-хисапсыз хәзер — Чаллы, Түбән Кама якларына кешеләрнең йомышы күбәйде.

Автомат телефон янында стенага сөялеп озак торды ул. Кыска тунының изүе чишелгән, алсу-күкле шарфының бер башы җилкәсенә үк күтәрелгән, икенчесе, салынып, пинжәк итәгенә җиткән, бүреген, колакчынынннан элəктереп, портфеле белән бергә уң кулына тоткан, сул кулы белән калын кашларын сыпыргалый.

Берәү дә аны кайгы күтәреп тора дип уйламый, стена терәп ял итүчеләр азмыни монда?!

Урамда җилләнеп керергә дә теләмәде ул — моннан чыкса, аны калдырып китәрләр кебек тоелды. Әйтерсең самолет кырмыска оясыдай мыжлаган шушы залдан күтәрелә инде...

Нишләргә соң? Әллә капкалап алыргамы? Күпме көтәсе билгесез, иртән кунакханә буфетындагы коры-сарыдан гына авыз иткән килеш.

Тик ресторан ишегенә якын барырлык түгел иде. Ахры, кешеләр, ашап чыгуга ук, икенче тапкырына чиратка басалар бугай.

Ары-бире сугылып йөри торгач, депутатлар бүлмәсенә барып керде ул.

— Монда мөрәҗәгать итүдән дә ни файда, — диде мөсафир үз-алдына. — Депутат өчен генә көн аязмас...

Шулай да...

— Беләсезме, сеңелем...

— Беләм, абый, — диде депутатларга билет бирүче кыз Зөлфирә.

— Нәрсәне беләсез?

— Сезгә очарга кирәклеген.

— Әйе. — Һәм ул сәфәре өзелүнең сәбәбен аңлатырга кереште. Әмма юньле-башлы сөйләп бирә алмады. — Беләсезме, сеңелем, бер мөсафир мин, Казанга йомыш белән килгән идем. Авылдан кунакханәгә шалтыратканнар, бик ашыгыч кайтырга кушканнар. Семьяда, өйдә инде, нәрсәдер булган минем... Нindидер күңелсезлекме, әллә зуррак кайгымы... Нәрсә дип башыма китерергә дә белмим... Сез миңа ышанасызмы?

— Ышанам.

— Ышанасыз? Мин депутат та түгел...

— Әле мин сезгә билет бирергә җыенмыйм.

— Дөрес, мин депутат, әмма авыл советы депутаты, сездәге хокуклардан файдаланырга хакым да юк...

— Мин сезгә беренче рейска ук билет бирергә тырышырмын. Иртәнгә һаваның ачылуы көтелә.

Бу сөйләшү төнге уникедә булды. Иртән Зөлфирә, таныш түгел абыйга тәрәзә аша кул изәп, хәерле юл теләп калды.

...Урамның өске ягындагы кырый йортның кечкенә капкасы җырлап ачылды — капканың озын күләгәсенә кояш яктысы палас булып сузылды. Капкадан башта өч тәгәрмәчле велосипед йөгереп тәгәрәп чыкты, аннары аның кечкенә хуҗасы күренде. Кыз велосипедына җәһәт кенә утырды да Зөлфирәгә таба куаларга тотынды. Ул Зөлфирәгә текәлеп карый иде. Зөлфирә аның каршысына күтәрелде.

— Апа, болар минем әни эскәмияләре!

— Бик әйбәт, чибәрем.

— Миңа әнием «акыллым» дип дәшә.

— Эскәмиясе җайлы икән, рәхәтләнеп ял иттем.

— Әти ясап бирде. Минем әни — шофер. Ул юл йөрергә яратканга шофер булган. Сәфәр чыга алмасам да, юлны күреп утырырмын, дип ясаттырды әни эскәмияләрне.

— Хәзер кайда соң әниең?

Кызның авыз тирәләре мыймылдап куйды, күзләрендәге баягы җитдилек югалды.

— Хәзер... — диде дә, елап җибәрүдән тыелыр өчен, тукталып торды. — Хәзер... больницада әле...

Зөлфирә сүзне икенчегә борды.

— Ә син кая барасың?

— Казлар алып кайтырга. — Кыз җилкәсенә аскан уенчык сумкасын рәтләде. — Алларына ипи валчыгы сипсәң, минем арттан үзләре кайталар алар.

— Мине дә алып барасыңмы соң?

— Безнең казлар әнә теге тугайда гына булалар. Мин ипи ашаткач, — дип кабатлыйсы итте бала, — алар бер коенып кына чыгалар да кайталар үзләре миңа ияреп.

— Кешегә тимиләрме казларың?

— Ю-ук, алар олы апаларга тимиләр! Кечкенәләрне генә ыслап куркыталар. Минем дә синең хәтле апам бар. Ул колхозда сыер сава. Әле әти белән икесе әнине Казан больницасына алып киттеләр.

— Син үзең генә калдыңмы?

— Мин үзем генә дә курыкмыйм. Сыерны күрше әби сава, аннары, сиңа күңелсез булмасын дип, мине кочаклап кунып чыга инде. Әтиләр берсекөнгә генә кайталар әле. Әтигә дә Казанда озак торырга ярамый, зоотехник бит ул колхозда. Апа, син безнең авылга фермалар эшен тикшерергә килмәдеңме?

— Юк, акыллым. Йомышларым бүтән иде.

— Хәзер китәсең дәме?

— Синең белән казларны алып менник башта.

— Апа, син врачмы?

— Мин...

— Әнине дәваларга врач кирәк безгә. Минем әнине белсәң син! Минем әниме?! Иң әйбәт әни — минем әни!

— Врач табарбыз! — Зөлфирәнең әтисе шәһәрдә танылган хирург, тик моны хәзергә балага әйтергә ярамый иде: кыз Зөлфирәнең үзен врач дип уйлый ич.

— Минә ул шулай булсын иде, апа, кем дә булса каты авырып ятса, иң яхшы врачлар үзләре шуны белеп килсеннәр иде.

— Килерләр! — Зөлфирә этисенең ярдәм итәчәгенә ышана. Аның беркайчан да берәүнең дә үтенечен кире какканы юк. Бу кечкенә кыз да аның әтисе кебек фикер йөртә: кешедән изгелегеңне кызганма. Мин гомерем буе кешеләрнең миңа изгелеген тоеп яшәдем, мин кешеләргә гомерем буе бурычлы, ди аның әтисе. Ярдәм итәр әтисе, Зөлфирәнең әтисе бит ул!.. — Врач килер, акыллым! Ә әниеңнең кай төше авырта соң?

... Беркөнне Зөлфирәне дус кызлары шаярттылар.

— Сине бер абый эзләде.

— Ничек — абый? Бабай, диген!

— Йөз яшьлек бабайга бабай диярлек булмагач, кызык та түгел, — диде Зөлфирә шаяруга шаяру белән.

— Менә бер төргәк һәм хат язып калдырды, — диде дежур администратор. — Исемеңне дә белмәгән икән. Күперенгән сары чәчле, сипкелле дигәч кенә сине эзләвен аңыштык. Танышканда исемеңне әйтә торган бул...

Зөлфирә артык кызыксынмыйча гына конвертны ачты.

«Зөлфирә!

Теге чакта, февральдә, миңа Бигешкә очарга ярдәм иткән идегез. Ашыгычлык белән Сезгә рәхмәт әйтергә дә онытканмын. Бик зур рәхмәт.

Зөлфирә! Бу сәфәремдә дә Сезгә борчу ясарга туры килә әле. Шушы төргәкне авыл хуҗалыгы институтының өйрәнү-тәҗрибә хуҗалыгына илтеп бирә күрегез. Тышына кемгә икәнлеге язылган. Ул Мәскәүгә командировкага киткән, ай ахырында кайтачак. Үзен күрсәгез әйбәт булыр иде. Төргәктә бозыла торган әйбер юк, язулар гына. Кире алып китмәдем инде. Монысы Сезнең изгелегегезгә ышанудан. Аннары Казанда минем туган-тумачам яисә йомыш үтәрдәй дус-ишем дә юк.

Сез минем күңелемә изге кеше булып кереп калдыгыз. Һәрвакыт шулай яшәгез.

Депутат абый».

Хәтерли Зөлфирә бу кешене, ничек өзгәләнүе һаман күз алдында. Исем-фамилиясе ничек иде соң? Зариф, Шәриф, Гариф? Юк. Истән чыккан. Паспортын алып, билетны үзе тутырган иде, югыйсә.

... Таныш түгел абый яшәгән якларга менә Зөлфирә үзе киләсе итте. Быел, ял алгач, Чаллыны һәм Түбән Каманы күреп кайтырга булды. Үзең күпме кешеләрне шушы якларга озатып җибәр дә, үзең Бигеш аэропортын да күрмәгән бул инде. Их, әлеге абый адресын калдырса, Зөлфирә барып кына чыгар иде аларга. Шулай да, очратырмын бәлки дип, берничә авылны йөреп узасы итте ул. Теге абый үзе очраса инде. Югыйсә, аның турында сорашып та булмый бит: фамилиясе ничек тә үзе ни исемле, кайда эшли? Очратмаса инде, абыйның үзе килеп күрүен көтәргә кала. Йөрүнең ни зыяны, авыл табигатендә рәхәтләнерсең ичмасам бер. Бәлки теге абый очрап та куяр. Таныр иде микән аны Зөлфирә? Таныр иде, мөгаен. Калын кашы ярты маңгаен диярлек каплаган, ияге озын, очлы. Күзләре нинди иде? Төсе онытылган, ә болай... Ул күзләрне борчылу катыш кайгы пәрдәсе тоныкландырган иде.

Хәзер кайгысы беттеме икән? Зөлфирәнең тагын берәр ярдәме кирәкмиме икән аңа?..

Теге төргәкне илтеп тапшырды инде Зөлфирә. Якты чырайлы, ап-ак чәчле карт кына кеше рәхмәтләр яудырып алып калды.

Кайгылы абыйга тагын нинди ярдәм итә алыр икән Зөлфирә...

— Безнең әни машинасы белән юлда кунды бит. Шундый да буран иде ул төнне — берни күренми. Апам белән икәүләп төн буе

көттек. Әти Казанда иде. Анда кар бөтенләй дә яумаган, болай гына болытлы булган.

... Шул абыйның кызы бит бу!

— Әни төне буе азапланган. Юлдан карны көри икән, ә машинасына менеп утырганчы тагын кар басып китә... Машинасының бензины да беткән аннары. Аяклары өшегән, кулларына берни дә булмаган менә. Хәзер аяклары йөрми. Әчена салкын тигән.

— Үпкәсенә.

— Шул төннән соң гел йөткерә. Ул чакта әти әнине больницага салгач кына кайтып җитеште. Әтине эзләп колхоздан Казанга да шалтыраттылар. Үзе туры килмәсә дә, тиз табып әйткәннәр әтигә, хәзер үк кит, дигәннәр. Тик февральдә самолетлар очмады бит. Әнине баштан ук әти караса, әнинең авыруы көчәеп тә китәсе булмаган икән. Чөнки әни әйтә, ни ди, әтиегез хәстәрләп тәрбия иткәч, хәлем көннән-көн әйбәткә бара, ди.

...Әйе, әйе, шул абыйның кызы! Менә нинди хәсрәт кичергән икән ул абый...

— Февраль азагында рәттән өч көн самолетлар очмады, оча алмады алар, сеңелем. Кирәк бит...

Кырый бакча буендагы чирәмле сукмактан велосипедлы кыз килә. Зөлфирә, үр күтәрелгәндә, велосипедны этәләп ала. Аларга ияреп, аллы-артлы тезелешеп, эш майтарган кыяфәт белән, казлар менә. Иң алда — озын муенлы күк бәбкә каз, артта оя башлыгы — ана каз.

— Апа, миңа быел җиде яшь тула. Әти миңа туган көнгә ике тәгәрмәчле велосипед ала. Аннары тагын да катырак очам инде мин!

— Бик әйбәт булыр!

— Тик ул миңа велосипедны әни терелгән көнне алып бирсен иде.

— Алай озак булмасмы соң?

— Ю-ук, озак түгел! Минем туган көн кар яугач кына. Ә әни, киләсе атнага ук кайтырмын, диде.

Алар таллар турысына җиттеләр. Казлар, агачлар күләгәсенә кергәч, гайрәтләнеп каңгылдаша башлады — масайганнар, юл күрсәтүче кирәкми, янәсе, хәзер.

— Акыллым, кил әле, шушы тал төбендә рәсемгә төшерим әле мин сине.

— Фотоаппаратың юк ла.

— Бар. Сумкада... Рәсемеңне әниеңә җибәрерсең.

— Апа, минем әни республиканский дигән больницада. Син врачмы соң? Әйтмисең гел. Врач булсаң, син ул больницаны беләсеңдер ич инде.

— Рәсемеңне үзем кертермен, яме. Бүген Бигешкә барып җитешсәм, бүген үк Казанга очам. Төнлә рәсемеңне ясыйм да, иртәгә әниеңә илтәм.

— Хәзер безнең авылдан Бигеш ягына машина китә. Почта машинасы. Көн саен кич җидедә. Шоферына мин киткән саен кул болгыйм, ул миңа бармак яный, велосипедың белән юлда йөрмә, ди, машинаны таптатырсың, ди. Шул машинага утырып китәрсең, апа, яме?

Зөлфирә кызны ике тал янында рәсемгә төшерде.

— Акыллым, ә фотоны кемгә бирермен соң мин?

— Әнигә дидек бит.

— Кем соң ул?

— Зариповлар инде без. Әти — Зиннәт Зарипов, әни — Хөршидә

Зарипова, апам — Рәсимә Зарипова, ә мин... Апа, нигә син күзләреңне йомдың?

...Әйе, әйе, Зиннәт Зарипов! Бутап язмасын дигәндәй, берничә тапкыр кабатлады хәтта: Зиннәт Зарипов... Зарипов Зиннәт...

— Болай гына... Ә синең үз исемең ничек?

— Зөлфирә инде.

— Адашлар икәнбез ич! Мин дә Зөлфирә.

— Мин — Зөлфирә Зиннәт кызы Зарипова. Өч тапкыр «з» хәрефенә башланган исемнәр әйтә белсәң, мине онытмыйсың. Миңа Зөлфирә Зиннәтовна дип тә эндәшәләр.

Туры урамның аргы башында машина күренде.

— Зөлфирә апа... Әй, болай әллә ничек икән... Мин үземә үзем апа дип әйткән кебек булам... Апа, син минем әни янына барырга онытма, яме! Менә бу чәчәкне әнигә бирерсең! — Кече Зөлфирә юл читендә үскән кыңгырау чәчәген өзде.

— Барырмын дидем ич. Әллә ышанмыйсыңмы?

— Ышанам. Мин бар-бар кешегә дә ышанам. Онытма дип кенә кабатлыйм. Үзеңне врач түгел дигәнгә генә ышанып бетмим әле.

— Онытмыйм. — Ул кызны күкрәгенә күтәреп сөйде. Кече Зөлфирә, тузанлы тәпиләре белән аның өстен буямас өчен диптер бәлки, аякларын тезеннән бөгеп торды. Олы Зөлфирәнең сипкелләрен — әллә инде куптармакчы булып! — тотып та карады, күперенгән чәчләрен сыйпады.

Машинаны туктаттылар.

— Апа, син врач булгач беләсең бит инде, әйт инде, минем әнинең аякларын кисмәсләрме? Аның йөткерүе кайчан бетә?

— Зөлфирә... Акыллым... Мин сиңа иртәгә үк хат язармын, яме, Зөлфирә Зиннәтовна, яме!..

— Апа, апа, безнең әнинең аякларын кистермәгез! Апа, дим, апа, ишетәсеңме?!

— Без очрашырбыз, Зөлфирә акыллым! Тагын очрашырбыз, Зөлфирә Зиннәтовна...

— Апа, хуш... Апа...

... Их! Нигә соң әле бу әйбәт апа Зөлфирәнең ялгызын гына калдырды? Ни өчен аны да Казанга алып китмәде...

Машина инде шактый ерак китеп өлгерде. Ә шулай да ара якыная барган сыман тоелды Зөлфирә Зиннәтовнага...

# СОҢ

Көрт койманы ашып килә. Багана башлары кар өстенә тезгән бүкәннәр кебек, ә яткырып сугылган такталарның өске читләре шул бүкәннәрне әйтерсең бер-берсенә бау белән тарттырып тора. Монда малай-шалайга футбол кыры инде — кар батмый, җир кебек каты.

Гәрәйша, көрттән шуып төшкәч, борылып карады — чаңгы карны анда-монда гына тырнаган иде. «Буран бабай карны ничек тыгызлап өйгән! Балалар бәхетенә инде!» — дип уйлады ул. Әмма кузгалып кына китте — чаңгылары кар эченә чумды. «Күр инде, бер адым җир — ике төрле кар! Тыгызлап салынганы сыек шәмәхә төскә манылган, йомшагы — ап-ак. Әллә киресенчәме, ап-агы йомшак, ә сыек шәмәхәсе тыгызмы?»

Уйлый калсаң, бөтен табигать, бөтен дөньясы шулай капма-каршылыкка корылган инде. Кешеләр дә шулай. Бар йомшак күңеллесе, шөкер, чытырман-чәнечке холыклысы да җитәрлек. Сөйгән-сөелгәннәре күп, сөеп тә сөелмәгәннәре дә шактый...

Ул, уйларын таратырга теләгәндәй, ярыштагы кебек ашыгып шуа башлады. Тукта, кая болай очына соң әле ул?..

Гәрәйша шууын акрынайтты. Тик адымласаң да уйлар аңа тагылганнар, җилдертсәң дә аңардан калышмыйлар.

Үр төбәсен үткәч, иелеп этенә-этенә, түбәнгә — Шушма ягына тизрәк шуып китте ул. Нигә, уйларны да канатландырып, алар белән янәшә очмаска соң? Нигә тыелырга? Ни дип әле теләкләреңне томалап, йөрәккә богау салып яшәргә? Үз тормышыңны үзең корыту, үз бәхетеңне үзең төенләү түгелме соң бу?..

Ул Сабый тугаеның кырт киселгән һәм кар ятмый торган ярына терәлгәч кенә шып туктады.

— Киткәннәр икән... Киткән...

Хыял-уйларны аның үз сүзләре йомып куйды.

— Киткән...

Гәрәйша боз өстенә таллык башыннан әйләнеп төште һәм балыкчылардан калган бәкеләргә чаңгы таягы белән төрткәләде. Бәке авызлары чираган иде, тишекләрдән полт итеп су бәреп чыкты — күптән түгел генә кузгалганнар, димәк.

Петрух бабайларны шушында күрергә иде исәбе Гәрәйшаның. Һаман саен өйләренә барып йөрү уңайсыз бит. Әмма соңлады менә.

— Ашыгасы иткәннәр икән... Гадәттә тәмам караңгылык иңгәнче утыралар иде... Балык чиртмәгәндер, күрәсең.

...Гәрәйшаның Петров-Петрух дәдәй турында элек тә ишеткәне бар иде, чөнки Петрух — районда яшәүче удмуртлар арасында мәзәкче булып танылган кеше. Аның үзен гомердә күрмәгән кешеләр дә, мәзәк сөйләгәндә, Петрух дәдәй әйткән, дип кыстырырга онытмыйлар. Ихтимал, бу шаянлыкларның күбесе Петрухка сылтау гынадыр. Балтач төбәгендә яшәүче удмуртларның җорлыгын бер Петрухка гына кайтарып калдыру дөрес тә булмас. Әмма барыбер Петрух Петрух инде — удмурт дөньясы аны беркайчан да читләтеп узмый.

Алар былтыр җәй генә таныштылар. Петрухлар авылына Гәрәйша эш белән килгән иде. Йомышы шул — дүртенче класс җитәкчесе итеп билгеләнгәч, бу авылдан йөреп укыячак балалар белән алдан ук танышып куярга иде аның исәбе.

Балаларны күреп, аңлашып-сөйләшеп дигәндәй, инде китәр юлга борылганда, Гәрәйшага Петрух дәдәй очрады.

— Безнең сабак балабыз юк, шулай да безгә сугыл. Безнең самаварның чәе тәмле, — дип чакырды ул аны.

Карышмады Гәрәйша, үзе дә мәзәкчән удмурт карты белән танышырга теләп йөри иде.

— Авылга килеп, бездә чәй эчмәгән кеше булмаска тиеш, учитель. Аннары, ошап куйдың әле син миңа: үзең балаларны барлап килгәнсең. Ә бу, белүемчә, сезнең эштә мәҗбүри түгел бугай. Яратасың, димәк, аларны. Әйдә...

Чәйдән соң Гәрәйша, өй нигезе кырындагы буй тагарак өстенә утырып, папирос көйрәтте. Бераздан Петрух та аның янына чүгәләде.

— Тартасың икән, — диде ул.

— Гадәт инде.

— Син аны урак өстендә генә булса да ташлап тор. Нигә, дигәндә, урак өстенең үзенең тәмле исе була. Ә син, тәмәке сөрсетеп, шуны тоймый каласың.

Петрух дәдәй мәзәк сөйлидер дип көткән иде Гәрәйша. Аңарга бит мәзәк кенә булсын! Ләкин картның йөзендә-сүзендә шаянлык бөтенләй сизелмәде. Гомумән, аңа Петрух турында моңарчы ишеткәннәре ялгандыр, бу кеше бөтенләй шаярта белмидер сыман тоелды. Бу удмурт агаеның телен мәзәккә бору өчен әллә берәр сәбәп кирәкме дип уйлады Гәрәйша.

Петрух абзардан бер уч печән алып чыкты.

— Урак өстендә печәннең дә исе үзгә — җитлеккән була, бөркелеп тора, — диде ул. — Бик беләсең килсә, хәзер менә шушы күләгәнең дә исе бар.

Яртылаш кына тартылган папирос, тагаракка каплаган такталар арасыннан суга тидергәч, чыжлап сүнде.

Өйдән зәңгәр күзле Любаша чыкты. Күләгәгә кергәч, аның күзләре тагын да зәңгәрләнә төште. Ничектер җәйге эңгер-меңгердәге урман күле төсен хәтерләтте бу минутта алар Гәрәйшага. Кыз, Петрух белән Гәрәйша янынннан үтеп, капкага юнәлде. Кече капканы яртылаш ачкач, борылып:

— Мон кошки, атай [1], — диде.

— Ярар, Любаша, бар...

— Исән булыгыз, сөйләшми торган абый, — дип күз сирпеде кыз аннары Гәрәйшага. Любашаның нечкә кашлары бөгелеп куйды. — Тагын килегез.

«...Чыннан да, нәкъ Тәгъзимә төсле бит бу кыз! Күз сирпүе дә нәкъ Тәгъзимәнеке...»

— Төпчек кызым, — диде Петрух. — Соңгысы, — дип кабатлады ул бераздан. — Башкалары кош балалары кебек таралыштылар. Любашаны үз яныбызда гына торгызасы иде, әмма без теләгәнчә булмас шул. Сизәм, сизеп торам — төпчегем дә очар...

«Мондый чибәрне ата-ана канаты астында саклап булмыйдыр...» Гәрәйшаның башыннан шул уй йөгереп узды.

— Әйбәт эшли колхозда. Сарыклар карый, макталып килә.

«Уңган кызны егетләр тиз күрә, Петрух дәдәй...»

— Унынчыны бергә бетергән яшьтәше быел хәрби училищены тутырып командир булып кайтты. — Петрух бер мәлгә тукталып калды да ачыклап әйтте: — Сезнең мәктәптә түгел, Чепьяда укыды алар. Егет хәзер йолдызлы погоннар таккан, агайне. Шул чая егет, бер елдан өйләнешәбез, Любаша, дигән икән. Кызның бу хакта безгә тел ачканы юк әле.

«Хәрбиләр кыю була, эти кеше...»

— Нишләрсең бит, ата-бабадан калган йола. Каршы килеп булмас.

«Каршы төшеп тә ни кырырсың, Петрух дәдәй?!.»

— Бәхетләре булсын.

«Шулай дисәң инде...»

— Сөер кеше икәнсең, мин һаман лыкылдыйм, ә синең сыңар сүз әйткәнең юк.

«Күңел бутала бугай, Петрух дәдәй...»

— Любаша дөрес сизгән икән, сөйләшми торган абый, ди.

«Елмайганда кашы аз гына тартылып куйды үзенең...»

— Ярар, сөйләшәсең килмәсә, кыстамыйм.

«Петрух дәдәй, урак өстендә һәр нәрсәнең исе тәмле-татлы була, дисең. Хәтта һаваның да, хәтта күләгәнең дә. Урак өстендә яшьлек исе дә үзгә була икән бит... Бу вакытта уянган мәхәббәтнең дә исе бүтән бугай... Алай буламы соң әле ул?..»

Любашаны өйдә беренче тапкыр күргәч, Гәрәйша каушап-сискәнеп, тетрәнеп киткән иде.

— Тәгъзимә!! — дип кычкырып җибәрә язды ул.

Һәм бер мизгелдә аның башыннан бихисап уйлар куыша-чорнаша бөтерелеп үтте.

«... Юк, Тәгъзимә ничек терелеп кайта алсын?.. Инде елы тулып килә. Кайтса да, ул нигә монда булырга тиеш? Ә бу удмурт кызы ни

[1] — Мин китәм, эти.

исемле? Любаша? Шулайдыр шул... Нигә Тәгъзимә түгел? Ул нәкъ Тәгъзимә төсле бит... Тәгъзимәдер әле... Аның төсе-бите, гәүдәсе гел дә Тәгъзимә инде. Хәтта тавышы да Тәгъзимәнеке кебек — йомшаклыгы колакка ятышлы... Әмма син Любаша икәнсең шул... Тәгъзимә мине яратып күз сирпи иде...»

Петрух белән янәшәләп күләгәдә утырганда, бу уйларны ул кабат, инде ашыкмыйча, күңеленнән саркытып сөзде. Кыз аны сөйләшмәс итте, Любаша үзе...

Карт та, әнә, тукталды. Баштан ук сизенде ул, шуңа күрә, Гәрәйша йөрәгенә яра ясамаска, мәхәббәтне кабындырмаска тырышып, дәлилләрне саклык белән эзләп сөйләде. Гәрәйшаны чакырып, ике йөрәкне бер утка салдым бугай мин тиле-юләр, дип газаплады Петрух үзен. Бәлки алар бер-берсен тапмаган-белешмәгән булырлар иде... Уты бер, ә ике йөрәк ике учакта янарлар инде.

...Петрухлар авылына җәяүләгәндә дә бер тын алуга барып җитәсең, ерак түгел. Һәм Гәрәйша шушы удмурт авылы ягын якшәмбе саен диярлек урап кайтырга гадәтләнде. Туры Петрухларга керә һәм, озакка тукталмастан, картның хәлен генә белешә иде. Кайчакта Шушманың Сабый тугаенда очрашалар. Шул сәфәрләрдә Любаша туры килсә, кыз аңа һаман да бер сүзне әйтер иде:

— Исәнме, сөйләшми торган абый!

Һәм Любаша алдында Гәрәйша чыннан да бер сүз дә сөйләшми. Ә Петрух белән бөтенләй үк сүзсез утырмый. Кыска-кыска соравы белән дә Петрухны озак сөйләтә иде. Бервакыт, җир туңдырып та кар төшәргә өлгермәгән чакта әле, Петрух озата чыккач, аңа болай дигән иде:

— Мин генә кунак булу килешми, үзең дә, Петрух дәдәй, безгә рәхим ит. Апа белән парлап, Любаша да барсын...

— Булмас шул.

— Аңламадым.

— Карчык белән Любаша барсыннар, тыярым юк.

— Син үзең?

— Мин бармыйм.

— Нигә?

— Син гаҗәпләнмә, тәртип шундый инде минем. Ишеткәнең юкмыни бу турыда?

Шушмадагы асылма басма турына төшә торган тыкрыкка борылгач, Петрух кыска бер хикәятен сөйләде.

— Безнең басу аркылы кайчандыр Гондыр елгасы аккан. Сезнеңчә Аю елгасы була. Хәзер суы кипкән инде. Шуның башланган төшендә гөлҗимеш агачлары күп. Шәп агач, сез, татарлар, аны кайчак тагын да матуррак исем белән атыйсыз — саваплы җимеш, дисез. Карсыз вакытта мин шул саваплы җимеш куаклыгын көнаралаш барып карыйм. Нигәме? Чөнки агачлар гына түгел, ә елга башы үзе дә саваплы кебек. Бирге болында Шушманың элекке эзе булып күл калды. Төнбоеклары тын гына тирбәлә, камышлары сызгырып үсә күлнең. Шунда мин ел саен көймә төшерәм. Үзем инде көймәгә утыра алмыйм, баш әйләнә — картаелды. Кирәк кеше игелеген күрсен. Аннары, конюшня утарына кергәч тә, әйләнмә кайрак бар. Колхоз оешканнан бирле шунда тора, кайрагы һаман тузмый — шәп икән. Шул кайракның тагарагын ташлар белән тераткәннәр. Бер ягындагы таш тигезләнгән мәрмәрдән дә шома, икенче ягындагысы пычак йөзедәй үткен кырлы. Шундый ташларны мин бүтән җирдә күрә аламмы? Бөтен дөньясына берәр генә алар...

Петрух түн якасын торгызды, сирәк мыегын шомартты.

— Миңа бит, Гәрәйша, көн дә бәйрәм. Күзем ачылгач та күргән әйберләрне көн саен кабат күрәм мин, үзгәрешләрне белеп торам.

Бер күргән төшне икенче тапкыр күрә алмау — бәхетсезлектер ул. Минем гел күрергә күнеккән кырларым-тауларым, урманым-суларым бар. Үз авылым...

«Туган якны яратуы үзенчә икән Петрух дәдәйнең...»

— Үз авылым байлыгы җитә миңа. Минем хәтта беркайчан күрше авылга да барганым юк.

«Гадәтең сәер икән, Петрух дәдәй...»

— Кешеләр үзләре килә безгә. Хәтта күрше-тирә кунарга керә. Өегезнең һавасы әйбәт, диләр. Шулай булмый ни, юан нарат бүрәнәләрдән ундүрт нигрәле итеп салдык бит өйне, биек итеп.

«Өй зурлыгында гына хикмәт түгелдер, күңел киң сезнең. Туган җирне бөтенләе белән күңелегезгә сыйдырган кешеләр икәнсез...»

Петрух басма тросын бәйләгән багананың түгәрәкләп шомартылган башына терсәге белән таянды.

— Шулай да авылдан бер тапкыр китеп торырга туры килде. Сугыш кырына барып кайттым. Гитлерның миңа атаган «күчтәнәче» булган икән, мина кыйпылчыкларын ботка санаусыз тутырган иде, докторлар, чүпләп бетерә алмыйча, озак интектеләр. Сугыш ул матур истәлек түгел.

«Сугыш кыры — иген кыры түгел, дип әйтүең инде...»

— Ачуланма, Гәрәйша, бармыйм мин сезгә, үзең килеп йөр, ешрак кил. Любаша әйткәнчә, сөйләшми торган абый.

«Любаша бүген күренмәде, эштә булгандыр. Теге чакта, беренче очрашканда, күз сирпеп карады. Миңа! Тәгъзимә кебек... Нигә икән?..»

— Тавыкның ерак сәфәре әрәмәлек, дигәндәй, мин дә шул авылыбыз тирәсеннән ерак китә алмыйм. Ә балаларым ил гизә. Йөрсеннәр — теләкләре. Любаша да китәр, китәчәк. Булачак кияү, командирымнан рөхсәт сорадым, тиздән кайтам, туй ясыйбыз, дип хат язган. Любаша аны әнисенә укып күрсәткән, миңа әйтмәде үзе, кызлар сере әнкәгә сыя шул. Мин яшьләрнең теләгенә каршы килмим. Озатырга җыенабыз Любашаны...

«Шулай тизме?»

... Петрух белән Любашаны Гәрәйша бу яңа ел кергәч тә Сабый тугаенда очраткан иде. Якшәмбеләрдә карт шунда балыкка йөргәли. Любаша да бу көнне аның белән төшкән булган. Гәрәйша алтынчы класста укый торган малаен иярткән иде. Алар шушы тугайга чаңгыда шуып килгәндә, Петрух белән Любаша балыкны алмаш-тилмәш чыгарып кына торалар иде. Боз өстендә алабугалар, бәртәсләр карга манчылып сикерешәләр.

Малае чаңгы эзе белән яр-тауны сырлап бетерде, ә Гәрәйша гел балыкчылар янында булды. Тәненә суык кагыла башласа гына хәрәкәтләнеп җылынып алды. Ул һаман Любашаның күз сирпеп каравын көтте. Әмма беренче очрашудагы караш кабатланмады. Юк, кабатланмады... Дөрес, Любаша аңа күтәрелеп тә карамады.

Ә малайны озак-озак текәлеп күзәтте. Аның чалбар балакларыннан төерләнеп каткан карларны куптарып төшерде. Йөгереп килеп ялтыравык бозда җитәкләшеп шудылар. Хәтта малайны йомшак кына итеп күкрәгенә дә кысты. Тегесе дә Любашага сыенды. Тик бу күз иярмәс тиз булды, икесе дә, хисләрдән айнып, ярамый, дигәндәй бер-берсеннән тайпылдылар. Нәрсә турында уйладылар алар? Ахры, малай — әнисен, Любаша — шул ананы алыштыру мөмкин булмавын...

Әйе, Гәрәйшага бөтенләй карамады, курыкты бугай. Нидән? Кем белә инде...

«Әй, йөрәк, нигә җилкенәсең соң әле? Любашаның капкадан чыгып барганда күз сирпүе ялгыш кына булгандыр, ул үзе моңа әһә-

мият тә итмәгәндер. Әле бәлки бөтенләй күз дә сирпемәгәндер. Өлкән бит син, Гәрәйшә. Любашадан күп өлкән. Инде бер өйләнгән кеше, малаең үсә... Тәгъзимәң юк югын... Ничек инде — юк? Ә Любаша? Ул Тәгъзимә бит инде, нәкъ Тәгъзимә!.. Әй, йөрәк, җилкен, әйдә, яшерен сөй дә яшерен көй! Белмәсен дә моны Любаша! Шулай да... Любаша элеккечә бер генә карасын иде. Тик бер генә тапкыр, ял булыр иде сиңа, йөрәк...»

— Бүген Петрух дәдәй ялгызы гына идеме икән, әллә Любаша да төшкән булганмы? Әллә монда башка балыкчылар утырганмы? — дип куйды үзалдына Гәрәйшә һәм тугайдагы бәкеләрне тишеп бетергәнче борылып-сырылып йөрде.

Әнә, Петрух дәдәйләр авылы. Елга эчләтеп кенә барсаң да була, авыл ягына елга туп-туры сузыла, әйләнеч түгел.

Гәрәйшә соңгы бәкегә күзләрен кыса төшеп карап торды — керфекләрен бәс сара иде.

«Әллә барып килергәме соң? Ай тула инде күрмәгәнгә. Үткән якшәмбеләрдә чыгып китеп булмады, өй һәм малай мәшәкатьләреннән арынмыйсың...»

Ул рәшәткә буена көрәп өелгән чокырлы-кантарлы көрткә чаңгыларын кадады. Ботинка ырмавындагы карларны себергәч, ишек шакыды.

— Әйдүк! — диделәр эчтән. Һәм Петрух ишекне учы белән сугып ачып җибәрде. — Гәрәйшә! Нәрсә син, белмәгән-күрмәгәндәй, ялындырып кына керәсең?!

Гәрәйшә өйнең Петрух мактаган ләззәтле һавасына чумды. Бөтен йорт эче аңа Любашаның карашыдай сирпеп карый иде.

— Бик сагышлы заманнар әле. Туйдан соң өйдә һаман ямансу, инде өч атна үтте, югыйсә. Өйдән чыгып та йөрисе килми. Теге командир егет, кияүне әйтәм, Любашаны алып китте бит тәки...

«Киткән икән...»

— Төпчек кызны, соңгы баланы озатуы авыр булды...

«Соңгы... Мәхәббәтнең дә соңгысы була икән, Петрух дәдәй... Һәм соңарганы...»

— Әйдә әле, сөйләшми торган абый, сыйланып, күңел ачып утырыйк әле бер! Дөньясы үзебезнеке бит, шөкер иткересе!..

«Күңел ачарга риза, Петрух дәдәй. Әмма күңел беркайчан да бөтенләй ачылып бетмәс бит, беркемгә дә сөйләнмәячәк сере бар аның. Ялкынын сүндермичә мәңге сөяр, мәңге сызар йөрәк...»

— Бәхетләре үзләре белән булсын кызыгыз-киявегезнең, Петрух дәдәй! Миннән аларга — иң изге теләкләр. Ихластан.

— Рәхмәт яхшы сүзеңә. Менә хаты килде әле Любашаның. Әйбәт барып урнашканнар. Кияү башлы малай шул безнең! Любаша сиңа да сәлам җибәргән. Үзең укы, мә, татарча язган ул төшен...

Гәрәйшә хатның соңгы битен ачты: «Атай! Сөйләшми торган абыйның килгәне бармы? Миннән аңарга күп сәлам әйт. Һәм малаена да».

...Любаша өйнең кай төшенәдер яшеренгән дә, теге чактагы кебек — капкадан чыгып баргандагы кебек — күз сирпеп карый иде. Карый бит менә, карый, тик үзе генә күренми...

**Роза Хәлиуллина**

## Каенана

ПОЭМА

Сылу булып үсеп җитте
Каенсеңелем Әлфия —
Әле генә гөл кия дә,
Гөлен салып ал кия...
Каенанама дәште бер көн
Чая каенсеңелкәш:
«Әни, миңа син баш түгел,
КамАЗ, БАМнар, Себер баш»...
Каенанам Казанда калды
Күзләреннән түгеп яшь...
«Олакты» башларын алып
Каенсеңел — чая баш!

Еллар үтә, хатлар килә:
«Саумы, чибәр җиңгәчәй!
Безнең хәлләр ярый әле,
Җитә шикәр, җитә чәй...
Җиңгәй, мине Себерләргә
Тарткан икән мәхәббәт!
Башым алып «олагуга»
Булган икән шул сәбәп.
Таныш бул: менә минем яр.
Җәмил. Себер татары.
Җиңгәй, җибәр әле безгә
Суган-сарымсакларың...»
Илләә кырыс, илләә чая,
Гадәте шул һаман да:
Чит якларда төче күптәй,
Ачы көтә Казаннан.
Төчесеннән ачысына
Омтылырсың һаман да...
Тик иләшә алсаң ярый
Анда Себер бабаңа.
Себер каты ормагае
Гөлдән нечкә балага.
(Язмыйм инде, уйлыйм гына —
Шомлану ят аларга).
... Сарымсаклар эзләп менә
Килеп чыктым базарга.
Татлысы бик булмаса да,
Ачы күп ул Казанда.

«Салам суган-сарымсагын,
Шул кирәкме, Себер? Дәш!
Дус-ишләрен, үз ишләрен
Сыйласынчы сеңелкәш!
БАМ төзергә булышсынчы
Безнең ачы-төчеләр!..
Ачы-төче тату кирәк
Сезгә, чая кешеләр!
Сарымсаклар белән салам
«Сакмар» белән «Сарман»ны!
Татарстан җырлары да
Төзешсеннәр БАМнарны.
... Кулга алган гамәлегез
Түгел, сеңел, җиңелдән,
Әмма «Себер — кәтер» түгел,
Кадер көтә Себерләр.
Меңәр еллык карагайлар
Гөрселдәп ауган чакта,
Кайнар-кайнар сәламнәр яз,
Ешрак яз туган якка.
Ә Себерне кадерләгез,
Бер кадерләр Себер дә.
Хәтерегез калмаячак,
«Себер киткән» сеңелләр».
...Салдым шулай ящикларга
Казан кучтәнәчләрен.
Салмадым тик каенанамның
Түккән ачы яшьләрен...
Тормас ич ул сылу сеңел
Һаман ал да гөл көйгә —
Гүзәллеген ятка түгел,
Бирә ул ич илкәйгә.
... Монысын да әйтмәдем мин
Хатларымда гөлкәйгә:
«Тапмадыңмы, татар эзе
Төшми калган җир кайда?..»

Әлфиякәй тормыш корган.
Ире Җәмил — якты йөз...
«Чибәр җиңгәй, улым туды.
Җәлил диеп атыйбыз...
Җәлил туе — яшенле туй
Булды безнең Амурда.
Күкрәп-яшьнәп күк уйнады,
Коеп торды яңгыр да!
Апкилдек бу яланнарга
Синең сәламнәрне дә.
Яңгырларга манчый-манчый
Өздек «Сарман»нарны да.
Беренче кат бәбинең дә —
Бал-май түгел — ирненә
Сарымсакны сыгып, суын
Тигезәләр бирәдә.
Ә аннары шул суны без
Имезлеккә тигездек.
Себер икән Себер дидек,
Себер сорый тигезлек...»

— Әнкәй, әнкәй, Әлфиякәй —
Инде Себер килене!
— И илаһым, төпчегемә
Сабырлыклар бир инде!
— Әнкәй, әнкәй, оныгың бар,
Җәлил атлы оныгың!
...Җәлилем! — дип,— оныгым! — дип,—
Елый ана күнозын!..
Иртәгесен каенанаем:
«Китимче, ди, БАМнарга?
Балам — ил төзергә, ә мин
Кирәк — бәби багарга!»
...Һай, телләрем, һай, телләрем,
Ник тыела белмәдем?
Себерләрдә ничек чыдар
Чал анамның йөрәге?
... Изге юлга чыгып киткән
Ананы кем карт дия?
Баксаң, «бәби багасы» дип,
Дәшкән икән партия!
«И балакай», «балам» ди-ди
Анам БАМда ярсына...
Бәби генә баккан килеш
Ул үзе дә БАМ сала.
«Син баш түгел!» димәс хәзер
Әлфия дә, аңлагач:
Балага да, БАМнарга да,
Себергә дә ана баш.

«... Килен, миңа насыйп булгач,
Суырам суган суы...
Әй сагынам туган якны,
Сагынам Идел суын...»
Шулай дип хат язган бит ул,
Ни диярсең син моңа...
...Бер уч туфрак, бер шешә су
Салдым анам — дустыма.
Белдем: БАМнар сузар өчен
Кирәк туган туфрак та,
Кирәк изге Идел суы
Тәкать җуйган бер чакта.
Себерләргә салдым инде
Ачым-төчем, җир, суым.
... Бала «дала!» ди... Ананың
«Бала» диеп җирсүе...
...Менә шулай, бу яшәүнең
Бик катлаулы җае бар —
Себерләргә китеп барды
Шулай минем Каеннар...
— Ачымы? Бал-май өстеннән
Узмый шул БАМ келтерәп.
— Сагышмы? Анысын аның
Ала икән кем теләп?
— Яшь Каеным — чая Каен.
Сагышланма, чал Каен!
Юкса, мин дә яннарыңа
Чыгып китәм, әнкәем!

«— Юк, юк, килен, килә күрмә,—
Дигән анам хатында. —
Син онытма шул туфракта
Яткан ирең хакында.
Туңмый гына үссен инде
Оныгым — Ринатым да.
Мең рәхмәтләр укып яшим
Җибәргән һәр хатыңа.
Үз ягымның төсләре дип
Хатларыңны йөз үбәм...
Ә гомер бер. Зая итмә...
Очрый калса үз дигән...»

Ә яшьлек ул кош белән бер.
Ни аңа җир чикләрең!
Әлфияләр бәйли икән
Көн-төн БАМның челтәрен!..
Карагайлар, йа, тайгалар!
Ах, җиңүе кыен да!
Ничек җиңел бирелсен БАМ
Гөлдән нечкә Каенга...
Сузылыр бу юл, сузылыр,
Гомер юлда узылыр:
Тундраларда туңа-туңа
Узган юл тик үз булыр.
... Ә мин менә кич утырып,
Чигү чигәм Казанда:
Ак батиска ефәк белән
Яулык чиктем анама!
Ак намазлык чиктем тагын...
Картаюын исәпләп...
Чиктем дә ак бүләкләрне,
Бер еладым кочаклап.
Бу ыруның мин бердәнбер
Караучысы Казанда.
Ак яулыклар чигеп салдым
Ак каендай анама!
Чал башкаен горур тотып
Баксын әле БАМнарга.
Бәби генә бакмый анам,
Китте БАМны багарга!
...Себердә минем Каеннар,
Шунда аналы-кызлы...
Аларга мин җырлар язам
Һәр җәй-кыш, язлы-көзле.
Шулай мин Казаннан торып
Булышамын БАМнарга.
Булышам Каеннарыма,
Себерләргә ярарга.
Шулай кылды безнең төбәк!
Мең төбәктән ни булыр?
Меңәр йөрәк шулай типсә,
Себер — бер гөл-ил булыр!!!

≈≈≈≈≈

# Вәзыйх Исхаков

# КАРТ һӘМ ЧӘЧӘКЛӘР

НОВЕЛЛА



*Язучыларның әдәбиятка килү юллары төрлечә. Берәүләргә кече яшьтән, мәктәп эскәмиясеннән үк әдәбият «чире» йога башлый, икенчеләре, олыгая төшкәч, ныклы белем алгач, әдәби образлар, кызыклы вакыйгалар дөньясына кереп китә.*

*Быел 50 яше тулган башкорт язучысы Вәзыйх Исхаков әдәбиятка Совет Армиясе сафларында байтак вакыт хезмәт иткәннән соң килә, ныклы ышаныч, какшамас иман белән килә. Моның бик җитди сәбәбе бар: Совет Армиясе офицерын татар һәм башкорт халыкларының Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чоры батырлары кызыксындыра. Мулланур Вахитов белән Әхтәм Бәхтизинны, Хөсәен Мәүлетов белән Якуб Чанышевны, тагын башка күп кенә геройларны ул архивлар аша, саргайган, әмма ут сулап торган документлар аша укучыларга кайтарып бирде.*

*Вәзыйх Исхаков белән мин 1965 елда, Мәскәүдә, революцион темага иҗат итүчеләр курсында танышкан идем. Туры сүзле, эчкерсез булганы, мавыгучан холкы өчен яраттым. «Идел кызы» романын язу теләген беренче мәртәбә миндә ул уятты.*

*Вәзыйх Исхаковны, гомумән, без, аның каләмдәш иптәшләре, үзе эзләп тапкан темага турылыклы булганы, илебез каһарманнарын армый-талмый эзләгәне, тапканы, яшь укучыларны мавыктырырдай итеп яза белгәне өчен ихтирам итәбез.*

*1927 елда туган, колхозда ат караучы, МТСта шофер, Совет Армиясендә офицер булган, Башкорт дәүләт университетын тәмамлап, «Агыйдел» журналында баш редактор урынбасары, Башкортстан Язучылар союзы идарәсендә җаваплы секретарь булып эшләгән, башкортча, татарча, русча дистәдән артык әсәр: повесть һәм романнар бастырып чыгарган каләмдәшебезне 50 яшь тулган көндә чын күңелдән котлыйбыз.*

*Иҗатың гел уңышлы, юлларың гел көяшлы булсын, Вәзыйх дус!*

*ГАРИФ АХУНОВ*

Күптән булганы юк иде инде аның монда. Бик күптән...

Килергә дип берничә тапкыр омтылып та карады. Әмма эш, мәшәкать аркасында килә алмады. Ә гомер дигәнең үткән дә киткән икән...

Хәбир Хәсәновичның техникум бетерүенә дә әле генә сыман. Шушы шәһәргә ул аягына чабата, өстенә сырган бишмәт киеп килгән иде. Аркасында биштәр... Аның яшь чагы. Егет чагы. Ул техникумда укып йөргән елларда монда югары уку йорты булдыру турында хәтта телгә дә алган кеше булмады. Хәер, ул вакытта шәһәр бик бәләкәй иде шул. Аны хәзер дә әллә ни зурайган, нефтьле районнардагы кебек киңәеп үсеп киткән диярлек түгел. Күбесе бер-ике катлы агач өйләр. Икешәрөчәр катлы таш йортлар бик сирәк. Аларның да күбесе искедән калып, әүвәлге өяз дәверен хәтерләтеп торалар. Тимер юллардан, үзәктән ерак булу сәбәпле, шәһәр артык зураеп үсеп китә алмаган.

Ләкин бу шәһәрнең үз матурлыгы бар. Урамнарга, тротуар буйларына һәм аллеяларга тезеп утырткан тәлгәш-тәлгәш каеннар шәһәрне бизәп, озын чәч толымнарын тарап куйган сихри матур кызларны хәтерләтә. Әйе, менә шушы ак каеннар да элек бик яшь иде бит. Аз гына искән җилгә дә сыгылып-бөгелеп торалар иде. Ул каеннарны утыртканда үзе дә катнашкан иде Хәбир Хәсәнович. Хәзер әнә шул каеннар танымаслык булып, карап туя алмаслык матур булып үскәннәр!..

Хәбир Хәсәновичның күңелен тетрәткән, аның яшьлеген, һәм, ниһаять, беренче мәхәббәтен хәтерләткән нәрсәләр аз түгел икән шул монда.

...Шушы шәһәрдә аның яшьлеге үтте. Бетмәс-төкәнмәс уй-хыяллар белән яшәгән чаклары шушында башланды. Беренче мәхәббәте шушында бөреләнде... Хәзер ул бөтен республикага танылган галим, профессор... Ә ул чакта мыек та чыкмаган бер егет иде. Аннан соң инде күпме сулар аккан, ә ул бер тапкыр да күреп китә алмады, шушы, яшьлеге үткән шәһәрне.

Ихтимал, бу юлы да ул үзе тәвәккәлли алмас иде әле. Ләкин аны монда дәүләт имтиханнарын кабул итү буенча комиссия председателе итеп билгеләделәр. Башка вакыттагы шикелле, эшем күп-фәлән дип, карышып та торырга урын калмады... Менә ул кызыл постау ябылган озын өстәл артында иң түрдә утыра.

Студентлар берсе артыннан икенчесе килеп билет ала. Берсе артыннан икенчесе имтихан тота. Тик Хәбир Хәсәновичның уйлары аларда түгел. Хәер, алай дип әйтеп тә булмый әле. Чөнки ул яшьләргә карап әллә кайчангы вакыйгаларны, үзенең дә яшь чагын хәтерләп утыра.

Заманында ул да менә шушы яшьләр сыман имтиханнар биргән иде. Соңгы имтихан көне хәтеренә аеруча нык уелып калган.

...Җәйге аяз көн иде. Хәбир, имтиханын тапшырып, атылып болдырга чыкты. Ишек төбендә аны сөйгән кызы Зөлфия көтеп тора иде.

— Ничек, Хәбир, булдымы? — диде Зөлфия, аңа омтылып.

Кызның озын керфекләре юеш иде. Тик Хәбир аңа артык игътибар итмәде. Ул имтихан тапшыру куанычына чумган иде.

— Биш! — дип җавап бирде ул горур гына итеп.

Аннары Зөлфияне култыклап алды. Кыз да сүзсез-нисез аңа иярде...

Урта буйлы, кабарынкы бөдрә чәчле, коңгырт күзләре ут уйнап

торган, уткер карашлы бер егет иде Хәбир. Аны күрсәләр, кызларның һушы алына. Ләкин егет аларның тик берсен генә — әле менә үзе белән култыклашып атлаган Зөлфияне генә сөя иде... Кыз да андый-мондый гына түгел. Ул буй-сын дисеңме, ул карлыгач канатларыдай каерылып киткән матур кашлар дисеңме — килешмәгән бер генә җире дә юк. Озын чәч толымнарын күргән егетләр борылып-борылып карыйлар иде аңа... Шәһәр зур авыл шикеллерәк кенә булгангамы, кая карама — танышлар. Бу шәһәр үзе кечкенә булса да, революция елларында зур-зур бәрелешләр, катлаулы вакыйгалр байтак булган монда. Тау башындагы туганнар каберлеге — шул тарихи хәлләрнең шаһиты. Каберлеккә мәрмәрдән мәһабәт һәйкәл куелган һәм ул рәшәткәле койма белән уратып алынган... Егет кызны шунда алып барды. Каберлек тау битендә булганга, әллә ни чаклы җирләр күренә иде. Аста боргаланып, киң тасма булып, Агыйдел ага. Ә аның аръягында болынлыклар, куе әрәмәлекләр, күлләр җәелеп ята. Елга өстендә баржалар, көймәләр йөзә. Нинди хозурлык, нинди матурлык монда! Өстәвенә шундый тыныч — беркем комачауламый...

— ...Хәбир Хәсәнович, ничәле куябыз?

Бу сорауны ишеткәч, профессор сискәнеп китте. Ул һаман әле үзен тау башында революция корбаннарына куелган һәйкәл янында, һаман әле беренче мәхәббәте Зөлфия янында хис итә иде.

Хәбир Хәсәнович ни диярга дә белмичә аптырабрак торды. Аның эндәшмәвен күргәч, бергә имтихан алучы укытучы соравын кабатлады:

— Сездән бәя көтәбез, Хәбир Хәсәнович.

— Шулаймы? — диде профессор һәм егеткә текәлеп карады да сорау бирде:

— Киләчәккә нинди планнар корасыз?

Егет баскан урынында таптанып алды. Аннары әйтте:

— Аспирантурада калырга дигәннәр иде, ләкин мин башта берике ел мәктәпкә кайтып эшләп килмәкче булам.

Укытучысы да аның сүзләрен раслап куйды:

— Ул безнең отличник, Хәбир Хәсәнович!

— Алай,— диде профессор.— Бишле куярга кирәк.

Аның фикерләре таркау иде. Шулай да ул егетнең соңгы җавабыннан канәгать булды. Профессор моннан кырык ел элек үзе дә шушы сорауны ишеткән иде. Тик шул чакта дөрес җавап бирә алдымы икән? Аны хәтерләми инде Хәбир Хәсәнович. Тик шунысын бик яхшы хәтерли: ул уку, белемен камилләштерү турында хыяллана иде ул чакта.

Профессор тагын инде ничәнче тапкыр уң кулы белән костюмының түш кесәсен капшап куйды. Юлга чыгардан ике-өч көн элек кенә аңа бер хат килгән иде — кесәсендә шул хат.

Ә теге чакта һәйкәл янында торган кыз аңа:

— Хәбир, әйдә, киногa барабыз,— дигән иде.

— Зөлфия, үзең уйлап кара: шушындый шатлыклы минутларда ничек кинода утырмак кирәк?!

Кыз үпкә белдерде:

— Әй, синең гел шулай, хыялый булдың инде!..

Алар сүзсез генә кайтыр якка атладылар.

— Ярый, ярый,— диде аннары егет, кызның кәефен табарга теләп.— Әйдә, синеңчә булсын.

Әмма аның бу соңарып ризалашуы кызга бөтенләй кирәк түгел иде, ахрысы.

— Сине тагын да укырга китә дип әйтәләр, шул хак сүзме? — диде ул, егетнең тәкъдимен гел дә җавапсыз калдырып.

Бу турыда ничек әйтергә дип, Хәбир күптән инде җай эзләп килә иде.

— Әйе, мине Уфага җибәрәләр, институтка,— диде ул.

— Алай икән...

Кыз бүтән эндәшмәде. Алар, акрын гына атлый-атлый, шәһәрнең үзәк мәйданына барып җиттеләр. Моннан чак кына читтәрәк элек зур чиркәү булган. Хәзер анда кинотеатр. Мәйданны уратып, икешәр катлы таш йортлар тезелеп утыра. Һәркайсы үзенчә матур орнаментлар, колонналар белән бизәлгән ул йортлар мәйданга аеруча бер ямь өстәп торалар иде.

— Ничәнче сеанска керәбез? — диде егет кинотеатрга якынлашкач.

— Юк, кинога кермик.

— Бәй, үзең бит кинога дигән идең.

— Хәзер кермәскә булдым.

Егет тә кыстамады.

— Яхшы. Әйдә, алайса, Агыйдел буена төшәбез.

Шунда ул кызның борчулы карашын тоеп алды. «Моңа ни булган бүген? — дип уйлады Хәбир эчтән генә. Күңеле белән нидер сизенепме, аның йөрәге әрнеде. Кызның борчылуына да үзенчә бәя бирергә тырышты: — Мин китәсе булганга хафалана торгандыр...»

Урам буендагы тар гына газон янына җиткәч, кыз егетне терсәгеннән тотып туктатты да:

— Хәбир, өзеп бирче миңа монавы чәчкәләрне,— дип, чәчәктә утырган канәферләрне күрсәтте.

— Што син, газон лабаса бу!

— Булса ни...

— Әйдә, мин сиңа базардан сатып алам.

— Юк, андагы түгел... Мин бүген синең кулыңнан шушы газонның чәчәкләрен алырга телим... Шушыларны, нәкъ шушындагыларны... Кем белә... Бәлки...

— Ярамый бит, Зөлфия.

— Бүген дәме?..

Шунда, төпченеп, беләсе калган да бит... Мәхәббәт утында янган яшь егетнең башы әйләнгән чак иде шул. Югыйсә, Зөлфия күңелендәге газабын сиздереп тә куйды да бит. Бүген дәме диде...

Кем уйлаган, кем белгән ул вакытта кызның күңелендә ниләр булганын! И-их, ул минутларны искә алмаска иде дә бит, юк, булмый шул, булмый...

Нәкъ әнә шул көнне кызга яучы килгән иде. Зөлфия каршы төшкәч, әнисе авыз да ачтырмады: «Ата-ана сүзеннән чыгып, кая бармакчы буласың тагын?» Шуңа да кыз, ашыгып, сөйгән егете — Хәбире янына йөгергән иде. Зөлфия барысын да аңа сөйләргә әзер иде. Егете әйтсә, хәтта шунда аңа ияреп кияүгә китәргә дә риза иде. Юк, әйтмәде бит...

Ә Зөлфиянең күңеле кителде дә куйды: ул баш иеп язмышка буйсынырга — әнисе сүзеннән чыкмаска булды. Әгәр шул минутта егете аңлаca икән аны... Әмма эш узган иде инде.

Хәбир бик авыр кичерде бу югалтуны. Төннәр буена йоклый алмый яткан чаклары да күп булды. Зөлфиянең сыны күз алдыннан китми җәфалады. Күпме хис, күпме сагыш түкте ул Зөлфия дип. Әнә шунда гына кызны ни тикле нык яратуын тойды. Әнә шунда гына мәхәббәткә ни тиклем җиңел каравын аңлады... Хатлар да язып карады ул Зөлфиягә. Тик бирсенә дә җавап алмады...

Профессорның уйларын имтихан алучы укытучы бүлдерде:

— Хәбир Хәсәнович, тәнәфес.

— Ә-әә...

— Тамак ялгап алыйк, — дип башлаган иде укытучы, профессор:
— Юк, юк, рәхмәт,— дип баш тартты. Ә бераздан өстәп куйды: — Шәһәрне карап килмәкче идем.
Өстенә плащын киеп, профессор урамга чыкты. Салмак кына атлап, ул яшьлеген, егет чагын һәм шушы шәһәрдә техникумда укыган елларны хәтерләткән юллар белән китте.
Барган саен аның йөрәге чәнчеп-чәнчеп алгандай итте. Алда әнә тәлгәш каеннар... Алар калын чәч толымнарын таратып җибәргән яшь киленнәрне хәтерләтә хәзер. Әнә теге тау башы... Тауга ук менеп торырга вакыты юк иде, профессор кирегә борылды. Ул, үзе дә аңламастан, теге вакытта чәчәк атып утырган түтәл янына барып туктады. Газондагы канәферләр нәкъ теге чактагы кебек шау чәчәк атып утыра иде.
Профессор шунда, шул газон янында бая имтихан биргән егет белән яшь кенә бер чибәр кызны очратты. Алар көлешә-көлешә үзара сөйләшеп торалар иде. Профессор колак салды.
— Өз инде анавы ак канәферне! — диде кыз бала.
— Ярамый дим бит...
— Ә син өз!
Бу сүзләр карт профессорның игътибарын үзенә тартты. Әйе, әйе, теге вакытта аның Зөлфиясе дә нәкъ менә шундый ак канәферләр өзеп бирүне теләгән иде бит...
Профессор үтә бер тәвәккәллек белән:
— Өз, егет, өз! — диде һәм, егетнең кыюсызлыгын күреп, газон өстенә үрелде дә чәчкәләрнең икесен өзеп алды.
— Ай-яй-й! Гражданин, бу ни эш, ә?
Профессор күтәрелеп караса, каршында матур гына бер ханым тора иде. Профессор каушап калды.
— Ә... Гафу итегез,— диде ул ят бер тавыш белән. Аның кулындагы чәчкәләре җиргә төште.
Хатын профессорны шелтәләде:
— Олы кеше үзегез! Яшь-җилкәнчәк булса тагын бер хәл.
— Гафу итегез...
Ул арада алар тирәсенә кешеләр җыелып өлгерде.
— Вот сиңа картлач! — диде арадан берсе әче телләнеп.
Профессор уңайсызланудан кулларын кая куярга белми тора. Бу хәлгә әлеге егет белән кыз да аптырап, бер як читтәрәк басып торалар иде. Хәбир Хәсәнович, иелеп, җиргә төшкән чәчкәләрне алды да берсен теге матур кызга сузды.
— Мә, кызым, миңа да бүген нәкъ шушы канәферләр кирәк иде.
Карт профессорның әйткәне тавыш күтәргән хатынны хәйранга калдырды. Ул нидер сизенгәндәй иде. Картка якынрак килде дә:
— Сиңа ни булды, бабай? — диде ул йомшарып.
Карт кул селтәде.
— Әә-әй, кызым, аны тиз генә аңлата торган түгел шул.
Хәбир Хәсәновичның күңел түреннән чыккан шушы үкенү-әрнүле сүзләрен ишеткән хатын, үз гаебен ничек тә җуярга теләгәндәй, Хәбир Хәсәновичка тагын да бер канәфер өзеп бирде.
— Башта ук әйтәләр аны, бабакай!..

* * *

Хуш исле чәчәкләрне букет рәвешенә китереп, профессор күкрәгенә кысты. Аның күкрәк кесәсендә Зөлфия хаты ята иде. Анда: «Хәбир, мин сине, гомерем буена бары сине генә яраттым. Зөлфия»,— дип язылган иде. Шул ук хатта икенче төстәге кара белән: «Хәбир Хәсәнович, әнине җирләдек»,— дигән җан өзгеч сүзләр дә бар иде...

**Хәниф Хәйруллин**

# БРИГАДИР ЗӨФӘР

ОЧЕРК

Пугач тавы өстендә кояш нурлары уйный башлаганда Зөфәр ишегалдында иде инде. Әнә абзардан, сөтле чиләген күтәреп, хатыны Халисә дә килеп чыкты.

— Тордыңмени, черем итсен әле беравык дигәнием, аннары уятырмын дигәнием.

Зөфәр дәшмәде, хатынына өстән сөзеп кенә карады да капкага таба атлады.

Кичтән телгә килгәннәр иде Халисәсе белән. Килерлегең дә бар. «Иртәнге эшләреңне карагач, ындыр табагына мен, Пугач тавы хәтле булды ипи өеме, симинә салырга җитешә алмыйлар»,— дигән иде. Юк, менмәде. Шул фермасына барса, кадалып ята. Ә эш күп булды кичә. Ун комбайн керде аның бригадасы җирләренә. Бер көндә дүрт мең ярым центнер борчак кайтты ындыр табагына, борын төртер урын юк. Көзге чәчүчеләрнең ашламасы беткән икән, председатель аңа шуны оештырырга кушты. Җитеш кенә, чәчүен чәч, урып-җый, җитмәсә тагын, сөте кимегән, җәйләүне бер урасы бар. Их, кырык куллар булса, кырык!

Соң гына, көтүләр кайтып, урам буйлап анасын эзләп йөргән сарык бәрәннәренең инде тамагы карлыккач кына өйгә кайтып керде ул. Арылган иде. Өстәл янына утыргач, алдына бүлеп куелган ашка да үреләсе килмәде. Кулындагы кашыгын әйләндергәләде дә, үзе дә сизмәстән, өстәлгә бер-ике бәреп алды. Халисә аңа сәерсенеп карады.

— Ник менмәдегез ындыр табагына?

— Ферма мөдире Әсгать кәс кисәргә апкитте безне.

— Мин әйткән закон түгелмени сезгә?

— Кәсе дә кирәк бит инде аның, Зөфәр.

— Кәс, кәс!.. Уттай урак өстендә кем кәс кисеп йөри? Әсгатен дә әйтерием инде... Парткомнар булып эшләп йөргән кеше.

— Калган эшкә кар ява ул.

— Яудырам мин сезгә. Иртәгә үк тракторыгызны алам. Ишелеп чыга Ферма-Сәвекле басуыннан бодай. Машина җиткереп булмый.

— Бирә ди сиңа Әсгать тракторны!

— Күрерсең!

— Я инде, атасы...

— Атасы!.. Бүген ындыр табагына менмәгән өчен фермагыз-ниегез белән агач мылтыктан атасы сезне!.. Күпме ипи барын беләсеңме син анда? Гомер күрелмәгән, колхоз гомерендә күрелмәгән ипи кайта анда быел... Ә сез... Кәс-с-с!

Тамагына да рәтләп ашамады, тизрәк яту ягын карады.

Әле хатынын күргәч, кичәге әнә шул исенә төште. Шуңа Халисәсенә дәшмичә чыгып китте әле ул бүген.

Әнә, утлы укларын күк гөмбәзенә атып, Пугач тавыннан кояш та тәгәрәп килеп чыкты. Колхозның икенче бригадасы булган Каташ-Каран авылы шул тау итәгенә урнашкан. Мәгърур күкрәгән җилләр кимергән ком тавының иң биеген бу якларда Пугач тавы дип йөртәләр. Чындырмы, Пугач яулары вакытында бу тау башында аның чатыры торган дип сөйлиләр. Хактыр, халык тикмәгә генә тау-чишмәгә исем кушмый. Нәрсәдер булган инде. Әмма Зөфәрне әле монысы кызыксындырмый хәзер. Әнә шул тау өстеннән болай таба төшеп килүче комбайннан күзен ала алмый тора ул. «Тау өстендәге борчакны бетерделәр микәнни? Мамдух абый, Даутов бу. Кунган, төне буе эшләгән бу җен. Болай булса, Каташ-Каранлылар бетерә борчакны беренче». Ул, шулай уйлап, аскы урамнан өскә — идарәгә таба кызу-кызу атлап китте. Идарәгә җитәрәк Гарифетдин абыйсы очрады. Ияк кагып кына исәнләштеләр.

— Иртәләгәнсең, — диде аңа Зөфәр.

— Җүнле әдәм җоклыймени хәзер. Комбайнның карап бетерәсе җирләре бар. Чөгендер алыр чак та җитә бит. Төш турларына ындыр табагына менәргә исәп.

— Шәп булыр иде.

Гарифетдин тыкрыкка борылды һәм паркка менеп китте. Зөфәр идарәгә килеп җиткәндә, председатель Мизхәт Габдрахманов болдырда басып тора иде. Кул биреп күрештеләр.

— Төсең һаман юк, ник чыктың, ятарга иде әле. Үзебез дә ерып чыгарыек, — диде Зөфәр.

— Җибәрде кебек... Менә, Зөфәр, нәрсә: бүген Түбән Камадан унбиш машина килә. Синең ындыр табагыннан төйиләр. Төнгелеккә колхозның барлык машиналарын, «Беларусь»ларны иген төяп Чаллыга озат. Бер минут тик торыш булмасын. Бүген бөтен эшең шул булсын. Синдә бөтен ышаныч...

— Киттем мин, алайса, ындыр табагына.

Зөфәр болдыр баскычына куйган аягын алган гына иде, председатель аның киң җилкәсенә кулын суздьы.

— Зөфәр, кичтән теге «Московская-121» арпа басуын урадым. Баш ата башлаган. Иң ышанычлы комбайнчыны бүген шуны урырга керт. Граммын да әрәм иттермә, чәчүлеккә ул.

— Ярар...

Зөфәр ындыр табагына ашыкты. Тиз генә аерылып китмәсәң, исенә төшеп, председатель аңа бер-бер артлы эш йөкли, аны кем башкарырга тиешлеген дә абайлап бетерми: агрономмы, зоотехникмы.

Әйтерең юк, бик тә тынгысыз председатель. Эшне белә, югары белемле агроном. Бөтен районда авторитеты зур — КПСС райкомы бюросы члены. Кая барса да сүзе үтә. Тик менә, соңгы ике елда, йөрәге бик «шаяра» башлады. Больницада да ятып чыкты инде берничә рәт. Әз генә арулandымы, йөрәк кешечә тибә башлады, егетләр, дип, тагын эшкә чыга. Менә тагын аякка баскан бит әле. Югыйсә, әле үткән атнада гына тәннәре суына башлаган хәлдә больницага алып киткәннәр иде. Кайткан. Кирәкле уколларны үзебезнең медпунктта алырмын дип, кайткан да килгән. Көянәгрәк. Кушкан эше майлагандай бармаса — өзгәләнә. Әйтеп тә караганы бар Зөфәрнең: «Колхоз бит ул, анданиләр генә булмый, кайчак, шаг впе-

ред, два шага назады да була аның. Әмма барыбер без дигәнчә барып чыга аның азагы. Төкер кайбер чүп-чарларга, бетермә үзеңне юкка», — дип. Юк, алай яратылмаган шул, нихәл итәсең.

Председатель турында әнә шулай уйлый-уйлый тыкрыкка борылгач, Зөфәр авыл өстендәге арпа басуына күз ташлады. Җиде гектар гына ул. Суперэлита чәчтеләр анда. Беренче тапкыр аммиак суы кертеп. Председатель үзе карап, чәчкечләрне үзе көйләп чәчтерде бу мәйданны. Әнә ничек алтын стенадай утыра! Кояш күтәрелеп чык кибү белән чырт-чырт килеп баш ата башлый ул — бөтен басуда борчак куыралармени. Беравык сокланып карап торды Зөфәр арпа басуына...

Аннары техника паркына сугылды. Комбайннарның кайберләре капкадан чыгып килә иде инде. Ул аларны бер-бер артлы уздырды... Арпа урдыруны кайсына ышанып тапшырырга? Башында әнә шул уй иде. Әле байтак комбайннар тезелеп тора. Мастер-наладчиклар төнлә ягулыгын салып, майлап, көйләсен көйләп куйсалар да, һәр комбайнчы үз агрегаты тирәсендә мәш килә, һәр узелны җентекләп карый. Дөрес тә бит, басуда туктап калганчы монда чакта итәгеңне җыеп бетерү мәслихәт. Берең ватылса, урып-җыю эшенең агымы туктала. Комбайн-транспорт звеносы системасы белән эшләү тукталып торуны бер дә яратмый ул.

Нияз комбайны янында туктады. Зөфәр аны әйләнеп чыкты. «Бара бу» дип уйлады да хедер полотнасын рәтләп торучы Ниязга:

— Теге арпаны урасың бүген, — диде.

Нияз аңа күтәрелеп карады, күзләрендә сорау галәмәте чагылды.

— Синең урынга, группага Әхнәфне өстәрбез.

— Ярар.

— Чамалап йөр. Дикаңны бик кысып та бетермә, бер бөртек калырлык та, имгәнерлек тә булмасын, киләсе ел өчен симинәгә ул. Мыскалы алтын аның колхоз өчен.

— Ярар...

Нияз күперчеккә менеп китте. Стартерга басуга, мотор гөртләтеп кабынды, комбайн, иртәнге аяз күккә төтен алкалары чөя-чөя, урыныннан кузгалды. Зөфәр дә эре-эре адымнар белән атлап китте.

Ул ындыр табагына килеп кергәндә ашлык чистарту машиналары бөтен куәтенә эшли, ике машина кузовына транспортердан гәрәбәдәй ашлык агыла иде. Эскерт кебек көшел кырые әкрен генә эчкә суырыла. Зөфәр ындыр табагы мөдиреннән чистартылган күпме ашлык барлыгын сорады. Мең центнерлар барын-бар икән дә, ләкин бүгенгә әз иде бу. Зөфәр ашлык чистарту агрегаты янында эшләүчеләрне күздән кичерде, чәчүлек орлык салучыларны санап чыкты. Кеше аз, җитешмәячәкләр. Ул ындыр табагына гына орынып торган дуңгызчылык фермасына таба китеп барды.

«Бүген мендерермен мин сезне ындыр табагына!» — дип бик яскынып бара иде, Әсгать үзе менеп килә, барысын да иярткән, хәтта фермага ремонтка куелган төзүчеләрне дә калдырмаган. Күңеле булды моңа Зөфәрнең. Тик төзүчеләрне эштән бүлүне генә өнәп бетермәде.

— Ремонтчыларны бүләсе түгел иде, — диде. Әсгатьнең өске иреннәре тартышып китте.

— Җитешәбез, хафаланма. Мизхәт Мәхмүрахманович сугылган иде фермага. Бүген безнең колхозга ике мең центнер тапшырырга задание җиткергәннәр. Булышсагыз иде сез дә, — диде.

Зөфәр телен шартлатты.

— Ике мең! Безнең бригададан күпмесе?

— Ике меңе дә шушыннан, — диде председатель.

Зөфәрнең киң кара кашлары җыерылды. «Ялдагы укытучыларны, медпункт эшчеләрен дә җыештырырга туры килә болай булгач», — дип уйлады ул һәм, Әсгатьләргә кул болгап, авылга таба ашыкты...

Электр утлары кабынып, авыл өстенә эңгер-меңгер пәрдәсе elenгәч, ындыр табагына ике җиңел машина килеп керде. Зөфәр арпа кешеле өстендә әлеге мәйданнан күпме уңыш чыкканын исәплап утыра иде. «Кырык җиде центнердан артык бит! Күңеле ышанмады, тагын бер исәпләде: кырык җиде дә дүрт! Бер гектардан! Шушы сортны — «Московская-121» сортын — үрчетергә кирәк бездә!» Әнә шундый куаныч белән ул сикереп торды, өс-башын каккалагандай итте, кирәктәй кулларына карады: басу тузаны, икмәк тузаны сеңгән, ничава, чиста пычрак!.. Ул машиналар янына атлады. Колхоз җитәкчеләре белән КПСС райкомының агитация-пропаганда бүлеге мөдире Дамир Гарифуллин килгән икән. Райком вәкиле кулында комач байрак.

Соңгы бишкөнлектә дәүләткә ашлык сату буенча беренчелекне алган колхозга олылап тапшырды байракны Дамир Гарифуллин.

— Үзең яуладың, инде кулыңнан ычкындырма, — дип, күчмә Кызыл байракны аның кулына тоттырдылар. Башта куллары калтырады Зөфәрнең, аннары ул байрак сабын өзәрдәй итеп кысты, әкрен искән җил белән кызыл комач аның йөзен сыйпап алды һәм бөтен гәүдәсенә ниндидер илаһи көч йөгергәндәй булды, көне буе чабып арыганнар мизгел эчендә каядыр эреп югалды.

— Бу куллардан моны алу авыр булыр,— диде байракка таба ымлап һәм аны югарырак күтәрә төште. Ындыр табагындагылар барысы да гөжләтеп кул чаптылар.

Машиналар китеп барды. Эш дәвам итте.

Икенче көнне ике комбайнның паркка ватылып кайтып керүе Зөфәрнең «җеннәрен кузгатты», Алып батырдай гәүдәсе белән ыжгырып килгәнен күргән комбайнчы, хедер алдына чүгәләгән җиреннән торып, копнитель артына тайды. Ләкин Зөфәрнең тавыш-тыны ишетелмәгәч, копнитель артыннан чалбарын рәтли-рәтли чыккан атлы булды. Зөфәр күз йөртү белән эшнең нәрсәдә икәнен шунда ук белде һәм күлмәген салып ташлап майкадан гына калды да комбайнчыга булыша башлады.

Шулай бик тә киеренке барды урып-җыю. Колхоз бөртеклеләрнең һәр гектарыннан егерме өч центнердан артык уңыш җыеп алды. Зөфәр Сәлахов җитәкләгән бригадада ул тагын да югары булды.

Тырыштылар да инде — тел-теш тидерә алмыйсың. Республиканың көнчыгыш районнарында тоташ биш ел килгән корылык күп нәрсәгә өйрәтте бу як игенчеләрен. Барлык байлыкларыбызның анасы — җирне кадер-хөрмәт итәргә гадәтләнделәр. Туңга сөрүне нигездә август аенда төгәлләделәр, сөрү алдыннан органик, минераль ашламасын мул керттеләр. Җирле ашлама күп кертелгән сызма культуралар мәйданына, чиратлаштырып, бөртекле культуралар урнаштырдылар.

Сыйфат бишьеллыгының беренче язы коры килде. Моны искәрү белән тракторчы Әсәт Госманов бөтен басуны ике кат катокларга кирәк дигән тәкъдим кертте. Уйлаштылар, киңәштеләр, хуп күрделәр моны һәм чәчкәннән соң басулар ике тапкыр катокланды.

Тагын киләсе елларда да нык кулланылырга тиешле сыналмыш уздырдылар: «Саратов-36» бодае урнашкан бер басуның һәр гектарына ике-ике ярым центнер аммиак суы кертелде. Нәтиҗәсе: гектардан утыз ике центнер уңыш! Ә бу шифалы су әләкмәгән җирләр егерме берәр центнер гына бирде! Ике-ике ярым центнер шушы ши-

фалы су менә күпме өстәмә уңыш бирде! Минераль ашламаның җир элексиры икәнен инандыручы матур күренеш бу.

Коммунист тракторчылар Дахьян Бәһауов, Минләис Сафин, үзләрендә тәмамлагач, Югары Ослан районына ярдәмгә барып, анда ике мең ярымнар центнер ашлык суктырган Әнәс Ильясов, Әсәт Миңнуллин, сызма культуралар игү осталары Зәйнетдин Җәләев, Гарифетдин Шиһапов һәм башка дистәләрчә ялкын йөрәкле механизаторлар эше белән яуланды ул үрләр. Зәйнетдин белән Гарифетдинны гына ал. Авылда аларның икесен дә «профессор» дип йөртәләр. Элек-электән килгән һәм хәзер дә шулай — авылда кушаматсыз кеше табалмыйсың син. Күп кешене шулай гына искә алалар. Боларның исә берсе — «Кукуруз профессоры», икенчесе — «Чөгендер профессоры».

Зәйнетдин менә ундүрт ел инде кукуруз игү звеносын җитәкли. Киләсе елда кукуруз чәчеләчәк мәйданны ул алдан үзе билгели. Агроном фатихасын алгач, шул җирләргә ашлама кертә, аны күздән үзе сөреп калдыра. Язын мәйданнарны дирбиялап эшкәртә, чәчү срокларын, үсемлекләрнең тишелеп чыгу вакытларын билгели, ашламасын кертә — кыскасы, кукуруз язмышын хәл итү остасы ул. Яшел массаны җыеп алганда транспорт белән генә тәэмин ит син бригаданы. Әйбәт уңыш үстерде Зәйнетдин ул елны: йөз җитмеш гектардан өч йөз илле бишәр центнер яшел масса уңышы чыкты.

«Чөгендер профессоры»да йөзенә кызыллык китермәде: йөз дә биш гектардан йөз сиксән тугызар центнер татлы тамыр уңышы җыеп алынды. Шул уңыштан гына бригада дәүләткә унсигез мең центнер шикәр чөгендере сатты. Җиткерелгән план унбиш мең ярым гына иде.

Саннар, саннар... Укыр өчен ялыктыргыч кебек алар. Әмма беренче карашка гына шулай. Чынында һәр кешенең күпме файдалы эш башкаруын, һәр тармакның ничек үсүен, кая таба баруын күрсәтүче барометр алар. Әнә шул барометр дөрес, гел безнең файдага күрсәтеп торсын дисәң, һәр тиенне санарга, производствога салынган һәр тиеннең үзенә ничә тиен кайтарып бирәчәген алдан белергә кирәк.

«Бу пленумда яңадан басым ясап әйтәсем килә: хәзерге этапта авыл хуҗалыгын тагын да күтәрү проблемасы — барыннан да элек, — диде Л. И. Брежнев чыгышларының берсендә, — аның нәтиҗәлелеген һәрьяклап күтәрү проблемасы ул. Гомуми бурычны болай билгеләргә мөмкин: авыл хуҗалыгын үстерү өчен дәүләт тарафыннан бирелгән гаять зур ресурсларны акыл белән, хуҗаларча файдаланырга, җиргә сак карарга, һәр гектарның, салынган һәр сумның, һәр тонна ашламаның максималь файда бирүенә ирешергә».

Игенчелектә бу программаны тормышка ашыру буенча, күренгәнчә, Зөфәр Сәлахов җитәкчелегендәге бригада байтак эшләр башкарды.

Ә бит аның әле терлекчелеге дә бар һәм аның иң авыры — озак еллар теңкәгә тигәне — дуңгызчылык булды.

Мизхәт Габдрахмановның яңарак колхоз председателе булып эшли башлаган чагы иде. Дуңгызчылыкта хәлләр мөшкел: үлем-китем күп, үсеш аз алына. Колхоз дәүләткә ит сату планын үти алмый. Нишләргә? Бу артталыктан ничек котылырга? Ниһаять, бер уртак фикергә килделәр: дуңгызчылыкны хуҗалык исәбенә күчерергә! Карарга килүе җиңел, әмма аны ничек тормышка ашырырга соң? Мәсьәләнең әнә шул ягы бар бит әле. Дуңгызчылыкны хуҗалык исәбенә күчерү турында башлап аваз салган элекке партком секретаре Әсгать Сәлимовка сүз куштылар. Идарә утырышында, сүз йомгагын җайлап кына чишә-чишә, җеп очын Әсгать кулына тоттыр-

дылар. Ни кушсаң да җаны-тәне белән эшләп йөрүче Әсгать ялындырып тормады.

— Риза мин. Тик шартын тудырыгыз, Зөфәр белән сугышырлык булмасын, ферманы үги итмәсен, — диде ул, Зөфәргә кырын күз белән карап.

— Кысыр хатыннан бала таптырмасаң, сугышмабыз, — диде Зөфәр,— һәм фуражын сорама син миннән, башкасы булыр. Ә фуражын менә болардан сора, — дип, колхоз председателе белән партком секретарена төртеп күрсәтте. Бу сөйләшү җитмеш дүртенче елның август аенда булды.

Ике ел рәттән коры килде, фураж ягы чамалы булды. Әмма башка азыгын җитәрлек әзерләделәр. Әйтерең дә юк, нык алынды Әсгать, үз дигәнен эшләде, фермага хуҗалык исәбен кертте. Җитмешбишенче елны бер центнер дуңгыз итенең үзкыйммәте туксан ике сум булды, ферма колхозга 69 меңнән артык сум саф табыш бирде. Дәүләткә ит сату планы арттырып үтәлде. Соңгы елда исә беренче декабрьга мең биш йөз чамасы центнер дуңгыз ите озатылды. Бу — колхозда җитештерелгән барлык итнең алтмыш проценты дигән сүз.

Кыскасы, зур җиңүләр елы булды Сарман районының Серго исемендәге колхоз өчен ул ел. Колхоз дәүләткә ашлык, татлы тамыр, бәрәңге, ит, сөт, йон сатуның халык хуҗалыгы планнарын барысын да арттырып үтәде. Ә бу җиңүгә иң күп өлешне Зөфәр Сәлахов җитәкләгән бригада кертте.

... Бу тәҗрибәле бригадирны мин күптәннән белә, аның ташып торган энергиясенә соклана һәм һәммәсенә ничек җитешә икән бу дип гаҗәпләнә идем. Колхозда бер очрашкач, аңардан:

— Зөфәр, барысына үзең чабасың, ничек өлгерәсең син? — дип сорадым. Ул елмайды һәм:

— Йөз илле ике тезгенне тотарга кирәк бит, — диде.

— Нинди йөз илле ике?

— Бригадада шул хәтле эшче көч бар. Аларның һәрберсенә — аерым тезген. Шуның кайсын бушайтасың, кайсын ныграк тартасың. Юкса, эш бармый, брат,— ул бераз уйланып торды, аннары: — аз бу безнең бригада өчен, яшьләр аз кала бит авылда, аеруча кызлар. Егетләр армиягә китү белән кызларга канат чыга, төрле якка очып таралып бетәләр. Сыер савучыларыбыз да пенсиягә чыгар көннәрен санап тора. Ә кем алмаштырыр? Нишләргә, брат? Ярый ла, соңгы елларда армиядән кайткан егетләр читкә каермый башлады. Шуларда өмет. Тик алар да тиз генә күз-башлы булырга ашыкмыйлар. Белмиләр Зөфәр абыйларының уңган киленнәрне дүрт күз белән көткәнен, — дип сөйләп китте.

Әйе, иң зур байлык, хәзинә — кеше. Зөфәр үз бригадасындагы һәр кешегә әнә шулай карый, тик шуларга таяна. Аның уңышының, бригада җитәкчесе булып ун елдан артык эшли алуының, халык белән уртак тел табуының сере дә, мөгаен, шундадыр.

**Валентин Белокопытов**

# ЯШӘҮ ХАКЫНА

> Әстерхан губернасыннан башлап Татарстан республикасы һәм Пермь губернасына кадәр — һәркайда корылык ашлыкны да, үләнне дә бөтенләй диярлек көйдереп бетерде. Миллионнарча кеше — хезмәт иясе крестьяннар һәм эшчеләр, миллионлаган баш терлек үлемгә дучар ителгән һәм үлә дә инде... Афәт шундый зур...
>
> В. И. Ленин.

Идел буйларында яшеллек әсәре калмады — барысы да саргаеп-көеп бетте. Корылыктан туфрак көйрәде. Башка елларда ашлык диңгезе дулкынланып торган кырлардан тузан болытлары күтәрелде. Ил өстенә бәла килде, афәт килде. Ачлык, корылык!..

Шомлы хәбәрләр Мәскәүгә бик тиз иреште. Шундый көннәрнең берсендә Ленинның эш кабинетына Леонид Борисович Красин керә. Ильич ифрат та борчулы. «Ул, әледән-әле тәрәзә янына килеп, корылыктан дөрләп китәрдәй булып күренгән күккә карый, әйтерсең берәр болыт кисәге күренмәсме дип көтә, шуңа өметләнә»,— дип яза соңыннан Красин.

Һава хәле турында Идел һәм Урал якларыннан килгән хәбәрләрне Кремльдә зур игътибар белән укыйлар. Чөнки бу хәбәрләр, сугыш кырларыннан алынган мәгълүмат шикелле үк, ашыгыч чаралар күрүне таләп итә.

...Бик күп төбәкләрен сугыш уты көйдереп узган илнең игенчеләре һәркайда 1921 ел язын дүрт күз белән көтеп алды. Аңа зур өметләр багланды. Яз килде, ләкин өметләр акланмады. Идел буендагы барлык җирләрдә һава кызу, көннәр чалт аяз торды. Күктә дөрләгән ут шары — мәрхәмәтсез кояш көннәр, атналар, айлар буена туфрактагы дымны суырды, җирнең җелеген киптерде. Күлләр, буалар юкка чыкты, тирән елгалар саекты. Иртә яз чәчелгән кырларда буразнада борын төрткән яшь шытымнар җәелеп үсеп китә алмады — кибеп, бөрешеп катты... Ә эссе җилләр тынмады — исте дә исте. Йөгән күрмәгән кыргый аттай дулап, алар кыр-басулар буйлап чаптылар, тузан-туфракны ялмадылар. Көтүгә чыккан сарыклар үлән кыягы тапмады, бәрәннәр кипшенеп үлде. Иң үләнле дигән җирләрдә дә сыер теленә эләгердәй кыяк калмады... Авыллар, мәет чыккандай, тынып калды, тирән кайгыга батты. Крестьян агайлар, көн саен басу капкасы янына җыелып, кырларга күз текәп торалар.

Басулар күренеше күңелләргә шом салырлык: элек арыш башаклары тирбәлеп торган урыннарда кара җир генә! Ерактагы урманнар да, афәткә тарган шушы җирнең кешеләре кебек үк, ач һәм ачулы булып күренәләр... Табигать гүя өмет белән күккә күз төбәгән кешеләрне үчекли. Чалт аяз күкнең бер почмагында, офык читендә сыңар болыт кисәге пәйда була да кырлар өстенә ишелердәй булып килә башлый. Хәзер беренче тамчылар тамар, кипшенгән җир шифалы дымга сөенер, дип көткәндә, әлеге болыт, шатыр-шотыр яшен аттырып, китеп тә бара...

Идел буенда крестьяннарниләр генә эшләп карамады: рус авыллары, иконалар күтәреп, кырларга чыктылар — ходай тәгаләдән яңгыр сорадылар. Буразнага тере әтәчләр күмеп карадылар — күк җавап бирмәде. Татарлар басу өстендә, намазлыклар җәеп, яңгыр теләү намазлары укыды — аллага ялварып, җирнең сусавын бастыруны үтенде. Ләкин яңгыр яумады.

Игенчеләрнең өмете-ышанычы сүрелгәннән-сүрелде. Тирә-юньдә бөтен нәрсә кибеп-корып беткәч, авыллар урыннарыннан куба башлады. Тәрәзәләргә аркылы такталар сугыла, ишекләр кадаклана. Туган җирләрен, ата-баба нигезен ташлап китә кешеләр. Корылыктан, ил өстенә үкереп килгән афәттән — ачлыктан качып котылырга тели алар. Юлларда арбалар шыгырдый. Урман янганда кая барып бәрелергә белмәгән киек җәнлекләр шикелле, сала халкы кай тарафка юл алырга аптырый. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга олагалар... бәлки бер телем икмәк, сусаганда су табып әчәрлек җирләр бардыр бу дөньяда... Тәтеш кантоны Келәнче авылы крестьяны А. Габделсаттаровның әйтүенә караганда, 1921 нче ел җәендә бу авылның бик күп кешесе, йорт-җирен, терлек-туарын сатып, икмәкле җир эзләргә чыгып китә. Биш йөз хуҗалыктан йөзләбе генә утырып кала.

Ачлыктан башы-зиһене чуалган кешеләр Себергә, Урта Азиягә юл ала. Ул якларда иген уңган дип сөйлиләр. Кышны, җан саклап, исән-имин үткәреп булса, язгы чәчүгә, белмәссең, туган якларга кайтып җитәргә дә булыр иде, шәт.

Әйе, ул елның җәе һәм көзе коточкыч авыр була. Күпләр Идел буена кара афәт булып килгән ачлыктан котылу юлын күрми, өметсезлеккә бирелә. Ләкин илнең зирәк уллары — заманында Колчакны һәм Деникинны дөмбәсләгән солдатлар, утны-суны кичкән коммунистлар — паникага бирелми. Бергәләшеп, бәладән котылу әмәлләрен эзлиләр. Авылларда үзара ярдәмләшү комитетлары оештырыла. Алар күпләрне ач үлемнән коткарып кала.

Авыл көрәшә, ачлык тырнагыннан котылмакчы булып тернәкләнә. Ләкин Идел буендагы авыллар мондый авыр хәлдән үз көчләре белән генә чыга алырлык түгелләр. Башка төбәкләр читтән ярдәм итмәсә, ач үлем барыбер бугаздан алачак. Тик кешеләр ышана: Совет власте булышыр!.. Совет власте бәладән йолыр!..

Коммунистлар партиясе, Совет хөкүмәте, Россиянең барлык гражданнарына мөрәҗәгать итеп, ачлыктан интегүчеләргә һәр яктан ярдәм кулы сузарга, ачлыкны пролетариатның бердәм көче белән җиңәргә чакырды. Идел буйларына килгән һәлакәткә каршы бөтен ил басты.

Идел буе көйгән, ләкин бар бит
Иген уңган, ашлык мул җирләр.
Шул яклардан: «Менә, иптәш, ал!» дип,
Туганнары икмәк бирерләр.

Пролетар шагыйрь Демьян Бедный ул көннәрдә шулай язды.

Ачларга, чыннан да, төрле яклардан ярдәм килә башлады. Авылларга орлык кайта, ашлык китерәләр. Ачлык тырнагыннан котылу-

ларына ышанып җитмәгән игенчеләр яшь аралаш елмая. Күзләрендә яшәү уты, сөенеч нуры кабына.

— Совет власте ярдәм итә... Бирешмибез, димәк!..

Ленин җитәкчелегендә Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте республиканың бөтен көчен ачлыкка каршы көрәшкә туплыйлар. Булган азык-төлек запаслары, акчалата ярдәм — барысы да Идел буйларына җибәрелә.

Ачларга булышлык күрсәтү өчен Бөтенсоюз комиссиясе (Помгол) һәм урыннарда аның җирле органнары оештырылды. Совет хөкүмәте аларга үз карамагындагы бөтен товар фондын тапшырды. Ул алтын белән 599 мең сумлык иде. 1921 елның июленнән соңгы өч ай эчендә Азык-төлек комиссариаты ачлыкка дучар булган районнарга 1 миллион поттан күбрәк ашлык, меңләгән пот фасоль, дөге, балык китертте. 1922 елның 1 мартына дәүләт Идел буе өлкәләренә орлык өчен 14 миллион пот арыш бирде. 5.218.400 пот бәрәңгенең 862 мең поты Татарстанга кайтарылды... Ачлыкка каршы бөтен халык көрәше барган айларда Совет хөкүмәте Идел буена алтын түләп алынган 170 миллион сумлык ашлык, чәчүлек орлык һәм ашамлык продуктлар белән ярдәм итте. Һәркайда ашханәләр ачылды...

Татарстанга ярдәм төрле яктан килде. Ләкин аңа иң зур булышлык иткән урыннар Петроград, Владимир губернасы һәм Себер булды. Казан яклары шулар белән «бәйләнешкә кертелгән» иде. Революция бишеге булган Петроград кешеләре 1918—19 нчы елларны искә төшерәләр. Ул чакта Идел буе игенчеләре ачлык янаган Петроградка икмәкне эшелон-эшелон озатып тордылар. Хәзер инде, киресенчә, Питер эшчеләре Идел буендагы ачларга ярдәм итә. «Петроградская правда» газетасының 1921 елгы 13 ноябрь санында өч кеше — А. Хамеляйнен, Я. Борисов һәм К. Бабичның хаты басылып чыга. Алар, Нева ярындагы шәһәр хезмәтчәннәренә мөрәҗәгать итеп, менә нәрсә язалар:

«Кадерле иптәшләр!

... Казан шәһәрендә һәм кантоннарда яшәүче хезмәт халкының газапларын сүз белән аңлатып кына булмый... Татарстан республикасының бүгенгесе белән чагыштырганда, 1918—1919 елларда безнең шәһәр кичергән ачлык бик күпкә җиңел булган. Татарстанда хәл ифрат та авыр...

Барлык хезмәт халкының зур булышлыгы кирәк!..»

Питерлылар Идел буена ярдәм фондына 80 миллион сумлык алтын-көмеш әйберләр җыеп тапшыра, шуның 6.715.920 сумы Татарстанга бирелә. 1922 елның 16 мартында Петроградтан азык-төлек төялгән 74 вагон Казанга озатыла.

Ачларга илнең төрле якларыннан ярдәм кулы сузган эшчеләргә һәм игенчеләргә Татарстан халкының рәхмәте ТатЦИКның өченче сессиясе исеменнән махсус хат белән белдерелә. 1921 елның август башында ук Владимир Ильич, Украина игенчеләренә мөрәҗәгать итеп, аларны шулай ук Идел буендагы сыйныфташ туганнарына ярдәм итәргә чакырды. Шуннан соң ике ай үтүгә, Ильичның ялкынлы сүзләре Арал диңгезе балыкчыларына ишетелде. Ленинның Бугун советы балыкчыларына һәм эшчеләренә язган хаты, бүген укысаң да, дулкынландыра. Юлбашчының һәр сүзе — дәртле чакыру. Хәтта ачларга туганнарча ярдәм итүнең әһәмияте, политик мәгънәсе ачыла: «Юмарт кулдан ярдәм итегез, хөрмәтле иптәшләр, — Арал диңгезендә балык тотучылар һәм эшчеләр! — дип яза Владимир Ильич.— Моның белән сез кешелек намусы кушуын үтәп кенә калмассыз, эшчеләр революциясе эшен дә ныгытырсыз... Идел буеның авыр яраларын дәвалау өчен бөтен эшчеләр сыйныфы, бер кешедәй булып,

күтәрелсен, ә туфрагы уңдырышлы Идел буе моны безгә киләчәк елларда үзенең икмәге белән кайтарыр.

Сугыш елларында хуҗалыгы җимерелгән, таланган Советлар республикасының миллионнарча ачларны үлем тырнагыннан берьюлы тартып алырдай мөмкинлекләре булмый, әлбәттә. Ленин моны бик яхшы аңлый. Бу хакта ул Максим Горький белән дә сөйләшә. Ильич киңәше белән, бөек әдип Европа һәм Америкадагы намуслы кешеләргә мөрәҗәгать итә, аларны Россиядәге ачларга булышлык итәргә, медицина хезмәте күрсәтергә чакыра. 1921 елның 13 июлендә Горький имзасы куелган телеграмма бөтен дөньяга тарала. Озакламый аңа җаваплар да килә башлый. Немец язучысы Герһардт Гауптман рус җиренең бөек әдибенә болай яза: «Мин шуны расларга җөрьәт итәм: цивилизацияле кешелек дөньясы сезнең тетрәткеч чакыру авазыгызны колак белән генә түгел, йөрәге белән дә ишетте, ул аны җавапсыз калдырмас. Җир йөзе бу җәһәттән ничек күбрәк эш күрсәтсә, ачлыкны һәм авыруларны шул хәтле тизрәк җиңәргә мөмкин булыр һәм кешелек дөньясы үз намусын кердән шул хәтле яхшырак арындырыр». Горький тавышы, Идел буендагы ачларның хәле турында белдереп, җир шары буйлап яңгырады һәм бик күп акыл ияләрен, культура, әдәбият, сәнгать эшлеклеләрен, миллионнарча гади кешеләрне кузгатты. Исемнәре бөтен дөньяга мәшһүр галимнәр, әдипләр, рәссамнар җавап сүзен озак көттермәде. Анатоль Франс ачларга ярдәм фондына үзенә бирелгән Нобель премиясен тапшыра, Ромен Роллан, Анри Барбюс, Мартин Андерсон Нексе, Теодор Драйзер, Герберт Уэллс, Альберт Эйнштейн һәм башкалар ачларга ярдәм итү өчен акчалата өлеш кертәләр.

1921 елның октябрь аенда немец рәссамнары, артистлары, язучылары үз илләрендәге барлык интеллигенциягә мөрәҗәгать итәләр: «...Россиядә ачлыктан 20 миллион кеше интегә! Сез аларга булышырга тиеш, сез аларга булышырсыз!..» Рейн ярларыннан Идел буйларына ярдәм кулын сузган культура эшлеклеләренең берсе күренекле шагыйрь Иоһаннес Беһер булды. Бөек галим Альберт Эйнштейн, 1922 елның февралендә түләүле доклад сөйләп, акчасын ачларга ярдәм фондына тапшырды.

Горький чакыруын бөтен йөрәге белән кабул иткән һәм аңа җаны-тәне белән кушылган кешеләр арасында Норвегиянең бөек галиме Фритьоф Нансен аеруча күренекле урын тота. Аның исеме һәм эше Идел буендагы ачлыкка каршы көрәш барган елларда халыклар туганлыгының символына әверелде. Ул да, үз исеменнән бөтен дөньяга мөрәҗәгать итеп, намуслы кешеләрне ачларга ярдәм оештырырга өндәде. Аның тавышы, Горький чакыруына кушылып, еракерак илләрдә яңгырады. Халыкара Кызыл Хач җәмгыяте президенты Густав Адор галимнән Идел буендагы ачларга ярдәм итү өчен төзелгән гомумевропа оешмасына җитәкчелек итүен сорый. Исеме дөнья шаулаткан илгизәр Ф. Нансен, Үзәк Азиягә сәяхәткә әзерләнү эшләрен ташлап, бу тәкъдимне кабул күрә һәм ачларга ярдәм оештырырга керешә. Бөек гуманист ачларның авыр хәлен ерактан торып кына күзәтми. Ул Ригага килә, монда М. М. Литвинов белән очраша. Шуннан ук Мәскәүгә юл ала. Биредә доктор Нансен Г. В. Чичерин һәм Л. Б. Красин белән очраша, сөйләшүләр алып бара. Мәскәүдә «Ачларга ярдәм итү өчен халыкара комитет» төзү хакында килешү төзелә. Аңа Нансен белән Чичерин кул куя.

Фритьоф Нансенны үз иле һәм Европа бер яктан алкышлап, икенче тарафтан сәерсенеп каршылый. Кешелек күзендә абруе гаять зур булган галимнең Россиядәге ачларга ярдәм итү комитетын җитәкләргә риза булуын прогрессив карашлы кешеләр хуплый, ә миллионнарын банк сейфларында саклаучы «капйотлар» моны өнәп бе-

терми. «Сары» һәм «ак» матбугат әнчекләре Нансенга каршы өрә башлый...

В. И. Ленин бөек галим һәм аның бу мәсьәләдә фикердәшләре белән капиталистик дөнья арасында башланган көрәшне зур игътибар белән күзәтә. Г. В. Чичеринга язган бер хатында ул болай ди: «Нансен яклылар», «Нансенга каршылар» кампаниясе ачык күрсәтә... без Нуланс тәкъдимнәрен гадәттән тыш кискенлек белән кире кагарга тиешбез... Шул чакта, һәм бары шул чакта гына отачакбыз, РГО-Нансен яклы элементларны үз тарафыбызга яулап, Нансенга каршыларның уенына чик куярбез...» Ильичның бу урында «уен» сүзен куллануы тикмәгә түгел. Моны ачыклап үтик. Революциягә кадәрге Россиядә француз илчесе булган Жозеф Нуланс совет властеның иң явыз дошманына әверелә. Кулыннан килсә, ул аны чәйнәп өзәр иде. Нансенга каршы даирәләр нәкъ менә шушы бәндәне Милләтләр лигасының Россиягә ярдәм итү комиссиясе башына утыртып куялар. Аларның ничек итеп «булышырга» теләве үзеннән-үзе аңлашыла. Нуланс «комиссиясе», ачларга ярдәм итү сылтавы белән, советка каршы эш алып барырга маташа. В. И. Ленин шундый «тәкъдим»нәрне катгый рәвештә кире кагарга кирәген әйтә, ә Нансенга игелекле эшләрендә мөмкин булган һәр урында булышырга тәкъдим итә.

Мәскәүдәге сөйләшүләрдән соң, Ф. Нансен Милләтләр лигасы аша Европа дәүләтләре хөкүмәтләреннән 250 мең франк акча табарга һәм бу суммага ачлар өчен ашлык сатып алырга өметләнә. Ләкин галимнең өметләре акланмый. Яшь совет дәүләтен күралмаган капиталистик хөкүмәтләр Идел буендагы ачларга булышырга, акча бирергә җыенмыйлар. Нансен аларны Милләтләр лигасы трибунасыннан фаш итәргә керешә. «Европа халыклары кышның-кыш буе кул кушырып утырыр һәм еракта миллионнарча кешенең ачтан үлүен тыныч кына күзәтеп торыр дип уйлый алмыйм, моңа ышана алмыйм. Канадада быел уңыш бик әйбәт булды — ул без сораганнан өч тапкыр күбрәк икмәк сата ала. Америка келәтләрендә ашлык черер ята, сатып алучы юк. Аргентинада маис шундый уңды — аны паровоз мичләренә ягалар. Америка һәм Европа портларында буш суднолар тора. Ә көнчыгышта миллионнарча кеше ачлыктан интегә...» Милләтләр лигасы аның мөрәҗәгатенә өзеп җавап бирми, доктор Нансенның тәкъдимнәрен өйрәнү өчен комиссия төзү белән чикләнә. Ике атнадан җавап бирелә: янәсе, «комиссия доктор Нансен белән килешә алмый»... Шулай итеп, акча сейфлары сагында утыручы капиталистик хөкүмәтләр ачларга булышудан рәсми рәвештә баш тарталар.

Фритьоф Нансенның тавышы Милләтләр лигасы трибунасыннан кабат яңгырый. Ул инде мәсьәләне бөтен кискенлеге белән куя. «Бирегә, совет хөкүмәтенә булышканчы, 20 миллион кешенең ачтан үлгәне хәерлерәк, дип әйтүче кеше табылырмы икән? Җыелыштан мин шушы сорауга җавап таләп итәм... Мин Европа илләрен тарихтагы иң зур афәткә — ачлыкка каршы көрәшергә өндәвемне дәвам иттерәчәкмен. Инде кыш якынлашып килә. Тиздән Россиядә елгалар туңачак, ә коры җир транспорты өчен юлларны кар күмеп китәр. Шушы озын кышта миллионлаган кешенең йөрәкләре тибүдән туктарга юл куярбызмыни без? Вакыт бар әле. Ләкин күп түгел... Кешелеклелек хакына, игелек хакына үтенәм мин. Үзегезнең дә бит хатыннарыгыз, балаларыгыз бар, уйлап карагыз әле бер: хатыныңның, балаңның ач үлемгә йөз тотуын нинди күз белән күрмәк, моңа ничек түзмәк кирәк! Шушы трибунадан мин хөкүмәтләрне, Европа халыкларын ачларга ярдәм итәргә чакырам. Ашыгыгыз, булышыгыз, әле соң түгел!..»

Нансенның рече тәмамлангач, Лига делегатлары утырган зур залда кабер тынлыгы урнаша. Ә аннары бөтен бинаны көчле алкышлар тетрәтә. Әмма кул чабучы кешеләр галеркада гына утыралар, ә делегатлар — аста. Алар бармакка бармак та сукмый. Ачы хакыйкатьне кешелек дошманнарының йөзенә бәреп әйтә Нансен. Юк, ул коммунистлар исеменнән сөйләргә килгән оратор түгел, зур түрәләр җыенына очраклы гына эләккән ярлы игенче дә түгел, үз язмышын кайһәрләр дәрәҗәгә җиткән эшче дә түгел. Ул — Нансен, дөньяга мәшһүр галим. Ул — үзе дә капиталистик дөнья кешесе, әмма шушы дөньяның акчага, алтынга табынучы гали затларын яндырырлык сүзләр әйтә. Нәкъ менә «үз кешеләре» әйткәнгә күрә дә Фритьоф Нансенның һәр сүзе «әфәнделәрнең» яңагына чалтыраткандай булып яңгырый. Милләтләр лигасы, ниһаять, 30 сентябрьдә соңгы сүзен әйтә: Россиянең Идел буйларындагы ачларга ярдәм итү — аерым кешеләр ихтыярындагы эш. Теләгән кеше игелек күрсәтә, булыша ала...

Нансен шундук ачларга булышу фондына үзеннән шактый зур өлеш кертә. Ә соңрак, Нобель премиясе алгач, Советлар Россиясендә ике урында үрнәк авыл хуҗалыгы станциясе булдыру өчен тагын 122 мең крон акча тота. Ачларның чын хәлен белү, аларга ярдәм оештыруны тагын да яхшырту нияте белән, Нансен Идел буена да килеп җитә. Самарада, Пугачев өязендә ул бушап калган авыллар аша уза, ачлыктан хәлсезләнгән, шешенгән кешеләрне күрә. Европага кайткач ул, тагын да зуррак тырышлык белән, ачларга ярдәм фондына акча җыярга керешә.

1922 елның беренче октябрена кадәр Нансен комитеты Россиягә 4.775,8 мең пот азык-төлек китертә. Моның өчен алтын белән 19580,8 мең сум акча түләнгән. Хәзер инде тәгәл әйтергә була: Нансен комитетының тырышлыгы 477 мең кешенең гомерен саклап калды. Бу олы җанлы бөек кешегә ничәмә-ничә буыннар рәхмәт укып торса да күп булмас!

Совет халкы Фритьоф Нансенның фидакарьлеген, хезмәтләрен ул чакта ук югары бәяләде. Советларның IX Бөтенроссия съезды 1921 елның 25 декабренда аңа республика хезмәт иясе исеменнән зур рәхмәт белдерде. Мәскәү шәһәр советы Нансенны үзенең почетлы члены итеп сайлады. Советлар республикасының Идел буе төбәкләрендәге ачларга ярдәм оештырган галим бу илнең якты киләчәген якты итеп алдан күрә. 1923 елда басылган «Россия һәм дөнья» дигән китабында ул: «Рус халкының киләчәге зур... Европа тормышында аңа бөек бурычны хәл итәргә туры килер», дип яза.

Ачлыкка каршы көрәштә илебезнең культура, әдәбият, сәнгать эшлеклеләре дә зур фидакарьлек күрсәттеләр. М. Горький, А. Луначарский, Д. Бедный, В. Маяковский һәм башкалар ачларга булышу өчен кулдан килгәннең барысын да эшләде. Маяковский ул авыр чакларда: «саф сәнгать» өчен «кара эш» булып саналган шөгыльләрдән — плакатлар әзерләү, азык-төлек налогы турында шигырь язудан да читләшми: Идел буендагы кыенлыклардан файдаланып үз кесәләрен калынайтырга маташкан капкорсакларны, капиталистик илләрнең эшкуарларын сатира уты белән көйдерә.

Шундый газаплы көннәрдә республикабыз әдипләре китаплар язды, артистлар спектакльләр куйды — иҗади хезмәтләре өчен алынган акча исә республиканың ачларга булышлык комиссиясенә тапшырыла. Шуны гына әйтү дә җитә: цирк артистлары манежда чыгыш ясаганнан соң станциягә вагоннардан ашлык һәм чәчүлек орлык бушатырга китәләр.

Идел буендагы әлеге хәтәр айлар дистә елларга тиңләрлек. В. И. Ленин андагы хәлләргә игътибарын бер генә көнгә дә киметми.

1921 елның көзендә һәм егерме икенченең язында да ул бу төбәкләрдә чәчүнең барышы белән даими кызыксынып тора. Бу — бик табигый. Иген уңса — тормыш чәчәк ата.

Шундый уй-хис белән канатланып, ачлыкның сират күперен кичкән игенчеләр язгы кырларга чыга. Күңелле җырлар да яңгырамады, ләкин көчсез сыкрану авазларының да ишетеләсе юк. Буразналар ярыла, ашлык чәчелә. Басуларга тургайлар кайтты. Ләйсән явып үтте. Терлекләр көтүгә чыкты. Татарстан кырларыннан ачлык чигенде. Үлем сызыгы артта калды, тормыш җиңде. Табигать китергән афәтне пролетарийлар туганлыгы, халыклар дуслыгы җиңде. Димәк, революциянең дә җиңүе иде бу! Хәлиткеч вакытта Нансенга каршы күтәрелгән кара көчләр басылып калды.

... Шуннан соң тагын күп язлар үтте, күп сулар акты. Күп милләтле Ватаныбыз зур тарихи сынаулар аша тагын күп тапкырлар узды. Аграр ил үзенең куәтле индустриясен булдырды. Совет халкы кешелекнең иң хәтәр дошманын — фашизмны тар-мар итте. Россия халкы турында Нансенның: «Европа тормышында аңа бөек бурычны хәл итәргә туры килер» дигән сүзләре чынга ашты. Кайчандыр Нансен тарафыннан ачлык тырнагыннан, үлемнән тартып алынган кешеләрнең оныклары бөтен кешелек дөньясын фашизм коллыгыннан коткарып калуда катнаштылар. Тарихи бурыч исәп белән түләнде.

— Игенче хезмәте — яу кырында җиңү белән бер ул!

Заманында героик эше белән Татарстанны шаулаткан комбайнчы Социалистик Хезмәт Герое Даһи Гарифуллович Шәрифуллин миңа шулай дигән иде. Шунда ук бу фикерен ачыклап та бирде: «Игенчегә каршы торучы көчләр аз түгел бит: корылыгы да була, вакытлы-вакытсыз яуган яңгырлар да теңкәгә тия. Кыравы-суыклары бар тагын... Шуларның барына да каршы тора белсәң генә — уңыш аласың. Техникага таянасың, фәнгә. Шулар белән табигать стихияләренә каршы торасың...»

Бу сүзләрне мин 1972 елда искә төшердем. Ул елны да Идел буйларына корылык килде. Шуннан нәкъ 51 ел элек булган шикелле үк, кырларда туфрак көйрәде, көтүлекләрдә үләннәр кибеп бетте. Шундый ук рәхимсез кояш, бөтен яшеллекне кырып салырга теләгәндәй, көннәр, атналар, айлар буена күктә ут шары булып дөрләде. Июль аенда республикада явым-төшем нибары 3,9 миллиметр булды. Августта исә тамчы да таммады. Туфрак температурасы кырык җиде градуска җитте. Кыскасы, һава шартлары нәкъ менә егерме беренче елның җәен хәтерләтте. Бәрәңге сабагы тамырда кипте, күлләр саекты... Ләкин Идел буйларына егерме беренче ел афәте килмәде, килә алмады. Татарстан игенчеләре җитмеш икенченең көзендә һәр гектардан 10,9 центнер ашлык җыеп алдылар. Зур уңышмы бу? Чагыштыру өчен бер белешмә китерик: революциягә кадәрге Казан губернасында крестьян хуҗалыклары иген бик яхшы уңган елларда уңышны шул чамада алганнар... Җитмеш икенче елда Татарстан халкы корылык афәтен сизмәде диярлек. Дөрес, кайбер кытлыклар булды: малларга азык җитмәде — күрше өлкәләр ярдәмгә килде. Республикада бәрәңге ярамады — Белоруссия җибәрде, тугандаш социалистик илләр — Польша һәм Румыния булышты. Идел буена илнең төрле якларыннан эшелоннар агылды. Ләкин аларны без гадәти йөкләр дип кенә кабул иттек.

Бу җиңү иде. Безгә Октябрь биргән кодрәтнең җиңүе!

# ДАВЫЛЛЫ ЕЛЛАР АША




елның башы. Хәтта очар кошлар җиргә егылып төшәрлек салкын көннәрнең берсе. Ләкин Хәмәтгали абзый йортындагылар көннең суыклыгын әйтерсең бөтенләй сизми. Өй ишекләре берөзлексез ачылып-ябылып тора. Анда керәп-чыгып йөрүчеләрнең һәркайсы абзар-кура тирәсендә кайнашкан Хәмәтгалинең шатлыгын уртаклаша.

— Башыңны югары тотып, күкрәгеңне киерә төшеп йөрсәң дә тулы хакың бар синең, — диләр алар Хәмәтгалигә. — Тагын бер улың дөньяга килү белән котлыйбыз үзеңне.

Балага кендек әбисе булган Мәрфуга карчык та малайның әнисен куандырыр өчен үзенең бөтен тел байлыгын эшкә җигә.

— Үз гомеремдә күпме балага кендек әбисе булып, мондый таза, мондый тере баланы күргәнем юк иде әле минем, Фатыйма җаным. Тьфу, тьфу, күз генә тимәсен. Гади бала булмас бу, ил батыры булырдыр, — ди ул, малайны җылы, йомшак чүпрәккә төрә-төрә.

Бер атнадан соң Галиевләр йортында бәбигә исем кушу хөрмәтенә аш-су әзерләнә. Алдан ук киңәшләшеп, кендек әбисе дә, ата-анасы һәм туган-тумачалары да малайга Батырҗан аты кушарбыз дигән фикергә киләләр. Әмма авыл мулласының сүзе өстенлек ала.

— Ходай хәерле гомер насыйп итсә, сезнең бу улыгыздан зур акыл иясе, әйтик, һәр тарафта олуг ихтирам казанган имам-хатиб мөгаллим чыгуы мөмкин, — ди юмарт телле Сафа мулла. — Шуңа күрә мин аңа Муллагали дигән исемне мәслихәт күрәм.

Бу исем өлкән яшьтәге агай һәм апайларның күңеленә хуш килсә дә, Муллагалинең үзен еш кына кыен хәлләрдә калдыра. Бераз үсә төшкәч, иптәшләре аны: «Мулла буласы Гали», дип үрти башлыйлар.

Җиде яше тулгач, әтисе Галине Сафа мулла мәдрәсәсенә укырга бирә. Ата кеше аны кечкенәдән үк басуга, болынга яки урманга үзе белән бергә алып йөри, аның һич бетеп тормас сорауларына иренмичә җавап бирә, башыннан кичкән яки кешедән ишеткән төрле кызыклы вакыйгалар турында сөйли. Ә кем белә, бәлки ул Галинең, Сафа мулла әйткәнчә, чыннан да кешеләр телендә мактап сөйләнерлек зур белем иясе булачагына ихлас инангандыр.

Урбар авылында ул үзе дә халык ихтирам иткән алдынгы карашлы, эш сөючән кешеләрнең берсе була. Хәреф тә танымаган гади бер крестьян гаиләсендә туган Хәмәтгали, әтисенә хуҗалык эшләрендә булышу белән бергә, муллага бушлай хезмәт итеп, русча һәм татарча укырга-язарга өйрәнә.

1878 елны, егерме яшендә, аны солдатка алалар. Ул чик буенда хезмәт итә, Россия белән Төркия арасында барган сугышларда катнаша. Ун елга якын хәрби хезмәттә булганнан соң, 1888 елда яңадан туган авылына әйләнеп кайта. Ләкин аны монда күңел юатырлык бернинди дә куаныч-шатлык көтми. Кайтуына ата-анасы инде үлгән, ә авылда калган туганнары, Хәмәтгалигә өлеш чыгармыйча, йорттагы мал-мөлкәтне үзара бүлешеп бетергән булалар. Шунлыктан аңа йорт-җир торгызу хәстәрлеген күрү эшен өр-яңа нигезгә казык кагудан башларга туры килә. Озак та үтми, ул авылның аз сүзле, йомшак табигатьле Фатыйма исемле уңган кызына өйләнеп, гаилә корып җибәрә.

Көннәрне һәм айларны яңадан сүтелмәс тыгыз йомгакка урап, ел артыннан ел уза. Шул елларга юлдаш булып, кызлар һәм малайлар бер-бер артлы туа тора. Муллагалигә унбиш яшь тулганда аларның унынчы балалары дөньяга килә. Ун баланы карап үстерү өчен ата-анага, ял һәм йокыларын онытып, көн-төн эшләргә кирәклеге үзеннән-үзе аңлашыла. Аларның иң зурысына унҗиде яшь, ә калганнары берсеннән-берсе кечкенә. Дөрес, бу гаиләдә балалар эшкә иртә өйрәнәләр. Муллагали дә бик бәләкәйдән үк кул арасына керә башлый, абыйсы белән бергәләп йорт эшләрен карый, аллавыткә урман кисәргә ялланган этисенә булыша.

Әйе, Хәмәтгали абзыйның балалары табындагы бер телем ипекәйнең ни бәя торганлыгын, аның авыр хезмәт бәрабәренә табылганлыгын бик иртә аңлыйлар. Очын-очка көч-хәл белән ялгап барган бер вакытта, көтүдә яшел арпа ашап, аларның сыерлары үлеп китә. Кәтелмәгәндә килгән бу бәла һәркайсын тирән кайгыга сала. Эссе җәй көннәрендә балаларның тамагын ничек туйдырыйм дип уйлана-уйлана үзе ашсыз-йокысыз калган Фатыйма җиңги урынга егыла. Әле биш ае да тулмаган сабые бишектә яткан ананың күкрәгендә сөт кибә.

Җан тынычлыгын югалткан Хәмәтгали абзый, сыңар ат җигелгән арбасына эшкә ярарлык барлык балаларын төяп, иртә караңгыдан басуга чыгып чаба. Кичен өйгә кайткач ул йөзе суырылып, күзләре эчкә батып кергән Фатыйма апаны юатырга, күңелен күтәрергә тырыша. Ә үзе читкә борылып, аңа күрсәтмичә генә, битe буйлап тәгәрәгән яшь бөртекләрен сөртә. Муллагали боларның барысын да күреп, барын да сизеп тора, этисенә ничек итеп булышу турында баш вата. Уйланып яткан шундый төннәрнең берсендә аның исенә Урта Азиядә яшәүче, этисе ягыннан туган тиешле Солтан абыйсы килеп төшә. Ул озын-озак уйлап тормый, өйдәге хәлләрне аңлатып, аңа хат язып сала, үзенең шул якларга китәргә теләге барлыгын белдерә. Атна-ун көн дигәндә, Муллагалине үз янына чакырып, абыйсыннан телеграмма килеп төшә. Кинәт аптырашта калган ата-ана моңа ни диярга дә белми. Хәмәтгали абзый, каршысына утыртып, улы белән беренче тапкыр зурларча сөйләшә, аны авылдан беркая да китмәскә үгетли, көзен Түнтәр мәдрәсәсенә укырга бирергә ниятләвен әйтә. Аның сүзләрен бүлдермичә, дикъкать белән тыңлап торган Муллагали әтисенең хәтерен калдырмаслык итеп, әмма катгый җавап бирә:

— Укырга әле соңыннан да өлгерермен. Ә хәзергә, кулымнан килгәнчә, сезгә ярдәм итәргә телим.

Муллагалинең үз уеннан кире кайтмаячагына тәмам ышанган ата-анага улларына хәерле сәфәр теләүдән башка чара калмый. Берничә көннән Муллагали, Ташкентка китүче кешеләргә ияреп, Урта Азия якларына юл тота.

Ике атнада ул Әндиҗан шәһәренә килеп җитә. Солтан абзыйсы аны якты йөз белән каршы ала. Ашап-эчкәннән соң, бергәләп шәһәр карарга чыккач, таштан салынган икешәр-өчәр катлы йортлар, биек-биек манаралар, түбәләре калай белән ябылган зур-зур кибетләр авыл малаен тәмам хәйранга калдыра. Шул ук вакытта әлеге таш йортлар арасында утырган саман өйләрне, кызыл балчыктан өелгән тәбәнәк коймаларны күрү Муллагалигә авыр тәэсир итә: «Бай дип исәпләнгән бу шәһәрдә дә ярлы кешеләрнең чуты-чамасы юк икән». Аны әнә шундый күңелсез уйлар биләп ала. Җитмәсә тагын көннең эсселегенә түзеп торыр әмәл юк. Урам буйлап аккан арыклар суының да бу эсселеккә каршы торырга кодрәтеннән килми икән: урыны-урыны белән алар я бик нык саеккан, я бөтенләй кибеп беткән.

Әнә шуларны карап йөргәндә Муллагали моннан инде бик ерактагы туган авылын, аның янындагы Куңыр тавын, бормаланып-бормаланып аккан инеш суларын күз алдына китерә. Үзен озатканда, капка төбенә чыгып, кул болгап калган әти-әнисен, туганнарын исенә төшергәч, аның үксеп-үксеп җибәрәсе килә. Ләкин Муллагалигә ничек кенә булса да түзәргә, башкалар алдында сер сынатмаска кирәк бит...

Шәһәргә килгәннең икенче көнендә Солтан абыйсы аны Солтанбеков дигән бер байның мамык чистарту заводына алып барып эшкә урнаштыра. Беренче айларны ул өйрәнчек малай булып эшли, ни кушсалар — шуны башкара. Әмма, унбиш яшендә генә булуына карамастан, киң күкрәкле, таза беләкле, эшкә сәләтле Муллагалине, зур яшьтәгеләр рәтенә кертеп, тәүлегенә ундүрт-унбишәр сәгать эшләтә башлыйлар. Шыплап мамык тутырылган зур-зур капчыкларны, эре-эре төргәкләрне ул кенәзын иңнәренә күтәреп, икенче-өченче катларга ташый. Иң көчле ирләрне дә аяктан ега

торган бу авыр эш атналар-айлар буе дәвам итә. Ни хәл итмәк кирәк, башка һөнәрең булмагач, тешләреңне кысып түзәргә туры килә. Байга хезмәт итү беркемгә дә җиңел түгел.

Заводта эшләүчеләрнең күпчелеге казакълар, үзбәк һәм кыргызлар. Телләре охшаш булганлыктан, Муллагали аларның һәркайсы белән җиңел аңлаша, аларга газеталар укый, күбесенең хатларын һәм гаризаларын яза. Шуңа күрә, малай гына булса да, ихтирам йөзеннән аны «яшь мулла әкә» дип йөртәләр, кирәк вакытта киңәшкә киләләр. Буш вакытларында әти-әнисенә язган хатлары да сирәкләми аның, хәл-әхвәлләрен белеп тора, берничә тапкыр күпмедер акча да җибәрә.

Заводта ел ярым чамасы эшләгәч, мәдрәсәдә алган белем белән генә әллә ни ерак китеп булмаячагын аңлап, 1911 елның көзендә Муллагали рус телен өйрәнү буенча түләүле ике еллык кичке курсларга укырга керә. Анда укыганда ул 1905 елгы Беренче рус революциясендә актив катнашкан алдынгы татар эшчеләреннән Мансуров дигән кеше белән таныша. Мансуров аны революцион хәрәкәт тарихын өйрәнү түгәрәгенә тарта. Бу түгәрәккә йөргәндә укылган күп санлы политик китаплар һәм брошюралар Муллагалигә иҗтимагый үсеш законнарын тирәнтен аңларга ярдәм итә. Тора-бара ул үзе белән бергә эшләүчеләр арасында завод-фабрика хуҗаларының кемнәр исәбенә баеганлыклары, аларга каршы ничек көрәшергә кирәклеге турында әңгәмәләр алып бара башлый.

1914 елда кабынып киткән беренче бөтендөнья сугышы Россиянең барлык хезмәт ияләренә моңарчы күрелмәгән зур бәхетсезлекләр алып килә. Бу канлы сугыш меңәрләгән кешеләрне үз упкынына бөтереп ала. 1915 елның январенда Муллагали Галиевне дә хәрби хезмәткә чакыралар. Полк мәктәбендә өч ай укытканнан соң, ефрейтор исеме биреп, аны каты сугышлар бара торган Карпат фронтына җибәрәләр. Начар коралланган, сугышка бернинди хәзерлексез килеп кергән патша армиясе полклары, дошманның кысрыклавына каршы тора алмыйча, бер-бер артлы чигенәләр. Солдатларның күбесе бу сугышның капкорсаклар файдасына алып барылган талау сугышы икәнлегенә көннән-көн ныграк төшенәләр. Ефрейтор Галиев хезмәт иткән полкны, каты сугышлардан соң сирәгәеп калган сафларын тулыландыру өчен, артка чигерәләр. Командирлар җитешмәү сәбәпле, Муллагали Галиев офицерлар хәзерләү курсына укырга җибәрелә. Анда уку чорында ул курсантлар арасындагы большевик агитаторлар белән элемтәгә керә, сугышка каршы чакырып язылган листовкаларны таратуда аларга булыша. Крестьян гаиләсеннән чыккан яшь офицер Галиевнең революцион юлындагы беренче адымнары әнә шулай башлана.

Курсларда укулар тәмамлангач, унтер-офицер Галиевне яңадан алгы сызыкка озаталар. Тагын канлы сугышлар... Тагын җир өстенә түшәлеп калган солдат мәетләре... Бу вакытта инде окопларда большевикларның: «Патшаны бәреп төшерергә!», «Сугышны туктатырга!» дигән чакырулары көннән-көн көчлерәк ишетелә башлый. Солдатлар үзләре дә сугышка каршы ачыктан-ачык чыгышлар ясыйлар. Бу чыгышлар большевистик карашлы агитаторларның, шул җөмләдән офицер Муллагали Галиевнең дә солдатлар арасында алып барган аңлату эшләре нәтиҗәсе була.

Патша тәхеттән бәреп төшерелеп, монархиягә алмашка килгән Вакытлы хөкүмәт тә җиргә, тынычлыкка, иреккә сусаган хезмәт ияләренең өметләрен акламый. Большевиклар аның халык интересларын яклаучы хөкүмәт булмавын фаш итеп, эшче-крестьяннарны һәм солдатларны социалистик революция ясау өчен көрәшкә өндиләр. Муллагали Галиев үзе хезмәт иткән полкта уздырылган митингларда, җыелышларда русча һәм татарча чыгышлар ясый. Солдатлар аны полк комитеты члены, рота җыелышларында рота комитеты председателе итеп сайлыйлар.

Октябрь революциясен Муллагали чыныккан агитатор булып каршылый. Революция яклы солдатларның һәм офицерларның аның чыгышларын бик күп тапкырлар тыңлаганнары була. Шунлыктан алар Муллагалигә үз кеше итеп карыйлар, аңа ышаналар һәм үзләренең рота командирлары итеп сайлап куялар. Большевиклар партиясе вәкилләре белән бергәләп ул контрреволюцияне яклаган офицерларны кулга алуда актив катнаша, кадетлар, эсерлар һәм меньшевикларга каршы аяусыз көрәш алып бара. Ленинның сугышны туктату, җирне крестьяннарга бирү, завод-фабрикаларны капиталистлар кулыннан тартып алу турындагы сүзләрен солдатларга җиткерә.

1918 елда ул, армиядән демобилизацияләнгәч, туган авылына кайта. Аның өйдән саубуллашып чыгып китүенә инде тугыз елдан артык вакыт узган була. Исәнлек-саулык сорашканнан соң сүз дөнья хәлләренә күчә.

— Ничек анда, элеккесе урынына яңа патша куймаслармы? — дип сорый Хәмәтгали абзый улыннан. — Тагын сугыш башланып китмәсме?

— Үзең дә аңлый торгансыңдыр, әти, — дип җавап бирә аңа Муллагали, — ил халкының бәхетсезлегенә, барыннан да элек, патша хөкүмәте гаепле иде. Патшаны бәреп төшергәннән соң исә хезмәт ияләре алдына Совет властен ныгыту, тормышны өр-яңадан көйләп җибәрү бурычы куела. Ә моның өчен элек патша куштаннары кубызына биегән барлык чиновникларны алыштырырга, дәүләт башына эшчеләр һәм крестьяннар арасыннан чыккан кешеләрне куярга кирәк.

Ул әтисе белән сөйләшеп утырган арада сеңелләре чәй өлгертәләр. Муллагали, юл капчыгыннан чыгарып, табынга үзе алып кайткан күчтәнәчләрне куя. Чит-ят җирләрдә булып, озын походлар үтеп, сагындырып кайткан уллары белән ата-анасы һәм туганнары арасындагы әңгәмә табын янында да бик озак дәвам итә. Ләкин күп еллардан бирле күңелдә җыелып килгән сүзләрне сөйләп бетерерлек кенә булмый.

Чәйдән соң һәркайсы үз эшенә тотына. Муллагали, күрше-күләннәр һәм авыл картлары белән күрешеп кайтырга дип, урамга чыгып китә. Ә икенче көнне, иртүк торып, Малмыжга — өяз хәрби комиссариатына юл тота. Аның документлары белән танышканда хәрби комиссарның кырыс йөзе кинәт яктырып киткәндәй була.

— Сез безгә бик кирәкле вакытта килдегез, — ди ул Муллагалигә һәм телефоннан партиянең өяз комитеты секретарена шалтырата: — Кичә сез сораган иптәш бүген менә үзе килеп керде, иптәш Ибраһимов. Аны сезнең янга җибәрергә мөмкинме?

Секретарь Муллагали Галиевне, күптәнге танышын күтеп алган шикелле, аягүрә басып каршылый. Исәнлек-саулык сорашканнан соң Ибраһимов аның сугышка кадәр кайларда укуы, эшләве, сугышта кайда һәм кем булып хезмәт итүе белән кызыксына, армиядән демобилизацияләнгәндә бирелгән документларына күз төшереп ала.

— Менә нәрсә, иптәш Галиев, — ди ул аннары, бераз сүзсез торганнан соң. — Безнең монда өяз мәгариф бүлегендә эшләр бик үк шәптән түгел. Ун-унбиш көннән без аның мөдирен эштән бушатырга уйлыйбыз. Аның урынына сезне куярга дигән тәкъдим бар. Моңа ничек карыйсыз?

— Бу эш өчен җитәрлек белемем дә, тәҗрибәм дә юк бит минем, — дип җавап кайтара аңа Муллагали. — Белмим, сезнең ышанычыгызны аклый алырмынмы икән...

— Революция елларында солдатлар арасында алып барган эш тәҗрибәгезгә таянырсыз, — дип бүлдерә аны секретарь. — Ә белемегезне күтәрергә беркайчан да соң түгел. Мөдирлекне кабул итеп алганчы әле вакытыгыз бар. Тагын бер тапкыр ныклап уйлап карагыз. Ә аңарчы сезгә бер авыр эш йөкләмәкче булабыз. Урбар волосте безнең өязләрдә иң караңгы волостьларның берсе. Сез анда атаклы Ишми ишанны яхшы беләсездер. Хәзерге көндә ул һәм аның мөритләре төрмәдә утыралар. Ләкин ишанның төрле авылларда калган койрыклары халыкны Совет властена, партиягә каршы котырту алып баралар. Бу волостьта хезмәт ияләре арасында агитация-масса эшләрен җанландырып җибәрүдә ярдәм итә алсагыз бик яхшы булыр иде.

Шул ук көнне Муллагали партиянең өяз комитеты мандаты белән агитатор булып туган авылына әйләнеп кайта. Өйдәгеләр дә, волость идарәсе җитәкчеләре дә вакытлыча гына булса да эшкә аның Урбарга билгеләнүен ике куллап хуплыйлар. Якындагы ун көн эчендә җыелышлар уздырылачак авылларның исемлеге төзелә. Икенче көнне иртән Урбарда, кичен Курамял авылындагы җыелышларда ясаган чыгышларында Муллагали Галиев үз якташларына Совет властеның хезмәт ияләре интересларын яклавы, ил халкы алдында торган бурычлар турында гади һәм аңлаешлы итеп сөйли. Шундый ук җыелышлар өязнең татарлар һәм удмуртлар яши торган тагын ундүрт авылда үткәрелә. Аларның һәркайсында йөзәрләгән кеше катнаша...

Ун көннән соң Муллагали башкарма комитет утырышында өяз мәгариф бүлеге мөдире итеп билгеләнә.

Ә өяздә мәгариф эшләренең торышы шәптән түгел. Муллагалигә көн аралаш диярлек ерак авылларга чыгып китәргә, күпмедер дәрәҗәдә халыкка аң-белем бирергә сәләтле мөгаллимнәр эзләп табарга, яңа мәктәпләр оештыру турында кайгыртыр-

га туры килә. Эшләр акрынлап кына җайланып бара дигәндә, илдә гражданнар сугышы башланып китә. Озак гомерләр буена көтеп, кан коеп алынган ирекне яклап калу өчен бөтен ил күтәрелә. Авыл җирләреннән дә йөзәрләгән-меңәрләгән егетләр, кулларына мылтык тотып, Кызыл Армия сафына басалар. Бу ташкыннан, әлбәттә, Муллагали Галиев тә читтә калмый. Шомлы хәбәрне ишетү белән Малмыж шәһәрендә оештырылган коммунистлар батальонына барып языла. Аларны Көнчыгыш фронтка, Колчакка каршы сугышка җибәрәләр. Фронтка килгәч, батальон 21 нче дивизиянең 188 нче полкы составына кертелә һәм күп кенә сугышларда катнаша. Бу сугышларда Муллагали Галиев башта взвод, аннары рота белән командалык итә. Колчак армиясенә каршы Курган янында алып барылган сугышта дошманны җиңүгә зур өлеш керткән батырлык өчен коммунистик батальонга рәхмәт белдерелә, анда Галиев ротасы аерым рәвештә телгә алына.

«Петроград куркыныч астында!» — дигән хәбәр яшен тизлеге белән илнең буеннан-буена тарала. Революция бишеген саклап калу өчен төрле фронтлардан полклар һәм дивизияләр ярдәмгә ашыга. Алар арасында Көнчыгыш фронттан килгән 188 нче полк та бар. Юденич армиясе, корал һәм сан ягыннан бик күп өстен, нык хәзерлекле булуына да карамастан, Кызыл Армия частьларына каршы тора алмый, җиңелүгә дучар ителә. 188 нче полк составындагы коммунистик батальон монда да сынатмый, үзенә тапшырылган сугышчан бурычны намус белән үти. Шушы кайнар көннәрдә Муллагали Галиев коммунистлар партиясе сафларына керә. Петроградны саклап калу өчен барган сугышта ул каты яралана. Госпитальдә ятып, терелеп чыккач, үзен яңадан алгы сызыкка җибәрүләрен сорый. Ләкин аны Пермь шәһәрендә төзелгән запас полкка билгелиләр. Пермьга килгәч, озак та үтми, Муллагали Галиевне губерна хәрби комиссариатының татар-башкорт секциясе начальнигы итеп куялар. Ә 1920 елның августында ул Мәскәүгә, Кызыл Армиянең политик идарәсенә — ПУРККага җаваплы эшкә күчерелә.

Интервентларның һәм ак генералларның Совет дәүләтен, төрле яктан чолгап алып, тиз арада буып ташларга дигән мәкерле уйлары барып чыкмый. Аларның коткысы һәм турыдан-туры катнашлыгы белән башланган гражданнар сугышы эшче-крестьяннар Кызыл Армиясенең җиңүе белән тәмамлана.

Илебез тыныч төзелеш чорын башлагач, көн тәртибенә сугыш елларында җимерелгән халык хуҗалыгын торгызу, завод-фабрикаларны аякка бастыру, ә моның өчен хуҗалык белән идарә итә алырдай белгечләр хәзерләү бурычы килеп баса — партия бөтен көчне нәкъ шул бурычларны үтәүгә туплый.

Гражданнар сугышы бетү белән Муллагали Галиевне партия Үзәк Комитетының Көнчыгыш бүлегенә инструктор итеп алалар. Аннан ул, Үзәк Комитет путевкасы белән, Көнчыгыш хезмәт ияләренең коммунистик университетына укырга китә. Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәндәге кебек үк, ул биредә дә җәмәгать эшләрендә актив катнаша, университетның профсоюз комитеты председателе вазифаларын үти. Университетта уку белән бер үк вакытта Милләтләр эше буенча Халык комиссариатының татар-башкорт секторы мөдире булып эшли. 1923 елның мартында ВКП(б) Үзәк Комитеты аны укыган җиреннән Урта Азиягә, Бохара коммунистлар партиясенә пропаганда эшләре буенча ярдәм итү өчен җибәрә. Монда килү белән Муллагали Галиев, РКП(б)ның Урта Азия Үзәк Комитеты секретаре Ян Рудзутактан задание алып, җиң сызганып эшкә тотына. Үзбәк халкының гореф-гадәтләрен, телен белү үзенә йөкләнгән бурычны үтәүдә аңа зур ярдәм итә. Бохарада ул, партия мәктәбе оештырудан тыш, анда укучылар алдында лекцияләр укый, күп санлы чыгышлар ясый, партия оешмаларын ышанычлы кадрлар белән ныгытуда булыша. Партия тапшырган бурычны үтәгәч, Муллагали Мәскәүгә кайтып, Плеханов исемендәге авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Бер елдан, тәҗрибә туплау өчен институтның кичке бүлегенә күчеп, СССР Сәүдә Халык комиссариатында экономист булып эшли башлый. 1927 елда, институт тәмамлагач, Татарстан Сәүдә Халык комиссариатының бүлек мөдире итеп билгелиләр. Аннары шул ук елның ноябрендә Муллагали Галиевне партия райкомының беренче секретаре, ә бераздан ВКП(б)ның Татарстан өлкә конференциясендә өлкә контроль комиссиясе председателе һәм Эшче-крестьян инспекциясе халык комиссары итеп сайлыйлар.

Бу чор партия эчендә һәртөрле дошманнарга — троцкийчыларга, зиновьевчыларга, солтангалиевчыларга, буржуаз милләтчеләргә каршы көрәш кызган еллар була. Муллагали Галиев, шуңа турыдан-туры катнашып, партия дошманнарының чын йөзләрен фаш итү буенча эзлекле эш алып бара. Татарстан делегациясе составында ул партиянең XV съездында катнаша һәм анда Үзәк Контроль комиссиясе члены итеп сайлана.

Ленин күрсәтмәләреннән чыгып, контроль органнары җитәкчеләреннән эшне яхшы белү, гаделлек, тугрылык һәм кешелеклелек таләп ителә. Гали Галиев — нәкъ әнә шундый сыйфатларга ия кешеләрнең берсе. Төпле һәм нигезле чыгышларында булсын, конкрет практик эшендә булсын, ул үзен партия куйган бурычларны үтәргә сәләтле җитәкче итеп таныта: хезмәт ияләренең шикаятьләрен, үтенеч-гозерләрен вакытында теркәп баруны һәм тикшерүне тәртипкә сала, уңай тәкъдимнәр буенча билгеләнгән күп төрле чараларны кичекмичә тормышка ашыруны гамәлгә кертә. Партиянең тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьне киң җәелдерү турындагы күрсәтмәләренә таянып эш итәргә кирәклеген ул һичкайчан истән чыгармый. Бу мәсьәләне Татарстан партия оешмасында күтәреп чыгучыларның да берсе ул була. 1929 елда аның «Тәнкыйть һәм үзара тәнкыйть» дигән брошюрасы рус һәм татар телләрендә басылып чыга.

1928—1930 елларда партиянең һәм хезмәт ияләренең бөтен көче беренче бишьеллыкны уңышлы үтәп чыгуга, авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә һәм шул нигездә кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерүгә юнәлдерелде. Сыйнфый дошманнар илдә социализм төзү эшен тоткарларга, партиянең бердәмлеген какшатырга маташтылар. Эшләрен Гали Галиев башкарган өлкә Контроль комиссиясе, партия өлкә комитеты җитәкчелегендә, республиканың барлык партия оешмаларын сыйнфый дошманнарга каршы көрәшкә туплады.

1930 елның февралендә Гали Галиевне Татарстан Госпланы председателе итеп билгелиләр. Ә берничә айдан соң ул РСФСР Госпланының торак-коммуналь секциясе председателе итеп күчерелә. 1931 елда Гали Галиев, партия Үзәк Комитеты путевкасы белән, Кызыл профессура институтына укырга керә. Үзе шунда уку белән бер үк вакытта ул партия Үзәк Комитеты каршындагы марксизм-ленинизм курсларында политэкономия укыта. 1933 елның көзендә ул, институтны тәмамлагач, Казагыстанга партия эшенә җибәрелә: башта партиянең Алма-Ата, аннары Төньяк Казагыстан өлкә комитетларында бүлек мөдире булып эшли.

Эшкә бирелгән, тугрылыклы һәм принципиаль булуы белән Гали Галиев үзенең иптәшләре, хезмәттәшләре арасында һәр вакыт зур ихтирам һәм хөрмәт казана. Аны партиянең XV һәм XVI съездларына делегат итеп сайлыйлар. Революция ветераннары һәм өлкән яшьтәге коммунистлар күңелендә ул бөтен гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган көрәшче булып кергән кеше.

Ә. ГАЛИЕВ.

**Мөхәммәт Гайнуллин,**
филология фәннәре докторы,
тәнкыйтьче

# УКЫДЫК, УКЫТТЫК, ЭШЛӘДЕК, ЭШЛИБЕЗ


XX гасыр башларында туган безнең буынга күпне күрергә, күпне йөрәктән кичерергә, бик күп дөньякүләм тарихи вакыйгаларның шаһите булырга һәм кайберләрендә катнашырга да туры килде. Бу яктан без бәхетлеләр.

Дөрес, бала һәм яшүсмер чакларыбыз бик авыр елларда узды. Туйганчы ашамаган, ачлык елларда бөтенләй интеккән чаклар да булды. Ул вакытларда без киндер күлмәк, алача ыштан, тула чикмәннән башка кием дә күрмәдек. Аягыбызда кыш һәм җәен дә, яз һәм көзнең пычрак көннәрендә дә салкын су бер ягыннан кереп, икенче ягыннан чыгып тора торган чабата иде. Нәкъ менә шул авыр тормыш һәм күпне күрү безне чыныктырды да.

Нинди генә авыр шартларда узмасын, яшь вакытның күңелдә калырлык ягымлы, матур яклары да була. Ул минем мәктәптә укыган елларым. Бәхеткә каршы, мин укырга кергән 1910 елда безнең авыл мәктәбенә яңа мөгаллим килеп бөтенләй яңача укыта башлаган иде. Соңыннан билгеле булганча, ул ерак Уральск шәһәрендә сөекле шагыйребез Габдулла Тукай белән бергә «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укыган, аннан Оренбургка килеп «Хөсәения» мәдрәсәсен тәмамлаган Зәки Рәмиев булып чыкты. Бөтен тормышын һәм табигый сәләтен халыкка хезмәткә багышлаган, мәктәпнең такта белән генә аерылып торган кечкенә генә бер бүлмәсендә яшәгән бу укытучыбыз безне, авыл балаларын, җәмгыятькә файдалы кеше итеп әзерләүдә гаять күп нәрсә эшләде, фәннәрнең нигезләре белән таныштыра башлау өстенә бездә әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләүгә дә зур көч куйды.

Ләкин 1914 елның җәендә башланган дәһшәтле империализм сугышы безне бу яратып укыган мәктәбебездән дә аерды. Чөнки авылның эшкә яраклы ирләре белән беррәттән бу укытучыбызны да солдатка — сугышка алдылар. Кешеләрне генә түгел, хәтта күп кенә крестьяннарның тазарак атларын да сугыш йөкләрен ташу өчен мобилизацияләделәр. Авылда барлык авыр эш картлар, хатын-кызлар белән без, яшүсмерләр, җилкәсендә калды. Без — унбер-унике яшьлек балалар сука да сукаладык, печән дә чаптык, урак та урдык, көтү дә көттек. Ата-аналарга балаларыннан, солдатларга ирләреннән килгән хатларны укып бирүче һәм җавап хатлары язучы да без булдык. Шунда иң авыры — үлем хәбәре китергән хат яки рәсми белдерү кәгазен укып бирү иде. Шуны ишетеп иңрәеп калган, еларга яшьләре дә булмаган аналар һәм апаларның хәсрәтле йөзләре бүген дә күз алдында. Шундый авыр елларда безгә укуыбызны дәвам иттерү һәм укып кеше булу турында уйларга да юл калмаган иде.

Ул юлны — барлык хезмәт ияләренә бәхет ачкычы алып килгән якты юлны — Бөек Октябрь социалистик революциясе ачты. Владимир Ильич Ленин җитәкчелегендәге Совет хөкүмәте беренче адымнарында ук барлык халыкны грамотлы итү мәсьәләсен көн тәртибенә куйды. Балаларны гына түгел, үз вакытларында укый алмый калган буй җиткән кызлар, егетләр һәм өлкән яшьтәгеләрне дә яңадан укыту башланды. Бер үк вакытта укытучылар әзерләүгә дә игътибар көчәйде.



Шулар рәтеннән мин дә 1918—19 нчы уку елында өяз шәһәребез булган Тәтештә алты айлык курсларда булып кайткач, унбиш яшемнән күрше Тутай авылына укытучы итеп билгеләндем. Көндезләрен мәктәптә балалар укытам, кичләрен аерым билгеләнгән йортта зурларны укый-язарга өйрәтә идем. Әле үсмер малай гына булсам да, олы яшьтәге абзыйлар да миңа олылап укытучы абый дип эндәшәләр иде. Икенче елны туган авылыма кайтып, укытучы һәм авыл советы секретаре булып эшли башладым.

Дөрес, бу елларда укыту һәм культура-агарту эшләре алып бару тыныч шартларда гына бармады. Революциянең эчке һәм тышкы дошманнарына каршы барган гражданнар сугышы чорында авылларда да сыйнфый көрәш катлаулы һәм көчле булды. Кулаклар, сәүдәгәрләр совет яклы кешеләргә каршы яшертен көрәш алып бардылар. Мәсәлән, безнең Коллар (хәзерге Кызыл Тау) авылында ярлылар комитеты рәисе булып эшләгән, алдынгы карашлы совет яклы кешене кулаклар яла ягып, караклыкта гаепләп кыйнап үтерделәр... Казанны ак чехлар алган айларда шундый ерткычлыклар тирә-як авылларда да булып торды.

Авылыбызның беренче коммунисты Хисам Бакиров гражданнар сугышына партия мобилизациясе буенча алынды. Миңа аны Тәтешкә кадәр озата барырга туры килгән иде. Юлда барганда аның сугышка китүенә зарланып түгел, бәлки оптимистик рух белән, җиңеп кайтуга һәм киләчәккә тирән ышаныч белән сөйләгәннәре бүген дә хәтеремдә. Бәхеткә каршы, ул яуда үлеп калмады, гражданнар сугышы беткәч кайтты һәм күп еллар буе авыл советы председателе булып эшләде. Аның маңгаена ак офицерлар утлы күмер белән басып язган «коммунист» дигән сүз күп елларга кадәр капланмыйча ачык күренеп торды.

Шундый фаҗигале күренешләрнең шаһиты булу бездә халык һәм революция дошманнарына каршы нәфрәтне көчәйтте, сыйнфый аңыбыз үсүгә ярдәм итте.

В. И. Ленинның 1920 елның октябрендә игълан ителгән «Яшьләр союзының бурычлары» дигән тарихи докладды безне, яшь укытучыларны, җитди уйлануларга этәрде. Даһи Ленинның совет яшьләре алдында «Укырга, өйрәнергә кирәк» дигән бурыч куюы бик тирән тәэсир итте. Миндә дә ул белемгә булган омтылышны яңадан уятты.

Казанда Көнчыгыш педагогия институтында уку, әдәбият укыту һәм аны фәнни өйрәнү эшендә дә Владимир Ильич Ленин әсәрләре безнең өчен һәр вакыт методологик нигез булып торды. Бигрәк тә В. И. Ленинның: «Кешелек дөньясының бөтен үсеше тудырган культураны төгәл белү юлы белән генә, аны яңадан эшләү юлы белән генә пролетариат культурасын төзергә мөмкин... Пролетариат культурасы ул капиталистик җәмгыятьнең, алпавытлар җәмгыятенең, чиновниклар җәмгыятенең изүе астында кешелек дөньясы тарафыннан эшләп чыгарылган белем запасларының законлы үсеше булырга тиеш»[1], — дигән күрсәтмәләрен һәр вакытта хәтердә тотып эшләргә тырыштым. Үткәннәргә хөрмәт белән карарга, әдәби мирасны заман тәнкыйте күзлегеннән карап файдаланырга, андагы уңай якларны өйрәнергә һәм халкыбызга фәнни эшкәртеп бирергә кирәклеген без даһи юлбашчыбыз тәгълиматыннан өйрәндек. Без моның белән горурланабыз.

Әдәбият тарихыбызны өйрәнгәндә һәм язганда кайта-кайта В. И. Ленин әсәрләренә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Ленинның «Без нинди мирастан баш тартабыз» дигән хезмәтен игътибар белән өйрәнү безнең мәгърифәтче язучыларыбыз иҗатын-

[1] В. И. Ленин. Әдәбият турында. Мәкаләләр һәм өземтәләр җыентыгы, Таттосиздат, 1947 ел, 164—165 битләр.

да булган уңай һәм йомшак якларны күрергә, әсәрләренең әдәбият тарихыбыз үсешендә тоткан урыннарын объектив дөрес бәяләргә ярдәм итте.

Мәгълүм булганча, мәгърифәтче язучылар үз әсәрләрендә сыйнфый каршылыкларны тулы гәүдәләндерә алмаганнар. һәм аны максат итеп тә куймаганнар. Бу хәл аларның үз заманы прогрессив карашларын яклаучылар булуын юкка чыгармыймы соң? Ачык җавапны В. И. Ленинның югарыда күрсәтелгән хезмәтеннән табабыз. «Мәгърифәтчеләр,— дип язды В. И. Ленин,— халыкның бер сыйныфын да үзләренең аерата игътибар предметы итеп аерып куймадылар, алар гомумән халык турында гына түгел, бәлки гомумән милләт турында сөйләделәр».

XIX йөзнең икенче яртысында һәм XX йөзнең башында иҗат иткән татар мәгърифәтче язучылары гомумхалык яки бөтен милләт интересы дип язып чыкканнар икән, югарыда күргәнебезчә, ул тарихи һәм законлы күренеш булган.

В. И. Ленинның Европа һәм рус мәгърифәтчеләре эшен билгеләгән характерлы сыйфатлар, мәгълүм дәрәҗәдә, татар мәгърифәтчеләре эшчәнлекләрендә дә чагылыш тапкан. Бу — аларның феодализм чорында тормыш-көнкүрештә урнашкан тәртипләргә, кадимчелеккә аяусыз каршы чыгуларында, сатира укларын яудыруларында, фәннең һәм культураның алга китүе нигезендә барлык халыкка бәхетле тормыш килә дип чын күңелдән ышануларында, үз халкының культура дәрәҗәсен күтәрү юлында армый-талмый эшләүләрендә күренде. Татар мәгърифәтчеләре, буржуаз милләтчеләрдән аермалы буларак, Россиянең прогрессив үсешен дөрес күрә алдылар, татар халкын рус прогрессив әдәбияты һәм культурасыннан үрнәк алырга чакырдылар, үз илләренең ялкынлы патриотлары булдылар. Рәсәйдә яшәгән барлык милләт халыкларына игътибар һәм дуслык белән карадылар. Менә шул гуманистик сыйфатлар аларның әдәби, культура һәм педагогик эшчәнлекләренең тарихи ролен һәм әһәмиятен билгеләде.

XIX йөз татар әдәбияты һәм җәмәгатьчелек фикере үсешен өйрәнгәндә җәдитчелек хәрәкәтен дә читләтеп үтеп булмый. Бу хәрәкәтне аңлау һәм аңлатуда күп еллар буенча каршылыклы фикерләр яшәп килде. Бу катлаулы проблемага ачыклык кертүгә дә В. И. Ленинның капитализм үсешенең закончалыгын күрсәтүгә багышланган теоретик хезмәтләре ярдәм итә. Мәгълүм булганча, Ленин капитализмны феодализмга мөнәсәбәттә бер адым алга китеш дип бәяләгән иде. Шуның шикелле, буржуаз яңару һәм либераль мәгърифәтчелек хәрәкәте булган җәдитчелек тә феодализм тәртипләрен саклап калырга тырышучы һәм дини фанатизмга ябышып яткан кадимчелеккә — консерватизмга караганда бер адым алга атлау һәм прогрессив күренеш булды.

В. И. Ленинның рус классик әдәбиятына, шулар арасында Л. Н. Толстойга карата язган мәкаләләре язучыларыбыз иҗатындагы каршылыкларны аңлауга бик ачык юнәлеш бирә. Язучыларның дөньяга карашларындагы чикләнгәнлекне һәм реакцион якларны тәнкыйть итү белән бергә, аларның иҗатында тормышны реалистик чагылдырудан килеп чыккан уңай идеяләрне популярлаштыру кирәклеген дә әйтә. Югары уку йортлары өчен татар әдәбияты дәреслекләрен төзегәндә, бигрәк тә Муса Акъегет, Заһир Бигиев, Риза Фәхретдинов һәм Фатих Кәрими иҗатлары турында язганда мин В. И. Ленинның югарыдагы күрсәтмәләренә таянып эш итәргә тырыштым.

В. И. Ленин өйрәткәнчә, кеше кешене изүгә корылган җәмгыятьтә «һәр милли культурада ике милли культура» була. Шуларның берсе — изүче сыйныфлар интересын яклаучы, артка өстери торган реакцион культура. Икенчесе — хезмәт халкын азатлыкка чакыручы, яки аңа теләктәшлек итүче, алга барышка булышучы прогрессив культура. Әдәбият тарихыбызны өйрәнгәндә һәм язганда юлбашчыбызның бу күрсәтмәсе, әлбәттә, якты маяк булып торды һәм торачак.

Узган заманның гуманист язучылары, ихлас күңелдән теләсәләр дә, халыкны бәхетле итүнең революцион юлын күрә дә һәм күрсәтә дә алмаганнар. Ләкин аларның талантлылары үзләре яшәгән җәмгыять тормышының каршылыкларын, социаль тигезсезлекләрен художество дәреслеге белән күрсәтә алганнар, җитешсезлекләрен тәнкыйтьләгәннәр. һәм шуның белән халыкның аңы үсүгә, революцион идеяләрнең киңәюенә объектив ярдәм иткәннәр.

Без, өлкән буын кешеләре, Октябрь революциясеннән соң яңадан тудык. Ленин безгә рух бирде. Укыдык, укыттык, тагын укыдык, тагын эшләдек. Соңрак, олы яшь-

тә булуыбызга карамастан, хәзерлек курслары үтеп югары мәктәпкә кердек. Аны тәмамлагач, аспирантурага, аннан гыйльми эшкә калдырдылар. Җаваплы бурычлар тапшырылды. Урта һәм югары мәктәпләр өчен әдәбият дәреслекләре төзүгә керештек. Нәтиҗәдә алар язылып бернична мәртәбә басылдылар да. Ниһаять, XIX һәм XX гасыр татар әдәбияты һәм публицистикасы тарихына караган ике зур китабым русча да басылып чыкты. Инде кырык бишенче ел югары мәктәпләрдә һәм фәнни институтларда эшлим.

Болар тик совет илендә, партиябезнең ленинчыл милли политикасы тантана иткән коммунизм төзүче җәмгыятьтә генә мөмкин булган чын хакыйкать.

Хәзер кешелек дөньясының өчтән бер өлеше коммунизм байрагы астында җирдә гадел, бәхетле якты тормыш төзү өчен гигант көрәш алып бара. Партиябезнең Май пленумында каралып, бөтен халык тикшерүенә куелган яңа Конституция проекты бу көрәштә, һичшиксез, миллионнар өчен якты маяк булачак.

Безгә, әдәбият галимнәренә, язучыларга һәм культура-сәнгать эшлеклеләренә иҗат өчен социалистик илебездә барлык мөмкинлекләр тудырылган. Игълан ителгән соңгы Конституция проектында тагы да киңрәк шартлар булдыру гарантияләнә һәм ул, һичшиксез, шулай булачак та. Болар бездә тиңдәше булмаган горурлык һәм туган партиябезгә ялкынлы рәхмәт хисләре уята.

**Риза Ишморат,**
драматург

## ИЗГЕ КӨН, ИЗГЕ ЕЛ...

**1919** ел. Октябрь. Күңелдә шатлык, йөрәктә ялкын, кайнар дәрт, күтәренке рух. Миндә генә түгел, күпләрдә шулай. Барлык хезмәт ияләрендә — эшче, игенче, хезмәткәрләрдә. Бу шатлыкны революция алып килде. Бөек Октябрь. Совет дәүләте. Ленин!

Революция булганга инде ике ел тулып килә. Ә аяусыз көрәш, канлы көрәш әле һаман дәвам итә. Гражданнар сугышы бара. Дәүләт башыннан бәреп төшерелгән патша ялчылары — завод, фабрика һәм җир хуҗалары, аларга ялланган армия, тиз генә бирелергә теләми, бугазга-бугаз килеп тартышалар.

Ни өчен соң әле сүземне 1917 елдан түгел, 1919 елдан башладым?.. Чөнки шушы елның ноябрь башында миңа 16 яшь тулды. Үземнең дөньяга, революциягә, киләчәккә карашымны яхшы ук ачык һәм нык билгеләгән чак. Сентябрь аеннан бирле комсомол сафында. Беренче шигырьләрем басылып чыккан вакыт.

Комсомолга кергәч тә үземнең яшьтәшләргә, кордашларга мөрәҗәгать итеп, «Яшь көч» газетасында:

> **Яшь Каһарман, син әгәр дә безгә якты көн дисәң,**
> **Тормыш сөйсәң, бәхет дисәң, әйдә син безнең белән!**

— дип язган идем. Икенче шигыремдә:

> **Тотындык та кулны-кулга без, яшь көчләр, һәммәбез**
> **Алда күреп якты нурлар омтылабыз алга без!**

— кебек юллар бар иде.

Якты һәм шатлыклы, мул һәм матур тормыш, халкыбызга иркенлек һәм бәхет бирәчәк иде үзебез төзиячәк социализм һәм коммунизм. Бу бәхет әле ул вакытта безнең хыялыбызда гына иде. Әлегә кискен көрәш бара. Дошманны җиңәргә, тар-мар итәргә кирәк. Илдә бөлгенлек һәм җимереклек, аны аяккка бастырырга кирәк. Чир-зәхмәт, йогышлы авырулар җәфалый, алардан котылырга кирәк. Күпчелек укый-яза белми, надан. Культура фронтында да авыр һәм җаваплы бурыч тора. Ләкин иң беренче бурыч Совет Ватанын дошманнан саклау. Дорес, Краснов, Деникин кебек бер төркем ак генераллар яшь Совет Армиясе тарафыннан инде тармар ителделәр. Дөньядан себереп түгелгән монархияне яңадан торгызу нияте белән ыжгырып килгән адмирал Колчак та инде Урал таулары артына, Себергә куылды. Ләкин әле ул исән, үзенең канлы эшен дәвам иттерә. Аны тар-мар итү төп бурычларның берсе. Ватан авыр көннәр кичерә. Шулай да дошманны җиңеп чыгуга ышанычыбыз

зур. Без партия һәм дәүләтебезгә, бөек Ленинга ышанабыз. Ленинның: «Без Совет дошманнарын җиңәргә тиеш һәм җиңәчәкбез», — дигән сүзләре безне көрәшкә, батырлыкларга рухландыра.



*Риза Ишморатов. 1920 ел.*

Шул рухлану белән мин Октябрьның ике ел тулуына багышланган шигырь яздым. Ул 1919 елның 7 ноябрендә, Уфаның «Кызыл юл» газетасында «Изге көн» исеме белән басылып чыкты. Бик сөендем моңа. Үземне яшь шагыйрь итеп тоюдан да бигрәк яшь көрәшче итеп хис иттем. Менә аның баштагы дүрт юлы:

**Изге көн бу, изге ай, изге ел, изге сәгать,**
**Чөнки бу көн барча мәзлум халыклар булды азат.**
**Юк, түгел бу явыз, ерткыч, канэчкеч шаһлар көне,**
**һәм капиталга табынган бәдбәхет Колчак көне.**

Бәдбәхет Колчак! Редакция Колчак сүзен «байлар» дип төзәткән. Ошамады. Мин әле күптән түгел генә Уфадан куып җибәрелгән Колчакны — мәкерле, конкрет дошман итеп күргән идем. Ләкин үзем бөтенләй тәҗрибәсез язучы, яшем дә уналты тулар-тулмас кына булгач, сүз көрәштереп булмады.

Изге көн! Халыкларны коллыктан азат иткән Октябрьга, социалистик Ватаныбызны барлыкка китерген революция көненә, дан җыры иде бу.

1920 ел башы. Февраль. Колчак армиясе тар-мар ителде. Шулай да әле бу канлы сугышның соңы түгел иде. Совет дәүләтенең эчке дошманнары да, тышкы дошманнары да күп әле. 1920 ел башларында сәнәкчеләр дип аталган кулаклар бандасы күтәрелеп чыкты. Коммунистларны, комсомолларны, Совет активларын, укытучыларны җәзалап үтерәләр, күп кенә очракларда тереләй җиргә күмеп китәләр. Минзәлә, Бөре, Бәләбәй, Уфа өязләрен, «Кара Кош» исеме белән йөртелгән кара яу каплап алды. Партиябез үзенең членнарын, комсомолларны һәм барлык хезмәт ияләрен шундый бандаларга каршы көрәшкә чакырды. Мин дә, үземнең классташ дустым Хәснулла Сәетов белән бергә, ирекле рәвештә, комотрядка язылдым. 1920 елның февралендә социалистик Ватаныбызны дошманнан саклау нияте белән, беренче тапкыр кулыма корал алдым. Март, апрель айларында Уфа, Бәләбәй, Бөре, Минзәлә өязләрендә сәнәкчеләргә каршы, ә җәй айларында көньяк Урал якларында, бик хәвефле шартларда, җаваплы хәрби операцияләрдә катнаштык. Әле 17 яшь тә тулмаган иде үзебезгә. Шулай да Совет дәүләте язмышы, социалистик Ватаныбызны дошманнардан саклау эше өчен үз-үзебезне аямадык. Илебез язмышы, халкыбыз язмышы, партия һәм дәүләтебез язмышы безнең үз язмышыбыз иде.

1925 елдан членлыкка кандидат, 1927 елдан партия члены булдым мин. Партия һәм дәүләтебез нинди генә җаваплы эш йөкләсә дә, аны һәр вакыт, һәр җирдә, һәр эштә намус белән башкаруны үземнең изге бурычым итеп санадым.

Туган илебез язмышы хәл ителгән Ватан сугышы елларында да, башта танк частьларында рядовой солдат, соңрак майор дәрәҗәсендә, 1 нче Украина фронтында чыгарыла торган «Ватан намусы өчен» газетасында редактор урынбасары буларак, өстемә йөкләтелгән хәрби бурычларны намус белән үтәдем. Берлин өчен булган урам сугышларында яраланып госпитальдә ятып чыгарга да туры килде. Сугышта миллионлаган кешеләребез батырларча һәлак булды. Өч туганым сугыш кырларында ятып калды. Ә без, җиңүче исемен яулап, туган илгә кайттык.

Театр — халыкны тәрбия итүдә зур көчкә ия булган тылсымлы сәнгать. Бөтен иҗат көчемне сәнгатьнең шушы төренә — драматургиягә багышладым.

Иҗат хәзинәмдә, кечерәк пьесаларны да кертеп санасаң, барлыгы 37 драма әсәрем бар. Барысы да социалистик Ватаныбызны саклауда, аны ныгытуда героик көрәш алып барган кешеләрне, аларның югары мораль сыйфатларын, мәхәббәт, дуслык хисләрен чагылдырган әсәрләр.

Бөек Ленинның Казан университетында уку һәм революциягә беренче адым атлаган чорын чагылдырган «Давылга табан» драмасын язуга мин аеруча зур җаваплылык белән килдем. Бу әсәр өстендә шактый озак еллар эшләвем дә шуның белән аңлатылса кирәк. Беренче тапкыр Казанда В. И. Качалов исемендәге зур драма театрында куелган бу героик драма Татарстанда һәм үзәк матбугатта югары бәя алды. Аның татар һәм рус телләрендә берничә тапкыр дөньяга чыгуын һәм аеруча Бөек Октябрьның 60 еллыгы уңае белән Мәскәүдә кабат басылып чыгуын үзем өчен зур бәхет саныйм.

«Үлмәс җыр» героик драмасы аерым игътибарга лаек булса кирәк. Мин бу пьесамда көрәштәшем һәм каләмдәш дустым Муса Җәлилнең Ватан сугышында күрсәткән кыюлыгын, тиңсез батырлыгын һәм шагыйрьлек талантын гәүдәләндерүне бурыч итеп куйдым. Бу әсәр дә беренче тапкыр рус телендә Качалов исемендәге Зур драма театрында куелды, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (1957) Мәскәүдә күрсәтелеп, үзәк һәм Татарстан матбугатында югары бәя алды, татар һәм рус телләрендә кат-кат басылып чыкты.

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай үзенең тылсымлы моңы, җыры, шигырьләре белән гомерем буе миңа юлдаш булды. Аның дәртле, ялкынлы, тирән мәгънәле шигырьләре белән телем ачылды. Әле соңгы вакытта гына Тукайның гүзәл дә, ялкынлы да, фаҗигале дә булган гомерен чагылдырган «И мокатдәс моңлы сазым» исемле романтик драма тәмамладым. Якын елларда аны да театрларыбызның берсендә күрергә өметләнәм.

Әнә шундый тарихи шәхесләрне, аеруча бөек Ленин образын сәхнәдә гәүдәләндерү белән үземне бәхетле саныйм. Бу бәхетем өчен мин, барлык Совет кешеләре кебек үк, Бөек Октябрьга, аны барлыкка китергән партиябезгә һәм даһи Ленинга бурычлы.

Бу кечкенә язманың соңгы юлларында әйтәсе килгәнем шул: алтмыш ел гомер эчендә халкыбыз ирешкән җиңүләрне, ирекле, иркен тормышыбызны раслап барлыкка килгән яңа Конституция — тормышыбызның Төп Законы, Советлар Союзында яшәүче барлык кешеләрнең зур бәхете булган кебек үк, минем дә бәхетем, горурлыгым ул.

## Габдрахман Әпсәләмов,

прозаик

# ЮЛ КҮРСӘТҮЧЕ ЙОЛДЫЗ

Олы бәйрәм — Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгы якынлашкан көннәрдә һәр совет язучысы үзенең иҗатын тагын бер тапкыр күздән кичерә, нинди дер йомгаклар ясап киләчәккә планнар кора торгандыр. Бөтен иҗатлары Октябрьдан соңгы чорга туры килеп, аның җылы кояшы астында шытып, шаулап чәчәк аткан язучыларның куанычы аерата зур. Безгә бер нәрсә көн кебек ачык: Октябрь җиңмәсә, без, чүлдәге кылганнар кебек, кибеп беткән булыр идек. Бөек Октябрь безне җитәкләде, әдәбиятыбызга юл күрсәтүче якты йолдыз булды.

1936 елгы Конституцияне кабул иткән шатлыклы көннәр хәтердә уелып калган. Ул эшкә инде кырык ел вакыт үткән, тик бернәрсә дә онытылмаган кебек. Хезмәткә, укуга, ялга хокук бирелүгә чиксез шатланган идек.

Инде Октябрьның данлы 60 еллыгы якынлашкан көннәрдә яңа Конституциянең проекты игълан ителде. Күп миллионлы совет халкы аны тагын да зуррак дәрт белән каршы алды. Бу тарихи вакыт эчендә без яңа җәмгыять, кешелек дөньясы әле моңарчы белмәгән җәмгыять төзедек. Бу — безнең бөеклегебез һәм горурлыгыбыз. Шул ук вакытта бу — совет кешесенең дә чын бөеклеге, чын горурлыгы.

Әдәбият халыктан башка яшәми, аның чәчәк атуы өчен халыкның барлык рухи көчләре азат булуы кирәк. Буржуаз җәмгыятьтә икеләтә социаль изелү астында яшә-



гән кечкенә милләтләр мондый бәхеткә ирешә алмый. Татар әдәбиятының тарихы меңъ еллларга сузылса да, ул бары тик 1905 ел революциясеннән соң гына чынлап торып баш калкытты. Әмма революция дулкыны сүрелә башлагач, аның яшел үрентеләре дә боегып башларын иделәр. Бәхеткә каршы, бу хәл озакка бармады. Октябрь кояшы чыгуга, бәрәкәтле май аендагыча, барысы да җанланып, терелеп китте.

Коллыктан азат ителгән халык үз арасыннан мәдәният мәйданына яңа талантлар чыгара башлады, ә революциягә хәтле үк яза башлап та иҗат көчләре бөтен куәтенә җәелә алмаган өлкән язучылар исә гүя икенче яшьлекләрен кичерде. Мисалга олы талант иясе Галимҗан Ибраһимовны гына алыйк. Аның «Казакъ кызы», «Безнең көннәр» дигән гүзәл романнары, революциягә кадәр үк язылган булуларына да карамастан, үз вакытында дөнья күрә алмады, полиция бүлмәләре тузанына күмелеп ятты. Бары тик Октябрьдан соң гына алар якты дөньяга чыктылар.

Шундый олы талантларга да юл булмагач, ул чорда яңа күтәрелүче яшьләр иҗатына игътибар итү турында сөйләп тә торасы юк. Кыскасы, яшь талантларны вакытсыз шиңүдән Октябрь гына коткарды, ул гына аларга үсеп китү өчен моңарчы күрелмәгән шартлар тудырды. Шуңа күрә дә без барыбыз да үзебезне Октябрь тудырган әдипләр итеп саныйбыз. Һәм без хәзинәбездә булган барлык иҗат җимешләрен халкыбызга бирә алуыбыз белән бәхетле. Бары тик халыкка ирешә алган, халык тормышына яраган, ягъни яңаны тезәргә булышкан югары художестволы әсәрләр генә җәүһәрләргә санала ала. Сандык төбендә ятканнары, никадәр зур һәм матур булмасын, алар чын җәүһәр түгел әле.

Мин күп санлы татар язучыларының гади бер вәкиле. Минем барлык әсәрләремә яшәү көчен Октябрь бирде дип әйтә алам. Минем бер генә романым да Октябрь идеяләреннән читтә тормый. Яшьлегемдә мин кешелек бәхете өчен тормышларын аямый көрәшкән батырлар белән мавыктым. Ленин образын гәүдәләндерү — минем иң татлы хыялым иде. Ләкин хыялны чынга әверелдерү җиңел түгел. Башта Ленин нигез салган тормышыбызны төрле яклап чагылдырган әсәрләр язарга, тәҗрибә тупларга кирәк иде. Аннары инде, көчем җитәрлек булса, хыялдагы темага тотынырга. Бу күпме вакыт таләп итәр — әле билгеле түгел иде.

Әдәбият тормыш белән бергә атлый. Теге яисә бу әсәрнең тууын да тормыштан аерып карау мөмкин түгел. Мин хәрби романнар язармын дип уйламаган да идем. Әмма иҗатымның башлангыч чорында ук Бөек Ватан сугышы башланып китте. Империализмның удар отряды булган фашизм Бөек Октябрь казанышларын җимерергә, беренче социалистик дәүләтне — Ленин дәүләтен тар-мар итәргә ыргылды. Совет халкы, шул исәптән яшьләр, комсомоллар, бер кешедәй булып, туган илне сакларга күтәрелде. Башкалар белән бергә мин дә фронтка киттем. Без бер нәрсәне яхшы аңладык: туган илебездән башка безгә тормыш та юк, иҗат та юк. Шуңа күрә кол булырга теләмәдек.

Бөек Ватан сугышы совет халкының гүзәл җиңүе белән тәмам булды. Әмма дөнья күләм әһәмиятле бу җиңүнең тирән мәгънәсен, зурлыгын аңлау, фашизмны тар-мар итү белән халыкларга иң зур бәхет — тынычлык китерүнең нинди изге эш икәнен төшенү вакыт сорый иде. Аннары сугышны бөтенләй күрмәгән яшь буын да үсеп җитте. Аларга да сугыш турында дөресен сөйләү, халыкның биниһая батырлыгын күрсәтү кирәк иде. Моны, беренче чиратта, без, сугышны күргән язучылар, эшләргә тиеш идек. Кайнар эзләр буенча «Алтын Йолдыз», «Газинур» романнарын яздым. «Алтын Йолдыз»да үзебез үткән сугышчан юл, ягъни Ватан намына күрсәткән батырлык гәүдәләнсә — Алтын Йолдыз иң югары

батырлык символы ул, «Газинур»да коммунистлар партиясе тәрбияләп үстергән гади совет кешесенең рухи бөеклеген күрсәтүне бурыч итеп куйдым.

«Газинур» романына тотынуымның икенче сәбәбе дә бар иде: Газинур әдәби герой гына түгел, ул безнең чынбарлыкта яшәгән кеше, коммунист, гаҗәеп батырлыгын да ул аңлы рәвештә эшли, аның батырлыгын үлем ачысы белән йолдыз кебек атылу дип кенә аңларга ярамый. Үлгәннән соң Газинурның күкрәк кесәсендә Александр Матросовка багышланган листовканың табылуы дөрес факт, язучы уйлап чыгарган нәрсә түгел. Газинур — Октябрь баласы, яңа социалистик җәмгыять батыры. Мондый герой яшь укучыларга бик нык тәэсир итәргә тиеш иде.

Фашизмга каршы көрәшнең интернациональ характерын ачыклау, сугышның дөньядагы барлык кешеләргә дә бәла гына китерүен күрсәтү теләге белән «Мәңгелек кеше» романын яздым. Аның да төп геройлары тормышта булган кешеләр, тик фамилияләре генә әзрәк үзгәртелгән. Сугыш салган яралар йөрәктә шул кадәр көчле булганга, әле күптән түгел генә «Агыла болыт» дигән яңа әсәр яздым. Монда да геройларның күпчелеге тормыштан алынды.

Тынычлык чиксез зур корбаннар бәрабәренә яулап алынды. Совет халкы Ватан сугышында егерме миллион кешесен югалтты. Без аларны һичкайчан оныта алмыйбыз. Шуңа күрә тынычлыкны ныгыту белән бергә коммунизм төзүне дә кызу темплар белән алып барабыз. Коммунизм — тынычлык ул. Шул героик эшне күрсәтү теләге белән эшче сыйныфка багышланган «Сүнмәс утлар» романын яздым.

Бирегә шуны басым ясап әйтергә кирәктер: укучы күңеленә хуш килерлек әсәр язу өчен тормышны яхшы белү, аның эчендә кайнау, үзеңә дә шул эшкә актив катнашу мәҗбүри. Читтән карап кына бернәрсә дә иҗат итү мөмкин түгел. Монда иң кыю фантазия дә ярдәм итә алмый. Әгәр үзем заводта слесарь булып эшләмәсәм, «Сүнмәс утлар»ны һичкайчан яза алмаган булыр идем.

Яңадан-яңа темалар никадәр мавыктырса да, гомер дигәнең бик тиз үтеп бара икән. Бервакыт тирән уйга калдым. Иң зур хыялымны тормышка ашырганым юк бит әле минем: Ленин турындагы әсәргә тотына алмый йөрим. Артык сузарга да мөмкин түгел. Күңел бит: мин булмасам, башкалар язар, дип тынычлана алмый. Ленин темасы — чиксез тема, аңарга һәр язучы үзенчә якын килергә мөмкин.

Ниһаять, «Күк күкрәр» романын да тәмамладым. Аның беренче кисәге «Карышкан кызлары» — зур теманың киңәйтелгән экспозициясе булса, икенче кисәге — «Беренче тау» — Владимир Ильич Ульянов-Ленинның Казан чоры тормышына багышланган. Бу әсәр 1975 елда аерым китап булып басылып чыкты. Ләкин аны әле бүген дә камилләштерүдән туктаганым юк. Яңадан-яңа фикерләр туа, моңарчы синең игътибарыңа чалынмаган материаллар кулга эләгә...

Хәзер «Күк күкрәр»нең русча басмасын хәзерлим. Рус язучыларыннан бик кыйммәтле рецензияләр алдым. Әлбәттә, миңа әсәрне тагын бер мәртәбә яхшылап карап чыгарга туры килә. Бу эшкә көчемне кызганмам.

Ленин темасының милли язучыларга өстәмә кыенлыклары да җитәрлек. Юлбашчыбыз гаять үзенчәлекле бөек шәхес. Аның үзенә генә хас кадерле кешелек сыйфатлары, характеры, сөйләшү манерасы, кешеләрне тыңлый белүе бар. Боларны милли телдә тугәл бирү ифрат читен. Рус язучылары Ленинның үз сүзләрен үзгәрешсез алалар, ә безгә барысын да тәрҗемә итәргә туры килә. Ә тәрҗемә тәрҗемә инде ул.

Октябрь революциясе җиңде, Октябрь революциясе дәвам итә дигән тирән мәгънәле төшенчә бар. Әйе, Октябрь революциясе кайчандыр булган һәм бер урында катып калган тарихи вакыйга түгел. Октябрь социалистик революциясе бүген дә дәвам итә, безнең дөнья күләм героик көрәшләрдә, илебез күтәргән бөек төзелешләрдә, совет халкының көндәлек хезмәтендә нурланып чагыла.

Совет язучылары тормышны художестволы тикшерүләрен туктаусыз дәвам итәләр, чынбарлыкның әдәби елъязмаларын бирәп киләләр. Безнең иҗатыбыз партияле. Заманыбызның зур язучысы М. Шолохов әйткәнчә, безнең һәрберебез үз йөрәге кушканча яза, ә йөрәкләребез партиягә, халыкка бирелгән.

Бу сүзләргә артык бернәрсә өстәргә кирәкми. Монда барысы да коммунистларча туры, ачык әйтелгән.

**Атилла Расих,**
прозаик

# ӨЧ ФАРЫЗ

Бөек Октябрьның кайнар сулышын мин бүген дә әле яхшы тоям. Дөньяны дер селкеткән бу титаник вакыйганың туган илгә һәм бөтен кешелеккә нинди зур үзгәреш ясавы минем күз алдымда булды. Язмыш баштан сыйпап үстермәде. Әмма мин гражданин буларак та, язучы буларак та бәхетле. Чөнки барлык авырлыкларны халык белән бергә уздырдым, тормышның гел кайнап торган җирләрендә булдым. Һәм бу хәл язучылык язмышымны бик нык җиңеләйтте дип уйлыйм.

Революция тәэсирендә кешеләрнең тормышка карашлары үзгәрүен мин үз күзләрем белән күрә килдем, үзем дә шул ук үзгәрешләрне кичердем. Шәһәрләрнең, авылларның яңару процессы — болар һәммәсе күз алдыбызда узды. Мин бу гадәттән тыш, могҗизадай күренешләр тасмасын күңел экранымда чагылдырып, теләсәм кайчан күзәтә алам. Ә бит мондый байлык, мондый хәзинә, ягъни тиңе булмаган тарихи вакыйгаларның шаһиты булу һәр язучыга бирелми. Әдәбият тарихы үзенең сәхифәләрендә бик күп әдипләрнең исемен саклый. Ул шөһрәт ияләренең күбесеискиткеч вакыйгалар тезмәсеннән торган елларның, чорларның шаһиты булганнар. Ләкин аларның күбесенә Бөек Октябрь революциясе тудырган искиткеч зур әһәмияткә ия вакыйгаларның шаһиты булырга туры килмәгән. Шул күзлектән караганда уникаль, моңарчы күрелмәгән зур бәхеткә ия әдәбият эшлекләләре без. Бу беркайда да, бер язучыга да насыйп булмаган бәхет. Без исә шул бәхетне тоеп, һәм шул бәхетнең җаваплылыгын да аңлап иҗат итәргә тиешбез.


Кайчагында безнең уйларыбызны, гамәлебезне ыгы-зыгы читкә алып китә башлый. Дарыларыбыз тиешле корылыгын югалта төшкәндәй була, иҗатыбызның гражданлык ялкыны сүрелгәли кебек. Хәлбуки беренче фарыз, минемчә, заманыбызга, илебезгә, ниһаять, совет язучысы дип аталган әдәбият остасы өчен иң бөек дәрәҗәгә лаеклы художник булып калуда.

Бөек Октябрь революциясенең ганимәте азчылык милләтләргә аерата күп тиде. Чөнки алар социаль азатлык белән бергә милли азатлыкка да ирештеләр. Безгә моны һич тә истән чыгарырга ярамый. Интернационализм байрагы безнең кулларда бик югары тотылырга тиеш. Бу, минемчә, безнең икенче фарыз эшебез.

Матур әдәбиятыбыз ирекле рәвештә һәм шатланып бөек Ленин васыятьләрен, чорыбызның бөек даһие оештырган партия теләкләрен үтәү өчен көрәшен дәвам иттерә. Ләкин мәкерле империализм белән барган киеренке идеологик көрәш дәверендә безнең бер генә «патрон» да бушка атылырга тиеш түгел. Ягъни безнең әсәрләребез тиешле эмоциональ тәэсир ясасыннар, күңелләрне сафландырып, укучыда кешелеклелек, батырлык һәм изге эш өчен үз-үзен аямыйча яшәү куанычы тудырсыннар.

Татар совет әдәбияты һәм хосусән аның прозасы сугыштан соңгы елларда шактый кыю адымнар ясап, әдәби осталык җәһәтеннән ярыйсы гына алга китте. Шулай да әле кайбер укучыларыбыз прозабызда Чыңгыз Айтматов һәм Василь Быковларның булмавына хафалануын белдерә. Мин үзем, дөресен әйтим, бу мәсьәләдә кара кайгыга батарлык урын бар дип санамыйм. Безнең прозабызда бәлки аерым «сөнге»ләр юктыр, мәгәр прозабызның фронты киң, тылы нык, тирән. Ә инде безнең әсәрләребезгә бөтенсоюз вакытлы матбугатында рецензияләр бик аз күренә икән, бу мәсьәләдә тәнкыйтьчеләр үзләренә үпкәләсеннәр.

Әмма безнең әдәбият яулаган биеклекләрдән канәгать булып, шул югарылыкта торырга тиеш дип әйтергә теләмим. Һәрбер әдәбият үзенең эчке закончалыкларына буйсынып хәрәкәтләнә. Аның объектив сәбәпләр аркасында текә күтәрелеш ясаган, яки бер урында таптанган чаклары да була. Әдәбиятыбызның үткәне никадәр генә зур булмасын, бәхәссез ки, аның киләчәге тагы да зуррак һәм яктырак. Каләмдәшләрем — татар язучылары да үсү һәм камиллеккә ирешү юлының тугандаш совет



әдәбиятлары арасындагы бәйләнешләр аша гына мөмкин булуын тирәнтен аңлыйлар булса кирәк. Кыскасы, безгә идея сафлыгын нык саклаган хәлдә, профессиональ осталыкнын яңа кыяларына үрмәләргә дә үрмәләргә әле... Бу өченче һәм бик мөһим фарыз. Әгәр без хәзер кызу темплар белән «ике телле»гә әверелә торган, зәвыгы көннән-көн үсеп барган укучыбызның санын, сыйфатын югалтырга теләмәсәк, бу эшкә бик җитди карарга тиешбез.

Моннан алтмыш ел элек бөтен дөнья тарихын яңа рельсларга кертеп, туфандай, зилзиләдәй шаулап Октябрь революциясе булып узды. Ул дөньяны тетрәтеп кенә калмады, ул бөтен планета өчен язгы ләйсәндәй игелекле, шифалы нәтиҗәләр дә бирде. Мин үземне шул революция идеалларына хезмәт итүче кеше дип исәплим. Совет гражданины мин! Бу минем өчен зур бәхет. Иң изге дип санаган омтылышларым — илгә, халыкка хезмәт итү — даһи Ленин күрсәткән юлдан һаман алга бару. Шулай булгач, бөтен иҗатым да шул ук омтылышларны гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

Бүгенге көндә язучыларны кызыксындырырга тиешле иң мөһим тема заман темасы икәнен яхшы аңлыйм. Ләкин шул ук дәрәҗәдә бик мөһим тагы бер тема бар. Ул — Ленин темасы, ул — тарихи-революцион тема.

Кайбер тугандаш әдәбиятлар бу җәһәттән бездән шактый алга киткәннәр. Аларның китап киштәләрендә бу темага караган әдәби әсәрләр байтак. Инде безнең татар совет әдәбиятына килгәндә, минемчә, тарихи-революцион тема, халкыбызның шанлы революцион тарихын эченә алган, конкрет шәхесләрнең героик юлын яктырткан проза әсәрләре җитенкерәми. Укучы, аерата яшь укучы, мондый китапларга мохтаҗ. Аның, тарихы яхшы өйрәнелгән милләт вәкилләредәй, үзенең гомуми тарихын һәм революцион тарихын гыйльми әдәбияттан да, художестволы әсәрләр укып та тирәнрәк беләсе килә. Моны аңардан милли һәм гражданлык горурлыгы таләп итә.

Мин менә шулардан чыгып бик күп вакытымны ялкынлы революционерыбыз, бишенче ел каһарманы, тугрылыклы ленинчы Хөсәен Ямашев образын тудыруга бирдем. Бу эшемне әледән-әле заман темасына мөрәҗәгать итү белән бергә чиратлаштырып барам. Хәзер «Ямашев»ның өченче китабы өстендә эш башладым.

Совет халкы Бөек Октябрьның алтмыш еллыгын яңа Конституция белән каршылый. Проект бөтен халык тикшерүенә тәкъдим ителгән. Төп Закон совет кешесе алдында мораль һәм материаль яктан үсү өчен яңадан-яңа мөмкинлекләр ача. Аның һәр бүлеге, һәр статьясы безнең күңелләрдә туган илебез һәм халкыбыз өчен шатлык һәм горурлык хисләре уята. Без аның алтын хәрефләр белән теркәлгән һәр сүзе, һәр җөмләсе Бөек Октябрь революциясенең татлы җимешләре икәнлеген тирәнтен аңлыйбыз.

Әйе, андый татлы җимешләрне үстерү өчен халкыбыз күп изалар чикте, утлы дәһшәт беркелеп торган упкыннарга бер тапкыр гына ташланмады, үзен күп нәрсәдә чикләргә мәҗбүр булды. Арысландай егетләрен, ирләрен югалтты, сылу кызларына, күркәм хатыннарына, әле буыннары ныгымаган күз нурыдай балаларына сырт сынарлык авыр хезмәт михнәтен йөкләргә мәҗбүр булды. Шул ук вакытта ул үтә кыйммәткә төшкән һәм шуңа күрә аерата кадерле булган җиңү тантаналарын да күреп куанды.

Болар барысы да безнең күз алдында үтте. Корбаннар, тырышлыклар бушка китмәде һәм безнең яңа Конституциябез шул казанышларның гүзәл бер билгесе.

Яңа Конституция туган илебезнең яңа тантанасы. Ул ирешелгән уңышларны законлаштырып, безне, язучыларны да, яңа омтылышларга, яңа иҗади казанышларга илһамландыра. Без тагы бер тапкыр илебезнең акыл мәркәзе, җитәкчесе һәм әйдәүчесе булган коммунистлар партиясенә кулны йөрәккә куеп рәхмәтебезне әйтәбез.

Рәсүл Гамзатов,
Дагстан халык шагыйре

# БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ПОСТ

Конституция проектын кат-кат укыйсың да халык тормышы, ил тарихы бөтенләй яңача нурлана башлый. Тарихта эра дигән төшенчә бар. Кешелек дөньясының ерак гасырлар тирәнлегеннән башланган тормышы шуның белән исәпләнә. Әмма сез бүген минем дагстанлы якташымнан, яки үзбәктән, яки казакътан, яки калмыктан: безнең эра кайчан башланды? — дип сорап карагыз. Һәркайсы: 1917 елның октябренда! — диячәк. Менә шушы эра барлык милләтләрнең, барлык буыннарның язмышын яктыртты.

Октябрь эрасына кадәр минем туган халкымны географик урыны, гореф-гадәтләре буенча таныйлар иде, хәзер аның йөзен Ленин идеяләре билгели. Ул дөньяда ничәмә-ничә мең ел яшәгән, ә республиканы революциядән соң гына алды. Октябрь безгә ераккарак карарга, тирәндәрәк ятканны тоярга мөмкинлек бирде. Малай чагымда мин авылда яшәдем, үсә-олыгая барган саен республикам халыкларының тормыш дәрьясына тирәнрәк чумдым. Хәзер исә, гомер юлын шактый узгач, мин бөтен ил тормышын гына түгел, гомумән, кешелек дөньясының халәтен аңладым. Кайда гына йөрсәм дә, үземне Дагстанның тулы вәкаләтле вәкиле итеп саныйм, ә туган ягыма бөтен кешелек культурасының хәбәрчесе булып кайтам. Бездә кечкенә халык кешесе кечкенә булмый, чөнки ул бөек тарихи бердәмлекнең — совет халкының аерылмас өлеше.

Кайвакыт миңа: «Бөек рус әдәбияты минем тавышымны күмеп китмиме?» дигәнрәк сорау бирәләр. Безнең дәвер — барлык халыкларның культураларын яңарту дәвере. Совет әдәбиятының куәте нәкъ менә шулай күп телле, күп аһәңле, күп бизәкле булуында да инде. Һәм шушы нәрсә аны гадәттән тыш баета, төрлеләндерә, тулы канлы итә. Күк йөзендә бер генә йолдыз ялтыравын күз алдына китереп карагыз әле. Биеклектә аңа, берүзенә, уңайсыз да, күңелсез дә булыр иде. Ә безнең күгебездә бик күп йолдызлар балкый.

Совет әдәбиятының бөеклеге һәм матурлыгы — күп төрлелектә. Совет властеның беренче елларыннан ук, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең беренче адымнарыннан ук, Дагстанда кешеләр арасында интернациональ туганлык рухы урнашты һәм ныгыды. Хәер, бу күренеш илебездәге барлык халыкларның да әдәбиятларына хас. Бары тик прогрессив, рухы белән тирәнтен интернациональ, югары идеяле әдәбият кына тормышчан була ала — бөек рус әдәбияты һәм бөтен совет әдәбиятының тәҗрибәсе шуны раслый. Безнең илебездә шигърият йолдызлары һәркайсы үзенчә җемелди һәм барысы бергә балкый.

Тау елгалары диңгезгә җитеп кушылгач кайсының суы кай тирәдә икәнен аерып булмый. Әдәбиятта исә шигъри бизәкләр һәм аһәңнәр индивидуальлекне югалтмый, киресенчә, бер-берен баеталар. Үз заманының алдынгы идеяләре белән өртелгән милли иҗат җимешләре барысы да интернациональ яңгыраш ала. Безнең көннәрдә милли горурлык тойгысы бөек интернационализм рухыннан башка була алмый. Бу рух милли горурлык хисен бизи. Мин кечкенә генә бер халык телендә сөйләшәм һәм язам. Ләкин язган чагымда бер теләк бик көчле: моны авар, Дагстан кешесе язганын, аннары, әлбәттә, мин — Рәсүл Гамзатов язганын барысы да белсен дип уйлыйм. Шул ук вакытта бер генә минутка да үземнең совет шагыйре, күп милләтле совет халкының вәкиле булуымны да онытмыйм.

Дөньяда бер-берен кабатлаган ике шагыйрь юк. Бер үк шагыйрьнең дә бер-беренә охшаган ике шигыре булмый. Алар барысы да төрлеләр. Шуңа да карамастан, мондый төрлелектә бөтенлек булырга тиеш. Бу бөтенлек — шагыйрьнең кредосы. Минем өчен ул менә нәрсәне аңлата: үз заманыңның күләгәсе түгел, ә яктылыгы бул.

Революциянең балкышын, утын сакла, аның идеяләре белән заманыңны яктырт. Заман — кешеләр ул, заман — туган халкыңның эшләре ул. Художник үз индивидуальлеген халык белән бердәмлектә таба. Шагыйрьне шагыйрь иткән нәрсә образлы фикерләү һәм рифмалы итеп сөйли белү генә түгел, бәлки аның үз замандашлары күңелендәге өрнүне дә, шатлыкны да аңлый, кичерә белүе. Шагыйрь йөрәгендә бөек көч — кешеләргә тартылу хисе яшәргә, кешегә игелек итәргә омтылыш уты дөрләргә тиеш. Чын талант үзенең фидакарьлеге белән аерылып тора. Ул үз кайгы-шатлыкларын оныта, башкалар хәсрәтен кичерә.

Кайгыга көенми, шатлыкка сөенми икән, андый кеше беркайчан да шагыйрь була алмас. Шигырь язарга да, китаплар чыгарырга да мөмкин, ләкин автор үзен генә кайгыртса, галәм үзәгенә «мин»ен бастырса, аның шигырьләре билгеле вакытка кешеләр өстенә кояшны чыгармый торыр, дөньяны каплап торыр — бары шул гына. Поэзия үзәнендә эгоист һәм үз-үзенә гашыйк кешенең болганчык шикләре түгел, халык тормышының якты елгасы агарга тиеш. Чөнки әдипнең заман алдындагы җаваплылыгы гаять зур. Александр Межировның «Коммунистлар, алга!» дигән шигъри юлын гына искә төшерегез. Бу чакыру бүген дә кешеләрне батырлыкка әйди.

Иҗатның зурлыгын, шагыйрьнең халык белән мөнәсәбәтен билгеләүче бизмән бер генә: шигърияттә халык тормышының чагылышы. Безнең авыл янында гына бер юл бар, ул бөтен Дагстан буйлап сузыла. Без, малай чакта, шушы юлда узышып уйный торган идек. Бер тын йөгерәбез дә кайтабыз. Шул юлдан читкә чыгу, ераграк китү уйга да керми. Дөньябыз шул тирәдә чикләнгән иде. «Аврора» залпы яңгыраганнан соң узган алтмыш ел эчендә аварлар да гаҗәеп зур юл үтте. Элек Кавказдагы кысан тарлавыклар арасында бикләнеп яткан халыкка дөньяның киң офыклары ачылды. Революциягә кадәр шагыйрь әтием Гамзат Цадасаның исемен тауларда гына беләләр иде. Ә хәзер аның шигырьләре күп милләтле Ватаныбызда гына түгел, чит илләрдә дә билгеле. Советлар Союзы заказы белән Югославия верфендә төзелгән бер теплоходка аның исеме бирелде. Ул хәзер җир шарының бик күп диңгезләрендә, океаннарында йөзә.

Бөек Октябрьга чаклы Дагстанда театрлар юк иде, артистлар булмады. Бүген безнең «Лезгинка» бию ансамблебез бөтен дөньяга мәшһүр. Циркларда канат өстендә йөрүче артистларыбыз Японияндә дә, Америкада да, Франциядә дә чыгыш ясыйлар. Дагстан театрлары тугандаш республикаларда гастрольдә йөри. Дагстан сәнгатен дөнья культурасының менә нинди киңлекләренә чыгарды Бөек Октябрь, халык талантларын өнә ничек ачты! Халык тормышындагы мондый тарихи үзгәрешләрне чагылдыру өчен ни дәрәҗәдә илһамлы шигырьләр кирәк! Художник иҗатының төп чыганагы — халык тормышы. Ул — тауда син басып торган кыя сыман, ул — бина астына салынган нигез шикелле. Художник халыктан аерылса, аңа таяныч калмый, иҗатына терәк калмый. Мондый иҗат җансыз булачак, кешеләргә аның кирәге юк.

Халык тормышы белән яшәсә дә, шагыйрь кешеләр арасында күмелеп калырга, үз тавышын җуярга тиеш түгел. Ул үзенең поэтик йортын — саклясын үзе кора, үзенең поэтик бакчасын үзе эшкәртә. Моны бүтән беркемгә дә ышанып тапшыра алмый. Шагыйрь әйтәсе сүз — тик аның сүзе, кемдер әйткәнне кабатлау түгел. Шагыйрь әйтте икән инде — ул сүз бөтен халыкныкы булып әверелсен. Әйткән сүзен бүтәннәр аңламаса, андый шагыйрьнең бәясе сукыр бер тиен генә! Сине авылың аңлап, илең аңламаса — гаеп түгел. Илең аңлап, авылың аңламаса — ярты бәла. Ләкин инде балаларың аңламаса, ата-анаң аңламаса, Дагстан аңламаса, ил аңламаса — монысы иң зур бәла. Художник иҗаты шундый булсын: сүзе бөтен халыкка аңлашылсын, чакыру белән яңгырасын.

Конституция проектында культура казанышларын файдалану хокукы аерым юл итеп язылган. Димәк, поэзиядән файдалану хокукы да бит бу! Проектның кыска гына бер юлы шагыйрьгә нинди зур җаваплылык йөкли! Шигъриятне белгечләр генә бәяли торган заманнар үптән узды инде. Хәзер поэзияне миллионнар укый һәм аңа бәя бирә. Шигырьләрнең беришесе кызыксыну тудыра — шуның белән вәссәлам! Икенчеләре турында бәхәс куба, ләкин болары да җанны җылытмый. Иҗатлары турында беркайчан да бәхәс күтәрелми торган шагыйрьләр бар. Аларны укыйлар. Алар турында уйлыйлар, шигырьләре кешеләр күңелендә яши. Менә шушы инде ул чын халыкчан поэзия! Аның көче — шагыйрьнең намусы һәм батырлыгында, кешелек-

лелегендә һәм халык язмышын кайгыртуында. Чын шагыйрьнең язмышы халык язмышыннан аерылгысыз.

Александр Твардовский — мин аны чын мәгънәсендә халык шагыйре итеп саныйм — бервакыт әйткән иде: поэзия белән кызыксынмый яшәгән кешеләр аның шигырьләрен укый башласа — шуларны язган кеше шагыйрь булып җитешкән дигән сүз. Димәк, аның иҗаты чынбарлыкны чагылдырып кына калмый, бәлки шушы чынбарлыкның аерылгысыз өлешенә әверелә.

Поэзиянең олы гражданлык максатларын аңлау кемдер кушканны үтәү түгел ул. Гаделлек идеяләренә аңлы рәвештә хезмәт итү, кагыйдә буларак, шагыйрьнең бөтен тормышы, язмышы, биографиясе белән билгеләнә. Миннән бервакыт: «Җәмәгать эшчәнлеге әдәби эшегезгә комачау итмиме?» дип сорадылар. Моңа болай җавап бирдем: гәрчә, русның бөек шагыйре Некрасов «көрәш миңа — шагыйрь булырга, ә җырларым көрәшче булырга комачаулады» дип язса да — дөрес аңларга кирәк: әгәр ул көрәшче булмаса, бөек шагыйрь дә була алмас иде.

Чын халык шагыйренең шигъри миссиясе — кешелек һәм гражданлык бурычын үтәү. «Шагыйрь чумарга тиешле дәрья — интим хисләр ул» дип йөрүчеләр мине сәерсендерә. Шагыйрьне шагыйрь иткән нәрсә — халыкның әрнүләре һәм шатлыклары. Пушкин шагыйрьне кайтавазга тиңләде. Лермонтов аны намус колы дип атады. Анна Ахматова шигъри музага: «Тәмуг сәхифәләрен Дантега син әйтеп яздырдыңмы?» дигән сорау бирде. Ә Твардовскийның йөрәге дөньядагы барлык әрнүләргә һәм шатлыкларга ачык иде. Минем өчен заман шагыйрьнең идеалы — ул.

Шагыйрь, барыннан да элек, гражданин булырга тиеш. Үтә нәфис һәм нәзакәтле шигырьләр язарга да мөмкин — әмма аларны әдәбият белгечләре генә аңлар һәм бу язмалар биек тау башындагы чишмәне хәтерләтәчәк: сусавын бастырырга анда һәркем дә менеп йөри алмый. Чишмәләрнең авыл янындарак булганы яхшы — саф суын бөтен кеше эчә.

Әдәби хезмәт — җитди һәм күпкырлы эш. Китаптан укып белгән нәрсәләр турында шигырь язарга ярамый. Чын поэзияне тормыш үзе тудыра.

Хәзер илнең зур өлкәләрендә һәм республикаларында совет әдәбияты көннәре уздыру традициягә керде. Язучылар урыннарга бара, шәһәр һәм авыл халкы белән очраша, шигырь укый, китаплары турында сөйли. Бу, әлбәттә, бик һәйбәт эш — совет әдәбиятын пропагандалауга булыша. Тик мин бернәрсәне аңлап җитмим: ни өчен мондый очрашуларны иҗат командировкасы дип атыйлар? Шагыйрьнең халык арасына чыгуы командировка гына була алмый. Аның бөтен тормышы халык биографиясеннән аерылгысыз, бөтен тормышы — беренче көненнән соңгысына кадәр — иҗади командировка бит?!

Үз гомеремдә мин китапларны аз язмадым. Алар барысы да үзем өчен нигез дип санаган ике темага — Ватан һәм мәхәббәт хакында иҗат ителде. Моңа башлап тотынучы, әлбәттә, мин түгел. Без югында ук инде ул темага күпләр язган. Дөньяның иң акыллы фикер ияләре Ватан турында уйлаган, аның мәнфәгатьләрен кайгырткан. Шулар язган бөек китапка гына мин бер юл булса да өстәргә телим.

Мәхәббәт, хатын-кыз турындагы китапны да миңа хәтле яза башлаганнар. Гадәттә, яңа җирләрне диңгез сәяхәтчеләре генә ача диләр. Шагыйрьләр дә үзләренең генә утрауларын һәм континентларын ачалар. Кайчагында бу үзең көтмәгәнчәрәк тә килеп чыга. Күптән түгел мин Мексикада булдым. Шунда тормыш тагын бер тапкыр миңа нәрсәне раслады: гражданлык тойгысыннан башка лирика юк, лирикасыз исә гражданлык хисе була алмый. Мексикада миңа диңгездәге бер атауның хатын-кызлар утравы дип йөртелүен әйттеләр. Шул тарафка очтым. Самолетта очканда хатын-кызның бөеклеген уйладым. Күз алдыма Афродитаның йөзе, Джульеттаның язмышы килде, Ярославнаның елау авазын ишеткәндәй булдым, Жанна д'Арк һәм Валентина Терешкованың батырлыгы искә төште. Үземне Колумб, Магеллан дип хис кылдым — яңа җирләр ачарга барам, имеш. Һәр шагыйрьнең үзе генә ачкан утравы булырга тиеш икән, мин ачасы утрау мәхәббәт атавы булачак, дип өметләнеп барам.

Ә чынбарлык дигәнең башкачарак икән. Дөрес, утрауда фәкать хатын-кызлар гына яши. Ә ирләр, диңгездә давыл вакытында, барысы да һәлак булган. Шунда мин утрауларны түгел, Франциядәге шахтер шәһәрләрен күз алдына китердем. Аларда ирләрне шахталар басты... Белорус авылларында ирләрне сугыш кырды, хатын-кыз

этисез, ирсез, улсыз калды... Шуларны уйла да лириканы гражданлык тойгысыннан, мәхәббәтне көрәштән аерып кара?!.

Планетабызда үлем утраулары аз булмады. Әгәр тынычлык саклау эшен үз кулыбызга алмыйбыз икән, бөтен җир шарының хатын-кызлар утравына әверелүе ихтимал.

Җир йөзенә тынычлык кирәген кешеләр торган саен яхшырак аңлый. Ә поэзия— тынычлык өчен көрәш коралы да. Шунлыктан шагыйрьнең һәр сүз өчен җаваплылыгы зур. Бәләкәй чакта мин, үз саклябызны саклап, малайлар белән сугыштым. Туганнарым Бөек Ватан сугышында ил-йортны саклап һәлак булды. Ә бүген мин үземнең шагыйрьлек бурычымны тынычлыкны саклауда, игелек, мәхәббәт һәм наз чигендә торып, явызлык һәм нәфрәткә каршы көрәштә күрәм.

Шагыйрь сугыш елларында да, имин чакларда да — һәр вакыт сафта. Аңа төгәл приказлар бирүче командир да юк. Командиры — үз вөҗданы, идеягә инануы, халык алдында җаваплылык хис итүе. Үз юлын шагыйрь үзе сала. Үз утрауларын һәм континентларын да үзе ача, аның компасы — дөньяга коммунистик караш — дөрес юлдан яздырмый, һәр вакыт хаклык турында җырларга куша. Безнең халыкның максатлары бик олы. Без дөньяга дуслык кулы сузабыз, учыбыз ачык. Ләкин, идеалларыбызны якларга кирәк була калса, ул учны без куәтле йодрыкка да йомарлый алырбыз.

Бервакыт мине Кремль курсантлары кунакка чакырды. Алар арасында Ленин Мавзолеенда — Беренче номерлы постта торучылар да бар иде. Шунда чыгыш ясаган чакта мин уйладым: безнең совет поэзиясе дә Беренче номерлы пост бит. Ул Ленин идеяләренең ут-ялкынын саклый. Бу постка басар өчен шигырь яза белү, рифма һәм образлар белән эш итә белү генә җитми. Үзеңнең бөтен характерың белән шагыйрь булырга — туган халкыңны чиксез яратырга кирәк. Яңа Конституция проектында социалистик Ватанны саклау һәр гражданның изге бурычы диелгән. Шагыйрьнең изге бурычы — үзенең бөтен тормышы, иҗаты белән Совет Ватанының рухи, әхлакый чикләрен саклау.

«**КОММУНИСТ**» журналы, № 9, 1977 ел.

Сәет Шәкүров

# КЫЗ БИРҮ

ӨЧ ПӘРДӘЛЕ МОҢСУ КОМЕДИЯ

КАТНАШАЛАР:

Ш ә ң г ә р ә й — пенсионер
Б и б и — хатыны, пенсионерка
С ө е н б и к ә — кызлары, студентка
Б а к ы й — эшче
Г ө л б а н у — хатыны, трамвай йөртүче
Т и м е р — уллары, студент.
Г а р и ф — күрше карт.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Өч бүлмәле шәһәр квартирасы. Ишектә озын-озын өч звонок ишетелә. Биби кухнядан, кабаланып, шуны ачарга йөгерә.

Б и б и. Бу кайсы булыр икән?.. (*Ишек ача, ишектә Шәңгәрәй.*) Шаштың мәллә, шул кадәр басмасаң звонокка? Җитмәсә, өчәр мәртәбә.

Ш ә ң г ә р ә й. Шартлы звонок. Беренчесе — син, икенчесе — кызым, өченчесе — мин. Бикләә ишекне! (*Кабаланып алга уза.*)

Б и б и. Кая барасың? Кара ул аякларыңа! Нинди шартлар куеп маташу инде ул пенсионер кешегә.

Ш ә ң г ә р ә й. Сөенбикәләр кая?

Б и б и. Киттеләр.

Ш ә ң г ә р ә й. Икесе бергәме?

Б и б и. Бергә инде, бергә, гел бергә! Сал аякларыңны!

Ш ә ң г ә р ә й. Ә кая киттеләр?

Б и б и. Белмим. Сал дим.

Ш ә ң г ә р ә й. Син аларның кая киткәннәрен генә түгел, кая басканнарына кадәр белеп торырга тиеш бу көннәрдә... Мин генә пенсионер түгел хәзер бу йортта, шуны онытма. Аннан соң килеп мин инде стажлы пенсионер. Ул сүзгә күнеккән, үртәлмим. Ә менә яшь пенсионерларга...

Б и б и. Ярый, ярый... Пенсионер сүзен телгә алмаска дип килештек бит инде бер.

Ш ә ң г ә р ә й. Үзең бит...

Б и б и. Кара ул өстеңне, чыланып беткәнсең. Тагы шул Ләтскойда булдыңмы?

Шәңгәрәй. Шунда.

Биби. Сал плащыңны, идәнгә саркый. Коеп яуганда, бакчада шахмат уйнап утырамы кеше?

Шәңгәрәй. Шахмат уйнамадым мин.

Биби. Нишләдең соң?

Шәңгәрәй. Бала карадым.

Биби. Ә?!

Шәңгәрәй. Бала карадым.

Биби. Кем баласын?

Шәңгәрәй. Парамон кордашның игезәкләрен. Бәләкәйләр, шундый матурлар.

Биби. Плащың гына түгел, пинжәгең дә чат су. Ул бәләкәйләрне дә җебетеп бетергәнсеңдер бит...

Шәңгәрәй. Юк шул, җебетмәдем, яңгыр ява башлагач, мин плащымны салып бәби арбасына каплыдым.



Драматург Сәет Шәкуров

Биби. Парамон кордашың плащын салып капласын иде. Аның бәләкәйләре бит.

Шәңгәрәй. Үзе ул җәмәгать эше белән йортлар идарәсенә китте. Миннән оныкларын карап торуны үтенде...

Биби. Син инде бик рәхәтләнеп...

Шәңгәрәй. Алар миңа тәмам ияләнеп җиттеләр. Яңгыр ява башлагач башымны плащ астына тыктым. Плащка шыбыр-шыбыр яңгыр ява. Ә тегеләр минем белән сөйләшәләр... Ыггы... Ыггы... Имеш, нәрсә ул анда шабырдый, нигә безне томаладың?.. Куллары белән очыналар, янәсе, плащны алып ташла, томалама...

Биби. Матурлармы?

Шәңгәрәй. Шундый матурлар, шундый... Ә исләре? Исләре борынны кытыклый.

Биби. Соң шунда бакчада тилмертмәсәң шул бәләкәчләрне коеп яңгыр яуганда, монда алып кайтсаң?

Шәңгәрәй. Ә Парамон? Шаярма!.. Кая... Кая әле безнең теге мин алып кайткан бәби арбасы?

Биби. Нишлисең аның белән?

Шәңгәрәй. Үлчәп карыйм. Безнең ул таррак булмас микән... (*Караңгы бүлмәдән өр-яңа коляска тартып чыгара да, кесәсеннән бау алып, үлчәп карый.*) Әйттем бит, тар. Менә Парамон кордашның арбасы нинди киңлектә.

Биби. Соң бит ул игезәкләр арбасы.

Шәңгәрәй. Ә бәлки безнең дә игезәк булырлар, каян беләсең.

Биби. Куй, зинһар, арбаны урынына, тумаган тайның билен сындырма. Сөенбикә кайтып керер.

Шәңгәрәй. Туар, туар, алла бирсә. Егете белән бергә киттеләр диден бит.

Биби. Китсәләр, ЗАГСка китмәделәр бит әле алар. Институтларына кая билгеләнү турында язу алырга киттеләр.

Шәңгәрәй. Соң үзең бит, шул язуны алу белән үк язылышабыз дип әйтте Сөенбикә, диден. ЗАГСка да гариза биреп кайттылар диден түгелме?

Биби. Дидем дә бит... Әле үзләрен кая җибәрерләр, билгесез. Әллә кая җәһәннәмгә җибәрсәләр...

Ш ә ң г ә р ә й. Беркая да җибәрмиләр, монда, Казанда, аспирантурада калдыралар. Бу инде тәгаен хәл кылынган. Тиздән туй, арба кирәк булачак, алла бирсә...

Б и б и. ЗАГСтан соң туй... Туйдан соң тагы тугыз ай көтәсе бар. Ә син арба белән.

Ш ә ң г ә р ә й. Балалар чукыр-чукыр килеп үзебезнең янда яшәсәләр, тугыз ай тоелмый да ул әнисе. Аннан соң инде мин дә арба тартып Лядскойга... Парамон арбасына борылып та карамыйм аннары мин. Парамонга ялыныч бетә... *(Арбаны тирбәтеп.)* Әме, улым, ыгы-ыгы... минем кадерлем!..

Б и б и. Куй арбаны, әнә ишектә кеше бар...

Ш ә ң г ә р ә й. Алармы, Сөенбикәләрме!?

Б и б и. Белмим, бар, үзең кара.

Ш ә ң г ә р ә й. Яшер... Капла, капла арбаны. Сөенбикә күрмәсен. Күргәне юкмы әле? Күрсәткәнең юкмы? Белмиме арба алганны?

Б и б и. Нишләп күрсәтим инде, син бигрәк тагы...

Ш ә ң г ә р ә й. Кызыгын бетереп, әме, әнисе?..

Б и б и. Ач ишекне, кайчаннан бирле звонок биреп тора кеше. *(Шәңгәрәй ишекне ача, ишектә Гариф.)*

Г а р и ф. Аз гына да ихтирамың юк кешегә. Шылдыравык төймәсен баскан килеш шунда, бусагада, үлеп калсам... Гөнаһысы кемгә? Янә килеп сиңа.

Ш ә ң г ә р ә й. Нигә үләсең ди әле син, шул гәүдәң белән?

Г а р и ф. Гәүдәдәмени эш? Үзәк, үзәк какшаган!..

Ш ә ң г ә р ә й. Үзәгең дә какшамаска тиеш, әле пенсиягә дә чыкмаган килеш... Аннан безгә, пенсионерларга, ни кала?

Г а р и ф. Пенсия алам дип өйдә тик ята алмыйм инде мин. Сигезенче дистәгә китсә дә. Каравылда, авыр булса да, вакыт тизрәк үтә.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә мин сиңа кайчаннан бирле әйтә киләм, чык ул каравылдан дип.

Г а р и ф. Чыгып кая барасың, кулыңда башка кәсебең булмагач. Әй, калдыр әле, сөйләнерлекме соң хәл... Тамак кипте. Кая, аллыгөлле Гөлбибинурҗамал, әнә шул ликтирически самаварыңны кабызып җибәр әле, сайрасын бераз. Һич түзәр хәлем калмады. Савап булыр, җомгадан кайтышым. Тәһарәтем исән чакта чәй эчеп, догасын кылып чыгыйм. Күрше хакы бар диләр бит. Ә мин күрше генә дә түгел — кардәш, димәк, икеләтә савап... Шәңгәрәй кордаш белми ул аны, мәчет карты булмагач.

Ш ә ң г ә р ә й. Беренчедән, кордаш ук түгел, алай бик картайтма кешене. Аннан килеп гөнаһым да юк минем мәчеткә йөрергә. Гөнаһ кылырга вакытым булмады. Эшләдем. Гомерем буе эшләдем. (*Журнальный өстәлдәге башланган шахмат тактасына күрсәтеп.*) Әйдә, утыр, кичә калган уенны бетерәбез.

Г а р и ф. Ә, юк... Мин бу уеннан отказ бирәм. Син мәтәштергән моны. Минем ладиям монда калмаган иде.

Ш ә ң г ә р ә й. Соң, алла колы, үзең ракировка ясап чыгып киттең бит.

Г а р и ф. Ясаса да, болай түгел иде. Менә болай иде.

Ш ә ң г ә р ә й. Шулай йөрдеңме? Ярый, йөр. Ә менә мин болай...

Г а р и ф. Кызык.. шулай итеп мәчеткә гөнаһлы кешеләр генә йөриләрмени инде синеңчә?

Ш ә ң г ә р ә й. Белмим. Мәчет картларының барысы турында да хөкем йөртүне өстемә ала алмыйм. Ә менә мин белгәннәре шулайрак. Гомер буе гөнаһ кылалар да, картайгач, сакал-мыекларын түгәрәкләп кырып, кырпу бүрекләр киеп, суфи булып мәчет юлын таптый башлыйлар. Әйтерсең алтмыш ел буе кылган гөнаһны биш-

алты ел мәчеткә йөреп кенә юып була... Нишлисең, куй пешканы... Күрмисеңмени?..

Гариф. Күрәм, күрәм... Белмәссең... Тәһарәте нык булып, ихлас күңелдән сәҗдә кылса... Менә шулай...

Шәңгәрәй. Ә менә син? Ихлас күңелдән кыласыңмы сәҗдәне?

Гариф. Мин чутка кермим. Минем гөнаһ кылганым булмады.

Шәңгәрәй. Ничек син генә читтә калдың икән ул гөнаһтан?

Гариф. Чөнки мин үз гомеремдә бер генә мәртәбә дә өйләнмәдем. Хатын өстеннән йөрмәдем, хатын җәберләмәдем.

Шәңгәрәй. Ә ни өчен соң сиңа «Күке Гариф» кушаматы кушканнар яшьрәк вакытыңда?

Гариф. Кушканнар инде. Заманасы шул булган... Кушамат бит гөнаһ түгел.

Шәңгәрәй. Ничек гөнаһ түгел? Ничә бала атасы икәнеңне беләсеңме соң син үзең?

Гариф. Беразын беләм.

Шәңгәрәй. Шулай да?

Гариф. Мин белгәннәре — уникегә тула бугай.

Шәңгәрәй. Менә, күпме сабыйлар өмете, күпме ятимнәр яше...

Гариф. Аның каравы, алар үсеп балигъ булгач ирекле. Шуның белән квит.

Шәңгәрәй. Ничек алай бик тиз генә квит әле ул?

Гариф. Билгеле, квит. Әйтик, мин өйләнеп, үз өемдә үстерсәм ул балаларны, үскәч һәркайсы миңа алимент түләр иде. Хәзер бит ул модада. Ә болай алар — ирекле казак. Алимент та юк миңа, черт та юк.Теләсәң ничек яшә. Ярый әле, Гөлбибинурҗамал кардәш игелекле кеше булып чыкты. Туган җанлы.

Шәңгәрәй. Туган инде. Чыбык очының чыбык очы.

Гариф. Туганлыкның оч-төбе юк.

Шәңгәрәй. Нинди очы да, нинди төбе турында сөйлисең син? Минем Бибиәсмам Казан артыннан. Ә син Бишбалта.

Гариф. Менә шул Бишбалта дигәннәре — минем бабамның бабасының бабасы, авылдан-авылга самавар төзәтеп йөргәндә, Бибиәсма кардәшнең туганнан-туган әбисенең әбисен ябештереп алып киткән дә инде үзенең Бишбалтасына.

Шәңгәрәй. Болай булгач, якын туган була икән... Моны сиңа кайсы әбиең сөйләгән иде?

Гариф. Ә нишләп әби? Әнә шул, сезнең ишегалдындагы фатирыма күчеп килгәч, миңа моны синең Бибиәсмаң үзе сөйләде һәм шул көннән бирле, ходаның рәхмәте, мине ашыннан-суыннан калдырмый. Менә мә — мат!

Шәңгәрәй. Тукта, тукта, ничек — мат?

Гариф. Шулай инде, мат. Тегеләй дә, болай да бара алмыйсың... Квит!

Шәңгәрәй. Башта минем нервамда уйный, чыгырымнан чыгара, аннан — мат. Туган, имеш.

Гариф. Ник булмасын, билгеле, туган.

Биби *(кухнядан чыгып)*. Чәй булды!

Гариф. Әйттем бит. Менә ул туганлык!

Биби *(Шәңгәрәйгә)*. Әйдә, син дә эчеп ал бер табында. Сусагансың син дә, көне буе кеше баласы карап.

Гариф. Әйттем бит... Юкса, ул миннән көлә, «Күке», имеш. Безнең күкелек, кордаш, бер чамадарак. Әйдә сыйлаганда — су эч дигәннәр... *(Тәрәзәгә карый.)* Кем ул? Сезнең кыз кемне иартеп кайтып килә? Попмы дип әйтим, шундый озын чәчле. Алай дисәң, нигә сакалы юк?

Ш ә ң г ә р ә й. Цең! Бар тизрәк кухняга! Сакалың бөртекләрен берәм-берәм йолкып кисәңә тутырмас борын...

Г а р и ф. Барам, барам. Сакалсыз калуга караганда, сакал белән мәртәбәлерәк. Сакал — сакал инде ул. Сакалга аңа ихтирам-хөрмәт. *(Кухняга кереп китә.)*

Ишектә дүрт мәртәбә звонок.

Б и б и *(ишек ачып)*. Бу нишләвегез инде шул звонок белән? Өчәр, дүртәр мәртәбә.

С ө е н б и к ә белән Т и м е р керә.

Ә... Тимергали дә бар икән, гафу итә күр зинһар. Мин Сөенбикәне үзе генә дип торам. Аның шулай шаярта торган гадәте бар.

С ө е н б и к ә. Звонокны Тимер бирде, нәүбәт буенча ул — дүртенче.

Т и м е р. Нигә кызартасың син мине, Сөенбикә? *(Шәңгәрәй белән исәнләшә.)* Исәнмесез!

Ш ә ң г ә р ә й. Исәнме, кем, Тимергали улым... Я, кая төбәделәр үзегезне?

С ө е н б и к ә. Безнең шәхси эшебезгә кемдер берәү читтән торып тыкшынган, ахры.

Т и м е р. Берәү генә микән?

С ө е н б и к ә. Безнең икебезне дә Казанда калдырмакчы булалар.

Ш ә ң г ә р ә й. Шул начармы?

С ө е н б и к ә. Безнең өчен начар. Хәтта бик начар.

Ш ә ң г ә р ә й. Сөйләмә, кызым, юкны. Казан — сезнең туган илегез. Биредә сезнең әти-әниләр...

С ө е н б и к ә. Безнең бит үз планнарыбыз, үз хыялларыбыз бар. Юк инде, әткәй, без үз язмышыбызны үзебез хәл кылыйк инде.

Ш ә ң г ә р ә й. Үзегез хәл кылып кая бармакчы буласыз?

С ө е н б и к ә. Башкалар кая барса, без дә шунда.

Ш ә ң г ә р ә й. Безнең турыда уйларга тиештердер бит сез, кызым.

Б и б и. Ярар инде, әтисе, үзләре беләләрдер, бала түгелләр бит.

Ш ә ң г ә р ә й. Ничек инде бала түгел? Син ни сөйлисең?

Б и б и. Чәй эчеп ал дим. Фикерләрең чуала башлый озак чәй эчмәгәч. Әнә, мат алуың да шул чәй эчми тору галәмәте.

Ш ә ң г ә р ә й. Сиңа көлке. Сиңа бүген булса, шул җитте. Син иртәгә турында уйлый белмисең.

Б и б и. Минем дә шул инде, әтисе, чәйсез чигәм түнә. Әйдә, чәй янында чукырдашыйк булмаса.

Ш ә ң г ә р ә й. Балаларны да дәш чәйгә.

Б и б и. Аларны син тынычсызлама. Аларга бу якта әзерләрмен. Үзләре дигәнчә утырырлар, үзләре дигәнчә эчәрләр. Хәзерге яшьләр шуны ярата. Ирек куй син аларга.

Ш ә ң г ә р ә й. Нәрсә? Мин аларның иркен тыям мәллә? Әллә мин начарга әйтәмме?

Б и б и. Әйтмисең, әтисе, әйтмисең. Әйдә, чәең суына. *(Кухняга чыгалар.)*

С ө е н б и к ә. Менә әйттем бит. Бу, һичшиксез, безнең әтинең җиңел кулы белән эшләнгән булырга тиеш, дидем. Ул ничә ел инде аспирантура дип тукып килә.

Т и м е р. Безнең әти дә тик ятмаган. Бүген мине ректоратка чакырып алдылар да сигезенче төзү-монтаж трестында калырга тәкъдим иттеләр. Тресттан минем фамилиягә заявка килгән.

С ө е н б и к ә. Трест трест әле ул, аспирантура түгел. Анда, ичма-

са, үзеңә бер участок бирсәләр, рәхәтләнеп, җәелеп үзең дигәнчә эшли аласың.

Т и м е р. Эшләрсең, бар, безнең эти белән. Әйтәм ич, егерме ел инде ул үзе шул трестта эшли. Имеш, мин ул трестка барсам, аның кубызына гына биеп яшим булып чыга. Тегене — тегеләй итмә, моны — болай итмә. Менә сиңа ирек, инициатива, перспектива! Рәхәтлән...

С ө е н б и к ә. Ә аспирантурада? Шул ук кафедра, шул ук карт профессор. Күзләре белән синең һәр адымыңны йотардай булып тора.

Т и м е р. Әллә шулай?!

С ө е н б и к ә. Нишләсен инде ул? Сиксәнгә кадәр кафедрада утыргач.

Кухнядан Гариф чыга.

Г а р и ф. Сиксән яшьлек картка ни булган? Сиксән яшьлек карт көчендә әле ул. Менә мин сезнең атагызны матка утырттым түгелме, шушы сиксән яшьлек башым белән.

Ш ә ң г ә р ә й *(кухнядан чыга).* Син бит ул. Сине бит юкка гына күке димәгәннәр.

С ө е н б и к ә. Әткәй, кирәкми, алай тупас булма. *(Кухняга керә.)*

Г а р и ф. Дорфа сөйлисең, кордаш, дорфа.

Ш ә ң г ә р ә й. Кордаш түгел, картайтма кешене!

Г а р и ф. Күрше, алайса, күрше. «Күрше хакы — тәңре хакы» дигән китап. *(Тимергә.)* Наданлык галәмәте. Хуш, сезне кем дип атыйк иде, чибәр егет?..

Т и м е р. Тимер.

Г а р и ф. Тимер... Тимергали була инде ул мулла кушкан атыгыз белән әйтсәк. Бик хуп, бик күркәм. Кил, күрешик, булмаса. *(Ике кулын сузып.)* Гарифулла абзаң булам инде мин. Бу тирәли килеп салып йөрүеңне бик куптәннән күзәтеп килсәм дә, үзеңне күреп, сөйләшә алганым юк иде. Чибәр генә егет икәнсең бит, сачларың да...

Ш ә ң г ә р ә й. Гарифулла абзый!..

Г а р и ф. Ә... Әйе шул, түргәме? Түрдән узыйкмы? Әйдә, алайса, кем, Тимергали улым, бәхетең-тәүфыйгың белән диикме? Төкле аягың беләнме?

Ш ә ң г ә р ә й. Кем, Гарифулла, безне калдырсаң ничек булыр икән?

Г а р и ф. Булмастыр, миннән башка барып чыкмастыр. Әле шул сач турында иде сүзем. Күркәм, бик күркәм. Атамыз адәм дә шушындый озын кара сачлы булган, имеш, дигән сүрәләр дә бар. Аннан килеп пәйгамбәрләремез дә озын сач йөрткәннәр. *(Көйли.)*

Йөз мең алтын торур ирди
Бәнем башымда таҗым.
Инде таҗ урынына калди
Шушы озын кара сачым.

Ш ә ң г ә р ә й. Син примерга сүрә китерә башладың, күрше. Робагыйларыңны калдырып торсаң ничек булыр икән?

Г а р и ф. Робагый түгел бу. Мин фикеремне китап сүзе белән расларга күнеккән. *(Тимергә күз кысып.)* Наданнар гына бит ул безнең бүгенге мөхтәрәм яшьләремезнең шушындый күркәм озын сачларындин көләргә яраталар. Көлке түгел бу. Озын сач — безнең борынгы бабаларымызның күрке. Тарих ул ничәмә-ничә елларга бер әйләнеп кайта ди китап. Яшьләремезнең ушбу күркәм сачларын мин тарихымызның кире әйләнеп кайтуы дип саныйм... Килер бер көн... Читек-кәвеш киеп мәчеткә дә йөри башларлар әле безнең яшьләремез. *(Тимергә борылып күз кыса, үзе кети-кети көлә.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Син чәй эчтеңме?
Г а р и ф. Эчтем.
Ш ә ң г ә р ә й. Кайда?
Г а р и ф. Кухняда.
Ш ә ң г ә р ә й. Алайса, бар, догасын да шунда, кухняда, кыл инде син, монда безне ялгызыбызны гына калдыр. Сүзебез бар.
Г а р и ф. Ә... Әйе. Ләббәйкә. *(Кухняга кереп китә.)*
Т и м е р. Күңелле карт.
Ш ә ң г ә р ә й. Күңелне болгата торган карт. Я, әйдә, утырыйк. Хәзер табын әзерләрләр. Менә монда... Монда утыр, түргә...
Т и м е р. Юк, анда ук кермим мин.
Ш ә ң г ә р ә й. Шунда, шунда, фәкать шунда. Менә шулай. Я... Тәбрик итәм үзегезне. Казанда, трестта калуыгыз белән.
Т и м е р. Булмастыр. Авырга туры килер безгә Казанда. Бигрәк тә ул трестта калсак.
Ш ә ң г ә р ә й. Килмәс, килмәс... Аллага тапшырып, теге-ни... Әлеге шул үзегез турында... Сез... Тәвәккәлләгез генә, тәвәккәлләгез!
Т и м е р. Әле әткәйләр белән дә киңәшмәгән.
Ш ә ң г ә р ә й. Ә, әйе, алар белән килешү кирәк. Алар белән киңәшсез эшләнә торган эш түгел бу.
Т и м е р. Шулай, әлбәттә. Ләкин менә башта сезнең белән...
Ш ә ң г ә р ә й. Безнең белән? Ә... Әйе, әлбәттә, безнең белән. Әнисе, әнисе дим, чык әле бире. *(Биби чыга.)* Менә Тимергали улым башта безнең фикерне белергә тели, ни дисең?
Б и б и. Ә? Ай, ай алла! *(Елый.)*
Ш ә ң г ә р ә й. Тукта әле, ник елыйсың?
Б и б и. Ничек еламыйсың инде, ана лабаса мин, нинди ана соң шулай кинәт кенә... Бердәнбер кызын...
Ш ә ң г ә р ә й. Нинди кызын? Кемнең кызын? Нәрсә син, шаштың мәллә? Ул бит синең кызыңны сорарга килмәгән. Казанда калу-калмау мәсьәләсендә бездән киңәш сорарга килгән. Шулай бит, кияү? Әй, ни, Тимергали дигәнем лә...
Б и б и. Оятлы гына иттең. Белер-белмәс башың белән... *(Елап кухняга кереп китә.)*
Ш ә ң г ә р ә й. Тавык төшенә тары керә ди, тукта инде, шыңшыма инде анда.
Г а р и ф *(кухнядан чыга)*. Шыңшыйсы-нитәсе юк, аллага тапшырып алдым-бирдем ясарга да...
Ш ә ң г ә р ә й. Бар, зинһар, үз өеңә чыгып яса әле алдым-бирдемеңне.
Г а р и ф. Кая төртәсең, ул ишеккә түгел.
Ш ә ң г ә р ә й. Кайсы ишеккә соң?
Г а р и ф. Анда, ваннага. Төтен юллыгына фифируз төтәтәсем бар бит әле минем, чәйдән соң.
Ш ә ң г ә р ә й. Үз өеңдә төтәтерсең.
Г а р и ф. Ярамый. Намазлыкка исе сеңә. *(Ванна бүлмәсенә кереп китә.)*
Ш ә ң г ә р ә й. Менә бит, куып та чыгарыр хәл юк үзен. Әнисе дим... *(Кухняга кереп китә.)*

Кухнядан Сөенбикә чыга.

С ө е н б и к ә. Әллә аңлаштыгыз да инде?
Т и м е р. Аңлаша язып калдык.
С ө н б и к ә. Анда әнкәй елап чыккан.
Т и м е р. Гомумән алар мине дөрес аңладылар.
С ө е н б и к ә. Нишләргә инде болар белән?

Тимер. Артык сузарга ярамый. Бүген үк, менә хәзер үк аларның рөхсәтен алырга да...

Сөенбикә. Рөхсәтне алар бик теләп бирерләр. Ә аннан соң нишләргә? Беребез кафедрада, беребез треста калабызмы?

Тимер. Юк инде. Бу турыда ике уйлану юк. Сөйләштек, бетте.

Сөенбикә. Сөйләштек тә бит.. Картлар кызганыч. Күрәсең: елыйлар.

Тимер. Елый бирсеннәр.

Сөенбикә. Каты бәгырьле икәнсең син, Тимер.

Тимер. Минекеләр елап кына калмаячаклар. Минем әткәй якадан ук алачак. Шуннан куркып мин җебеп калырга тиешме? Үз хыялыма хыянәт итәргә? Үземнең киләчәгемне җимерергә? Булмый...

Сөенбикә. Бәлки җайлап... Күз-яшьсез, якалашусыз гына да күндереп булыр.

Тимер. Ничек?

Сөенбикә. Башта ике якның да рөхсәтен алыйк, өйләнешик, язылышыйк, туй итик, аннан соң... Аннан соң алар үзләре дә каршы килмәс.

Тимер. Белмим. Алай гына риза булмаслар.

Сөенбикә. Күрербез. Әйдә, башта ризалыкларын алыйк. Бар, шакы, чакырып чыгар үзләрен монда.

Тимер. Синсез булмый. Синнән башка минем кыюлык җитми. Әйдә икебез бергә.

Сөенбикә. Ә ничек?

Тимер. Менә болай. Башта шакыйбыз. Алар чыга башлау белән мин синең кулыңнан алам, алар күренү белән «шап» итеп каршыларына тезләнәбез.

Сөенбикә. Юк, син генә тезләнәсең. Минем кулымнан алган килеш син тезләнәсең, ә мин басып торам.

Тимер. Ихтирамсызлык була бит бу.

Сөенбикә. Булмый.

Тимер. Юк, икебез дә тезләнәбез.

Сөенбикә. Син генә тезләнәсең. Йоласы шулай, минем күргәнем бар. Егет кызның кулыннан ала да әтисе-әнисе каршына килеп тезләнә. Менә болай: тезлән-тезлән. Алай түгел.

Тимер. Ничек соң?

Сөенбикә. Егет бер тезенә генә тезләнә. Уң кулы белән кызның сул кулын ала да, үзенең сул тезенә тезләнә. Менә шулай...

Тимер. Шуннан нишли?

Сөенбикә. Шуннан башын күтәреп тантаналы рәвештә сүз башлый. Хөрмәтле...

Тимер. Хөрмәтле Шаңгәрәй абзый һәм хөрмәтле Бибп апа!

Сөенбикә. Чыгалар...

Тимер. Тезләнәбез.

Сөенбикә. Син генә тезләнәсең.

Тимер *(Сөенбикәнең кулыннан алып тезләнә.)* Хөрмәтле Шаңгәрәй абзый!..

Гариф чыга.

Гариф. Гарифулла абзаң әле бу. Тезләнүең дә шәригатькә сыймый. Татар тезләнми. Татар үлгәндә дә үрә катып үлә.

Тимер. Үрә катып кыз сорамыйлар инде, Гарифулла абзый.

Гариф. Сорамыйлар шул.

Тимер. Ә ничек сорыйлар.

Гариф. Бер ничек тә. Әгәр чын егет икән, сорамыйча гына урлап алып китә. Әгәр инде җебегәнрәк булса, яучы җибәрә.

Тимер. Ә кемне?

**Гариф.** Карчык-корчыкны. Әгәр инде дәрәҗәлерәк булса, ир-ат җибәрә. Ир-атның да күркәмен, мөхтәрәмен. Менә минем кебекне.

**Сөенбикә.** Бу инде дәрәҗәле егет, Гарифулла абзый. Инженер булды, диплом алды. Ә менә кыюсыз. Урлап китә алмый. Бәлки... *(Тимергә күз кысып)* бу егетнең яучысы сез булырсыз?

**Гариф.** Яучы булып Шәңгәрәй каршысына барыргамы?

**Сөенбикә.** Әйе.

**Гариф.** Куркыныч, кыйнап чыгарыр.

**Сөенбикә.** Чыгармас. Үзем яклармын.

**Гариф.** Шулай дисәң генә, юкса, ул денсезгә ышаныч юк. *(Тимергә күз кысып.)* Кая, бар, ваннада әниеңнең чупләмәле сөлгесе эленеп тора иде. Алып чык шуны. *(Сөенбикә сөлге алып чыгып бирә, Гарифулла иңбашына сөлге аса, читек балтырыннан бер балагын чыгара.)* Безнең заманда менә шулай яучылыйлар иде аны... *(Кәмит уйнап, әкрен генә тамак кырып ишеккә бара башлый.)* Аллага тапшырдык!.. Әй, тукта әле, тукта. Моның соң мәһәре күпме булыр?

**Тимер.** Нинди мәһәре?

**Гариф.** Соң, алла колы, мин сиңа бушка йөрмәм ич. Яучылык вазифасы зур нәрсә ул. Илчелек вазифасына тиң, ди китап. Бәс, шулай булгач, аның мәһәре дә шулайрак булырга тиеш.

**Тимер.** Күпме соң, күпме?

**Гариф.** Мин сездән акчалата сорамам инде. Әле хезмәт хакы алып караганыгыз юк үзегезнең. Атай кесәсеннән өйләнү бик үк егетлек саналмый бу заманда, әйдә, была ни была, вак-төяк бүләкфәләнгенә алып бирерсез.

**Тимер.** Нинди бүләк?

**Гариф.** Әйтик, укалы кәләпүш, каюлы читек, аннан килеп вилюр эшләпә, кримплен пәлтә.

**Тимер.** Аз икән.

**Сөенбикә.** Бер инженерның ике айлык хезмәт хакы.

**Гариф.** Бер юлы бирмәссез, ай алла, качкан җирдә түгел бит, кәтәрмен. Ала каргада алачагың булсын ди. Я, ярый, хәерле сәгатьтә... *(Ишеккә бара башлый.)*

**Тимер.** Гарифулла абзый, бер балагың чыккан.

**Гариф.** Бу кадәр дә надан булыр икән хәзерге яшьләр. Аның бөтен мәгънәсе дә балакта бит! Я, ярый, аллага тапшырдым. *(Кухня ишек төбенә барып тәкбир әйтә.)* Аллаһы әкбәр, валлаһы әкбәр лә илаһе-иллалаһе, валлаһе әкбәр...

Кухнядан атылып Шәңгәрәй килеп чыга.

**Шәңгәрәй.** Бу нинди кәмит бу?

**Гариф.** Әссәләмәгаләйкем!

**Шәңгәрәй.** Туктат дим, хәзер үк, шәмәкәй!

**Гариф.** Илгә иминлек, йортка бәрәкәт, үзегезгә кодрәт бирсен.

**Биби** *(кухнядан чыгып уен икәнен аңлап ала.)* Шулай булсын, шулай булсын, амин.

**Шәңгәрәй.** Син нәрсә, күрә торып, шул чалмалы клоунның сүзен җуплисең?

**Биби.** Син аның кыяфәтенә кара, кыяфәтенә.

**Шәңгәрәй.** Төкерәм мин аның кыяфәтенә!

**Гариф.** Төкермә! *(Сыңар балаклы аягын алга куеп.)* Күрәсеңме моны?

**Шәңгәрәй.** Күрдем ди, я шуннан?

**Гариф.** Нәрсә бу?

**Шәңгәрәй.** Балак.

**Гариф.** Нинди балак?

Ш ә ң г ә р ә й. Сыңар балак.
Г а р и ф. Сыңар балак шул, сыңар балак. *(Көйли.)*

Сыңар балак пар сорый,
Сыңар балаң яр сорый.
Сыңар балак кигертмә —
Сыңар балаң тилмертмә.
Пары барда парлап кал,
Яры барда ярлап кал.
Балагын тык урынына,
Балаңны яр куенына
Урнаштыр син, әй ата!
Балаң ярын ярата.
Яшәсен алар парлап,
Бер-берен карап, барлап.
Матур гомер уздырсын,
Сиңа онык тудырсын,
Китсен буын-буынга,
Яшәүнең яме шунда!

*(Бар да көләләр. Шәңгәрәй Гарифның шаяртканын аңлап ала.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Кара син аны, ә? Һәй, егетләр, ул ниләр белә! Мин бит моны һич кирәкмәгәнгә яши дөньяда бу карт дип уйлап йөри идем. Ә ул ничек көйли? Бәдәваммени! Күреп укыйсыңмы аны, ул кадәрне, яттан беләсеңме?

Г а р и ф. Күреп укыйм.

Ш ә ң г ә р ә й. Кайдан күреп?

Г а р и ф. Менә бу ике яшь гашыйкның күңел күзеннән.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә син алар күңеленә ничек алай тирән керә алдың?

Г а р и ф. Анда керүнең кирәге юк. Ул аннан утлы чишмәдәй ургып чыккан. Вакытында чарасын күрмәсәгез, харап булулары бар.

Ш ә ң г ә р ә й. Нинди чара соң ул, картлач?

Г а р и ф. Аның чарасы бер генә. Бу ике яшь йөрәкне бергә кушу.

Ш ә ң г ә р ә й. Дөрес сөйлиме ул, балалар?

С ө е н б и к ә. Дөрес, әткәй.

Т и м е р *(Сөенбикәнең кулыннан алып.)* Хөрмәтле Шәңгәрәй абзый һәм сөекле Биби апа! Безгә рөхсәтегезне биреп, безне бәхетле итсәгез икән...

Ш ә ң г ә р ә й. Я, ни дисең, әнисе?

Б и б и. Мин әйттем бит инде... Мин бая ук әйттем бит инде... *(Елый.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Елама!

Б и б и. Шатлыктан ул, әтисе, шатлыктан...

Ш ә ң г ә р ә й. Рөхсәт дисеңмени инде?

Б и б и. Нишлисең бит, йоласы шул, берни кылып булмый.

Ш ә ң г ә р ә й. Үзләре нәрсә ди соң? Бер-берсен яхшы сынаганнармы? Тормыш юлын лаеклы итеп үтә алырларына ышаналармы?

С ө е н б и к ә. Ышанабыз, әти.

Т и м е р. Ышанабыз.

Ш ә ң г ә р ә й. Алайса, бәхетле булыгыз, балалар, миннән фатиха! *(Яшьләрнең кулларын кулга тоташтырып, маңгайларыннан үбә.)*

Т и м е р.
С ө е н б и к ә. } Рәхмәт, әткәй, рәхмәт, әнкәй!

Г а р и ф. Менә шулай... Ә хәзер өстәл, туй!

Ш ә ң г ә р ә й. Ашыкма! Кияү бит үзе генә түгел. Ата-анасы бар. Туй кебек зур нәрсәне бергә җыелып, бер өстәл артында хәл кылырга кирәк. Әйтик, ничек, кайда, кайчан? Мин, профессиям буенча бухгалтер кеше буларак, туй кебек нәрсәнең сметасын да алдан карап кую ягында.

Б и б и. Әй, этисе, карап торган бердәнбер кызыбызның гомер эчендә бер килә торган туен смитләп тормабыз инде.

Ш ә ң г ә р ә й. Белмисең син, карчык, дөньяда бер нәрсә дә сметасыз эшләнми. Шулай бит, кияү?!

Т и м е р. Әлбәттә, шулай. Без бу турыда үзара сөйләшкән идек инде.

Ш ә ң г ә р ә й. Сез сөйләшкәнсездер, анысында шигем юк. Ә менә без, ике якның да ата-аналары, бергә җыелып бу нәрсәне бергә хәл кылырга тиеш. Инде, шулай булгач, сиңа хәзер, кияү, өегезгә кайтып, этиеңне, әниеңне, ягъни кода белән кодагыйны, бирегә алып килергә туры килер. Ә без синең белән, әнисе, табынны шәп итеп әзерли торыйк.

С ө е н б и к ә. Мин дә барыйммы, әткәй?

Ш ә ң г ә р ә й. Кая?

С ө е н б и к ә. Тимер белән.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә, юк, кызым, сиңа хәзер килен булып төшмичә ул йортка барырга ярамас.

Б и б и. Әй, балакайгынам, бер генә дә янымнан җибәрәсем килми үзеңне. Бердәнберем бит син минем *(елый).*

Ш ә ң г ә р ә й. Шыңшыма! Сезнең анда, кияү, алты бала диденме әле?

Т и м е р. Алты.

Ш ә ң г ә р ә й. Синнән башкамы?

Т и м е р. Миннән башка.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә квартирагыз өч кенә бүлмәлеме?

Т и м е р. Юк, дүрт бүлмәле.

Ш ә ң г ә р ә й. Дүрт бүлмә дә аз инде алты балага. Бәлки әнә шул квартира мәсьәләсен күздә тотып, этиегез Казанда калмаска үзе киңәш иткәндер сезгә?

Т и м е р. Юк, киресенчә. Безнең әти Казаннан китүгә бөтенләй каршы.

Ш ә ң г ә р ә й. Акыллы кеше күренә синең этиең. Туган җирен ташлап киткән кешенең хәлен белә, димәк, ул.

Т и м е р. Ул бит шул трестның патриоты. Мин төзүчеләр институтына керү белән үк минем колак итен ашарга тотынды — укып бетергәч, безнең трестка киләсең, безнең СМУның прорабы буласың, дип. Үзенең прорабы белән килешә алмый. Егерме ел инде бергә эшлиләр, егерме ел буена бер-берсе белән якалашып киләләр.

Ш ә ң г ә р ә й. Беләм, беләм, этиеңне яхшы беләм. Ишетеп кенә түгел, күреп беләм. Кем булып эшли әле ул?

Т и м е р. Монтажник.

Ш ә ң г ә р ә й. Кайсы участокта?

Т и м е р. Алтынчы СМУда.

Ш ә ң г ә р ә й. Исеме ничек иде соң әле?

Т и м е р. Бакый.

Ш ә ң г ә р ә й. Әйе. Бакый Курманаев. Әле син безгә килеп йөри башлагач ук, шул Курманаев токымы түгел микән бу дип уйлап йөри идем... Әйе, уйлаган алга килә...

С ө е н б и к ә *(бүлмәсеннән).* Тимер, бер генә минутка кер әле.

Т и м е р. Хәзер. *(Сөенбикә бүлмәсенә кереп китә.)*

Б и б и. Нәрсә, танышмы әллә?

Ш ә ң г ә р ә й. Таныш кынамы соң?

Б и б и. Бигрәк әйбәт.

Ш ә ң г ә р ә й. Нәрсәсе әйбәт?

Б и б и. Уртак тел табарга дим.

Ш ә ң г ә р ә й. Табарсың бар, Курманаев белән уртак тел. Аның белән каберең якын булмасын.

Б и б и. Ни сөйлисең син, әтисе?

Ш ә ң г ә р ә й. Трестта беренче партизан! Анархист!!!

Б и б и. Әтисе дим...

Ш ә ң г ә р ә й. Прорабның үзе белән егерме ел якалашалар дип әйтеп тора бит синә...

Б и б и. Якалашмыйча гына эш бармый инде ул кайчакта.

Ш ә ң г ә р ә й. Прораб кынамы соң? Управляющийның үзенең якасыннан алганы бар. Ә минем? Ничә мәртәбә кереп якамнан алды. Ул өстәл сугумы кирәк... Юк, юк... Ул кеше белән уртак тел табып булмый.

Б и б и. Тынычлан әле, әтисе. Курыккан эш хәерлегә була ул. Балалар инде, аллага шөкер, бер-берсен сынаганнар. Бер-берсен яраталар. Ә кайда ярату — анда бәхет. Нинди генә ата-ана булмасын, үз баласының бәхетенә каршы төшми. Әйдә, киен әле, әтисе. Барыйк әле икәүләп шул кода каршысына. Сөйләшик әле иплэп, мәсьәләне ачыктан-ачык уртага куеп. Аңлашырбыз, шаять.

Ш ә ң г ә р ә й. Кая барыйк? Курманаевларгамы? Аллам сакласын! Башым ике түгел лә минем, күрә торып, көпә-көндез Курманаевка барып керергә.

Сөенбикә белән Тимер чыгалар.

Т и м е р. Болай караганда кырыс минем әтием, ә асылда әйбәт кеше ул. Яхшы күңелле, аның белән килешеп була.

Ш ә ң г ә р ә й. Булса, үзе монда килсен әле ул. Менә мин аның белән сөйләшеп карыйм әле үз өемдә, аяк терәп.

Т и м е р. Килә, әлбәттә, бик рәхәтләнеп килә.

Ш ә ң г ә р ә й. Килсә — алып кил. Егет ягы йөрергә тиеш яучылап. Кыз ягы түгел. Безнең алай этеп-төртеп бирә торган кызыбыз юк. Әнисе, шуны аңла.

Т и м е р. Киттем. Әйдә, Сөенбикә.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә ул кая?

Т и м е р. Безгә. Аның бит әле бездә булганы юк. Әниемнең Сөенбикәне бик күрәсе килә.

Ш ә ң г ә р ә й. Күрәсе килсә, ул да килсен. Әтиең белән бергәләп, тәпи-тәпи басып, колак сөенчесен култык астына кыстырып. Менә ул булыр безнеңчә...

Т и м е р. Киттем. Ләкин... минем дә бер шартым бар.

Ш ә ң г ә р ә й. Сөйләп кара, нинди шарт ул?

Т и м е р. Әтием белән бер булып, уртак тел табып, икегез безне үзегезнең трестыгызда калдырырга кыстый күрмәгез. Безнең үз планнарыбыз, үз хыялларыбыз бар...

Ш ә ң г ә р ә й. Әгәр дә үз хыялларыгызны тормышка ашырырга теләсәгез, сез нәкъ менә шул безнең трестка төпләнегез дә инде, улым. Ул Россия Федерациясендәге иң алдынгы трест. Аның офыгы киң, перспективасы зур. Мин үзем утыз ел шунда эшләдем. Беләм, кечкенә генә бер участокның гади хисапчысыннан башлаган идем, трест кадәр трестның баш бухгалтеры дәрәҗәсенә кадәр үсеп җиттем.

Т и м е р. Ничек кенә булмасын, без анда калмыйбыз. Без Казаннан китәбез.

Ш ә ң г ә р ә й. Юк инде, без моңа аслан риза түгел.

С ө е н б и к ә. Әткәй...

Ш ә ң г ә р ә й. Җитте. Шуның өчен үстердекмени сине? Картайган көнемдә үземне ташлап китәр өченме?

Б и б и. Тукта инде зинһар, тоткарлама кешене. Барсын, ата-

анасын бирегә алып килсен, башта төп мәсьәләне хәл итик, аннан... Бар, улым, бар, алып кил әтиләреңне.

Сөенбикә. Кара әле, Тимер, син озак йөрмә инде, яме?

Тимер. Бүген тамаша булачак монда. Күз яшьләре дә аз сыгылмаячак. Синең күз яшьләренә җеби торган гадәтең бар, кара аны, нык бул. *(Китә.)*

Биби. Бигрәкләр дә күркәм бала инде...

Шәңгәрәй. Күркәмеңне күрсәтер әле, Курманаев килсә.

Биби. Алар килгәнче табын әзерләргә кирәк, әйдә, кызым.

Гариф. Әйе шул. Табынны шәп итәргә кирәк. Кодалар алдында йөз кызартырлык булмасын.

Шәңгәрәй. Ә син кызартмассың, кодалар килгәндә үзеңә чыгып торырсың.

Гариф. Юк инде, мин беркая да чыкмыйм. Мин баш кода. Минем урыным түрдә.

Шәңгәрәй. Балагыңны җыйдыртыр әле ул синең, Курманаев.

Гариф. Җыймыйм. *(Бибигә күз кысып.)* Никах та укыйм әле мин шул балак белән кодалар килгәч, тәһарәтем исән чакта.

Шәңгәрәй. Пенсия дә аз ала, нинди хисапка яши икән бу карт дип баш вата идем... Карасаң, аның кәсебе бар икән.

Гариф. Бар шул, аллага шөкер. Өйләнсә — никах укыйм, туса — исем кушам, үлсә — ясин чыгам... вакыты җиткәч, үз җеназаңны кем укыр?

Шәңгәрәй. Җеназасын укытыйм әле шуның!..

Биби. Ходай өчен кирәкми, әтисе, шундый шатлыклы көннең ямен җибәрмә.. Күңелең киң булсын.

Шәңгәрәй. Син өйрәттең аны шул киң күңеллелегең белән.

Гариф. Дөньяда миһербанлы бәндәләр дә бар. Аллага шөкер.

Шәңгәрәй. Яп авызыңны!

Гариф. Ярый, ярый, комачауламыйм. Әзерлә табыныңны, мин чыгып торам. Кодалар килгәч әйләнермен тәһарәт яңартып.

Шәңгәрәй. Менә яңартырмын мин сиңа, аягыңны басасы булма.

Гариф. Кара әле, Нурлыбибигөлҗамал, син игелекле адәм, ничек яшәдең бу бәндә белән?

Шәңгәрәй. Җитте!

Гариф. Әт-тә-тә-тә! *(Чыгып кача.)*

Биби. Ни булды?

Шәңгәрәй. Әгәр моннан соң кодалар алдындамы, алар киткәчме, туй вакытындамы, туйдан соңмы — барыбер, бу карт минем бусагамны атлап керә икән, белеп тор, үзеңне дә шуның белән бергә куып чыгарам.

Биби. Әй, әтисе, нигә шулай дисең икән, үзең бит урамнан килеп кергән этне дә куып чыгара алмыйсың — ашарына чыгарып саласың. Бу бит кеше. Шуның өстенә карт кеше. Ялгыз, ятим...

Шәңгәрәй. Ялгыз булса, яшәсен үзе генә, нигә монда сыендырасың?

Биби. Сиңа шахмат уйнарга иптәш булсын дип... Шуның өстенә туган.

Шәңгәрәй. Нинди туган?

Биби. Чыбык очы. Минем әбиемнең әбисе...

Шәңгәрәй. Җитте... Барыгыз табын әзерләгез.

Биби. Күптән шулай диләр аны, әтисе!

*Йөгерә-йөгерә табын әзерләргә тотыналар, ут сүнә, пәрдә төшә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Табын әзерләнгән. Шәңгәрәй чәнечке-кашыклар барлап йөри. Бибя белән Сөенбикә кухнядан соңгы тәлинкәләрне күтәреп чыгалар.

Б и б и. Булды бугай инде. Син, кызым, сал алъяпкычыңны, бар бүлмәңә кер, киен.

С ө е н б и к ә. Мин аларга күренеп тормыйм, шунда бүлмәдә генә утырырмын.

Б и б и. Юк, кызым, без сине бу якка да чакырып чыгарырбыз. Аларның бит күрәсе-күрешәселәре килер.

С ө е н б и к ә. Оялмыйча...

Б и б и. Ояласың инде ул, кызым, оялмый булмый. Оялып булса да чыгарга туры килер. Шәбрәк киен.

С ө е н б и к ә. Кайсы күлмәгемне киим икән, әнкәй, әйдә бергә сайлыйк әле.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә мин ничек киеним?

Б и б и. Син бик әйбәт киенгәнсең. Ир кешегә тагы шуннан да артык...

Ш ә ң г ә р ә й. Алай димә әле, әнисе... Кемнеке — аныкы, дигәндәй... Аннан соң Курманаевлар алдында сер бирергә ярамый бит.

Ишектә берсе артыннан берсе озын-озын звоноклар бирә башлыйлар.

Бер, ике, өч, дүрт, биш...

Б и б и. Ай алла, нишләүләре бу?..

Ш ә ң г ә р ә й. Биш мәртәбә. Кем булыр икән бу?

Б и б и. Бар инде, кем булса да ач, үзең куйган шартлы звоноклар.

Ш ә ң г ә р ә й. Шунда шул хикмәт — бишенчебез юк бит безнең...

Б и б и. Булмаса — булыр, ай алла, көттермә кешене, бар ач.

Кызы бүлмәсенә кереп китә. Шәңгәрәй трюмо янына барып киемнәрен төзәтә. Пульверизатордан исле майлар сиптерә, аннан бик купшыланып ишек янына килә.

Ш ә ң г ә р ә й. Хәзер, хәзер... Рәхим итегез, рәхим итегез, кунак. Ә?! Син нәрсә?

Ишектән Гариф керә.

Г а р и ф. Шулай инде... Әле бер аягы керсә, икенчесе кермәгән килмешәк — дүртенче, ә безне бишенчегә калдырдылар. Мәнә ярты-шар сәгать бусагада шылдыравык биреп тор инде хәзер.

Ш ә ң г ә р ә й. Бишенче дә, унбишенче дә, илленче дә — бер кем дә түгел син, йөрмә, оныт бу ишекне.

Г а р и ф. Онытакан идем дә бит, искә төште. Анда төтен юллыгында фифирузым калган.

Ваннага керә.

Ш ә ң г ә р ә й. Ал да, бар, ычкын!

Г а р и ф. Тукта инде бераз. Кергән-кергән көйрәтеп тә китим.

Ш ә ң г ә р ә й. Өеңдә көйрәтерсең, хәзер кунаклар килә.

Г а р и ф. Килә шул менә, шуңа ашыгам да, кая, җибәр, ябыйк ишекне.

Ш ә ң г ә р ә й. Нишлисең?

Г а р и ф. Минем үземдә кран ватылган. Кайнар су килми. Тәһарәт яңартам. Никах укыйсы булыр... Яп ишекне! *(Ванна ишеген ябып эчтән бикли.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Биби! Бибиәсма!

Б и б и. Нәрсә инде?!

Ш ә ң г ә р ә й. Кара теге бишбалтаңны!..

Б и б и. Нишли?

Ш ә ң г ә р ә й. Никах укыйм ди.

Б и б и. Укымас, укымас, үрти генә бит ул сине.

Ш ә ң г ә р ә й. Әгәр мине кодалар алдында хур итсә, икегезгә дә ямь юк.

Б и б и. Итмәс, үртәнмә.

Ишектә звонок.

Ш ә ң г ә р ә й. Кем булыр икән?

Б и б и. Кем булсын инде?

Ш ә ң г ә р ә й. Килделәрме?

Б и б и. Килделәр, әлбәттә.

Ш ә ң г ә р ә й. Нишлибез?

Б и б и. Нишлисең, ач.

Гариф ваннадан чыга.

Г а р и ф. Туктагыз...

Ш ә ң г ә р ә й. Кая барасың?

Г а р и ф. Мин чыгып калыйм.

Ш ә ң г ә р ә й. Кая?

Г а р и ф. Өйгә.

Ш ә ң г ә р ә й. Чыкма, күренмә. Кит кереп ваннага.

Г а р и ф. Чыгам дидем — чыгармадың, инде үзеңә үпкәлә.

Ш ә ң г ә р ә й. Яп ишегеңне, шунда гына утыр. Тыныңны да чыгарасы булма.

Б и б и. Ач инде, ач ишегеңне. Көттермә кунакларны.

Ш ә ң г ә р ә й Әйе, шул. Әйдә... Рәхим итегез, рәхим итегез, кадерле кунаклар!.. *(Киң итеп ишекне ача.)*

Б а к ы й *(ишектә)*. Мөмкинме?

Ш ә ң г ә р ә й. Әйдәгез, әйдә. Рәхим генә итегез, мөмкин, бик мөмкин.

Ишектән Б а к ы й, Г ө л б а н у, Т и м е р керәләр.

Б и б и. Узыгыз, уз, кая, плащегызны монда бирегез. *(Икесе дә кунакларны чишендерәләр.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Әйдәгез, менә, түргә узыгыз, кем... Ничек әле?

Б а к ы й. Нәрсә? Оныттыңмы әллә? Шулай инде, хәтергә бераз саерак диләр бит сезне.

Т и м е р. Әти, үткәнне искә алмаска дип килештек бит инде.

Б а к ы й. Әйе, әйе шул, оныткан бит. Исемем Бакый булыр минем. Әти мәрхүм Габделбакый дип йөртә торган иде. Кемгә-кемгә, ә менә сиңа оныту һич тә килешми, начальник.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә минеке Шәңгәрәй. Шәңгәрәй Исламгәрәевич.

Б а к ы й. Ул кадәрлесен үк әйтеп тормам. Ич-мичләп сөйләшүне җенем сөйми. Олы кеше буларак Шәңгәрәй абзый гына диярмен. Кем белә, килешеп китсәк, бәлки кодалар да булып куярбыз. Гәрчә кайчандыр үзара якалашкан кешеләр булсак та.

Т и м е р. Әти!

Б а к ы й. Бетте, бетте.

Ш ә ң г ә р ә й. Әлбәттә, кодалар. Без инде сөйләштек, килештек, хәл кылдык.

Б а к ы й. Кем белән.

Т и м е р. Менә минем белән. Әти, син зинһар үзеңне кешечә тот. *(Тимер кыз булмәсенә кереп китә.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Әйе, Тимергали кияү белән.

Б а к ы й. Аңа бит безнең исемнән сөйләшергә вәкаләт бирелмәгән. Монда бит әле гаилә башлыгы — мин бар. Аннан килеп менә

әнисе... Танышыгыз, һәрвакыт минем кубызга гына биеп торучы минем хөрмәтле хәләл җефетем Гөлбану шәрифәләре.

Гөлбану. Ай, әтисе, ялгышмыйсың микән? Киресенчә түгелме?

Бакый. Нәрсә, мин синең кубызыңа бии булып чыгамыни инде?

Гөлбану. Булгалый. Кая кем...

Биби. Биби.

Гөлбану. Әйе, Биби кодагый, әйдә күрешик. Исән-сау гына яшисезме?

Биби. Бик аллага шөкер, дөбердәтеп.

Гөлбану. Шулай кирәк. Дөбердәтеп тә калмагач дөньясында... Кая, сезнең белән дә күрешик, кода.

Шәңгәрәй. Бик мәслихәт, бик күркәм. Шулай да сезнең кайсыгызның вәкаләт гамәлдә соң? Берегез кода ди, берегез вәкаләт юк ди.

Гөлбану. Минем. Мин бирәм вәкаләтне. Мин балаларымны туганда ук вәкаләт белән тудырдым. Кая, аякта хаклык юк диләр руслар, түргә узыйк, утырыйк.

Шәңгәрәй.
Биби. } Әйдәгез, рәхим итегез Менә монда утырыгыз.

Бакый. Хуш... Барыбыздан олы гореф-гадәт бар бит әле, бабайлардан калган. Алар нәрсә диләр иде? Иң әүвәл йортка бәрәкәт бирсен дип фатиха кыла торганнар иде. Амин!

Шәңгәрәй. Шулай булсын!

Гариф *(ванна бүлмәсеннән атылып килеп чыга).* Юк.. «Амин» дип кенә алай бик кыска тотмагыз әле сез, мөселман бәндәләр. Аминга кушып шунда берәр сүрәсен дә әйтеп җибәрик.

Шәңгәрәй. Сүрәләп тормыйбыз инде без, күрше. Анысы сметага кертелмәде.

Бакый. Бу күрше дигәнегезнең үзен дә сметага кертмәгәнсез, ахры, ваннага бикләп куйгансыз.

Шәңгәрәй. Аны берәү дә бикләми. Ул үзен-үзе шулай җәзалый. Тегe дөньяда әҗерен күрер өчен. Элек бит дөньядан ваз кичеп, тау тишекләрендә, мәгарәләрдә гыйбадәт кылып яшәүче изгеләр булган. Менә бу карт та инде шул изгеләрнең безнең заманга калган бер нөсхәсе, ләкин ул мәгарә урынына ванна бүлмәсендәге тәтен юллыгын кулайрак күрә.

Бакый. Тәтен юлында гыйбадәт кыламы?

Шәңгәрәй Юк. Тәтен юллыгына гыйбадәт кыла.

Гариф. Гыйбадәт гыйбадәт инде. Кайда кылсаң да әҗере тия. Менә бу мәҗлес шул гыйбадәт нәтиҗәсе түгелме соң?

Бакый. Мәҗлес булып җитмәгән әле. Мәҗлескә кадәр хәл кыласы мөһим мәсьәләләр бар.

Гөлбану. Анысын балалар үзләре хәл кылганнар инде, безгә калдырмаганнар. Мә, кодагый, рәхим итеп алып куй шушыны. *(Төенчек суза.)*

Биби. Бу нәрсә була соң инде?

Гөлбану. Мәһәре — колак сөенчесе.

Гариф. Бәрәкалла, ул мәһәрдә безгә дә өлеш булырга тиеш.

Бакый. Сез кем соң?

Гариф. Баш кода.

Бакый. Ничек баш кода? Без сезне кодалаганыбыз юк.

Гариф. Ягъни мәсәлән — яучы!

Бакый. Яучылыкка да ялламадык.

Гариф. Сез ялламадыгыз, анысы шулай. Ләкин яшьләр үзләре

ялладылар. Укалы кәләпүш, каюлы читек, вилюр эшләпә, кримплен пәлтә — вәт!

Гөлбану. Йоласы шул икән, булыр, абзыкаем, борчылма. Кримпленнар артыннан йөрергә әле вакыты булмады.

Гариф. Бәрәкалла! Менә бу нәкъ безнеңчә — мөселманнарча. Юкса, никахны нәрсә киеп укырмын икән дип баш вата идем.

Бакый. Никахын да йола буенча укыйсызмы? Башта килен буласы кешенең безгә үзен күрсәтмичә торып?

Гариф. Ә кәк-же.

Бакый. Ә юк, без каршы. Без башта киленнең үзен күрергә телибез.

Гариф. Сезгә нәрсәгә ул? Яшьләр үзләре күргән, күрешкән, шул җиткән.

Гөлбану. Юк, җитмәгән. Мин — ана. Булачак балакаемның үзен күрергә тиешмен.

Бакый. Әйе, бу заманда киленне ата-анага күрсәтми бирмиләр.

Шәңгәрәй. Килен дисеңме?

Бакый. Әйе, килен. Безнең өчен инде ул килен була, ягъни мәсәлән. Кая чыксыннар иде. Күрешсеннәр биредә.

Шәңгәрәй. Ярый, әнисе, аллага тапшырдык, җебемә. Нишләмәк кирәк, шулай язгандыр инде. Әйт, чыксыннар. Чыгып карасыннар булмаса.

Биби *(ишеккә барып)*. Балалар, балакайлар...

Гөлбану *(ишеккә барып)*. Улым, Тимер.

Биби. Кызым, Сөенбикә.

Гөлбану. Чыгыгыз бирегә, акыллыларым.

Биби. Кызым, кода-кодагыйларның күрешәсе килә үзең белән.

Гөлбану. Әле бит без синең белән күрмәгән-күрешмәгән.

Шәңгәрәй. Әйдәгез, балалар, әйдәгез.

Сөенбикә белән Тимер керә.

Биби. Оялма, кызым, оялма, бер синнән генә калмаган. Башта менә әти булачак кеше белән күреш.

Шәңгәрәй. Нинди әти, кайнатай диген.

Бакый. Как то-есть әти түгел? Әти... Самый настоящий әти. Исәнме, кызым? Кая, бир кулыңны, күрешик. Әйбәт, бик әйбәт, акыллы бала күренәсең, рәхмәт, рәхмәт. Менә инде әниең белән күреш.

Биби. Балакаем минем...

Шәңгәрәй. Җебемә дим...

Гөлбану. Рәхмәтләр генә төшсен үзеңә, балакаем. *(Сөенбикәнең маңгаеннан үбә.)* Бәхетең-тәүфигың белән, кызым!

Гариф. Кая, утырышыгыз.

Шәңгәрәй. Нишләмәкче буласың безне утыртып?

Гариф. Утыргач күз күрер. Кодалар, менә түргә узыгыз. Кияү белән кыз менә монда, минем уң ягыма, ә кодагыйлар читтәрәк торыгыз.

Гөлбану. Нишләп без читтә торыйк ди?

Гариф. Ярамый, хатын-кызга килешми, ди китап. Барыгыз, бар, кухняга ук чыгып торыгыз.

Шәңгәрәй. Ә син нишләмәкче буласың аларны кухняга чыгарып?

Гариф. Никах укыйм...

Шәңгәрәй. Юк инде, алар чыкмый. Алар менә монда, табынның түрендә утыралар. Ә син бар үзең чык. Әнә төтен юллыгы тирәсенә кереп укы никахыңны.

Гариф. Никахыңны, имеш? Миңа кирәкмени ул никах? Әнә, балаларыгызга кирәк. Шунсыз тору дөрес түгел, ди китап.

Шәңгәрәй. Тора башлагач үзләре дөресләрләр. Анысын синнән сорамаслар.

Гариф. Эх, җәмагать, Мөхәммәт өммәте, мөселманнар! *(Елаган булып күзләрен сөртә, үзе читкә борылып көлеп тә ала.)* Шушы көнгә калдыкмыни соң инде? Никахсыз тору, беләсезме, ни дигән сүз?

Бакый. Белмибез, белмибез. Безгә чуртымамы кирәк? Әнә үзләре теләсә нишләсеннәр.

Шәңгәрәй. Алай. Безнең әле аннан мөһимрәк мәсьәләне хәл кыласыбыз бар, әйеме, кода?

Бакый. Нинди мәсьәлә?

Шәңгәрәй. Кая, әйдәгез, табынга утырышыйк.

Гариф. Юк, җәмагать, никахсыз табында утырмыйм. Шәһит китсәм китәм, барыбер никах укыйм.

Шәңгәрәй. Мәгарәңә кереп укы.

Гариф. Укыйм. Кайда укысам да укыйм, тик укуым гына хак булсын.

Шәңгәрәй Төтен юллыгына кычкыр, монда ишетелмәсен.

Гариф. Ишетелмәс. Ә ояты сезгә булыр.

Бакый. Сметага кертмәгәч, ояты да булмас аның, абзый.

Гариф *(ваннага юнәлә.)* Аллаһы әкбәр, валлаһы әкбәр, лә илаһы иллалаһы, валлаһы әкбәр! *(Ванна бүлмәсенә кереп китә, бар да көлешәләр.)*

Шәңгәрәй. Ягез, утырышыгыз. Кода белән кодагый менә монда түргә. Ә син, әнисе — минем янга. Ә балалар...

Бакый. Аларның кирәге булыр микән бу табынга? Алар инде үзләренекен эшләгәннәр, кем әйтмешли, безне фактка китереп терәделәр. Безгә хәзер шул фактны хәл кылырга кирәк. Смета дисең бит үзең. Бухгалтер булмасам да, мин дә смета дигән нәрсәне яратам. Ә смета ул безнең кесәдән чыга. Шулай булгач, без үзебез генә хәл кылыйк инде моны, кем...

Гөлбану. Кода.

Бакый. Ашыкма... Хәзерге яшьләр бит алар керемен-чыгымын уйлап тормый, ресторан ди башларлар... Чәчәккә, ефәккә күмелгән такси, тарантас, пар ат!..

Шәңгәрәй. Ә нигә пар ат, тройка!

Бакый. Әнә бит!

Тимер. Әти, сез ул ягын үзегез генә хәл кылыгыз инде. Без...

Бакый. Әйе шул, бар, бар, курыкма, мин артыгын ычкындырмам. *(Яшьләр эчке бүлмәгә кереп китә.)* Шулай... Тройка дидеңме әле кем...

Гөлбану. Кода.

Бакый. Тукта! Теге шешәдә нәрсә ул?

Шәңгәрәй. Коньяк.

Бакый. Без анысын эчеп тормабыз. Безнең эчкә килешмәс ул. Кандала исе килә. Безгә әнә тегесен үзебез шикелле простоен сал. Ә, юк, шаяртма... Уймак белән аракы эчәргә өйрәнмәгән без. Безгә әнә теге стаканга сал. Тутырып. Я, тапшырдык... Танышу-күрешү өчен. *(Эчәләр.)* Мин үзем күп эчмим эчүен. Миңа тагы бер стакан тутырып куегыз да... Анысы килешү өчен булыр. Әгәр килешә алсак. Килешә алмасак, шулай тулы килеш калыр. Мин аңа иренемне дә тидерәчәк түгел. Хуш, нәрсәдә туктап калдык әле без? Тройкадамы?

Гөлбану. Анысы инде аның сүз иярә сүз чыккач кына. Хәзерге заманда каян табасың аның тройкасын.

Б а к ы й. Сүз иярә сүз чыкмасын ул. Чыктымы, таптыра. Ә мин тройкалый алмыйм, бигайбә. Минем әле анда, әнә ул малай артында тагы алтысы чират көтеп тора.

Г ө л б а н у. Син, әтисе, алай, гел юкка салышма. Аннык кына рәтебез бар.

Б а к ы й. Рәтне бит аны рәтләп рәтләргә кирәк. Шунсыз ул рәтнең рәте булмый ди. Кыскасы шул: беренче көнне, ягъни ЗАГСтан кайткач — башта сездә — кыз йортында туй мәҗлесе уздырабыз.

Г а р и ф *(ваннадан чыга)*. Туй мәҗлесе түгел, никах мәҗлесе. Башта «Риза булып алдыңмы?» «Риза булып бардыңмы?»ны кычкыртабыз.

Ш ә ң г ә р ә й. Сиңа анда төтен юллыгында кычкырт дип әйтелгән бит.

Г а р и ф. Төтен юллыгында төтен иснәп кенә булмый бит... Ә монда әнә... *(исни)* бәлеш исе димме?

Ш ә ң г ә р ә й. Ал әнә кергән, безне генә калдыр.

Б а к ы й. Мә, бәлеш артыннан берне тотып та җибәр. Укырга җиллерәк булыр.

Г а р и ф. Аллам сакласын, булмаганны, ул хәрамнең минем авызыма да кергәне юк. *(Коньяк шешәсенә карап иреннәрен ялый.)*

Б а к ы й. Ә син күрсәтми генә, итәк астыннан гына. *(Беркемгә дә күрсәтмичә, Гариф кесәсенә коньяк шешәсен яшерә.)*

Г а р и ф. Аллаһы әкбәр, валлаһы әкбәр лә илаһы иллалаһы, валлаһы, әкбәр. *(Кесәсен капшый-капшый ваннага кереп китә.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Хуш, шуннан нишлибез?

Б а к ы й. Шуннан инде икенче көнне килен төшерәбез. Ярый, такси белән булсын ди, аласыларын төяп йортка алып кайтабыз... Һәм шунда — төп мәҗлес. Бу йорттагы мәҗлеснең сметасын син төзисең, төп йорттагы мәҗлеснең сметасын мин төзим. Син үз йортыңа кемне телисең, шуны чакырасың, мин үз йортыма кемне телим, шуны чакырам Ә теге төтен юллыклы мәгарә козгынын син дә чакырмыйсың, мин дә чакырмыйм.

Ш ә ң г ә р ә й. Өченче көнне нишлибез?

Б а к ы й. Өченче көнне яшьләрнең үз ишләрен җыеп әйбәтләп кияү коймагы белән сыйлыйбыз. Шуннан — вәссәләм! Дүртенче көнне эшкә! Космос чоры, атналар буе туйлый торган заман түгел.

Ш ә ң г ә р ә й. Ярый, мин риза. Мин бу шартларның барысын да берсүзсез кабул итәм. Ә менә сез киленне, ягъни минем кызымны, төп йортка төшерәбез дидегез. Моны ничек аңларга?

Б а к ы й. Шулай, туры мәгънәсендә.

Ш ә ң г ә р ә й. Озаккамы инде?

Б а к ы й. Ничек озаккамы? Бөтенләйгә! Безнең нәселдә бер алып, бер җибәреп йөрү гадәте юк. Мин моны не позволю берсенә дә.

Ш ә ң г ә р ә й. Ләкин бит минем кызымның төп йорты монда. Менә шушы нигездә.

Б а к ы й. Ә, юк... Кыз баланың төп йорты килен булып төшкән йорт була. Ә туган йорты аңа кош оясы сыман нәрсә — бер очып киттеме, ул анда кире кайтмый.

Ш ә ң г ә р ә й. Бу элек, хосусый милекчелек чорында шулай булган. Ә хәзер синең йорт та, минем йорт та юк. Коммунальный! Кайда торса да барыбер.

Б а к ы й. Барыбер түгел...

Ш ә ң г ә р ә й. Бу очракта бер түгел, әлбәттә. Биредә алар өчен яхшырак, киңрәк, иркенрәк, тынычрак.

Б а к ы й. Син нәрсә, бездә тыныч түгел димәкче буласыңмы?

Ш ә ң г ә р ә й. Алай димим, әлбәттә. Шулай да анда алты бала... Алтысы да ир заттан... араларында буй җиткән егетләре дә бар.

Юк, юк булмый. Минем кызым, минем бердәнбер кызым андый шартларда яши алмый.

Б а к ы й. Булмаса — булмый. Әнә стаканың... Хатын, ал колак сөенчеңне, әйдә киттек, бигайбә!

Г ө л б а н у. Утыр, нишләвең бу?

Б и б и. Ай алла, бу нинди мәсхәрә?

Б а к ы й. Син, хатын, тартма чабудан. Башыңнан чүпрәгең күптән төшкән, уйлап кара син дә бераз. Без нәрсә, малай өйләндерәбезме, әллә малайны кияүгә бирәбезме? Ә?.. Ә ул акыллы карт кызын өйләндерә булып чыгамы? Шулаймы? Әйт, шулаймы?

Г ө л б а н у. Кычкырма, кеше өе бит бу.

Б а к ы й. Кычкыртасың килмәсә кеше тегәрмәненә су коеп утырма. Бар әнә теге якка чыгыгыз. Хатын-кыз эше түгел бу. Без, ирләр, үзебез хәл кылырбыз.

Б и б и. Әйдә чыгыйк, кодагый, чыгыйк. Теләсә генә нишләсеннәр.

Г ө л б а н у. Ярый, чыгабыз. Тик шуңарчы менә моны иснәп кал әле син, этисе. *(Бакыйның борын төбенә йодрыгын китереп куя.)* Шуны да исеңдә тотып хәл кылырсың.

Гөлбану, Биби кухняга чыгалар.

Б а к ы й. Адәм мәсхәрәсе... Мин, Бакый, малай кадәр малай үстерәм дә, населгә тап төшереп, шуны кияүгә бирәм, шулаймы?

Ш ә ң г ә р ә й. Кем әйтә аны шулай дип? Сез малаегызны өйләндерәсез, без кызыбызны бирәбез. Ләкин алыш-биреш беткәч, туйлар узгач, алар бирегә күчеп киләләр. Бу йортта яшиләр — бары шул. Менә аларның үзләренә генә аерым бер зур йокы бүлмәсе. Менә зал. Ә без карчык белән теге як бүлмәдә. Сездә бит мондый мөмкинлекләр юк.

Б а к ы й. Кем әйтә аны юк дип, кем әйтә? Әгәр өйләндерәм икән, димәк, бар. Аерым йокы бүлмәсе дә бар, залы да бар.

Ш ә ң г ә р ә й. Бардыр, бәхәсләшмим. Ләкин бит әле сезнең тагы алты бала да бар. Аларны кая куясың?

Б а к ы й. Анда синең эшең булмасын. Бәлки мин коридорга сәндерә ясап шунда тутырырмын аларны.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә өйләнсәләр берәм-берәм?!

Б а к ы й. Өйләнсәләр дә табарбыз! Тик өйләнсеннәр генә, йортка кермәсеннәр!

Ш ә ң г ә р ә й. Ах, менә ничек? Ләкин иске караш бит бу, кода. Иске караш!

Б а к ы й. Теләсә ничек булсын, йортка керү егетлек түгел. Ә мин егетләр үстерәм. Җиде егет, җидесе дә җелек кебек. Горурлар! Ул үзе дә йортка керми. Горур ул! Тимер, чык әле монда! *(Тимер Сөенбикәне җитәкләп чыга.)*

Т и м е р. Нәрсә, әткәй?

Б а к ы й. Үзең генә чык!

Т и м е р. Сүз безнең икебез турында барачактыр бит?

Ш ә ң г ә р ә й. Дөрес, улым, икегез турында барчак.

Б а к ы й. Улым түгел, кияү!

Ш ә ң г ә р ә й. Юк, улым! Минем кызымның кияве миңа улым кебек булырга тиеш. Минем кызым бер генә. Мин аны үз янымнан җибәрә алмыйм. Минем карап торганым бит ул.

Б а к ы й. Соң алай булгач син аны кияүгә бирмә. Карап кына тор үзенә.

Т и м е р. Әткәй!

Ш ә ң г ә р ә й. Яратышалар бит алар, мәхәббәткә каршы торырлык көч бармыни дөньяда?

Б а к ы й. Шулай булгач көчәнеп маташма инде. Егет өйләнә һәм кызны килен итеп үз йортына алып кайта, бары шул!

Ш ә ң г ә р ә й. Юк, монда алып кайта! Аларның безне ташлап китәргә хаклары юк! Кызым, китмисез бит, улым, кияү, монда торасыз бит?! Әйтегез инде шуңар, аңлатыгыз инде зинһар... Бу йорт сезнеке бит... Бөтен мөлкәте белән сезнеке.

Б а к ы й. Түгел! Аның үз йорты бар... Аның үз мөлкәте бар. Булмаса үзенекен булдырырлык көче бар, сәләте бар. Нигә ул синә йортка керсен? Нигә син аны мыскыл итәсең?

Т и м е р. Әткәй, туктыйсыңмы син, юкмы?

Б а к ы й. Юк. Син нәрсә, мине монда мыскыл итәр өчен алып килдеңме? Әнисе, җыен, китәбез! *(Кухняга бара башлый, аннан — Гөлбануның йодрыгы күренә.)* Ә?.. Йодрыкмы?.. Әнә аңа күрсәт син аны, белсен безнең нәселне!

Ш ә ң г ә р ә й. Безнең дә бит нәсел бар. Минем дә бит шул нәсел өчен тырышуым. Балалар безгә, әниләре белән икебезгә, берсеннән-берсе матур, туп шикелле түгәрәк йөзле оныклар булдырса, без шул оныкларны карап үстерсәк...

Б а к ы й. Нәрсә? Онык? Син әле оныкны да үзеңә генә өмет итәсеңмени? Үзең шикелле нәзек бармаклы бухгалтер ясар идең бугай минем оныгымнан. Юк инде, булмый торсын. Мин үзем тәрбияләп үстерәм үз оныгымны. Тимердәй нык итеп. Минем династиям — эшче! Хыялланма, картлач!

Ш ә ң г ә р ә й. Хыялланам. Кем генә хыялланмый? Гомерем буе шул оныклар дип хыялландым бит мин, балалар! Бар да беттемени соң?

С ө е н б и к ә. Әтием, елама!

Т и м е р. Әткәй, тынычлан!

Б а к ы й. Ә?.. Нәрсә?! Нәрсә дидең?! Әти дидеңме? Хатын, чык әле! Гөлбану дим, чык әле!

Г ө л б а н у *(кухнядан чыга)*. Нәрсә, исе беттеме?

Б а к ы й. Син ишеттеңме, син ишеттеңме ул аңа нәрсә диде?

Т и м е р *(Бакыйны кулыннан тартып читкә алып китә)*. Әткәй, минем артык түземем калмады, син мине чыгырымнан чыгардың, нәтиҗәсе өчен миңа үпкәлисе булма. Бер кайчан да! Сөенбикә, әйдә, киен, киттек. Безнең башка юлыбыз калмады.

С ө е н б и к ә. Тимер, тукта әле, Тимер, тыңла әле...

Т и м е р. Киен! *(Сөенбикәне бүлмәсенә озата.)* Әнкәй, сез безне гафу итегез, без бераз йөреп кайтыйк, институтка барыйк, дуслар белән киңәшеп карыйк. Болар белән хәзер бернәрсә дә барып чыкмас. Безгә хәзер үз юлыбызны табарга кирәк.

Г ө л б а н у. Барыгыз, балалар, бар. *(Тимер Сөенбикә бүлмәсенә керә.)* Болар икесе дә кызганнар, суытырга кирәк. Монысын мин аның хәзер үзем суытам.

Б а к ы й. Син бер нәрсә дә ишетмәдеңмени, алла колы!

Г ө л б а н у. Ишеттерим әле менә мин сиңа!..

Б а к ы й. Җыен, хәзер үк китәбез.

Г ө л б а н у. Утыр...

Б а к ы й. Син ишетмәдеңмени, ул аңа нәрсә диде?

Г ө л б а н у. Нәрсә диде?

Б а к ы й. Менә шушы картка «әти» диде.

Ш ә ң г ә р ә й. Кода, син минем авырткан җиремә кагылма. Акыллы булсаң, син бөкрегә бөкре димә. Юкса...

Б а к ы й. Нишләрсең, юкса? Нишләрсең? Минем малай, минем улым, үз әтисен... Су бирегез, су!..

Г ө л б а н у. Утыр! *(Бакыйны идәнгә төртеп утырта.)*

Б а к ы й. Янам!

Гөлбану. Мә, сүндер. *(Бакыйның баш түбәсенә өстәлдәге шешәдән «шифалы су» коя.)*

Шәңгәрәй. Нәрсә ди бит, ә? Ул миңа нәрсә ди! Ой, кулым, кулым корыша! Әнисе, грелка!.. Грелка бир! *(Биби грелка чыгара, ваннадан Гариф чыга.)*

Гариф *(Гөлбануга)*. Нәрсә? Тәһарәт яңартасызмы? Шешәдән, ә? «Шифалы су» белән? Ә соң комган, комган кая?!

Эчке бүлмәдән киенеп Тимер белән Сөенбикә килеп чыгалар. Гариф Тимернең ярсулы кыяфәтен күреп тиз генә ваннага кереп кача.

Тимер. Ярый, сез боларны шифалый торыгыз, ә без...

Биби. Озак йөрмәгез инде сез, балалар!

Сөенбикә. Без тиз кайтырбыз, әнкәй.

Гөлбану. Монда кайтырсыз бит, улым?

Тимер. Бирегә кайтырбыз, әнкәй, сез безне монда көтегез!

Тимер, Сөенбикә китәләр. Эчке пәрдә төшә.

Тимер белән Сөенбикә җитәкләшеп эчке пәрдә алдына килеп чыгалар.

Сөенбикә. Тукта әле, Тимер.

Тимер. Нишләдең инде?

Сөенбикә. Тын алыйк бераз...

Тимер. Тын алып торырга вакыт юк.

Сөенбикә. Әллә кире борылабызмы?

Тимер. Син ни сөйлисең?!

Сөенбикә. Әткәй кызганыч бит. Күрдең ич нинди хәлдә калды.

Тимер. Ул вакытта бар инде, борыл, ләкин шуны белеп борыл, мин бер кайчан да, бер кайдан да кире борылмаячакмын.

Сөенбикә. Димәк, син мине яратмыйсың?

Тимер. Яратсам да кире борылмаячакмын. Авыр булыр, сагынырмын, ләкин түзәрмен. Хуш!

Сөенбикә. Син нәрсә, китүеңмени инде?

Тимер. Әйе, китүем!

Сөенбикә. Кая?

Тимер. Кая дип сөйләштек соң?

Сөенбикә. Ул бит хәзер үк түгел иде. Бәлки хәзер үк китүнең кирәге дә булмас. Бәлки әткәйләр килешерләр. Бәлки килешкәннәрдер дә инде.

Тимер. Булмас. Безнең әткәй тешләгән җиреннән үзе тукталмый ул. Аннан соң аларның килешүләре әллә безнең өчен дип беләсеңме? Алар үзләрен кайгырталар. Аларга, беләсеңме... оныклар кирәк. Нәсел кирәк. Ә син гомер буе алар итәк астында соска кабып яшә. Эти, тегеләй итимме, эти, болай итимме?

Сөенбикә. Безнең эти андый түгел, ул безнең шәхси эшебезгә катнашмаячак.

Тимер. Ә аның өч бүлмәле квартирасы? Мин шунда яшәргә тиеш һәм шуның өчен...

Сөенбикә. Ни сөйлисең син? Минем этиемне кем дип беләсең? Син бу сүзләрең белән мине дә, минем этиемне дә хурлыйсың.

Тимер. Юк, минем аның турында начарны уйлап әйтүем түгел. Ул бик әйбәт кеше. Ләкин барыбер мин анда үземне квартирант итеп сизәчәкмен. Ә минем алай яшисем килми. Хуш!

Сөенбикә. Хуш.

Тимер. Я бар, нигә бармыйсың инде, бар!.. Бар, бар, этиеңнең канат астына...

Сөенбикә. Барырмын шул. Нигә син мине куасың?..

Тимер. Этиең ярдәмендә аспирантурада калырсың. Галим бу-

лырсың — кандидат, доктор, профессор... Һич югында, профессорша...

**Сөенбикә.** Ничек дидең?

**Тимер.** Профессор хатыны булырсың дим...

**Сөенбикә.** Нәрсә?! *(Кизәнеп Тимернең өстенә килә, ләкин кинәт туктап кала. Кулындагы сумкасын җиргә бәреп, ике кулы белән йөзен каплап елый.)*

**Тимер** *(җирдән Сөенбикәнең сумкасын ала. Сумкада аның туй күлмәге, туй бөркәнчеге).* Син боларны ни өчен алдың?

**Сөенбикә.** ЗАГСка барабыз дидең бит үзең. Ризалык белән барыбер биреп җибәрмәячәкләр, ябыштырып алып китәм дидең.

**Тимер.** Ябышып чыккан кыз ярты юлдан кире борыламы?

**Сөенбикә.** Кире борылмый идем мин... Барыбер... Әйткән белән дә...

**Тимер** Әйтмә дә инде син болай булгач... Мин үз бәхетемне үз җилкәмә күтәреп, юлсыз җирдән юл ярып, җилгә каршы алга, фәкать алга барам. Кирегә борылдык юк! *(Сөенбикәне күтәреп алга омтыла.)*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бакый идәндә, башына чалма кебек юеш сөлге ураган хәлдә, кулындагы буш «шифалы су» шешәсеннән баш түбәсенә әледән-әле су коеп утыра. Шәңгәрәй уң беләгендәге грелкага сул кулын салган да шуны туктаусыз селкеп идән буенча арлы-бирле йөренә. Гариф җырлый-җырлый өстәлдәге нигъмәтне сыпырта.

**Гариф.** Чын адәм җәннәткә керди,
Җөзә дәүләтләри ирди.

**Бакый.** Шыңшыма әле!

**Гариф.** Бакый күрди аны Иблис,
Идәрди Шәңгәрәй ихлас...

**Бакый.** Син үзең Иблис. Шабашник.

**Гариф.** Шабашник та була алмадым мин — шабаш! Артельгә алмадылар мине. Яшь чагымда да алмадылар. Күп сөйлисең, күпне күрәсең дип курыктылар. Эх... *(Көйләп.)*

Үтти инди ул заманнар,
Очтылар шул кош кеби,
Уйласам ул көннәрем тик...
Төннә күргән төш кеби...

Бу стакандагы аракыны эчмим дисең инде син, алайса?

**Бакый.** Эчмим. Иренемне дә тидермим.

**Гариф.** Бәрәкалла, бик дөрес эшлисең. Мөселман өммәтенә хәмер эчү харам. *(Стакандагы аракыны әле бер урыннан икенче урынга күчереп куя, әле аның өстен каплый, әле ача.)*

Йөз мең алтын торур ирди
Бәнем башымда таҗым.
Инде таҗ урнына калди...

**Шәңгәрәй.** Җитте, зинһар чыгып кит!.. Алла хакы өчен дип үтенеп сорыйм, чыгып кит!

**Гариф.** Китәм, китәм...

Чын адәм җәннәтин китди...
Өстәлләрдә нигъмәт бетди.
Шушы хәмер башка җитди,
Әвеш-тәвеш китәм ирди.

*(Чыгып китә башлый һәм шул чак аның шактый ук исерек икәне сизелә. Яныннан узганда, Бакый аның кесәсеннән баягы коньякның буш шешәсен тартып ала.)* Ал, ал. Кирәк нәрсә түгел ул. Минем аңа исем китмәде, яшь чагымда да... Тик менә җанымны кая куярга белмәгәч кенә... Кысыр кайгы кайгыртасыз сез икегез дә. Ул булдымы, кыз булдымы, тегендә тордымы, монда тордымы — барыбер түгелмени? Бәхетлеләр бит сез икегез дә... Ә менә мине ул бәхет читләтеп үтте. Эх...

Гәззелбану, чәчтәңкәң...
Безнең белән утырганга
Ачуланмасмы әнкәң?

Яна бит, яна менә монда... Акрын гына пыскып яна. Бер ел гына да түгел, ун ел гына да түгел. Алтмыш ел шулай яна. Әйтсәң кеше ышанмас. Шуңа күрә бер кайчан да, бер кемгә дә сөйләгәнем булмады. Беренче булып сиңа әйтәм: шабашник түгел мин, ломовой извозчик. Бишбалтаның заманында дан тоткан ломовой Гарифы. Гомерем буе ат белән эшләдем. Яңа бистәдә тире ташыдым мин ат белән. Күке дә түгел мин, Шәңгәрәй күрше, ишетәсеңме, күке дә түгел. Унике түгел, бер балам да булмады минем. Егет кеше әле мин. Акком астында Гәззелбануым бар иде. Миңа бирмәделәр. Ломовой Гарифтан хурландылар. Бер сәүдәгәргә биреп икебезне дә гомерлек бәхетсез иттеләр. Көн саен мин Бишбалтадан, Акком астын урап, Яңа бистәгә эшкә йөрдем. Ә ул, боегып, почмак тәрәзәсенең пәрдәсен аз гына күтәрә төшеп, минем арттан карап кала иде. Озак яши алмады. Сагыштан чахуткага сабышып вафат булды. Ә мин башка бер кемне дә яратмадым. Ярата алмадым. Гомерем буе аны уйлап яшәдем. Шул да буламы күке? Ә менә Гәззелбануның бер кызы калды... Калды аның бер кызы... Нәкъ Гәззелбануның үзенә охшаган... Ә кешеләр сөйлиләр, лыгырдыйлар бакылдыйлар... «Бишбалтада бакалар бакылдашып яталар...» *(Җырлый-җырлый чыгып китә. Аның җырына да, сүзенә дә беркем игътибар итми, хәтта тыңламыйлар да.)*

Шәңгәрәй. Ә мин кияүнең этисе син икәнен белгәч тә өметемне өзгән идем. Син дуамал белән уртак тел таба алмасыма ышанып.

Бакый. Ышангач соң нигә малайның үзенә үк отказ бирмәдең? Ник минем арттан җибәрттердең?

Шәңгәрәй. Кызганычка каршы, бүген генә белдем шул мин аны. Балаларның мәхәббәтен инде һичбер нинди сәбәп какшата алмас хәлгә килеп җиткәч кенә белдем. Озак йөрде малаең минем кыз тирәсендә, ә менә фамилиясен сорарга акыл җитмәде.

Бакый. Сорыйсың калган. Ул вакытта мин дә мондый ук хәлгә җитмәгән булыр идем.

Шәңгәрәй. Кайчандыр синең якаңнан алган анархистның кодасы булырга йөр инде син, карт юләр, ә?

Бакый. Ә ни өчен соң мин синең якаңнан алдым икән, хәтерләмисеңме?

Шәңгәрәй. Хулиган булганга.

Бакый. Булмастыр. Ялгышасыңдыр, картлач. Мин сәбәпсез берәүнең дә якасыннан алмыйм, инде шул хәлгә барып җиткәнмен икән, димәк, син мине үзең мәҗбүр иткәнсең.

Шәңгәрәй. Булдымы икән, ай-һай! Мин һәр вакыт синең шикелле анархистны читләтебрәк үтәргә тырыштым.

Бакый. Беләм мин сезне, кәнсәләр халкын, сез һәр вакыт җайлашырга яратасыз. Начальствога яраклашырга, димәк... Ә алар...

Шәңгәрәй. Син мине хакарәт итмә!

Б а к ы й. Сезнең ишене һәр вакыт ике йодрык арасында тотарга кирәк.

Ш ә ң г ә р ә й. Син нәрсә? Шуның өчен килдеңмени өемә: мине ике йодрык арасына кысарга? Булмастыр! Чөнки намусым чиста!

Б а к ы й. Шикләнмим. Шулай булмаса, мин синең бусагаң аша атламас идем. Ә мин үзем килдем, теләп килдем. Җитмәсә тагын, улыма узганны искә алмаска дип сүз биреп килдем.

Ш ә ң г ә р ә й. Уф...

Б а к ы й. Менә минем ул «уф»...

Ш ә ң г ә р ә й. Башың авыртамы?

Б а к ы й. Чатный. Махмырның нәрсә икәнен гомердә белми идем.

Ш ә ң г ә р ә й. Эчмәдең дә бит.

Б а к ы й. Лөкма дә капмадым. Эчми исердем.

Ш ә ң г ә р ә й. Эчми исерү начар эш ул... Менә минем үземә борчылырга ярамый... Аз гына борчылдым исә — кулым сызлый башлый. Үзәккәйләремә тия-тия сызлый.

Б а к ы й. Безнең хатын-кыз кавеме кайда соң?

Ш ә ң г ә р ә й. Кухняда. Килеште алар, чукыр-чукыр киләләр. Авызлары авызга, телләре телгә йокмый.

Б а к ы й. Йокмас шул, кодагыйлар бит!

Ш ә ң г ә р ә й. Без генә, кодалар, уңмадык бер-беребездән.

Б а к ы й Үзең бит менә нинди хәлгә китердең кешене. *(Чалмасына шешәдән су коя.)*

Ш ә ң г ә р ә й. Ә мине! Кулымны кая куяр урын тапмыйм. Бармакларым берәм-берәм сызлыйлар.

Б а к ы й. Зинһар, яңадан башлама. Гомерең буе счет төймәсен күп тартканга сызлый ул синең бармакларың.

Ш ә ң г ә р ә й. Эәә шул...

Б а к ы й. Теге, чыгып киткән карт нәрсә сөйләде ул?

Ш ә ң г ә р ә й. Белмим, бер нәрсә ишетмим, бер нәрсә күрмим.

Б а к ы й. Никах укымагандыр ич?..

Ш ә ң г ә р ә й. Укыды бугай.

Б а к ы й. Кайда.

Ш ә ң г ә р ә й. Анда — төтен юллыгы тарафларында.

Б а к ы й. Балалар ишетмәгәндер ич?

Ш ә ң г ә р ә й. Юк бугай.

Б а к ы й. Анысы ярый. Юкса, оятын кая куяр идең?

Ш ә ң г ә р ә й. Оятын кая булса да куярбыз... Ә менә балаларның үзләрен кая куярга? Тегендәме, мондамы?

Б а к ы й. Җитте! Яңадан кузгатма! Хатын!

Г ө л б а н у *(кухнядан чыга)*. Нәрсә, әтисе, әллә исе беттеме?

Б а к ы й. Исе башка тиде. Баш чатный, кызышам.

Г ө л б а н у. Ә син кызарга ирек бирмә. Шешәң кулыңда ич, суытып тор баш түбәңнән.

Б и б и. Ә синең, картым, грелкаңны яңартасы түгелме?

Ш ә ң г ә р ә й. Кайнар әле, кайнар.

Б и б и.. Алайса, әйдә, кодагый...

Г ө л б а н у. Әйе шул, кодагый. *(Бакыйга.)* Карагыз аны, шыңшыйсы булмагыз, тыныгыз да чыкмасын! Әгәр тагын безне бүлдерсәң, ямь көтмә. Рәхәтләндек кодагый белән сөйләшеп. Яңадан туган шикелле булдык. Әйдә, кодагый, болар белән вакытны әрәм итмик. *(Кухняга кереп китәләр.)*

Б а к ы й *(пышылдап)*. Кода, ә кода!..

Ш ә ң г ә р ә й. Нәрсә, кода?

Б а к ы й. Син тартмыйсың инде, ә?

Ш ә ң г ә р ә й. Юк иде шул.

Б а к ы й. Йөрәк янганчы тәмәке пыскысын дигән идем.

**Шәңгәрәй.** Теге картның бардыр ул анда, төтен юллыгында. Гел шунда калдырып чыгып китә. Икенче кирәргә сәбәп булсын өчен. *(Ваннадан папирос алып чыга.)* Менә, пачкасы белән. «Себер». Мә, сүндер йөрәгеңне. *(Папирос бирә, шырпы кабыза.)*

**Бакый.** Рәхмәт. *(Суыра, төтенгә тончыга.)*

**Шәңгәрәй.** Синең дә белеп тартуың түгел.

**Бакый.** Белеп эшләгән эш булмады шул әле монда.

**Шәңгәрәй.** Басыламы бераз?

**Бакый.** Әйе бугай.

**Шәңгәрәй.** Басылса, минем бер соравыма тыныч кына җавап бир әле. Әйтик, балалар, синең бер ничек тә акланмый торган законың буенча, сездә торып калдылар, ди. Әйтик, синең икенче малаең, яки өченче малаең өйләнгәнчегә кадәр, ди.

**Бакый.** Юк, бөтенләйгә.

**Шәңгәрәй.** Ярый, бөтенләйгә дә булсын, ди. Әйтик, шул вакыт эчендә боларның бәбиләре туды, ди...

**Бакый.** Соң?

**Шәңгәрәй.** Әйтик, минем оныгым?..

**Бакый.** Ничек синең?

**Шәңгәрәй.** Минем дип, икебезнеке дә инде.

**Бакый.** Уртак бала булмый.

**Шәңгәрәй.** Ярый, уртак түгел, сезнеке генә, ди. Сез икегез дә эштә, сезгә әле пенсиягә ерак.

**Бакый.** Сузма.

**Шәңгәрәй.** Шул. Сез эшкә киткән вакытта миңа, әнә шул кечкенә бәбине менә ышбу арбага салып... *(Караңгы бүлмәдән бәби арбасы тартып чыгара.)* Бакчага... Лядской бакчага тартып алып чыгарга рөхсәт итәрсезме?

**Бакый.** Юк.

**Шәңгәрәй.** Әгәр икенчесе туса?.. Өченчесе туса?..

**Бакый.** Юк, юк!

**Шәңгәрәй.** Башка улларыңнан да оныклар булса?

**Бакый.** Юк, юк, юк!

**Шәңгәрәй.** Әгәр дә җиде улың җидесе дә үзеңә охшап җидешәр бала булдырсалар?

**Бакый.** Җиде җидең — кырык тугыз гына була бит әле ул. Күпмени? Илле дә булмагач...

**Шәңгәрәй.** Комсыз икәнсең син, кода-кунак!

**Бакый.** Оньк кирәк булдымыни? Оньк кирәк булгач, малай үстерәләр аны, кыз үстермиләр, картлач...

**Шәңгәрәй** *(кинәт үзен-үзе онытып кычкыра).* Җит-те!

**Гөлбану, Биби** *(кухнядан атылып чыгалар).* Ни булды, ник кычкырышасыз?

**Бакый.** Ә юк, монысы мин түгел инде.

**Биби.** Нишләвең бу, картым?

**Шәңгәрәй.** Әнисе, беләсең бит, иң авырткан җиремә кагылсалар, мин үзлегемне югалтам.

**Биби.** Ә бу арбаны нигә чыгардың?

**Бакый.** Ул аны безгә бүләк итте. Придан итеп.

**Шәңгәрәй.** Юк инде, үзең сатып ал. Малмыни ул сиңа кырык тугыз арба! *(Арбаны урынына кертеп урнаштыра. Өстәлдәге буш шешәләргә карап.)* Кая соң, бер нәрсә дә калмаганмыни монда?

**Бакый.** Нәрсә эзлисең? Күршең әнә стаканны да каплап чыгып киткән. Мә, менә, суыр. *(Папирос суза.)*

**Гөлбану** *(папиросын тартып ала).* Каян алдың әле моны, ничә ел тартмаганны?

Б а к ы й. Мәгарә картыбыз сау булсын безнең. Кая әле, кодагый, бирәр нәрсәң юкмы шунда?

Б и б и. Суыткычтан башланмаганын чыгарам. *(Өстәлгә бер шешә коньяк китереп куя.)*

Б а к ы й *(шешәне ача, ике рюмкага салып берсен Шәңгәрәйгә суза.)* Тот, кода, борын салындырма. Әйдә, килешик, бәхетеңнән илленчесе туса — анысы синеке!

Ш ә ң г ә р ә й. Рәхмәт!

Б а к ы й. Рәхмәтең белән ашыкма — әле беренчесе тумаган.

Ш ә ң г ә р ә й. Җитте, мыскыл итмә. Минем дә шартым бар... Инде шул шартны тыңла.

Б а к ы й. Сайрап кара!..

Ш ә ң г ә р ә й. Мин сайрамыйм — әйтәм. Һәм бу — закон. Кыз белән кияү шушы йортта торачак. ЗАГСтан соң һәр кайсысы үз фамилиясендә кала. Беренче малайны кыз үз фамилиясенә, ягъни минем фамилиягә яздыра. Ә мин бар мөлкәтемне, дачамны, машинамны, гаражымны — барысын, барысын аңа, үземнең оныгыма, минем нәселемне, минем буынымны дәвам итүчегә васыятьнамә итеп язып калдырам. Менә шул!

Б а к ы й. Дачаңны? Нинди дачаңны?

Ш ә ң г ә р ә й. Дача нинди була? Ике катлы. Икенче катыннан балкон чыга. Балконнан бормалы баскыч төшә. Аннан сигез кырлы гөмбәзле беседкага керә. Беседкадан бассейнга сикерә. Бассейнда алтын балыклар...

Б а к ы й. Хыялланма, карт!.. Безнең нәселдә байлыкка кызыгучы булмады һәм булмас та...

Ш ә ң г ә р ә й. Булмаса, әнә ал колак сөенчеңне дә, рәхим итеп, үкчәңне ялтырат минем өемнән!

Б и б и. Әтисе, нишләвең бу?

Б а к ы й. Ярый, хатын, җыен!

Г ө л б а н у. Кузгалма!

Б и б и. Хараплар гына иттең, хурлыкка калдырдың башкаймны...

Ш ә ң г ә р ә й. Елама, син гаепле барысына да. Син, син, син! Син дә әнә кодагый шикелле, җиде бала таба ала идең. Теләмәдең. Тумас борын харап итеп бардың барысын да.

Б и б и. Акылыңа зәгыйфьлек килдеме әллә синең? Ни сөйләгәнеңне белмисең. Алар бит яшьләр. Кодагыйга нибары кырык. Тимер кияү аның беренче баласы. Ә мин кырык яшемдә чакта шушы төпчек кызыбыз туды.

Ш ә ң г ә р ә й. Төпчеге шул. Аннан элеккеләре кая?

Б и б и! Кая имеш!.. Сорый бит әле тагын... Безнең яшьлек нинди чорга туры килде соң? Җидешәр бала үстерерлекме?.. Сугышта өйләнештек. Икебез бер санбатта идек. Мин медсестра, ә ул казначай. Демобилизацияләнгәч Казанга кайтып төштек. Бер кемебез юк. Йөри торгач, шәһәр читендә бер квартир тапты бит бу. Квартир дип, квартир да түгел инде, пычкы чүбеннән катырган кечкенә генә бер куыш. Икебез дә эшкә урнаштык. Бу әлеге шул трестка счетовод, ә мин клиникада — сестра. Икебезнең хезмәт хакын кушсаң — айһайла!.. Я, әйт инде, кодагый, шул хәлдә ничә бала табарга тиеш идем мин? Илленче еллар уртасында гына үз квартирыбыз булды бит безнең. Әле ярый, шушы төпчегемне — Сөенбикәмне табып калдым.

Ш ә ң г ә р ә й. Табып шәп иттең инде, мине нәселсез хәлдә калдырдың.

Б и б и. Булыр, әтисе, булыр. Бер нәрсәбез юк иде, бар да булды

бит. Нәселебез дә булыр. Тик менә миңа шуны әйт әле син: ник ялганлыйсың? Кая безнең машинабыз, кая гаражыбыз?

Шәңгәрәй. Ник? Оныгыбыз булгач машина да, гараж да алабыз дип сөйләштек бит!

Бакый. Дөрес, кода, сөйләшүе хак булсын. Сөйләшенгән булса булыр. Ә дачасы? Анысы сөйләшенеп кенә калмагандыр бит?

Биби. Каян килгән ди. Идел буенда бер кечкенә генә куышы бар. Балыкчы бит ул. Җәй буе мине шунда сөйри, уха пешерергә дигән булып. Шулпалык балык тота алса икән үзе...

Бакый. Дәшмә, кодагый! Балыкчы ул бай була... Хыялга.

Шәңгәрәй. Хыялдан татлы нәрсә юк дөньяда, әгәр беләсең килсә. Ходай хыялдан аермасын!

Бакый. Амин, шулай булсын! Әйдә, тотыйк берне, соңгысын төплик. Миңа ярамый — иртәгә эшкә. Монтажник бит егерменче этажда.

Без монтажниклар биектә,
Без монтажниклар һавада,
Без монтажниклар һаман да
Күк түбәсенә менеп...

Күтәрдек! *(Эчә.)* Ярый, бигайбә, әле машинаң белән гаражың алынмаган икән. Алынса да безне кызыксындырмый ул. Машина бит ул — җирдә, түбәндә йөри. Ә без — монтажниклар. Без югарыда... Әйдә, хатын...

Гөлбану. Утыр. Нәрсә? Тагын шөрепләрең кыза башладымы? *(Кулына тулы шешә алып.)* Суытыргамы?

Бакый. Юк, безнеке кызмый. Трамвай түгел бит ул. «Трамвай ползет как черепаха» диләрме әле? Безнең бит не ползет. Безнең бит югарыда. Анда — җиләс! Әйдә, киттек!

Гөлбану. Юк, китмим. Мондый кодагыйны ташлап китәр хәлем юк. Мин монда калам. Улым белән икәү без монда күчеп киләбез. Монда иркен, сыярбыз. Ә син әнә алты малаең белән яши бир шунда. Тәккәббер, буш куык!

Бакый. Яшәрмен! Ашын пешерәм, керен уам. Гомер буе син икешәр смена трамвай кудың. Ә мин балалар карадым. Ә хәзер инде алар үзләрен-үзләре карый. Аш пешерәләр, кер уалар, идән юалар. Ләкин сиңа монда — кодагыең янына үзеңә генә күчәргә туры килер. Минем улым монда килмәячәк. Минем улым үзем шикелле горур ул.

Гөлбану. Килер...

Бакый. Килмәс!

Гөлбану. Килер...

Бакый. Килмәс!

Ишектән Тимер белән Сөенбикә кайтып керә.

Әнә, үзеннән сора.

Тимер. Нәрсәне? *(Кулындагы зур чемоданны, аркасындагы рюкзакны куя.)*

Шәңгәрәй. Юк, юк, кирәкми. Сорамагыз. Бер нәрсә дә сорамагыз!

Гөлбану. Юк, сорыйбыз. Бу мәсьәлә алар иркендә. Алар яшисе бит. Шулай икән, ничек телиләр — шулай булсын.

Бакый. Алар түгел ул! Малай хәл кыла мәсьәләне. Ир — баш, хатын — муен, дигәннәр бит.

Тимер. Сез әле һаман бер балык башы турындамыни? Без инде күпме җирдә булдык, никадәр мәсьәләне хәл кылып кайттык.

Гөлбану. Бу мәсьәләне дәме, улым?

Т и м е р. Нинди мәсьәләне?

Г ө л б а н у. Минә, туйдан соң кайда тору мәсьәләсен. Бездәме, яки минә кодалардамы?

Т и м е р. Билгеле, хәл кылдык.

Г ө л б а н у. Кайда?

Б а к ы й. Сорап маташа бит, ә? Ана, имеш, үз улын үз куллары белән тотып йортка кертмәкче була. Шалиш! Курманаевлар диләр аны... Курманаев токымы диләр аны!..

Т и м е р. Курманаев нишләргә тиеш соң, әткәй?

Б а к ы й. Курманаев Курманаевларда калырга тиеш.

Т и м е р. Гафу ит безне, әткәй, без анда калмаячакбыз.

Б а к ы й. Ә?

Т и м е р. Без ул йортта тормаячакбыз.

Ш ә ң г ә р ә й. Бездәме? Ай, рәхмәт, минә рәхмәт, кияү! Әнисе, ишетәсеңме?! Ач!!. Ач бүлмәләреңнең ишекләрен төбенә кадәр. Ал чемоданыңны, кияү... Алып кер чемоданыңны минә бу бүлмәгә!..

Т и м е р. Гафу итегез безне, бабай, без анда да тормаячакбыз.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә кайда, кайда соң?

Т и м е р. Сездә яшәсәк — әтиләр үпкәли, әтиләрдә яшәсәк — сез. Берегезне дә үпкәләтмәс өчен без китәргә булдык.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә?

Б а к ы й. Кая?!

Т и м е р. Эшкә, зур төзелешкә. Шулай яхшырак булыр. Сез дә үзара тыныч яшәрсез. Безнең хәлне белү өчен бер-берегез белән йөрешерсез. Без бит бүгенге көннән — төзүче инженерлар. Минә кулыбызда диплом һәм...

Б а к ы й. Һәм нәрсә?

Т и м е р. Путевка! Комсомол путевкасы.

Ш ә ң г ә р ә й. Ә трест? Берегезне трестта, берегезне аспирантурада калдырырга тиешләр иде бит сезнең?

С ө е н б и к ә. Юкка мәшәкатьләнгәнсез, әткәй. Без ул тәкъдимне кире кактык.

Ш ә ң г ә р ә й. Нигә?

Т и м е р. Трест, аспирантура алда әле ул. Ә безне зур төзелеш көтә.

Ш ә ң г ә р ә й. Нужа көтә диген.

Т и м е р. Романтика көтә.

Б а к ы й. Романтикагызны астыгызга җәеп, романтикагызны ябынып ятарсыз инде, ачык һавада, җил-давыл, яңгыр-буран астында.

Т и м е р. Безнең романтикабыз безнең иң зур байлыгыбыз ул, әткәй. Хәтерлә әле: мин сезнең беренче балагыз, кайда тудым? Романтиканың үзәгендә — чирәм җирләрдә, Казахстан даласында, кар өстендә, палаткада. Әнием белән икебезгә бер сыңар кашыгыбыз иде, дип сөйли идең бит үзең. Ә нигә соң без Сөенбикә белән икәүләп, минә бу йортка — әзергә килеп керергә тиеш? Я булмаса, үзең әйтмешли, төп йортка кайтып сезне һәм энекәшләрне кысрыкларга? Юк инде, авырлык белән үзегез тапкан, үзегез булдыргансыз икән, карт көнегездә рәхәтен дә үзегез күрегез. Ә безнең үзебезнеке булыр. Сез инде безнең өчен барысын да эшләгән — үстергәнсез, укыткансыз, канатлар биргәнсез. Моның өчен без сезгә чиксез рәхмәтебезне әйтеп баш иябез һәм безгә шул үзегез биргән канатлар белән үзебез теләгән якка, үзебезчә очарга рөхсәт итегез.

Г ө л б а н у. Я, күңелегез булдымы инде? Юкса, тумаган тайның билен сындырып, сугышу дәрәҗәсенә җиткән идегез, ике кода...

Б а к ы й. Мин нәрсә, мин болай гына... Асылда мин каршы түгел. Әйдә, тора бирсеннәр шушы йортта. Шушындый квартираны

ачык һавага алмаштырырга соң сез?.. Калыгыз. Бер кая да китмәгез. Кода, әйт инде... Кода, үтен инде... Хәтта мин оныкны да синең фамилиягә яздырырга риза. Тик әйт, китмәсеннәр...

Шәңгәрәй. Улым, кияү... кызым Сөенбикә... Әллә китмисезме? Япа-ялгыз калабыз бит...

Сөенбикә. Юк инде, әткәй, бу мөмкин түгел. Борчылмагыз, ерактагы кояш җылырак була, ди. Без хат язып торырбыз, җәен кунакка кайтырбыз.

Биби. Ә кайчан китәсез соң, балакайлар?

Сөенбикә. Бүген. Менә хәзер. Озакламый такси килеп җитәчәк. Без бит анда күбәүләп китәбез, әнкәй. Дуслар белән!

Биби. Ай алла, синең әйберләрең дә җыелмаган бит.

Сөенбикә. Җыелган, әнкәй. Без бөтенесен дә тутырып, төйнәп куйган идек. Тимер белән. Менә алар, минем әйберләр... *(Бүлмәсеннән чемодан, рюкзак алып чыга.)*

Биби. Ә ЗАГС, ә туй?

Сөенбикә. ЗАГСта да булдык. Күрмисезмени, менә мин туй күлмәкләреннән ич.

Биби. Әй, чыннан да, карагыз әле, без күрми дә торабыз. Ничек булдыгыз, кемнәр белән булдыгыз?

Тимер. Дуслар белән. Бөтен группа килде шаһит булып. Бүген үк китүебезнең сәбәбен аңлаткач, срогыннан элек яздылар. Менә никах кәгазебез. Котлый аласыз.

Гөлбану. Бәхетле булыгыз!

Шәңгәрәй. } Фатиха бездән, фатиха! *(Олылар балаларын*
Бакый. } *берәм-берәм үбеп тәбрик итәләр.)*

Сөенбикә. Туктагыз, мин бу күлмәгемне генә салып чыгыйм инде. *(Бүлмәсенә керә.)*

Бакый. Ә туй, туй кайчан?

Тимер. Атаң акчасына туй үткәрү егетлек түгел ул. Менә барыйк, эшлик бер-ике ай. Аннан туйны шунда үткәрербез. Комсомол туен. Үзең әйтмешли, ачык һавада. Романтика.

Бакый. Ә без?

Тимер. Сезне, әлбәттә, чакыртабыз. Туйның түрендә булырсыз. Яшел чирәм өстендә...

Биби. Әй, балалар, балалар...

Тимер. Әйдә, бераз утырып алыйк. Хәзер килеп җитәргә тиешләр.

Гөлбану. Сез соң моннан китәсезме? Өйгә кереп чыкмыйсызмыни?

Тимер. Без булдык инде анда. Минем әйберләрне җыйнап алдык. Энекәшләр белән саубуллаштык. Җиңгәләре хөрмәтенә шампанскилар шартлаттык. Бик тантаналы булды озату.

Гөлбану. Нигә соң шулай бик тиз китәсе иттегез?.. Ник безгә сәгате-минуты килеп җиткәч кенә әйтергә булдыгыз?

Тимер. Гафу итегез, әнкәй, без бүгенге группага язылырга соңга калдык... Анда урын беткән иде. Кинәт бүген ике урын бушады. Шулай ашыгыч рәвештә җыенырга туры килде. Өлгердек бит!.. *(Тышта машина гудогы).* Әнә, килделәр дә...

Сөенбикә *(юл киемнәреннән чыга).* Мин әзер.

Бакый. Ярый, ни булса да булган, хәерлегә. Утырып алыйк! *(Бары да утыралар. Озак пауза.)*

Бакый. Я, кода, син олы кеше, фатихаңны бир.

Шәңгәрәй. Ә?..

Биби. Фатихаңны бир, ди...

Шәңгәрәй. Ни дип әйтим инде мин?

Биби. Хәерле сәгатьтә диген.

Ш ә ң г ә р ә й. Хәерле сәгатьтә.

Г ө л б а н у. Я, балалар, кайда гына булсагыз да, игелекле юлдан йөрергә язсын.

Б и б и. Кешеләргә игелекле булыгыз.

Т и м е р.<br>С ө е н б и к ә. } Рәхмәт яхшы теләккә.

Б а к ы й. Әйдәгез, кузгалдык.

Б и б и. Әтисе...

С ө е н б и к ә. Әткәй...

Б и б и. Ярый, балалар, кузгатмагыз инде сез аны. Аңа чыгып йөрмәсә дә ярар. Фатихасын бирде бит инде. Утырсын ул, утырсын!..

Бакый, Гөлбану, Биби чемоданнарны алып чыгалар. Сөенбикә белән Тимер Шәңгәрәй каршысына килеп икесе ике якка тезләнәләр.

С ө е н б и к ә. Әткәй, сау бул, бирешмә! *(Үбә.)*

Т и м е р. Без сезне бер кайчан да ташламабыз. *(Үбә. Аннары торып, акрын гына чыгып китәләр, Шәңгәрәй хәрәкәтсез кала.)*

Ишектән акрын гына Г а р и ф керә. Озак итеп Шәңгәрәйгә карап тора. Аннан шахмат белән журнальный өстәлне алып Шәңгәрәй каршына китереп куя.

Г а р и ф. Әйдә... шуыштырып алыйк бераз. Син миңа ачуланма. Мин бит чынлап түгел. Аптыраганнан башны җүләрлеккә салып йөрү. Никахын да укымадым мин аның. Укый да белмим. Кайчандыр гаеттә төне буе тәкбир әйтеп йөри идек Бишбалта урамында. Күптән, мин малай вакытта ук. Аллаһы әкбәр, валлаһы әкбәр, дип. Шул күңелдә калган. Мәчеткә дә вакыт үткәрә алмаганнан гына йөрим. Кеше ятса ятам, кеше торса торам дигәндәй. Уңга борылганда да тәкбир. Артыгына рәт юк. Әйе, әрәм узды минем гомер. Бар куанычым — Гәззелбанудан калган кыз. Гомер буе аның үкчәсенә басып йөрим. Ә ул минем кем икәнемне дә белми. Әйе... Хәзер инде ул да пенсия яшенә җитте. Ә барыбер әнисе төсле. Әтисенә охшаса, мин бу кадәр берекмәгән дә булыр идем бәлки аңа... Бу квартирамны да бит мин аның монда күчеп килүен белгәч алыштырдым. Аны күрсәм, аның белән сөйләшсәм, Гәззелбануым белән сөйләшкән кебек булам. Юкса, вакытлы-вакытсыз монда кереп сезне борчып йөрер идеммени мин?

Озын пауза, ишектән күз яшьләрен сөртә-сөртә Б и б и керә.

Ш ә ң г ә р ә й. Сәгать ничә?

Б и б и. Алты тула. *(Шәңгәрәй торып киенә башлый).* Кая барасың?

Ш ә ң г ә р ә й. Бакчага. Лядскойга. Парамон кордашның барасы җире бар бугай. Игезәкләрне карап торырсың дигән иде. *(Чыга башлый.)*

Пәрдә

**М. Ф. Вәлиев,**
**КПСС өлкә комитеты секретаре**

# ЯКТЫ МАЯК

*Г. Ибраһимовның 90 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә сөйләнелгән чыгыш*

Галимҗан Ибраһимов — Бөек Октябрьга хәзерлек һәм Совет дәүләте төзелү елларында яшәп иҗат иткән культура һәм фән эшлеклеләребезнең иң күренеклеләреннән берсе. Туган халкына, аның үткәне белән киләчәгенә тирән тамырлар белән береккән бөек художник һәм революционерның таланты гаять күп кырлы, тормыш юлы — якты максатлы, халык һәм революция эшенә багышланган, ә әдәби, фәнни мирасы — күләмле һәм җуелмас.

Талантлы зур язучы, күренекле галим, мәшһүр тәнкыйтьче, ялкынлы революционер, олы җәмәгать эшлеклесе — Г. Ибраһимов әнә шундый сыйфатларны үзенә туплаган якты шәхес. Ул әдәбият һәм сәнгатьне, халык мәгарифе һәм милли вакытлы матбугатны үстерүгә, марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалау эшенә үзеннән лаеклы өлеш кертте.

Галимҗан Ибраһимовны олы художник һәм фикер иясе итеп Бөек Октябрь үстерде. Моңа ул марксизм-ленинизм тәгълиматын тирән үзләштереп, коммунистик якты идеаллар хакына армый-талмый көрәшеп, партиянең тугры һәм кыю көрәшчесе буларак ирешә. Галимҗан Ибраһимовның 90 еллык юбилеен тантаналы төстә билгеләп үткәндә дә, без аның таланты, әдәби һәм фәнни мирасы халыкка, коммунизм эшенә тугрылыклы хезмәт итүен һаман дәвам итә диеп, һич тә икеләнмичә, горурланып әйтә алабыз.

Ибраһимовның шәхси тормышы җиңелләрдән булмады, әмма аның гражданлык һәм иҗат язмышына сокланмый мөмкин түгел. Әдәбиятка Беренче рус революциясе тудырган демократик күтәрелеш дулкынында килеп кереп, кыска гына вакыт эчендә ул үзен хәзерге татар прозасына нигез салучыларның берсе, татар критик реализмы әдәбиятының күренекле вәкиле итеп таныта.

Г. Ибраһимов иҗатының җитлеккән, мул уңыш биргән чоры Октябрьдан соңгы социалистик төзелеш елларына туры килә. Бу иҗатның иң мөһим үзенчәлекләре дә нәкъ шул чорда тулырак ачыла төште. Үсеш юлының һәр вакыт магистраль сызыгында булу, тормышның җитди, төп мәсьәләләрен күтәреп чыгу, яңа тормыштагы уңай күренешләрне яралгы хәлендә күрә белү, иҗтимагый һәм социаль процессларны партияле, сыйнфый позициядән торып бәяләү — аларның кайберләре әнә шулар.

Ибраһимов иҗаты — үткән заман классик әдәбияты белән яңа совет әдәбиятын тоташтырып торучы җанлы күпер, ә ул үзе — татар әдәбиятында социалистик реализмга нигез салучыларның берсе һәм иң күренеклесе.

Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында туган. Унбер яшенә кадәр авыл мәдрәсәсендә укыганнан соң ул үз чорында реакцион тәртипләре һәм укытуның схоластик алымнары белән аерылып торган Оренбургтагы Вәли мулла мәдрәсәсендә белем ала. Булачак язучы искелек һәм золым атмосферасына түзеп тора алмый, хөр фикерле булуы һәм яңалык таләп итүе өчен аны мәдрәсәдән куалар.

1906 елда Галимҗан Уфага килә һәм «Галия» мәдрәсәсендә укый башлый. Әмма бу уку йорты да яшүсмернең белемгә сусавын канәгатьләндерә алмый. Тиздән ул аны

ташларга мәҗбүр... Бу елларда Ибраһимов үзлегеннән күп укый, тарих, әдәбият белән кызыксына, рус телен үзләштерә.

1909 елда ул Казанга килә. Биредә Хөсәен Ямашев, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал кебек танылган шәхесләр яши һәм эшли. Ибраһимов милли интеллигенциянең алдынгы вәкилләре белән аралаша башлый, әдәби һәм иҗтимагый-политик вакыйгалар сферасына кереп чума, атаклы язучылар, демократик карашлы яшьләр арасында үз кеше булып китә. Казанда аңа язучылык һәм журналистлык эше өчен дә чагыштырмача зур мөмкинлекләр ачыла. Ул күп яза, вакытлы матбугат битләрендә әдәбият һәм сәнгатьнең актуаль проблемаларын күтәреп чыга, социаль һәм политик мәсьәләләр буенча чыгышлар ясый.

Г. Ибраһимовның язучы буларак иҗат биографиясе 1907 елда басылып чыккан «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясеннән башланып китә. Аның беренче әсәрләрендә үк укучы кара һәм залим көчләрнең сукыр корбаны булырга теләмәүче горур кеше образы белән очраша. Авторның шәхси биографиясен хәтерләткән сюжетка корылган әлеге хикәянең герое да — шундый ук бәйсез шәхес.

Ибраһимовның алга таба язган әсәрләрендә дә без караңгы һәм ямьсез чынбарлыктан ычкынырга теләүче геройларга юлыгабыз. Яшь әдип тормыштан чын гүзәллек эзли, аны бәйсез, ирекле һәм олы характерлар, гадәттән тыш вакыйгалар мавыктыра. Әмма Октябрьга кадәрге чорда бу эзләнүләрнең уңай хәл ителүе өчен шартлар булмый әле. Ибраһимов кешедәге гүзәл сыйфатларның тантана итүен, җирдә азатлык, бәхет һәм мәхәббәтнең җиңүен сурәтләргә омтыла, ләкин боларның берсен дә патша Россиясе чынбарлыгыннан таба алмый. Шуңа күрә язучы үз идеалын, гүзәллеккә булган карашларын һәм хыялларын романтик образларда чагылдыра. Аның геройлары тирәлек белән кискен конфликтка керәләр, буржуаз чынбарлык белән килешеп яшәүчеләрне гаепләп чыгалар, аларга ачы нәфрәт белдерәләр, шәхси азатлыкка, бәйсезлеккә омтылалар. Тик, кызганычка каршы, әлегә алар бу тормышны үзгәртеп коруга сәләтсез. Мәсәлән, «Диңгез» хикәясенең төп герое тормышның җансыз торгынлыгыннан риза түгел, ул ниндидер илаһи, аныксыз гүзәллеккә омтыла. Аның өчен чын бәхет мизгеле — диңгездәге дәһшәтле давыл белән көрәш. Әмма давыл тына, ә максатын җуйган герой, соңгы шатлыгыннан мәхрүм калып, өметсезлеккә бирелә. Язучы һәм аның геройлары шул рәвешчә, бер яктан, буржуаз чынбарлыкка ризасызлык, социаль изү һәм хаксызлыкка протест белдерсә, икенче яктан, алар әлегә көрәшнең реаль юлларын һәм чараларын белмиләр иде.

1912 ел азагында Ибраһимов Казаннан Киевка китә. Язучының истәлекләренә караганда, ул анда мөселман студентлар белән конспиратив элемтә урнаштырырга җыенган. Чыннан да, аның тырышлыгы белән кыска вакыт эчендә яшерен студентлар группасы оеша. Һәм бу хәл охранканы сагаерга мәҗбүр итә. Тиздән полиция язучыны һәм аның актив көрәштәшләрен кулга ала һәм төрмәгә яба. Әле төрмәдән чыккач та Ибраһимов 1917 елгы Февраль революциясенә кадәр полиция күзәтүе астында тора. Әлбәттә, язучының идея-политик үсешенә Киев вакыйгалары зур йогынты ясаганнар. «Андагы эшләр, утырып чыгу минем өчен бер мәктәп булды. Дөресен әйткәндә, файдалы мәктәп. Күзем ачыла төште. Күп нәрсәне һәм кешеләрне дөресрәк күрә, дөресрәк таный башладым», — дип яза ул.

Социаль тәҗрибә туплау Ибраһимовның әдәби иҗатына да тәэсир итә. Ул торган саен проблемаларны кыюрак куя, аның әсәрләрендә реализм элементлары көчәя төшә, язучының демократик идеаллары ачыграк күренә башлый. Әсәрләренең төп герое итеп тә ул гади хезмәт кешеләрен ала. Геройларының көндәлек тормышын, кайгы-шатлыгын, моңын-зарын, өмет-хыялын Ибраһимов яратып һәм тәфсилләп тасвирлый. Шул ук вакытта ул чордагы татар хезмәт ияләренә хас караңгылык, томаналык, күндәмлек кебек күренешләргә дә күз йомып кала алмый язучы. Ләкин ул хезмәт ияләре ярлы рухи тормыш белән яши дип күрсәтергә теләми, киресенчә, хезмәт ияләренең эчке матурлыкка, якты һәм көчле хискә ия булуларын исбатлый. Язучының «Көтүчеләр», «Карт ялчы», «Табигать балалары» кебек хикәяләре — нәкъ менә шундый әсәрләр.

Илдә башланган революцион күтәрелеш гөрелтесенә Ибраһимов актив иҗади эшчәнлек белән җавап бирә. Билгеле булганча, бу күтәрелеш кара реакция чорында тоткарланып торды. Ул елларда халыкның революцион катламына каршы рәхимсез

репрессияләр башлана, прогрессив газета һәм журналлар ябыла, политик көрәшнең легаль формалары юкка чыгарыла. Мондый шартларда Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсенә укыту эшенә кайтырга мәҗбүр. Туплаган тәҗрибә һәм белемнәрен ул яшь буында югары гражданлык сыйфатлары һәм алдынгы идея карашлары тәрбияләүдә файдаланырга ниятли. Анарда белем алган яшьләрнең күпчелеге революциядән соң совет мәктәбе укытучылары, журналист, язучы булып киттеләр, шактый өлеше партия сафларына керде.

«Галия» мәдрәсәсендә укыту дәверендә Ибраһимов татар филологиясенә караган күп кенә фәнни-теоретик һәм методик хезмәтләр яза. Гомумән, революциягә чаклы ук инде ул милли әдәбияттагы революцион-демократик юнәлешнең иң танылган вәкилләреннән санала. Аның әдәби әсәрләре, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә караган күп санлы мәкаләләре татар әдәбияты формалашуына, милли әдәби тел һәм эстетик фикер үсешенә, хезмәт ияләрен революцион рухта тәрбияләү эшенә зур өлеш керттеләр.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң Г. Ибраһимов, танылган әдәбиятчы һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, тулысы белән революцион көрәш эшенә кереп чума. Ул Мәскәү һәм Казанда үткәрелгән мөселман съездларында катнаша, Фатих Сәйфи-Казанлы белән берлектә «Ирек» газетасы чыгара башлый. Бу вакытлы матбугат органы битләрендә марксистик лозунглар таратыла, мөселман буржуазиясе һәм руханиларның сатлык политикасы фаш ителә. Газета сугышны туктатырга чакыра, аның империалистик характерда булуын һәм халыкка каршы юнәлдерелгәнлеген кискен гаепли. Бу чорда ул революция идеяләрен пропагандалауда эшчеләр җыелышы, солдат митинглары, укучы яшьләр аудиторияләреннән дә оста файдалана.

Шулай итеп, февраль белән октябрь арасында язучы җитди политик көрәш мәктәбе уза. Октябрьның хәлиткеч көннәрендә дә ул баш күтәргән халык ягында була, зал һәм мәйданнарда «Бөтен власть Советларга!» дигән өндәмәне яклап чыгыш ясый. 1918 елның гыйнварында әдип, Учредительное собрание делегаты буларак, Петроградка килә. Сул канатка ияреп, большевиклар белән берлектә, ул Учредилканы ташлап чыга, «чөнки ул гасырларча алпавытлар, капиталистлар тарафыннан таланып, җәберләнеп килгән ярлы халыкның икътисади коллыктан азат ителү юлындагы теләгенә каршы барды»,— дип яза әдип үзенең сайлаучылары алдында хисап урынына язган мәкаләсендә. Ибраһимов тулысы белән Совет властен яклаучылар позициясенә баса. Советларның III Бөтенроссия съезды аны ВЦИК члены итеп сайлый. Мулланур Вахитов белән бергә, аның ярдәмчесе буларак, ул Халык Комиссарлары Советы янында Үзәк мөселман комиссариаты эшчәнлеге белән җитәкчелек итә башлый, комиссариат органы «Чулпан» газетасының редакторы була. Анда Г. Ибраһимов тәрҗемәсендә Совет властеның беренче декретлары һәм эшче-крестьян хөкүмәтенең карарлары татар телендә басылып чыга.

Октябрь революциясеннән соңгы беренче айларда рәсми рәвештә әле һаман да сул эсерлар партиясе члены булып кала бирсә дә, ул барлык принципиаль мәсьәләләр буенча практик эшчәнлегендә һәм политик карашларында тулысы белән большевиклар партиясе программасыннан чыгып эш йөртә. В. И. Ленинның чыгышлары аңа аеруча көчле тәэсир итәләр. Сул эсерлар совет оешмаларында эшләүдән баш тартып, турыдан-туры фетнә һәм саботаж оештыру юлына басу белән, Ибраһимов, бер дә икеләнмичә, бу партия белән барча элемтәләрен өзеп, үз постында эшләвен дәвам итә. Бу көннәрдә язучыны В. И. Ленин кабул итә. Ул аңа үзенең планнарын, уйлануларын сөйли. В. И. Ленин аны игътибар белән тыңлый һәм «Эшләгез!» ди. Бөек юлбашчының мондый игътибары һәм ышанычы Ибраһимовны тирән дулкынландыра, канатландырып җибәрә.

Ленин эшенә бирелгәнлек, социалистик революциянең хаклыгына нык ышаныч язучыны коммунистлар партиясе сафларына алып килә. 1920 елда ул РКП(б) члены итеп кабул ителә, ә партия стажы 1917 елның 15 апреленнән раслана.

1918 ел азагында Галимҗан Ибраһимов Казанга кайта. Ул вакытлы матбугатта актив катнаша, күп санлы публицистик мәкаләләр бастырып чыгара. 1919 елда, Колчак гаскәрләре һөҗүм иткән катлаулы чорда, ул махсус задание белән дошман тылына китә һәм безнең командованиегә кыйммәтле мәгълүматлар хәбәр итеп тора. Татарстан республика советларының беренче учредительный съездын хәзерләү һәм

үткәрүдә дә ул зур активлык күрсәтә. ТатЦИК һәм Татарстан өлкә комитеты члены буларак, Г. Ибраһимов партия һәм совет органнары эшендә культура һәм мәгариф өлкәсенә караган төрле чаралар үткәрүгә күп көч куя. Татарстан автономияле республикасы төзелүнең беренче көннәреннән үк ул коммунистлар партиясенең милли политикасын һәм культура революциясенең ленинчыл программасын тормышка ашыру өчен армый-талмый көрәшә башлый. Октябрьдан соң Ибраһимов чын-чынлап зур җәмәгать эшлеклесе һәм олы язучы булып өлгерә, аңа яңа канатлар үскәндәй була, ул бертуктаусыз эшли, яза, яңа чорның күп санлы иҗтимагый-политик, әдәбият, фән һәм мәгариф ихтыяҗларына җавап бирергә тырыша. Хәлиткеч идея — теоретик мәсьәләләрдә дөньяга марксистик-ленинчыл карашны принципиаль төстә яклаучы революционер-коммунистка әверелә Г. Ибраһимов.

Революция аның әдәби иҗатына да зур этәргеч ясый. «Мин үземнең иҗат көчләремнең иркен үсеп китә алулары тик Бөек Октябрь революциясе аркасында гына мөмкин булды дип табам», — дип яза ул соңыннан. Чыннан да, Октябрь эпохасы художникка җанлы геройлар һәм зур вакыйгалар дөньясын ачып җибәрде. Инде Ибраһимов гүзәллекне дә реаль чынбарлыктан эзли һәм таба. Ул аны яңа революцион хәрәкәттә, революция һәм социалистик төзелеш тудырган яңа кешеләр характерында күрә. Бу чорда ул аеруча илһамланып эшли һәм һәркайсы әдәбиятыбызда бер этап булырдай, күләмле әсәрләр иҗат итә. Бу әсәрләр яңа, социалистик әдәбиятның үсеш юлын билгеләделәр.

Әдәбият мәйданына яңа тарихи шартларда аяк баскан әдипләр каршында, элгәргеләрнең идея-эстетик тәҗрибәсенә таянып һәм гомум кешелек культурасы казанышларын үзләштереп, әдәбиятта хәлиткеч сыйфат сикереше ясау бурычы тора иде. Ш. Камал, Ф. Әмирхан һәм башка замандашлары белән бергә, татар әдәбиятында социалистик реализмга нигез салучыларның берсе буларак, Галимҗан Ибраһимов та бу җаваплы миссияне уңышлы үтәп чыкты. Ул һәр вакыт интернационализм байрагын югары тотып, милли чикләнгәнлеккә каршы көрәшүчеләр сафында булды. «Безгә... фәкать үз кабыгыбызга бикләнеп калырга мөмкин түгел,— дип язды ул.— Безгә гакыл вә фикеребезне гомум бәни адәм офыгына таба юнәлдерергә... татар әдәбиятыннан үтеп, бөтендөнья әдәбиятының тарихи агымнары белән дә танышырга лазим булачак».

Г. Ибраһимов рус әдәбияты казанышларына да еш таяна. Аның иҗатына бигрәк тә Белинский, Тургенев, Толстой әсәрләре уңай йогынты ясыйлар. Яңа, социалистик әдәбиятны башлап җибәрүче әдипләрнең берсе — А. М. Горький иҗатын ул аеруча кызыксынып өйрәнә. 1920 елда басылып чыккан «Безнең көннәр» романын Г. Ибраһимов бөек пролетар язучысы йогынтысында язды дип әйтергә була. Бу әсәр татар әдәбиятында беренче тарихи-революцион роман булды һәм ул милли прозаның аннан соңгы үсешенә һәм башка төрки телле әдәбиятларда тарихи-революцион әсәрләр барлыкка килүгә көчле этәргеч ясады. Әсәрдә татар җәмгыятендәге төрле катлаулар, шул исәптән татар интеллигенциясенең 1905—07 елгы революциядә катнашуы киң эпик планда тасвирлана. Без анда шулай ук, кара реакция чоры башлангач өметләре киселгән, көрәш рухы сүнә барган затларны да очратабыз. Әмма әсәрнең үзәгендә сыгылмас җанлы, соңгы сулышларына кадәр гомерләрен азатлык һәм революция эшенә багышлаган чын каһарманнар тора.

Г. Ибраһимов заман пульсын нечкә тоючы һәм шул чынбарлыкны типик һәм тулы канлы образларда гәүдәләндерүче художник була. Бу сыйфатлар бигрәк тә социалистик революция темасына багышланган «Яңа кешеләр» пьесасында ачык чагылыш таптылар. Пьесаның башыннан азагына чаклы калку гәүдәләнгән төп идея — аяусыз сыйнфый көрәш шартларында үзен яңа социалистик әхлак буларак раслаган революцион гуманизм. Пьеса үзәгендә — халык массаларының тирән катлауларын биләп алган, пролетариат эшенә бирелгәнлек һәм тугрылык саклаучы яңа кешеләрнең көрәш эпопеясы.

Иҗатында Г. Ибраһимов беркайчан да тар милли рамкалар белән генә чикләнеп калмый, еш кына ул илебезнең башка халыклары тормышы һәм язмышына да мөрәҗәгать итә. Интернационализм пафосы белән сугарылган бу үзенчәлек аеруча «Казакъ кызы» романында тулы чагылды. Тугандаш казакъ халкы тормышыннан алып язылган бу әсәр татар прозасының гына түгел, ә 20 нче еллардагы күп милләтле совет әдәбиятының да иң олы казанышларыннан берсе иде.

Г. Ибраһимовның новаторлык рухы белән сугарылган һәм үзенә чорның идея-эстетик, политик тәҗрибәсен туплаган мәшһүр «Тирән тамырлар» романы — татар әдәбиятында этап булырдай зур әсәр. Язучы монда социалистик революциянең иң хәлиткеч этапларыннан берсенә тукталып, яңалык белән искелекнең кискен бәрелеше нәтиҗәсендә туган драматик вакыйгалар панорамасын тудыра, авылда барган катлаулы сыйнфый көрәшнең кискенлеге хакында сөйли. Күз алдына намуслы, куркку белмәс Фәхри һәм аны яклаучыларның җанлы образлары килеп баса. Романда зур художникларга гына хас осталык белән халык массаларының тормышы сурәтләнә, иске тормыш гадәтләренең җимерелүе, кан һәм көрәш, чиксез кыенлыклар, авыр корбаннар, югалтулар аша яңа җәмгыять, яңа кеше формалашуы күрсәтелә. Әсәрнең югары партиялелеге һәм новаторлыгы да шунда. Гомумән, «Тирән тамырлар» романы милли әдәбиятыбызда социалистик реализм методын формалаштыруда әйтеп бетергесез зур роль уйнады.

Татар совет әдәбиятының авангардында баручы язучы буларак, Галимҗан Ибраһимов әдәбиятта реалистик тенденцияләрне яклады һәм иҗади хезмәт матурлыгына дан җырлады, кешеләрне сыгылмас җанлы, революция һәм социализм эшенә бирелгәнлек үрнәгендә тәрбияләде. Язучының совет чорында иҗат иткәне — татар совет әдәбиятының чын җитлегү чорына керүен күрсәтүче якты үрнәк.

Г. Ибраһимов күренекле каләм иясе, сүз остасы, танылган җәмәгать эшлеклесе генә түгел, бер үк вакытта ул филология һәм тарих фәннәренә зур өлеш керткән олы галим дә. Октябрьга чаклы язган әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә үк ул татар революцион-демократик әдәбияты үсешенә көчле йогынты ясаган идея-эстетик проблемалар күтәреп чыкты. Совет чорында исә Ибраһимов яңа әдәбиятның теоретик проблемаларын тирәнтен өйрәнүгә аеруча зур өлеш кертте. Әдипнең буржуаз милләтчеләргә каршы көрәше, социалистик идеологияне, әдәбият һәм сәнгатьтә марксистик-ленинчыл принципларны яклавы милли культурабыз язмышына, аның социалистик реализм юлыннан үсүенә зур йогынты ясады.

1925 елда Татарстан хөкүмәте карары белән ул республикада булган барча фәнни һәм культура-агарту эшенә җитәкчелек итәчәк Академик үзәкнең председателе итеп расланды.

Академик үзәкнең җитәкчесе буларак, Г. Ибраһимов республиканың фәнни көчләрен туплауда һәм хәзерләүдә актив катнаша, аларны татар халкының культура, сәнгать, тарих, этнографиясенә караган актуаль проблемаларны өйрәнү һәм чишүгә мобилизацияли.

Аның «Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы», «Шәрыкның бөек революционеры Мулланур Вахитов» кебек тарихи-публицистик хезмәтләре, «Татарлар 1905 елгы революциядә», «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре», «Урал» һәм уралчылар» кебек монографияләре һәм күп санлы мәкаләләре Татарстанда иҗтимагый фикер һәм революцион хәрәкәт тарихын өйрәнүгә нигез салдылар. Татарларда иҗтимагый фикер һәм революцион хәрәкәт тарихын марксистик-ленинчыл нигездә өйрәнүнең беренче карлыгачлары буларак, бу хезмәтләр әле дә үзләренең әһәмиятен югалтмыйлар.

Галимҗан Ибраһимов инициативасы белән 20 нче елларда республикада марксизм-ленинизмны татар телендә пропагандалау, фәнни социализмга караган хезмәтләр бастыру эше җәйгә салына. Ул В. И. Ленинның хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итү эшен дә үзе башлап җибәрде һәм шул эшне башкару өчен Татарстанның партия өлкә комитеты тарафыннан төзелгән махсус комиссиянең җитәкчесе булды.

Әдәбият галиме буларак та Галимҗан Ибраһимов бай мирас калдырды. «Пролетариат һәм социалистик төзелеш шартларында татар культурасының язмышы», «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» кебек китапларында һәм мәкаләләрендә Ибраһимов культура мирасына мөнәсәбәт мәсьәләләрен күтәреп, Октябрьдан соңгы чор әдәбият үсеше һәм аның үзенчәлекләре проблемасын яктыртты. Ул социалистик реализмның нигезендә ятучы сыйнфыйлык, партиялелек һәм халыкчанлык принципларына караган мәсьәләләрне өйрәнеп, әдәбиятның милли спецификасы — миллилек һәм интернациональлекнең бердәмлеге — турында тирән фикерләр язып чыкты, традиция һәм новаторлык, язучының дөньяга карашы һәм аның иҗат процессына ясаган йогынтысы кебек эстетик категорияләргә тирән анализ һәм аңлатма бирде.

Галимҗан Ибраһимов — тел һәм әдәбият укыту методикасына кагылышлы капиталь хезмәтләр авторы. Татарстан АССР төзелүенең марксистик концепциясен булдыруда, бу мәсьәләдә буржуаз милләтчеләр һәм эсер-меньшевикларның ялгыш трактовкасын фаш итүдә шулай ук Галимҗан Ибраһимовның роле зур булды.

Татарстан дәүләт тарихын өйрәнүчеләрдән беренче булып ул милли дәүләт төзелешендә В. И. Ленинның теоретик өйрәтмәләре нинди зур әһәмияткә ия булуны күрсәтеп чыкты.

1928 елда совет җәмәгатьчелеге язучының әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегенең 20 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтте. Әдәбият, фән һәм культура өлкәсендәге олы уңышлары өчен ВЦИК аңа Хезмәт Герое исеме бирде, ул Сәнгать фәннәре академиясенең гамәлдәге члены һәм берничә фән җәмгыятенең почетлы члены итеп сайланды.

Г. Ибраһимов, каты авыру сәбәпле, гомеренең соңгы ун елын Кырымда уздырырга, дәваланырга мәҗбүр булды. Ләкин бу елларда да ул актив эшчәнлеген ташламый, һаман яза. Аның күңеле һаман көр, ул татар җәмәгатьчелеге белән тыгыз элемтәдә тора. Язучы янына әледән-әле каләмдәш дуслары килеп тора. Ул күптән башланган әсәрләрен тәмамлау өстендә эшли, элек язылган кайбер хикәя һәм повестьларын яңадан карап чыга, эшкәртә. «Безнең көннәр» романының I томын яңадан редакцияләп чыга, II һәм III томнарын тегәлләү өстендә эшли. Бу эш аннан гаять күп көч сарыф итүне сорый... Әмма 1938 елның 21 январенда аның йөрәге тибүеннән туктый.

Безнең социаль һәм рухи тормышыбызда шактый зур үзгәрешләр булып тора. Ибраһимов яшәгән заманнан да безне шактый еллар аера. Еллар гына да түгел, материаль, социаль һәм рухи тормышта барлыкка килгән олы үзгәрешләр аерып торалар. Алар тирән һәм күп төрле. Инде яңа буын үсеп җитте, күп санлы яңа иҗтимагый, психологик, эстетик проблемалар туды, яңа, яшь сүз осталары үсеп җитеп әдәбиятка килде. Культура-сәнгать хәзинәсен кабул итүебез дә үзгәрешсез калмады, әлбәттә. Ләкин Ибраһимов, эре масштаблы художник буларак, вакыт чикләрен җәя төшә. Ул калдырган мирас бүген дә республикабызның иҗтимагый һәм әдәби тормышында яши һәм катнаша. Чөнки бөек художник буларак, ул заман сулышын сизгер тоючы гына түгел, һәр вакыт киләчәккә дә күз төбәүче, киң масштаблы итеп фикер йөртә белүче, иҗатында үзе яшәгән чорның иң кирәкле, иң мөһим проблемаларын куя белүче иде. Шул күзлектән караганда, Ибраһимов чын-чыннан халык язучысы, массаларның уй-фикерен әйтеп бирә белүче интернационалист иде. Галимҗан Ибраһимов татар әдәбиятында гына түгел, күп милләтле совет әдәбиятында да шулай ук тирән эз калдырган, танылган әдип.

Республикабыз хезмәт ияләре бөек язучының якты истәлеген олы хөрмәт белән искә алалар. Галимҗан Ибраһимов исемен Казанда яңа, киң проспектларның берсе, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы тел, әдәбият һәм тарих институты йөртә. Аның әсәрләре күп тираж белән татар һәм СССР халыклары телләрендә кабат-кабат басылып киләләр. Ниһаять, әдип әсәрләренең 8 томлыгы басылып чыгуы да культурабыз тормышында истә калырлык вакыйга булачак.

Г. Ибраһимов кызыклы, эчтәлекле, революцион яну белән балкыган данлы тормыш юлын үтте. Революцион идеяләр белән канатланучы, өзлексез үсештә булган, тормышны тирән мәгънә белән баетучы, якты киләчәккә якты өмет уятучы художник иде ул.

Без Галимҗан Ибраһимовның 90 еллык юбилеен илебез тормышын тамырыннан алып үзгәрткән, бөтен дөнья күләмендә искиткеч зур әһәмияткә ия булган Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгында билгеләп үтәбез. Бөек Октябрь үткәндә изелгән һәм кыерсытылган халыкларга чын азатлык китерде, экономиканың моңарчы күрелмәгән югары темплар белән үсүенә, культура һәм фәннең гөрләп чәчәк атуына чиксез мөмкинлекләр бирде. Туган җиребез Татарстан шуның җанлы шаһиты һәм мисалы булып тора.

Галимҗан Ибраһимов искиткеч тугрылык, фидакарьлек, хак эшебезгә тирән ышаныч белән эшләгән, көрәшкән, иҗат иткән, шул юлда җитди югалтуларга барган һәм безнең йөрәкләрдә якты маякларны, Алып батырларны хәтерләткән ленинчыл большевиклар гвардиясенең данлы плеядасы вәкиле иде. Шуңа күрә аның исеме һәм олы мирасы — үлемсез һәм мәңгелек.

**Рафаэль Мостафин**

# ФӘН-ТЕХНИКА РЕВОЛЮЦИЯСЕ ҺӘМ МИЛЛИ ӘДӘБИЯТЛАРНЫҢ ҮСЕШЕ

*Узган елның сентябрь-октябрь айларында Үзбәкстан ССРның башкаласы Ташкентта Азия һәм Африка илләренең яшь язучылары очрашты. Анда Африка һәм Азия әдәбиятлары үсешенең актуаль проблемалары күтәрелде, иҗтимагый әһәмияткә ия булган мөһим мәсьәләләр тикшерелде. Очрашуда катнашучылар кабул иткән «Мөрәҗәгать»тә болай диелә: «Без милли азатлык һәм бәйсезлек өчен көрәшнең, халыкара киеренкелеккә һәм ашкынып кораллануга каршы көрәшнең бер-берләреннән аерылгысыз икәнлегенә ышанабыз. Кеше рухының бөеклеген, кеше акылының көчен раслаучы прогрессив әдәбиятның урыны — шушы көрәшнең алгы сафында».*

*Әлеге очрашуда дөньяның 67 иленнән килгән яшь әдипләр катнашты. Совет делегациясе составында Ташкентка бездән тәнкыйтче һәм публицист, Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты Рафаэль Мостафин барды. Анда ул «Фән-техника революциясе һәм милли әдәбиятларның үсеше» дигән темага чыгыш ясады. Түбәндә без укучылар игътибарына шуны тәкъдим итәбез.*

Атаклы фантаст Герберт Уэллс егерменче гасырда зәгыйфь һәм артта калган телләрнең күбесе көнкүрештән я бөтенләй төшеп калачак, я киң таралган, дөньякүләм телләр тарафыннан кысрыклап чыгарылачак, йотылачак дигән иде.

Аннан бирле җитмеш елдан артык вакыт узды, әмма Уэллсның күрәзәлеге тормышка ашмады. Алай гына да түгел, егерменче гасыр тарихка милли-азатлык хәрәкәте моңарчы күрелмәгәнчә колач җәйгән дәвер, дөнья аренасына яңа халыклар — беренче нәүбәттә иң артта калган һәм үсәргә берниндн сәләтләре юк дип исәпләнгән халыклар күтәрелгән, империалистик Европаның акыллы башлары хәтта уйларына да китермәгән өр-яңа телләр, өр-яңа милли культуралар күтәрелеп чыккан чор булып кереп калачак. Җәмгыятьнең җитештерү көчләрендә генә түгел, миллионнарча массаларның аңнарында да кискен үзгәрешләр тудырган фән-техника революциясе чорында бу процесс аеруча зур тизлек белән бара. Соңгы берничә дистә ел эчендә генә дә элек изелгән, колониализм табаны астында газап чиккән йөзгә якын ил үзләренә политик бәйсезлек яулап алдылар. Ләкин политик бәйсезлек яулап алу белән ул илләр алдында торган барлык проблемалар, шул исәптән милли телләрне, милли әдәбият һәм сәнгатьне үстерү проблемасы автоматик рәвештә, үзеннән-үзе генә хәл ителми әле.

Милли культураларның үсешендә бүгенге көндә ике тенденция күзгә ташлана. Бер яктан, моңарчы кешелек җәмгыятенең культура тормышыннан ераграк торган халыкларның әдәбиятлары кызу темплар белән үсә, алга китә. Мисал төсендә Латин Америкасы илләрен һәм Япония әдәбиятларында проза жанрының алга китүен әй-

теп үтү дә җитә. Икенче яктан, күп кенә очракларда милли аермалыклар акрынлап югалуга таба бара.

Урбанизм процессы һәм гадәти көнкүреш тәртипләренең үзгәрүе төрле халыкларның яшәү рәвешләре арасындагы аерманы бетерүгә, кешенең ихтыяҗ-таләпләрен стандартлаштыруга китерә. Бу процесс әле яңа гына мөстәкыйльлек алган яшь Африка дәүләтләренә нихәтле кагылса, Якын һәм Урта Көнчыгыштагы борынгы культуралы, тарихы күп гасырлар белән исәпләнгән, язма әдәбиятлары булган илләргә дә шул ук дәрәҗәдә кагыла. Дөньяның хәзер телевидение, кино, радио, матбугат кебек информация чаралары үтеп кермәгән бер генә почмагы да юк. Фән-техника революциясенең кешеләргә булган йогынтысы чын мәгънәсендә массовый төс алды.

Бер яктан, төрле милләтләр һәм расалар арасындагы конфликтлар бик нык кискенләшсә, икенче яктан, тормышның патриархаль нигезләре җимерелә, үзләренә генә хас үзенчәлекле борынгы культуралар яңа культуралар белән алышына, кайбер милли телләр һәм культуралар юкка чыга.

Гади исәпләүләр буенча, җир шарындагы кешеләр ике меңгә якын телдә сөйләшә икән. Ә кайбер кешеләр бу сан өч меңнән артып китә диләр. Колониализм шартларында ул телләрнең һәм шул телләргә нигезләнгән культураларның үсеше тигез булмаган, шуның аркасында аларның күпчелеге хәзерге заман цивилизациясе дәрәҗәсенә ирешә алмый калган. Бүгенге көндә кешелекнең культура бәйләнешендә азмы-күпме дәрәҗәдә интенсив катнаша торган йөз-йөз егерме тел бар диләр. Бу исә дөньядагы барлык телләрнең нибары биш проценты дигән сүз. Галимнәрнең исбатлавынча, бөтендөнья культура хәзинәсенең уннан тугыз өлешеннән артыграгы нәкъ менә шушы биш процент телләргә туры килә. Барлык кешелек җәмгыяте сөйләшә торган телләрнең калган туксан биш проценты хәзергә кадәр әле үзенең эчке мөмкинлекләрен тулысынча ачып җиткермәгән. Ул телләрнең күпчелегенең хәтта үз язмалары да юк. Аз санлы халыкларның милли телен һәм культураларын киләчәктә нинди язмыш көтә? Егерме беренче гасыр ул халыкларның егерменче гасыр юк итәргә өлгермәгән тел һәм культураларын җир йөзеннән бөтенләй себереп түкмәсме?

Шушы ике тенденциянең яшәве галимнәр арасында күп санлы теорияләр һәм концепцияләр китереп чыгарган. Бердәм индустриаль җәмгыять теориясе буенча, мәсәлән, телләрнең, культураларның төрлелеге прогресс юлында бары тик киртә генә булып тора. Бу теорияне яклаучылар фикеренчә, әлеге төрлелек ни чаклы тизрәк бетсә, шул чаклы яхшырак булачак. Ә икенче яктан, империалистик реакция өченче дөнья илләрендә шовинизм һәм реакцион милләтчелек, дини фанатизм карашларын алга сөрә, теге яки бу җирле культураны бердәнбер, гадәттән тыш культура дип исбатламакчы була, кастачылыкны, милли артталыкны һәм чикләнгәнлекне яклап чыга. Бу теорияләргә җентекле анализ ясап тормастан, аларга каршы мин Октябрь революциясеннән соңгы ярты гасырдан артык вакыт эчендә илебез халыклары узган данлы юлны мисал итеп куяр идем.

Билгеле булганча, патша Россиясе дистәләрчә милләтләрнең культураларын кысып-буып торды, ул чын мәгънәсендә «халыклар төрмәсе» иде. Статистика мәгълүматларына караганда, Октябрь революциясе алдыннан Россия империясенең милли өлкәләрендә яшәгән 25 миллион халык хәтта капиталистик үсеш чорын да узмаган була. Ә төньяк халыкларның күпчелеге ул вакытта патриархаль-ыруглык строе шартларында яшәгән.

Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк Коммунистлар партиясе үткәннең авыр мирасын — милли окраиналардагы хезмәт ияләренең грамотасызлыгын, культура ягыннан артталыгын бетерү өчен көрәш башлады. Аларны үз телләрендә укыту өчен милли мәктәпләр ачылды, күп санлы дәреслекләр бастырып чыгарылды, газета-журналлар чыга башлады, театрлар, клублар, китапханәләр оештырылды. Илебезнең элек артта калган һәм изелгән дистәләрчә халыклары совет власте елларында үз язуларын булдырдылар. Революциягә чаклы ук язулары һәм әдәбиятлары булган телләр, урта һәм югары белемгә, чорыбызның зур казанышлары югарылыгында культурага ия телләргә әверелеп, үзләренең функцияләрен тагын да киңәйтә төштеләр.

Совет Социалистик Республикалар Союзының ярты гасырдан артык чорны үз эченә алган тарихы — илебездә яшәүче барлык милләтләрнең һәм халыкларның экономик һәм политик күтәрелеше, культураларының чәчәк атуы тарихы ул. Дөнья күләмендә, беренче тапкыр буларак, Советлар Союзы тәҗрибәсе төрле милләтләр һәм халыкларның интернациональ интереслары аларның милли интереслары белән диалектик бәйләнештә булуын ачык раслады. Тагын шуны басым ясап әйтеп үтәргә кирәк, яңа социалистик культураны үстерүдә бай культура тарихы булган, алга киткән милләтләр генә түгел, аз санлы һәм элек культура дәрәҗәләре түбән булган милләтләр һәм халыклар да катнашты һәм катнаша.

Берничә дистә ел вакыт эчендә илебездәге милли культуралар бер-берләрен куып җиттеләр. Мисал өчен нибары берничә мең кешедән торган нивх халкын алыйк. Нивх әдибе Владимир Санги әсәрләре җитлеккән реалистик әдәбият алдына куела торган иң җитди таләпләр югарылыгында язылган. Алай гына да түгел, Владимир Санги совет әдәбиятын дөньяны үзенчә күзаллый белүе, милли фольклорның кабатланмас буяулары, үз халкының тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, традицияләре, легендалары, риваятьләре белән баетты. Манси язучысы Юван Шесталов әсәрләре турында да шул ук сүзләрне кабатларга була. Төньяк халыкларына икенче бер шартларда сәнгатьнең иң примитив формаларыннан бүгенге әдәбиятның роман, драма, поэма кебек катлаулы жанрларына чаклы булган араны үтү өчен йөзләрчә ел вакыт кирәк булыр иде. Аз санлы халыклар әдәбиятының күрелмәгән темплар белән үсеше илебез халыкларының туганнарча дуслыгы һәм үзара ярдәмләшүе нәтиҗәсендә генә мөмкин булды. Ләкин социалистик принципларга нигезләнгән яңа культураның үсеш процессына илебездәге барлык халыклар да берьюлы килеп кушылмады.

Революциягә кадәр Россиядә әдәби китаплар унөч телдә басылып килә. Совет язучыларының 1934 елда булып узган Беренче бөтенсоюз съездында «безнең барлык республикаларның төрле кабиләләрне, төрле телләрне эченә алган әдәбияты» беренче тапкыр «бербөтен әдәбият» буларак чыгыш ясый. Анда 52 тугандаш халыкның вәкиле катнаша. Ә СССР язучыларының 1976 елның июнь аенда уздырылган алтынчы съездында безнең илдә әдәби әсәрләрнең 75 телдә иҗат ителүе билгеләп үтелде. Монда сүз аларга үсү өчен мөмкинчелекләрнең тигез булуы турында бара. Ленинчыл милли политиканың асылын күренекле латыш шагыйре Ян Судрабкалн бик образлы төстә болай дип аңлатты: «Халыклар агачында бер генә ботак та корырга тиеш түгел».

Дөрестән дә, безнең галимнәр юкка чыгып, бетеп бара торган үсемлекләрне, хайваннарны саклап калу турында өзлексез кайгырталар. Аларны махсус «Кызыл китап»ка теркиләр, планетабыз ярлыланмасын өчен, кулларыннан килгән барлык чараларны күрәләр. Ә бит милли телләр, төрле халыкларның һәм кабиләләрнең авыз иҗатлары, этнография байлыклары, аларның сынлы сәнгатьләренең үзенчәлекләре, миф һәм легендалары да бөтен кешелек культура хәзинәсенең аерылгысыз бер өлеше. Әйтик, негр җырларының ритмнары хәзерге заман музыкасында аерым бер агымга нигез салды. Янсә аз санлы авар халкының мең еллык зирәклеге, образлы фикерләве Рәсүл Гамзатовның олы поэзиясенә юл ачкан шикелле үк, һәр халыкның, бүгенгә әле хәтта бөтенләй билгеле булмаган халыкның да, бөтен кешелек культурасын баетырга сәләтле нинди дә булса эчке мөмкинлекләре була.

Югарыда телгә алып үтелгән тенденцияләр арасындагы каршылык бары тик социализм шартларында гына бетерелде. Безнең илебездә һәр халык үзенә тулы ирек, үз телен, культурасын, үзенчәлекле сәнгатен үстерергә мөмкинлек алды. Ләкин бу үсеш башка халыкларның культураларын санга сукмау, ихтирам итмәү рухында түгел, ә бәлки үзара тыгыз бәйләнештә, бер-берләренә уңай йогынты ясау, бер-берләрен баету рухында барды. Шундый үсеш нәтиҗәсендә үзенчәлекле күп милләтле бердәм совет әдәбияты барлыкка килде.

Совет әдәбияты, әйтик, француз яки инглиз әдәбиятыннан аермалы буларак, бер генә конкрет милләт белән бәйләнгән әдәбият түгел. Шуның белән бергә, совет әдәбияты аерым әдәбиятларның гади җыелмасы гына да түгел. Ул эчке бер идея — эстетик бердәмлеккә ия. Ә бу бердәмлек СССРда яшәүче барлык халыкларның иҗатларындагы милли үзенчәлекләрне үз эченә ала. Бердәмлек һәм күптөрлелек — совет әдәбиятын башка барлык әдәбиятлардан аерып торган төп сыйфат. Шул күз-

пектән чыгып караганда, күп милләтле совет әдәбияты дөнья культурасында моңарчы тиңе булмаган күренеш дип саналырга лаек.

Илебез әдәбиятлары арасындагы үзара бәйләнеш елдан-ел үсә һәм киңәя, аларның социалистик бердәмлеге ныгыганнан-ныгый бара. Ләкин бу хәл әдәбиятларның берсендә дә милли үзгәлекләрне чагылдырырга комачауламый. Күренекле татар совет шагыйре Сибгат Хәкимнең «Шүрәле» дигән шигыре бар. Шагыйрь анда нәкъ менә шушы хакта уйлана. Татар композиторы Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балеты илебезнең һәм чит илләрнең бик күп сәхнәләрендә уйнала. Моның сере нидә? Бу әсәрдә тамашачы игътибарын үзенә нәрсә җәлеп итте соң? Автор фикеренчә, барыннан да элек, әсәрнең милли үзенчәлекле булуы, татар халкының авыз иҗатына һәм мифологиясенә таяну, бизәкләрнең кабатланмас аһәңлелеге.

**Йөрәгендә халык моңы аның,**
**Мәңге үлми торган саф моңнар:**
**Ул саф моңнар еллар һәм чорларның**
**Кайнар җаны аша саркылган.**
**Шигърияте тирән, рухы тирән,**
**Әллә инде шуңа күрәме**
**Күп яшәгән ветераннар белән**
**Бар дөньяны гизә «Шүрәле».**

Чыннан да, совет әдәбияты турында сөйләгәндә, безнең күз алдыбызга барлык милли әдәбиятларның иҗат алымнары, жанр һәм стилистик үзенчәлекләре төрле булган күп санлы вәкилләре килеп баса. Россия турында, Советлар Союзы халкы турында сүз барганда да без русларны гына түгел, башка барлык халыкларны да күз алдында тотабыз. Теләсә кайсы милләт язучысының талантлы язылган нинди генә әсәрен алып карама, аның үзенчә кабатланмас булуын күрәсең. Чөнки ул әсәр шул халыкның милли җирлегендә туган, аның тормышының үзенә генә хас булган үзенчәлекле якларын чагылдырган. Шуның белән бергә, мондый әсәрләр социалистик чынбарлыкны тагын да тулырак һәм тирәнрәк чагылдыру, совет кешесенең — замандашыбызның тулы канлы образын тудыру теләге белән иҗат ителә. Бүгенге көндә социализмның экономик һәм политик өлкәләрдә генә түгел, миллионнарча кешеләрнең аңнарында да тирән һәм ныклы тамыр җәюендә, тарихта кешеләрнең моңарчы булмаган уртаклыгы — совет халкының барлыкка килүендә төрле телләрдә иҗат ителгән, әмма рухы һәм максатлары белән бердәм булган совет әдәбиятының да роле аз түгел.

Безнең дошманнарыбыз: «Совет әдәбиятының органик бердәмлеге милли үзенчәлекләр арасындагы аерманы бетерүгә алып бара»,— дип кабатларга яраталар. Аларның бу раславы безнең илебез халыкларының үзара дуслыгын какшатуга, милләтчелекнең әле сүнеп җитмәгән утлы күмерендә кулларын җылытуга исәп тоткан чепчи ялган.

Совет әдәбияты барлык милләт әдипләренең көче белән үстерелә, шуңа күрә ул безнең уртак казанышыбыз булып санала. Бер милләтне икенчесенә каршы кую, милли тәкәбберлек, мин-минлек бер генә совет язучысы өчен дә хас түгел. Аерым алганда, мин үземнең әдәби-тәнкыйть эшчәнлегемдә милли үзенчәлек сәнгатьнең йөзен, тормышчанлыгын билгеләүче мөһим компонентларның берсе дигән караштa торам. Милли аермалык, һәр халыкның теле шикелле үк, кабатланмас характерда яши, бердәнбер була. Ә бу «бердәнберлек» — чын сәнгатьнең мәҗбүри шарты. Кайда шаблон, кайда күптән билге нәрсәләр кабатлана башлый — анда сәнгать юкка чыга.

Казакъ язучысы А. Нурпеисовның «Кан һәм тир» трилогиясенең төп темасы — революция һәм кеше. Ә бит бу темага совет әдәбиятында инде аз язылмаган. Мисалга М. Шолоховның «Тын Дон»ын һәм А. Толстойның «Михнәт чигеп йөрү» әсәрләрен китереп үтү дә җитә. Ләкин А. Нурпеисов нәкъ менә казакъ халкы вәкилләренең революциягә килгән үзенчәлекле юлын чагылдырган, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан башкаларны кабатламаган әсәрләр иҗат иткән. Үзенең бу әсәрендә ул

казакъ халкының авыз иҗатына, аның милли тарихына, мифларына, риваятьләренә таянган. Татар язучысы Фатих Хөсни дә «Җәяүле кеше сукмагы» романында шул юл белән барып уен-көлкечел, мәзәкчел, туктаусыз ил гизеп йөрүче крестьян егете Сәфәрғалинең якты һәм онытылмас образын тудырды.

Әдәбиятта тирән милли үзенчәлеккә ия булган әсәрләр тамырлары белән халыкның мең еллык тарихына барып тоташкан тел чаралары ярдәмендә иҗат ителсәләр, сынлы сәнгатьтә бу үзенчәлек буяуларның бер-берләренә туры килүендә, ә музыкада аһәңгә ярашлы һәм гармонияле фикерләүнең милли формаларында чагыла. Үз халкының әнә шундый үзенчәлекләреннән башка сәнгать чын мәгънәсендә сәнгать була алмый. Ләкин милли үзенчәлекне тышкы декоратив детальләргә генә (әйтик, үзбәк поэзиясендәге гөл һәм сандугач образларының кабатлануы, украин лирикасының романтик күтәренкелеге һәм пафосына) кайтарып калдырырга ярамый. Милли үзенчәлек — эчке, табигый органик күренеш ул. Чын художник ясалма кәләпүшләрдән башка да һәр вакыт үзенчә милли һәм кабатланмас була. Мәсәлән, Моабит төрмәсендә үзенең үлемсез шигырьләрен иҗат иткән татар шагыйре Муса Җәлилнең батырлыгы чех халкының патриот улы Юлиус Фучик, куркусыз рус генералы Дмитрий Михайлович Карбышев, фашистлар өнендә дошманнарга каршы көрәш алып барган Федор Полетаев, Василий Порик, Мехти Гусейн-заде кебек геройларның батырлыгына охшаш. Әмма шуның өстенә Муса Җәлил үзенең шигырьләрендә татар кешесе, татар шагыйре булып кала, үз халкының авыз иҗатындагы образларны һәм сурәтләү чараларын мул файдалана, татар поэзиясе классиклары Габдулла Тукай, Һади Такташ, Мәҗит Гафури кебек шагыйрьләрнең тәҗрибәсенә һәм традицияләренә таяна. Һәм менә шушы кабатланмас милли үзенчәлек аның шигырьләрен башка милләт укучылары өчен дә кызыклы итә... Ничек кенә парадоксаль булып тоелмасын, илебездәге әдәбиятларның бердәмлеге нәкъ менә милли үзенчәлекләрнең кабатланмас булырга тиешлеген көн тәртибенә тагын да кискенрәк итеп куя. Әйе, гомуми хорда югалып, күмелеп калмас өчен, үзеңнең милли йөзеңне ачык чагылдыру сорала. Башка әдәбиятлардан өйрәнү генә түгел, ә аларга үз йогынтыңны да ясар өчен, алар белән уртаклашыр нәрсәң булырга тиеш.

Күп милләтле совет әдәбияты өчен һәр вакыт үзара тыгыз бәйләнештә булу һәм ярдәмләшү хас. Безнең илебез халыклары арасында аларны бүлеп торган үтә алмаслык киртәләр юк. Һәр милли әдәбиятның уңышы барлык халыкларның уртак уңышы итеп кабул ителә. Бу уңайдан Украина ССР Фәннәр академиясе академигы Н. Шамота сүзләрен китереп үтәргә мөмкин: «Без, украиналылар, — дигән иде ул «Правда» газетасының 1972 елгы 4 август санында басылган мәкаләсендә, — үз әдәбиятыбызны яратабыз һәм аның Бөтенсоюз казанышына әверелгән уңышлары белән горурланабыз. Ләкин безгә тулы кыйммәткә ия булган рухи тормышыбызны Шолохов һәм Фединнан, Гамзатов һәм Җәлилдән, Межелайтис һәм Айтматовтан башка... күз алдына китерү бик авыр».

Әлбәттә, милли үзенчәлек үзгәрешсез кала алмый. Үзара аралашу процессында милли колорит та үзгәреш кичерә. Әмма шулай булса да милли әдәбиятның йөзе югалмый. Үзен тудырган халык белән бергә ул да яши.

Билгеле, җир шарының төрле урыннарындагы милли әдәбиятларның һәркайсы үзенчә, күп кенә очракларда ифрат катлаулы һәм каршылыклы шартларда формалаша. Ләкин бу шартлар нинди генә булмасын, безнең илебездә милли әдәбиятларның үсеш тәҗрибәсе зур игътибарга һәм җентекләп өйрәнүгә лаек.

# МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ДӘВЕРЕ ӘДӘБИЯТЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА

XIX йөз татар әдәбиятын бер бөтен итеп, иңен-буен киң рәвештә колачлап алып, җентекләп өйрәнүгә профессор Мөхәммәт ага Гайнуллин аеруча зур өлеш кертте. Бу галим эшчәнлегенең принципиаль яңалыгы нәрсәдә соң? Беренчедән, М. Гайнуллин узган гасырдан бирле теркәлә-языла килгән, ләкин төрле хезмәтләрдә, чыганакларда чәчелеп-сибелеп яткан фикерләрне һәм мәгълүматларны, тупланган тәҗрибәне, ленинчыл методология яктылыгында тәнкыйть күзлегеннән үткәреп, бергә җыеп алды, системага салды. Икенчедән, заманнар кичү, алфавитлар алышыну нәтиҗәсендә кайдадыр ерακта, гасырлар томаны артында инде тоныкланыбрак калган күп кенә язучы һәм шагыйрьләрне ул хәзерге чорга «кайтарып», аларның әсәрләрен бүгенге укучыга тәкъдим итте. Каюм Насыйри, Заһир Бигиев, Закир Һади, Шакир Мөхәммәдевләрнең калын-калын сайланма әсәрләрен җыеп чыгару аның тарафыннан башкарылды. Өченчедән, бу галим илебезнең төрле архивларында, китапханәләрнең кульъязма фондларында туктаусыз актарынып, булган мәгълүматларны тагын да киңәйтте һәм тирәнәйтте. Кыскасы, М. Гайнуллин хезмәтләре XIX йөз татар әдәбиятын өйрәнү һәм халыкка җиткерү юлында яңа баскыч булды, бөтен бер этапны тәшкил итте.

М. Гайнуллинның «XIX йөз татар әдәбияты» дигән яңа хезмәте рус телендә дөнья күрде.[1] Бу монографиянең төп яңалыклары менә нидән гыйбарәт. Беренчедән, китап татар әдәбияты тарихының зур бер чорын, әһәмиятле этабын ил киңлекләренә алып чыга, бөтен союз укучысы белән таныштыра. Бу — бик мөһим. Шуның белән бергә, галим моңа кадәр дөнья күргән хезмәтләреннән аермалы буларак, фактик материалларны барлау, теоретик гомумиләштерү юлында тагын да тирәнрәк катламнарны каера, яңа исемнәр, әсәрләрне ача һәм аларны әдәби процесска кертә.

Мисалга поэзияне алыйк. Соңгы елларда интенсив рәвештә тикшерелә башлаган әсәрләрнең берсе — патша түрәләренең халыкны коточкыч изеп, «котырган этләр» кебек талап яшәвен фаш иткән һәм татар поэзиясендә әһәмиятле демократик тенденцияне билгеләгән «Мәкәрҗә бәете». XIX гасыр урталарында бер татар авылында исеме безгә билгесез шагыйрь тарафыннан язылган бу әсәр шул елларда яшәгән рус революцион-демократларының да игътибарын җәлеп иткән. Татар тормышын якыннан өйрәнгән сәяхәтче галим, Н. А. Добролюбовның дусты П. И. Пашино «Современник» журналында (1860 ел, 81, 82 томнар) басылган «Идел буе татарлары» дигән очеркларында бу әсәр турында киң генә мәгълүмат бирә һәм аерым өзекләрен русча тәрҗемәдә китерә. Кызганычка каршы, әсәр авторының исеме, адресы күрсәтелмәгән. Күрәсең, бу — татар шагыйрен эзәрлекләүдән, «эт кебек иснәп» фетнә эзләп йөргән чиновниклардан саклау чарасы булгандыр.

«XIX йөз татар әдәбияты» китабында урын алган һәм анализланган бу әсәр М. Гайнуллин тарафыннан бөтен Россия масштабындагы азатлык хәрәкәте яктылыгында карала. «Мәкәрҗә бәете» шулай ук рус һәм татар халыклары арасында ныгый барган интернациональ бәйләнешләрнең әһәмиятле бер үрнәге буларак та кызыклы.

[1] М. Х. Гайнуллин. Татарская литература XIX века. Казань, Татарское книжное издательство, 1975 г.

М. Гайнуллин китабына кертелгән яңа исемнәр арасында Мулькай Юмачиков, Нигъмәтулла бине Бәшир, Сәгъдетдин бине Габделмәҗит кебек шагыйрьләр һәм аларның әсәрләреннән китерелгән үрнәкләр шулай ук зур кызыксыну уята.

Мәгърифәтчелек хәрәкәте тәэсирендә XIX гасыр азакларында әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлаган татар шагыйрәләреннән хәзерге җәмәгатьчелеккә нигездә бер Газизә Сәмитова гына мәгълүм иде. М. Гайнуллин исә үзенең хезмәтендә бу чор татар шагыйрәләре турында аерым бер бүлекчә ачып сөйли. Галимәтелбәнат Биктимирова, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллиналар белән дә таныштыра, әсәрләреннән өзекләр китерә. Болар барысы да XIX йөз татар поэзиясендә барган үсеш һәм үзгәрешләрне киңрәк һәм тирәнрәк күзалларга ярдәм итә.

Прозада да яңа исемнәр күрәбез. Мәсәлән, Галиәсгар Гафуров-Чыгтай һәм аның татар хатын-кызларының авыр язмышын, азатлыкка омтылышын чагылдырган «Тутам» повесте. Автор бу язучының татар мәгърифәтчелек прозасы һәм публицистикасы үсешендә мәгълүм эз калдырганлыгын билгеләп үтү белән бергә, йомшак һәм каршылыклы якларын да күрсәтә. Китапта шулай ук В. В. Радлов эшчәнлеген махсус яктыртуны да хупларга кирәк. В. В. Радлов әлегәчә атаклы тел галиме, тюрколог буларак өйрәнелә иде. М. Гайнуллин исә бу галимнең әдәби-тәрҗемәчелек эшчәнлегенә дә игътибар юнәлдерел, аның балалар өчен төзелгән «Белек» хрестоматиясенә (1872) күзәтү ясый.

Бу уңайдан шундый бер фикер туа: бәлки XIX гасырның икенче яртысында аерым бер тармак булып үсә башлаган балалар әдәбиятын инде махсус барлау, аны үзенчәлекле мөстәкыйль бер тема итеп гыйльми яктан өйрәнү вакыты да җиткәндер. К. Насыйри, Т. Яхин, Г. Фәезханов, В. В. Радлов һ. б. галим һәм язучыларның шушы өлкәдәге эшчәнлеге бу хакта аерым сүз алып барырга нигез бирә түгелме?

Монографиядә әсәр һәм китап исемнәренең, текстлардан алынган өземтәләрнең русча тәрҗемәләрен генә түгел, ә татарча оригиналларын да китерү, беренчедән, хезмәтнең фәнни төгәллек дәрәҗәсен күтәрсә (һәркем шунда ук чагыштырып карый ала), икенчедән, әлеге текстлардан татар укучысына да файдаланырга киң мөмкинлек бирә. Кайбер әсәрләрнең үз заманындагы басмаларыннан, кульъязмалардан, титул битләреннән үрнәкләр бирү, галим һәм әдипләрнең рәсемнәрен урнаштыру шулай ук хуплауга лаек.

Жанрлар мәсьәләсенә килсәк, М. Гайнуллин хезмәтендә ода жанрын махсус карау тәҗрибәсе — игътибарга лаеклы күренеш. Татар поэзиясендә борынгыдан килгән бу жанр идея-тематик һәм сәнгатьчә сурәтләү чараларының камилләшүе ягыннан XIX гасыр дәвамында зур гына үзгәрешләр кичерә. Электә күбесенчә алла һәм пәйгамбәргә, патшалар һәм төрле «изгеләргә» дән җырлаган мәдхияләрнең эчтәлеге үзгәрә бара. Г. Кандалый, Г. Чокрый, Акмулла һ. б. поэзиясендә оданың яңа иҗтимагый функцияләре формалаша, ул мәгърифәтчелек идеяләренең үтемле коралына әверелә. Алга таба бу жанр Г. Тукай һ. б. шагыйрьләр иҗатында үстерелә.

Безгә калса инде мәгърифәтчелек әдәбиятының жанр байлыгын бер бөтен система итеп күз алдына китерергә дә вакыт җитте булса кирәк. Мәсәлән, төрле җыентыкларда һәм хрестоматияләрдә басылган мәсәлләрне шулай ук аерым алып карарга мөмкин булыр иде. Яисә сәяхәтнамәләр. XIX гасыр иҗтимагый тормышында барган зур тарихи үзгәрешләр, мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашу, дини-феодаль идеологиядән — дөньяви-прогрессив идеологиягә, феодаль Көнчыгышны идеаллаштырудан — мәгърифәтле Россиягә, Европага таба борылыш процессы сәяхәтнамәләр жанрында да бик ачык күренә.

Бу тенденция З. Бигиевнең феодаль Урта Азиядәге иҗтимагый тәртипләр, укуукыту системасындагы схоластика һәм наданлыкны кискен тәнкыйть иткән «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәрендә кочәеп китә. «Европа сәяхәтнамәсе», «Кырымга сәяхәт» китапларында Ф. Кәрими татар укучысын рус һәм Европа фәне, культурасы белән таныштыра, татар тормышын һәрьяклап үзгәртү, «европалаштыру»ны яклый.

XIX гасыр татар әдип һәм шагыйрьләре дөнья әдәбиятында киң таралган сәяхәтнамә жанрының зур эчке мөмкинлекләреннән уңышлы файдаландылар. Аларның бу жанрдагы әсәрләрендә төп өч элемент: хикәяләү, тасвир һәм тарихи-географик мәгълүматлар бирү, публицистик фикер йөртү бергә үрелә. Бу яктан караганда сәяхәтнамәләр мәгърифәтче язучылар

өчен аеруча кулай жанрларның берсе булды.

Безнең язучылар һәм галимнәр чит илләрдә булганда андагы тарихи шәхесләр, вакыйгалар турында да язып, аларга үзләренең мөнәсәбәтләрен белдергәннәр.

Геройларның психологиясен, уй-кичерешләрен сәнгатьчә чагылдыруда киң мөмкинлекләр биргән һәм мәгърифәтче шагыйрьләр, прозаиклар тарафыннан яратып кулланыла башлаган эпистоляр жанрны мөстәкыйль рәвештә алып тикшерү шулай ук кызыклы нәтиҗәләр бирер иде.

XIX гасыр татар әдәбиятын чорларга бүлү мәсьәләсе дә әлегә тулысынча хәл ителеп беткән дип булмый. В. И. Ленинның Россиядәге азатлык хәрәкәте этаплары турындагы тәгълиматын нигезгә алып, шуның белән бергә әдәби процесс динамикасының үзеннән чыгып, М. Гайнуллин бу әдәбиятны төп ике чорга бүлә: беренчесе — XIX гасырның 60 нчы елларына кадәр, икенчесе — 1860—1905 нче еллар. Чыннан да, әдәбият үсешендәге бу ике чор арасындагы аерма ярылып ята. Беренчесендә әле урта гасыр әдәби традицияләре белән шактый тыгыз бәйләнгән дини-этик һәм дидактик характердагы поэзия зур урын тота. Икенче этапта инде әдәбиятның халык белән бәйләнеше ныгый бара, аның тормышын тасвирлауда реалистик поэма, повесть, роман кебек жанрлар формалаша, драматургия мәйданга килә. Бу очракта тикшерелә торган әдәбият тарихын шулай төп ике зур чорга бүлеп карау, әлбәттә, урынлы. Ләкин тарихи-әдәби процессны бер бөтен итеп алганда, чама белән 1895 еллардан, Россиядә азатлык хәрәкәтенең инде өченче этабы башлангач, татар әдәбияты үсешендә дә сизелерлек яңа сыйфатлар һәм үзенчәлекләр барлыкка килүне аерым искә алмыйча мөмкин түгел. Татар сәүдә капиталының торган саен промышленностька үтеп керүе, татар пролетариатының сан һәм сыйфат ягыннан үсүе, хезмәт ияләре арасында марксистик идеяләр тарала башлау мәгърифәтчелек хәрәкәтенә дә зур йогынты ясый. Әдәбиятка мәгърифәтчеләрнең яңа буыны килә. Бу хәрәкәтнең үз эчендә төп ике тенденция— буржуаз җәдитчелек һәм демократик мәгърифәтчелек — торган саен ачыграк төсмерләнә. Бер яктан, Р. Фәхретдинов, Ф. Кәрими кебек язучылар булса, икенче яктан, иҗатларында демократик мәгърифәтчелек идеалларын алга сөргән З. Һади, Ш. Мөхәммәдев, М. Гафури, Г. Камал кебек язучылар килә.

Сәнгатьчә сурәтләү чаралары ягыннан да бу елларда алга таба зур адым ясала, яңа сыйфат үзгәрешләре күренә. К. Насыйри, М. Акъегетзадә, З. Бигиев һ. б. әсәрләрендә әле нигездә борынгы төрки тел нормалары саклана, хәзер инде киң массага аңлаешлы җанлы сөйләм теленда язу практикага кертелә бара. Элегрәк хикәяләп язу өстенлек итсә, хәзер тасвирлап язуга, художестволы детальгә, пейзаж һәм портретка игътибар көчәя. Рус әдәбиятыннан тәрҗемә итү һәм иҗади өйрәнү активлаша. Ниһаять, юмористик һәм сатирик тасвир зур үсеш ала. Татар әдәбиятында беренче сатирик повесть — «Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай» мәйданга килә.

Менә болар барысы да ике гасыр чигендәге елларны (чама белән 1895—1905) XIX йөз татар әдәбияты үсешендә (һич булмаса аның икенче этабы эчендә) яңа бер баскыч итеп карауга, аерым билгеләп үтәргә нигез бирә шикелле.

Хезмәттә ачыкланып җитмәгән кайбер төгәлсезлекләр дә очрап куя. Мәсәлән, Әбелмәних Каргалыйның үлгән елы китаптан китапка 1826 дип күрсәтелеп килелә. Ләкин укучыны аптырашта калдыра торган икенче бер дата да бар. Шагыйрь «Хаҗи Мөхәммәт бай»га дигән мәгълүм шигъри хаты текстында бу әсәрен «мең дә сикез йөз дә утыз өч» нче елның 10 июлендә язганлыгын күрсәтә. Димәк, шагыйрь әле бу вакытта яшәгән, иҗат иткән булып чыга. Бәлки әлеге дата һиҗри белән 1233 тер? «Мең дә ике йөз» сүзе китапларда «мең сикез йөз» булып ялгыш басыла башлагандыр? Ул чагында шагыйрь бу әсәрен чыннан да милади 1817—18 елларда ук язган була. Мондый төгәлсезлекләрне ачыклыйсы, һич булмаса, искәрмә бирәсе иде.

Конкрет дәлил — теләсә нинди гыйльми мәгълүматның нигезе. Хәлбуки, бер авторның хезмәтләреннән икенче авторларның хезмәтләренә күчеп йөри-йөри «аксиома»га әверелеп барган, ләкин берсендә дә конкрет дәлилләр белән беркетелмәгән бәхәсле фикерләр дә яшәп килә. Мәсәлән, М. Гайнуллинның XIX йөз татар әдәбияты турында татарча һәм русча хезмәтләрендә Салихҗан Кукляшевның «Диваны хикәяте татар» (1859) хрестоматиясендәге хикәя һәм новеллалар «русчадан һәм башка теләрдән» тәрҗемә ителгән

дип күрсәтелә. Ләкин бу фикер, конкрет нигезләнмәгәнлектән, бәхәсле булып кала. С. Кукляшев үзе исә җыентыгына язган «Сүз башы»нда хикәятләрнең «кайберләре кульязма китаплардан алынды, кайберләре минем тарафтан Көнчыгыш телләреннән тәрҗемә ителде», — дип күрсәтә.

Күп кенә хезмәтләрдә, шул исәптән М. Гайнуллинның «XIX йөз татар әдәбияты» китабында, Хөсәен Фәезхановның 1853 елдан Казан университетында адъюнкт булып эшләгәнлеге турында языла килә. Ләкин, бу мәсьәләне җентекләп өйрәнгән С. М. Михайлова үзенең хезмәтендә күрсәткәнчә, әлегә галимнең Казан университетында эшләгәнлеген раслардык бер генә документаль чыганак та табылганы юк. Х. Фәезхановның туган авылын да Сабачай дип түгел, ә халыкның үз телендә йөргәнчә, Сафаҗай дип бирү төгәлрәк тә, матуррак та булыр иде.

Кыскасы, тагын да ачыклыйсы, конкретлаштырасы, өйрәнәсе нәрсәләр дә бар әле. Биредә телгә алынган теләкләрнең һәм гомумән башка күп кенә мәсьәләләрнең һәммәсенең дә бер кеше тарафыннан һәм бер хезмәттә генә тулы хәл ителүен таләп итүе дә кыен.

Йомгаклап әйтәсе килгән төп фикер шул: беренче чиратта мөхтәрәм галим Мөхәммәт ага Гайнуллин тырышлыклары нәтиҗәсендә ирешелгән казанышлар этабыннан, тупланган бай мәгълүмат һәм тәҗрибә югарылыгыннан безнең алда инде яңа үрләр ачыла, яңадан-яңа офыклар ячтыра.

**ШӘЙХИ САДРЕТДИНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

# ҖЫРЛАГЫЗ, ДУСЛАР, ҖЫРЛАГЫЗ...

БЕР КИТАПКА ИКЕ РЕЦЕНЗИЯ

*
* *

Кеше тормышының һәрбер җитди адымы җыр белән бергә үтә. Сабый чагында аны бишек җырлары җырлап, көйләп юаталар. Бала чакта ул такмак-такмазалар әйтә. Яшь егетләр һәм кызлар уен-бию һәм мәхәббәт җырлары белән күңел ачалар. Яшьлек елларының иң матур сәхифәләреннән булган никах мәҗлесләрендә туй җырлары яңгырый...

Ләкин халык җырларының әһәмиятен кешенең тик шәхси тормышы белән генә чикләп карау дөрес булмас иде, билгеле. Чөнки җыр халыкның иҗтимагый-политик тормышында да бик зур роль уйный. Әйтик, гасыр башында активлашып киткән революцион җырлар...

Әнә шул сәбәпләр белән бәйле рәвештә халык җырлары бик күп галим һәм әдипләрнең игътибарын үзенә тарта. XIX йөзнең башыннан бүгенге көнгә кадәр халык җырларына багышланган уннарча җыентыклар, мәкалә-хезмәтләр басылып чыкты. Татар халык иҗатының җыр кадәр күп һәм киң өйрәнелгән башка жанры юк. Соңгы еллардагы нәшрият практикасы да шуны раслый. Тик 1976 елда гына да халык җырларына багышланган өч җитди китап: Р. Исхакова-Вамбаның «Народные песни казанских татар крестьянской и городской традиций» исемле хезмәте, М. Нигъмәтҗановның «Татар халык җырлары» дигән әдәби-музыкаль җыентыгы һәм, ниһаять, «Татар халык иҗаты. Кыска җырлар»[1] китабы басылды.

«Кыска җырлар» китабының тышкы күренеше үк күңелне куандыра. Ул искиткеч матур һәм пөхтә эшләнгән, төсе дә уңышлы сайланган.

Китапның беренче битендә редколлегия исеменнән бирелгән аңлатмада мондый сүзләр бар: «СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты татар халык поэтик иҗатының иң матур үрнәкләреннән тупланган 12 томлык фәнни җыелма әзерләде... Укучыларга тәкъдим ителә торган бу китап — шул томнарның беренчесе».

Халык иҗаты әсәрләреннән торган күп томлык җыелмалар чыгару — безнең көннәр совет фольклор фәненең җитди казанышларыннан берсе. Мондый җыелмалар чыгару буенча шактый бай тәҗрибә дә тупланды. Әйтик, безнең иң якын күршеләребез башкортларда «Башкорт халык иҗаты» дип исемләнгән күп томлыкның биш томы басылып чыкты. Соңгы елларда СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты, милли институтлар белән берлектә, «Эпос народов СССР» сериясендә утыз томлык чыгара башлады. Аларның да, безгә мәгълүм булганча, җиде томы инде дөнья күрде. Димәк, «Татар халык иҗаты» җыелмасын әзерләүчеләр алдында билгеле бер үрнәкләр, әйтергә мөмкин, нәшрият практикасында урнашкан принциплар булган. Җыентык әнә шул принциплардан читкә китми. Фәннилек принцибы биредә мөмкин кадәр тәгәл сакланган.

Әмма бу — мәсьәләнең тик бер генә ягы. Чөнки һәрбер халыкның фольклоры— гаять тә үзенчәлекле. Ул аерым әсәрләрдә генә түгел, тулаем жанрларда да чагыла. Әйтик, былиналар тик рус халык иҗатына гына хас; кобайырлар башкорт

[1] Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (Дүртьюллыклар). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел. Төзүчесе И. Надиров.

фольклорында гына очрый; бәетләр татар халык әдәбиятында гына киң таралган. Шулай булгач, һәрбер халыкның әсәрләрен басмага әзерләгәндә, аларның милли үзенчәлекләрен истә тоту — мәҗбүри шарт. Әнә шул яктан караганда, «Кыска җырлар» китабы нинди рәк тәэсир калдыра соң?

Китапта 5600 дән артык әсәр урнаштырылган. Әлбәттә, аз түгел бу. Ләкин җыентык татар халык иҗатының кыска җырлар хәзинәсен тулысынча иңли дип булмый, билгеле. Бу хакта китапта ачыктан-ачык әйтелгән: «фондта (сүз Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты фонды турында бара — Ф. У.) җыелган дүрт юллы җырларның гомуми саны (вариантлары белән) илле меңнән артык» (377 бит). Ягъни, китапка фондтагы бу жанрга караган материалларның уннан бер өлеше генә кертелгән. Моны ничек аңларга? Иң җитди сәбәп, күрәсең, халык иҗаты җыентыкларын бастырып чыгару мөмкинлекләренең беркадәр чикләнгән булуында. Югыйсә, институтның фольклор секторы хезмәткәрләре кыска җырлардан гына да ким дигәндә ике-өч том төзи алган булырлар иде, әлбәттә. Мондый тәҗрибә безнең фольклор фәне һәм нәшрият практикасында булмады түгел. Бу очракта без Н. Исәнбәтнең татар халык мәкальләренә багышланган фундаменталь өч томлыгын күздә тотабыз. Анда 40 мең чамасы мәкаль һәм аларның күпчелегенә махсус аңлатмалар урнаштырылган иде.

Мәкальләр һәм табышмаклар кебек үк, кыска җырлар халык иҗатының «вак жанрлары» рәтенә керә. Әлбәттә, эчтәлеге белән түгел, формасы ягыннан. Аларны аерым төркемнәргә бүлү, классификацияләү — җитди һәм катлаулы эш. Кыска җырлар — искиткеч киң гомумиләштерүләргә нигезләнәләр. Бер үк әсәрдә туган илне сагыну, фәлсәфи уйланулар, саф мәхәббәт темасы да чагылуы мөмкин. Шуңа карамастан, җыентыктагы меңнәрчә әсәрләрне аерым төркемнәргә бүлү нигездә матур эшләнгән, фәнни принциплар, безнеңчә, дөрес сайланган. «Бу китап... — дип яза төзүче И. Надиров, — тарихи-хронологик һәм тематик принциплар нигезендә төзелде һәм аңа кыска җырның борынгыдан яңага булган юлын ачыграк күзаллау һәм хәзинәне тулырак күрсәтү өчен, Октябрьга хәтле чыккан төрле җыентыклардан, иске кулъязмалардан сайлап алынган җырлар белән бергә, совет чорында басылган китаплар, кулъязма чыганаклар һәм СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында тупланган фольклор фондындагы әсәрләр дә кертелде» (375 бит). Димәк, китапның чыганаклары ярыйсы ук бай. Бирердә игътибарны җәлеп иткән тагын бер фактны әйтеп үтәргә кирәк: фольклор фонды материаллары китапның яртысыннан артыгын тәшкил итәләр икән.

Җыентык унидүрт бүлектән тора. Арада «Мәхәббәт җырлары» кебек китапның өчтән бер өлешен алып торган бүлек тә, «Егетлек, уңганлык турындагы җырлар», «Шәкерт җырлары» шикелле алты-җиде битле бүлекләр дә бар. Бу бик табигый. Чөнки, әйтик, мәхәббәт темасы — халык лирикасының магистраль темаларыннан берсе. Ә инде әле генә күрсәтелгән кечкенә бүлекләрдәге җырлар халыкта ул кадәр үк дәрәҗәдә таралыш алмаган.

Бүлекләрне урнаштыру тәртибе дә әллә ни бәхәс уятмый, табигый кабул ителә. Чыннан да, беренче бүлек, мәсәлән, «Тормыш турында уйланулар, кайгы-хәсрәт, өмет, ышаныч җырлары» дип атала. Анда тирән фәлсәфи уйланулар белән сугарылган әсәрләр, халыкның революциягә кадәрге авыр язмышы кайгы-хәсрәт, моңсагыш, бәхетсезлек образлары һәм символлары ярдәмендә гәүдәләндерелгән җырлар бирелә. Бүлекнең образлар системасы әйтеп бетергесез бай.

Өченче бүлектә, шартлы рәвештә әйткәндә, береаз «вульгаррак» яңгыраган җырлар да очрый, бу бигрәк тә зимагур образы белән бәйле әсәрләрдә сизелә. Тулаем алганда исә анда сүз туган иленнән аерылып, ерак җирләрдә интегеп йөргән кешеләр турында бара.

Китапның иң матур бүлеге — «Мәхәббәт җырлары» булса кирәк. Ул халык күңелендә гасырлар буе яшәп, чордан-чорга камилләшә килгән әсәрләрне эченә ала. Аларда саф һәм тирән мәхәббәт, сөйгән ярыңа турылыклы булу, өзелеп сагыну хисләре җырлана. Бүлекнең образлар системасы искиткеч бай, сокландыргыч матур. Сөйгән кызның сылулыгын, матурлыгын, зифа буен, нечкә билен, тулган айдай йөзен, кара күзен, кыйгач кашын сурәтләгән җырларның гына да йөзләрчә үрнәкләрен табарга мөмкин. Бүлек яшьләрнең мораль сафлыгын, тирән кичерешләрен сурәтли, фольклор эстетикасының соклангыч икәнен раслый.

Ә инде китапның гомуми төзелешенә күз салып, беренче бүлектән соңгысына кадәр күзәтеп чыксак, җитди бер закончалык ачыклана. Революциягә кадәрге җырларда, әйтелгәнчә, кайгы-хәсрәт, моңсагыш образлары өстенлек итсә, үндүртенче бүлектә тупланган совет чоры җырларында бөтенләй яңа стиль, яңача яңгыраш, социализм төзүче халыкның фидакарьлеген, батырлыгын сурәтләүче образлар системасы алгы планга чыга.

Шул рәвешчә, һәрбер бүлекнең гомуми үзенчәлеген ачыклап, аларга кыскача характеристика биреп булыр иде. Биредә исә бу хакта һәр бүлекнең үзенә генә хас сыйфатлары булуын искәртү өчен генә әйтелә. Җыентыкның эчтәлеге белән тулысынча танышуны киң катлау укучылары ихтыярына калдырып, китапның башка кайбер якларына, әйтик, аерым бүлекләрдәге әсәрләрне туплау принципларына күз салыйк. Һәр бүлекнең баш өлешендә борынгырак җырлар, аннан соң яңа заман һәм тиешле очракларда совет чоры җырлары урын алган. Бүлекләрне болай төзү үзен тулысынча аклый. Чөнки бу очракта билгеле бер темага караган җырларның үсеш үзенчәлекләрен ачыкларга, аларның теле-стиле, образлар системасы һәм гомуми яңгырашы үзгәрүен күзалларга мөмкинлек туа. Ягъни аерым темага караган җырлар билгеле бер эволюциядә бирелә.

Югарыда әйтелгәннәрдән шундый нәтиҗә ясарга мөмкин. «Кыска җырлар» җыентыгы халык иҗатының бу жанрын махсус өйрәнү өчен зур мөмкинлекләр ача. Мәсәлән, аларның образлар системасы, символикасы, җырларда киң таралган һәм халык мәкальләре белән бер дәрәҗәдә торган хикмәтле сүзләр һ. б. мәсьәләләрне өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерер иде.

Китаптагы ярдәмчел материаллар, ягъни аның фәнни аппараты турында да берике сүз әйтеп үтәргә кирәк. «Татар халкының кыска җырлары» дигән кереш сүзне халык лирикасын күп еллар буе өйрәнеп килүче, әлеге җыентыкны төзүче һәм искәрмәләр хәзерләүче галим И. Надиров язган. Автор биредә кыска җырлар турында гомуми төшенчә, аларны җыю һәм бастырып чыгару тарихы, жанрның тематик эчтәлеге һәм эстетик үзенчәлекләре кебек мәсьәләләргә тукталып үтә. Мәкалә нигездә матур тәэсир калдыра.

Әмма җыентыкның «Искәрмәләр һәм чыганаклар» бүлеге хакында алай әйтеп булмый. Әгәр ул киңрәк һәм тәфсиллерәк төзелсә, фәнни чыганак буларак китапның әһәмияте бермә-бер артыр иде.

Тулаем алганда исә җыентык, безнең карашыбызча, матур эшләнгән. Ул көндәлек матбугатта да югары бәя алып өлгерде инде. Җитди коллектив әзерләгән бу әһәмиятле җыентык халкыбыз иҗатын җыю һәм бастырып чыгару тарихында үзенә лаеклы урынны алыр дип уйларга кирәк.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

*
* *

„Татар халык иҗаты" дигән күп томлык басманың беренче томы чыгуы фольклор фәне өчен генә түгел, ә гомум культура тормышыбызда куанычлы хәл. Кыска җырлар — дүртюллыклар, ягъни **әрбагыйлар**[1] — халык тормышының энциклопедиясе ул. Кыска җырлар, мәгълүм ки, исәпсез күп вариантларда яши, аларны һәркем үзенчә, үзенең кәефенә, зәвыгына туры китереп җырлый. Җыентыкны төзүчеләрнең бурычы менә шушы җыр диңгезеннән «халык җыры» дигән төшенчәгә лаек булырлыкларын табып алудан тора да. Фольклор җыентыгын төзегәндә кул астындагы конкрет вариантлардан читләшү, «реконструкцияләнгән» вариантлар бирү бер дә ярамый. Шундый шартларда җыентыкның сыйфаты «сөзелгән» җыр материалының күләменә һәм сайлап алу принципларының дөреслегенә бәйле.

Җыентыкны төзер өчен илле меңләп җыр каралганлыгы әйтелә. Күпме бу, азмы? Бер яктан караганда, илле мең куплет — 200000 юл — хәтсез генә кебек. Әмма шунысы да билгеле: саны бер миллион чамасы булган эстон халкыннан ике йөз мең җыр (шул исәптән, шактый озыннары да) язып алынган. Безнең фольклорчыларыбыз җыр җыюга тиешле дәрәҗәдә игътибар биреп җиткермиләр,

---

[1] Дүртюллыкларның элегрәк әрбагый дип аталганлыгы җырлардан ук күренә. Шул ук китап, 171, 173 һ. б. битләр.

рәсеҗ. Моны шушы җыентыкның үзеннән үк күреп була: анда бик күп җырлар (аларның сәнгатьчә эшләнеше тиешле югарылыкта булуга карамастан) керми калганнар.

Җырларны сайлап алуда, беренче чиратта, эчтәлеккә, мәгънәлелеккә, халык тормышын чагылдыруына игътибар ителгән. Кайбер җырлар хәзерге укучы өчен үтә беркатлы булып, хәтта пародиягә охшап күренергә мөмкин. Мәсәлән:

2337. Агыйделнең аръягында
Ташкүмер шахталары;
Эх, дускаем, йөзләреңдә
Электр яктылары.

Бу җыр «электр яктыларының» тансык булган, матурлык символы булып торган чакларында чыгарылган. Һәм аны җыентыкка кертеп, бик дөрес эшләгәннәр, әлбәттә. Ләкин, икенче яктан, җыр бит ул сәнгать әсәре һәм җыентыкка нинди дә булса нәфис бизәге, сәнгатьчәлек билгеләре булганнарын гына кертергә кирәк иде. Хәлбуки, бирәдә, сирәкләп булса да, берниндй нәфислек әсәре булмаган, «пешеп җитмәгән» куплетлар да очрый.

2618. Аклы күлмәк тектерсәгез,
Кесәләр кирәк икән;
Ярны сөйсәң, үзең белән
Тиң ярлар кирәк икән.
3316. Их, дускаем, бергә чаклар
Үттеләр, югалдылар;
Ярсып типкән яшь йөрәктә
Тирән эз калдырдылар.

Болар чын мәгънәсендә җыр түгел, ә кемнәрнеңдер җыр чыгарырга азапланып язган караламалары гына бит.

Аннан соң, кайбер очракларда җырларның ялгыш вариантлары китерелгән. Җырның бозылганлыгы күренеп торган очракларда, аны төзәтеп бирергә мөмкиндер. Мәсәлән:

1918. Җаныкаем, синең бишмәтең
Билләреңнән түбән — бик сөям;
«Валлаһи» дисәм язык булыр,
Фил хакыйкать, сине бик сөям.

Монда беренче «бик сөям» урынына, һичшиксез, б и ш с ө я м (сөям — үлчәү берәмлеге) булган. Нигә аны төзәтмәскә иде?

Җыентыкны төзүчеләр бик хаклы рәвештә җырларның кайбер вариантлары аерым кыйммәткә ия булуына да игътибар иткәннәр. Һәм томда күп кенә матур параллель вариантлар бирелә. Әмма җыентыктагы кайбер вариантлар чын вариант түгел, ә уңышсыз компиляциядән гыйбарәт. Мәсәлән:

51. Карлыгач та кара, биле (?) ала,
Һаваларга очса, югала;
Аталардан бала япь-яшь кала,
Күкрәк көче белән мал таба.

Монда ике җыр буталган. Беренчесе болай:

Карлыгачкай кара, муены ала,
Һаваларга менә, югала.
Кыз балалар бигрәк газиз бала —
Ата-анадан китсә, югала.

Икенчесе — бөтенләй үзгә темага.

Карлыгачкай кара, муены ала,
Канат очларыннан кан тама;
Аталардан калган, ай, яшь бала,
Күкрәк көче белән мал таба.

Җыентыкта китерелгән дүртюллыкның сәнгатьчә үзәге юк, аның очы-очка ялганмый. Һаваларга очып югалган карлыгач белән ни өчендер, гүяки, һәр вакыт атадан япь-яшь кала торган бала арасында мәгънәви параллельлек сизелми һәм сизделми. Ә китерелгән дөрес вариантларда параллелизм ярылып ята: кыз бала карлыгач кебек һаваларга китеп югала. Бик яшьли атасыз калып, буыны катмас борын авыр физик эш башкарырга мәҗбүр булган яшүсмер яралы карлыгачка охшатыла һәм аның «һаваларга менеп югалырлык» хәле юк.

Без монда һәрбер җырда параллелизм булырга тиеш дигән фикерне алга сөрмибез. Ләкин һәрбер чын җырның беренче һәм икенче мисраглары арасында нинди дә булса — кайчакта бик катлаулы һәм тирән — мәгънәви бәйләнеш була. Мәсәлән:

Һаваларда очкан аккошларның
Алларында озын сәфәр бар;
Кайтыр эникән минем җан кисәгем —
Яу басыла дигән хәбәр бар.

Монда беренче «мәгънәсез» мисраг чынлыкта әллә ничаклы тормышчан ассоциацияләр, фикерләр тудыра: «сагынылган җан кисәгем — аккош кебек», «без — пар аккош кебек», «егет яудан туган илен аккошлар кебек сагынып кайта» һ. б. Менә шундый эчке мәгънә бәйләнешләре, «архитектоникасы» булмаган һәрбер куплет гадәттә я ясалма, эшләнеп бетмәгән җыр, яисә уңышсыз компиляция булып чыга.

Җыр — хис чагылышы. Шуңа күрә җырлар классификациясе ул «хисләр классификациясе» булырга тиеш. Асылда җыентык шулай эшләнгән дә. Әмма төзүчеләр, берничә очракта шул принциптан читкә тайпылып, «Кызлар язмышы турында борынгы (?) җырлар» һәм «Шәкерт җырлары» бабларын кертсәннәр. Болар инде хисләргә түгел, бөтенләй үзгә нигездәге классификациягә туры киләләр. Шуның өчен

бу бабларда тематик бөтенлек тә күренми. Кызлар язмышы хакында, беренчедән, тормыш турындагы җырларда да мисаллар күп; аннан соң кызлар язмышы киләчәк томнарда биреләчәк йола җырлары, чеңләүләрдә дә төп урынны аласыдыр. Инде шәкерт җырларына килсәк, аларның төп урыны — мәхәббәт җырлары бүлекчәсе. Күп кенә «шәкерт җырларының» нәкъ менә шәкертләрнеке булуы да ышандырмый. Мәсәлән:

1509. Алпавытның бакчасында
Үсә диләр пар кавын;
Җаның сөйгән ярың белән
Торсаң иде бер кавым.

Гомумән, бу бүлекчәләрне — бабларны аерып бирү кирәкмәгәндер. Алар урынына яңа бер бүлекчә — пародия җырлары бабын ачарга да мөмкин иде.

Пародия җырларының бер өлеше гомумән җырга пародия була:

4456. Безнең авыл кырларыннан
Очып бара бер карга;
Су буеннан су төядем
Бастырыклап бер арба.

Икенче төр аерым бер мәгълүм җырны пародияли. Мәсәлән, җыентыкта шундый җыр бирелгән:

2960. Ач тәрәзәләреңне,
Күтәр пәрдәләреңне;
Күтәрсәң пәрдәләреңне,
Күрәм гәүдәләреңне.

Шушы җырга пародия итеп икенче бер җыр җырлана:

Күтәр пәрдәләреңне,
Күрсәт гәүдәләреңне;
Бәрәкәтле кылсын алла
Гыйшык сәүдәләреңне.

Бу пародия — чәнечкеле җыр да. Ләкин шулай да, төп җырны күрсәтеп, соңгысын пародияләр бүлегенә дә кертергә мөмкин булыр иде.

Пародия җырларының өченче төре аерым шивә, сөйләмнәрнең килбәтсезрәк тел үзенчәлекләреннән көлә:

Яңгыр ява, кар эри,
Каралты башы чери;
Әйт, апаем, кәнфит бирәм,
Апаң кем белән йөри.

(«Туганым» диясе урынга «апаем» дип сөйләүчеләрдән көлү.)

Уфаларга бардым кый,
Шәлъяулыклар алдым кый;
Чакырдым кый, килмәдең кый,
Җаннарымны кыйдың кый.

(«Кый» кисәкчәсен еш кулланучы Урал татарларыннан көлү.)

Бу җыентык үзенең максаты белән текстлар җыентыгы: без аңа карата тик текстларның дөрес бирелеше, дөрес сайланышы һ. б. шундый мәсьәләләргә бәйләнгән таләпләр генә куя алабыз. Китерелгән текстларны аңлату, аларга һәртөрле тарихи-этнографик яисә филологик шәрехләр, комментарийлар бирү, алар өстендә төрле тикшеренүләр алып барулар — киләчәк эше. Ләкин монда да күп кенә урыннардагы аңлатмаларны тәфсилләрәк итеп бирү комачауламас иде, чөнки кайбер аңлатмаларга фәнни тәгәллек җитенкерәми.

Мәсәлән, текстлар башланган 37 биттә үк **андыз** сүзе **дару үләне** дип аңлатылган. Белмәгән кеше өчен бу аңлатма берни дә бирми: нинди мәгънәдә ул «дару үләне»— дару үләннәренең барысы да **андыз** дип аталамы яисә **андыз** — дару үләненең бер төреме? **Андыз — тамыры дару хәзерләү өчен кулланыла торган күпьеллык бер үлән** дисәң дөресрәк булмас идеме икән? 41 биттә:

Чыгып киттем мин юл буйлап,
Дугайларым китәләй күл буйлап,

— дигәндә нәрсә ул **дугай!** — монысы бөтенләй аңлатылмый. Хәлбуки, төзүчеләр бу сүз турында белешмә тупласалар, җыр үзе дә төзекләнә төшәр иде. **Дугай** — тугайда була торган озынча, кәкре күл ул. Һәм китерелгән текстта бу сүз дөрес кулланылмаган.

Чыгып киттем мин юл буйлап,
Юлым китте дугай күл буйлап,

— дип язылса, дөресрәк булыр иде.

44 биттә **селәүсен** «киек җанвар» дип аңлатылган: хәлбуки, **киек** булгач, ул иткә аулана торган җанвар (русчасы «дичь») була, ә селәүсенне иткә ауламыйлар.

58 биттә **хәситә** — «хатын-кызларның бизәнү әйбере» дип, үтә гомуми аңлатма бирелгән. 96 биттә **тәһлил әйтү** — гарәпчә — «бер алладан башка алла юк» дигән җөмләне әйтү» дип аңлатыла. Ә бит **тәһлил әйтү** — җеназа мәрасименең мөһим бер өлеше, ул фольклорда үлемне символлаштыра (яратмаган кешегә чыкканда, «никахы тәһлил кебек ишетелә», диләр) һ. б.

Йомгаклап әйткәндә, «Татар халык иҗаты»ның беренче томы дүртюллык җырлар фондын шактый тулылык белән чагылдыра һәм ул тиешле югарылыкта хәзерләнгән. Татар халык иҗаты сериясенең башка томнары да шундый ук уңышлы булсын иде.

**РИФКАТ ӘХМӘТҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## ӘПКӘЛИ ЯЗМАЛАРЫ

### Мөштек Әпкәли Трөбкәле

Ошбу елның 1 апрелендә җиңел генә авырудан соң, 31 гасырдан безнең гасырга кайтып, «Үткәннәр авазы» дигән мәгълүм эпопея авторы Мөштек Әпкәли Трөбкәле вафат булды. Ул дөньядан соңга калыбрак китте — аңа инде 1133 яшь иде. Шуңа күрә дус-ишләре, якыннары соңгы юлга аны уйнап-көлеп, шаян җырлар җырлап озаттылар. Әпкәли бик зирәк кеше иде. Әҗәле житкәч тә ул шуны күрсәтте. «Кабереңә нинди һәйкәл куйыйк?» дип сораучыларга: «Кaберемә бернинди һәйкәл дә кирәк түгел, һәйкәлгә дигән акчаны литфонд бирәр яшь язучыга бирсен... Ә мине сагынган чакларда завод морҗаларына карагыз, морҗалардан төтен чыга икән — димәк, дөньяда минем рухым да яши»,— дип җавап бирде. Әнә шул тапкыр җавабы белән Әпкәли дөньядагы барлык завод морҗаларын үзенә һәйкәл итеп калдырды. Морҗалардан бөрөзлексез төтен чыга — җирдә Әпкәли рухы яши.

Әпкәлинең мең битлек «Үткәннәр авазы» эпопеясенең берничә бүлеген һәм мәрхүмнең архивында сакланып калган кайбер башка әсәрләрен матбугатка тәҗрибәле әпкәлиовед Фаил Шәфигуллин тәкъдим итте.

## ҮТКӘННӘР АВАЗЫ

*Эпопеядән өзекләр*

### Тагын йөз ел яшим...

Ул чагында Татарстан җирендә 150 гә якын союз әгъзасы һәм 300 дән артык яшь язучы яши иде. Әйе, рәхәт иде тормышлар. Отчетларга, докладларга кыстырып җибәрәсең, мин сиңа әйтим, трибуналардан торып тондырасың — тыңлаучыларның күзләре шар була. Ә кәкже, язучы биш йөздән иллегә генә ким бит.

— Ничек дисең, ничек дисең, Фабий? Әйберләрен кайларда бастырып бетерәләр иде дисеңме? Бетерәләр иде. Урын табыла иде. Ә кәкже, калын әдәби журнал бар иде. Дөрес, ул чагында бер генә иде ул. Шулай да җитә иде. Сезнең кебек имансыз түгел иде ул чагында әдипләр. Язарлар иде елга бер яки ике хикәя, утыз-кырык шигырь, ярты поэма, я булмаса бер дә язмаслар иде. Сез генә ул төне буе хикәя язып, таң тишегеннән күзегезне тозландырып редакциягә килеп җитәсез. Ичмасам, язган әсәрегезне кире борып та булмый. Язарга өйрәндегез, тишек борыннар. Үзегез нибарысы ике дистә. Ә үзегез уникe әдәби журналны туендырып торасыз. Язганнарыгыз буенча хөкем йөртсәң, кайсыгыз карт, кайсыгыз яшь икәнен дә аерып хәл юк.

һәркайсыгызның үз стиле бар, җитмәсә. Сюжетларыгыз да яңа. Образларны да бер-берегездән чәлдерәсез дип әйтеп булмый. Эшләр болай барса, тагын бер әдәби журнал ачмыйча булмас сезгә.

Кая, китер әле, Идеал, син нәрсә алып килдең тагын? Тәк, повесть? Машинкада ничә бит дисең? Алтмыш ике? Алтмыш ике? Озынрак бит, егет, озынрак. Сыкмый булмас тагын бераз! Һе, таптың чагыштырырга! Ул чагында икешәр йөз битле повестьлар язалар иде. Повесть язуны ни урынына да күрмәс иде халык. Нишләп инде ел саен 400 повесть китерсеннәр! Аның бары тик алты-җидесе басарга яраклы була иде ич... Язган әйберне бастырасы килә инде ул. Гаризалар, үтенечләр, каргышлар, янаулар, әллә ниләр язалар иде. Һич булмаса кешегә яздырырлар иде. Язучыга килешми дисеңме? Язучыга бит ул. Әмма дә ләкин редакциягә повесть күтәреп килгән һәрбер автор язучы булмый бит әле. Нинди повесть язуында хикмәт.

Чын шулай, язучылар сараеның унсигезенче катыннан кадалып төшим, бер журнал, дүрт йөз язучы иде. Язмагач, ни өчен язучы исемен күтәреп йөриләр иде дисеңме? Ничек дип әйтергә инде аны? Ну, әйтик, җыелыш заллары тулып торсын өчен.

Юк, алай димәгез. Укымышлы иде язучылар ул чагында да. Кемнәрдән өйрәнәләр иде дисезме? Классиклардан, әлбәттә. Аннан соң тагын яшьләр арасында Геродот, Фукидид, Авреций Августин, Томас Мэлори, Маттео Банделло, Гонгора, Җоашен дю Белле, Тальман де Рео, Антуан Гамильтон, Мариво, Босуэлл, Парни, Колридж, Петрюм Рорэль, Йожеф Этвеш, М. Әгъләмов, Леконт де Лиль, Якобсен, А. Бенуа, Шамфор, Элиан, Ши-Цзюн кебек язучылар бик популяр иде. Әйтәм бит, күп укыйлар иде яшьләр, әмма ходайның хикмәте, ни өчендер, үзләре язмыйлар иде. Дүрт йөз язучының кырыгы гына тартып бара иде бөтен әдәбиятны дисәм — сүзем ялган булыр микән, әмма, ант әгәр, шулайрак иде.

Нәрсә, Гыйльметдин, тагын хикәя китердеңме? Ну язып торасың син, ә! Молодец. Яшьләр журналына кертеп карыйсыңмы соң әллә? Әле запаста егерме җиде хикәя бар бит безнең редакциядә. Егерме җидесе егерме җиде темага. Өчесенә дә кердеңме яшьләр журналының? Алмыйлармы? Калдыр, алайса. Чиратка язып куярлар. Пасквильләр, афоризмнар, эпиграммалар кирәк безнең журналга. Яз әле, энекәш, яз. Ярый, ярый, хуш.

Әй, заманалар! Бер хикәягә тилмереп йөргән чаклар да бар иде бит. Дүрт йөз язучыдан бер адәм рәтле хикәя теләнеп ала алмас идең. Ә хәзер Гыйльметдин хикәяләрен генә басып торсаң да, шөкер, хәтта уникe журналның уникесен дә хикәягә кинәндереп була.

Кайтырга вакыттыр инде... Рәхәт. Корректураны исәп-хисап машинасы укый. Атна саен җыелыш, киңәшмә җыеп та ялыктырмыйлар. Болай булгач, тагын йөз ел яшим әле мин...

## ҮЛЕМСЕЗЛЕК ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

### Инглиз сюжетына

1976 елның җәе. Без, ике яшь шагыйрь — Туфан Миңнуллин һәм мин — сыраханәдә, сыекча чөмерә-чөмерә, гәпләшеп утырабыз. Туфанның башында милли түбәтәй, аягында үкчәләре ямьшәеп беткән йөз утыз тәңкәлек (иске акча белән) туфлиләр. Манжетлы чалбарының тез башлары иләкләнә башлаган, якасы кер-

ләнмәсен өчен ак күлмәгенең барлык сәдәфләрен дә ычкындырып җибәргән. Мин әле яңарак кына мәсәлләр җыентыгы чыгарган шагыйрь — өс-баш байларский.

— Я, нигә дәшмисең, ә? Драматургия синең жанрың түгел бит ул, туган. Давай, шигърияткә хыянәт итмик әле. Киләчәктә синнән, беләсеңме, нинди шагыйрь чыгачак!

Туфан, кызарып, башын аска иде. Мин дәвам иттем:

— Акчаң җитмиме синең, тамагың ачмы? Я, әйт әле, ни дип ябышып ятасың син шул драматургиягә?

— Акча да җитми...— диде Туфан Миңнуллин авыр сулап һәм башын тагын да аскарак иде.

— Подумаешь, «Миләүшәнең туган көне», «Диләфрүзгә дүрт кияү»... Мондый пьесаларың белән үзешчәннәр сәхнәсенә дә якын җибәрмиләр бит сине. Алыйк «Нигез ташлары»ның, яки әле гензә сюжетын сөйләгән «Әлдермештән Әлмәндәр»енне алыйк. Ни вакыйга, ни геройлар, ни заман сулышы юк. Ярамый, Туфан, ярамый болай. Әдәбиятта без һәркайсыбыз үз урынын табарга тиеш. Без, акча кирәк дип, бүгенге көн өчен генә яшәргә тиеш түгел. Киләчәк турында, мәңгелек дан, үлемсезлек турында уйларга вакыт безгә.

Туфан Миңнуллин башын акрын гына күтәрде. Бушаган бокалын дөпелдәтеп өстәлгә куйды һәм, дулкынлануын басарга тырышып, миңа эндәште:

— Син чыннан да миннән бөек шагыйрь чыгачак дип уйлыйсыңмы?

— И юләр, талант бит синдә, сирәк очрый торган шигъри сәләт. Ә драматургиядә син ярга чыгарып ташланган балык кебек кенә... Ярый, тегеләй-болай итеп, этләшеп дигәндәй, берәр пьесаңны сәхнәгә менгердең дә ди. Соң, халык карамаячак бит андый халтураны, беләсеңме син шуны, юкмы? Халык сиңа да, режиссерыңа да черегән йомырка тондыра-тондыра залны ташлап чыгачак.

Туфан, сөякчел бармакларын чәч араларына батырып, уйга калды. Аннары кинәт елмайды да:

— Все, бүгеннән соң бер генә юл пьеса да язмыйм,— дип йодрыгы белән өстәлгә сукты.

— Вәгъдәме?! Бир бишне.

— Вәгъдә. Мә.

— Күптән шулай кирәк иде,— дидем мин, эчем-тышым белән сөенеп.— Төкер драматургиясенә. Яшәсен поэзия! Яшәсен үлемсезлек!

Без тагын берәр кружка сыра алып авыз иттек.

Туфан ике күзендә ике илһам уты кабызып шигырь укырга кереште:

> Вәгъдәләр бирелгән,
> Иреннәр чыланган.
> Мәчеләр мыраулап
> Төшәләр чормадан...

Мин:

— Гениально, гениально,— дип, өстәл аша үрелеп Туфанның сыра күбеге кунган иягеннән үбеп алдым...

Ләкин Туфан Миңнуллин йомшак характерлы шагыйрь булып чыкты, вәгъдәсендә тормады — берничә көннән мин аның «Ак тәүбә, кара тәүбә» дигән яңа пьеса язганлыгын ишеттем.

## Газиз Нәбиуллин

### Мин һәм Салман

Күптән килгән гадәт булгач,
Мин дә инде кыймадым,
Утын китергәч, Салманны
Ярты белән сыйладым.
Хатыным да кыстап торды,
Айга-вайга карамый.
Миңа гына күз акайта:
— Син авыру, ярамый!
Салман китте. Салган баштан
Әй абына, әй түнә. —
Иртәгесен елап килгән
Җәмәгате Зәйтүнә.
...Бәйрәм ашы — кара-каршы,
Китап та аны мактый.
Салманга утын турыйбыз
Яртыны ваклый-ваклый.
Зәйтүнәсе бигрәк кыстый,
Айга-вайга карамый.
Салманына күз сала да:
— Син авыру, ярамый!
... Җыелыш булды, әй, бер көнне
Бөтен сүз хәмер булды,
Шул мәлгуньгә чик куярга
Бик катгый әмер булды.
— Чик куярга! — дигән сүзне
Мин дә керттем планга.
Салам китергәч, Салманга
Салдырмадым грамм да.
Салман китте. Салган сыман
Әй сөртенә, әй түнә.
Иртәгесен рәхмәт укый
Җәмәгате Зәйтүнә.
Салман күрше дә бу хәлне
Шул килеш калдырмады.
Мунчага нигез салышкач,
Грамм да салдырмады.
Телләрдән юып төшердек
«Юабыз» дигән сүзне.
... Кайберәүләр әле һаман
«Каралмасалар» ярый дип
Җәллиләр, имеш, безне.

# ШИҺАП РАМАЗАНОВ

*(1887—1948)*

Шушы елның 20 декабренда күренекле тел галиме, тәҗрибәле педагог Шиһап Рамазановның тууына 90 ел була.

Ярлы крестьян улы Шиһап авыл мәдрәсәләрендә белем ала һәм 16 яшеннән балалар укыту эше белән шөгыльләнә башлый.

Ш. Рамазановның фән һәм мәгариф системасындагы эшчәнлеге Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына киң колач белән җәелеп китә. Ул Саратов өлкәсенең төрле районнарында укытучы, мәктәп инспекторы, өяз халык мәгариф бүлегендә инспектор, интернациональ балалар йортының мөдире, 1924 елдан башлап Саратов педагогия техникумының татар укытучылары хәзерләү бүлеге мөдире, соңыннан татар педагогия техникумы мөдире һәм анда тел-әдәбият укытучысы вазифаларын башкара.

1928 елда Ш. Рамазановның укытучылык хезмәтенә 25 ел тулуга багышланган юбилей уздырыла һәм шул уңайдан аңа халык укытучысы дигән мактаулы исем бирелә.

1934 елда Казан педагогия институты каршындагы аспирантураны уңышлы тәмамлаганнан соң, Шиһап Рамазанов шул ук институтта 1946 елларга кадәр гомуми тел белеме, хәзерге татар әдәби теле курсларын укыта. 1942 елдан башлап ул СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни-тикшеренү эшләре алып бара. 1943 елда аңа филология фәннәре кандидаты исеме һәм доцентлык дәрәҗәсе бирелә.

Совет фәненә хезмәт итү юлында гомеренең соңгы көннәренә кадәр армый-талмый намус белән эшләгән Шиһап Рамазанов татар теленең иң актуаль проблемалары буенча фәнни-тикшеренү эшләре башкарды.

Ш. Рамазановның эрудициясен, эш диапазонын якынча гына күз алдына китерү өчен, ул иҗат иткән хезмәтләрне барлап чыгу да җитә. Аның Бөек Октябрьга кадәр һәм аннан соң вакытлы матбугат битләрендә татар тел белеме проблемалары һәм укыту методикасына караган 60 тан артык мәкаләсе басыла.

1934—35 елларда Ш. Рамазанов татар эшчеләре һәм колхозчыларының сөйләм телен өйрәнү буенча оештырылган экспедицияләргә җитәкчелек итә.

Татар теленең сөйләм стиле үзенчәлекләре белән якыннан кызыксынып, Ш. Рамазанов бер үк вакытта әледән-әле көндәлек матбугат теленә җитди анализлар ясап килә. Аның артистлар теле турындагы язмалары да шуңарга мисал булып тора.

1948 елда «Каюм Насыйри» исемле фәнни-популяр очерклар җыентыгында басылып чыккан «Каюм Насыйри татар әдәби теленә нигез салучы» дигән хезмәтендә Ш. Рамазанов атаклы мәгърифәтчене гомумхалык теленә нигезләнгән әдәби телебезгә юнәлеш биргән галим буларак күрсәтә. Аның «Г. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» исемле хезмәте язучыларның тел-стиль проблемаларын җентекле анализлауда башлангыч адым һәм үрнәк булып тора. Татар тел белемендә һәм тюркологиядә күптән танылган күренекле лингвист Гыйбад Алпаровның «Сайланма хезмәтләр»ен туплап, комментарийлар һәм күләмле кереш язып бастырып чыгару да Шиһап Рама-

занов эше. Ул рус графикасы нигезендә яңа татар әлифбасы төзү һәм аны гыйльми нигездә эшкәртүгә дә зур хезмәт куйды.

Татар телендәге сүзләрнең этимологиясенә караган хезмәтләрендә дә Ш. Рамазанов фән өчен әһәмиятле нәтиҗәләр ясый.

Фәнни-тикшеренү һәм педагогик эшчәнлекләрне чиратлаштырып алып барган бу галим озак еллар дәвамында югары уку йортлары өчен татар теленнән программалар төзү белән дә шөгыльләнде.

Аның грамматика, лексикология, терминология, орфография, гомуми тел белеме, стилистика һәм тел тарихына караган күп санлы язмалары Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивында сакланалар. Бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган, татар тел белемен үстерүгә турыдан-туры мөнәсәбәте булган фактик материалны үз эченә алган бу бай фәнни мирас әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Ул хезмәтләрне фәнни анализлау һәм укучыларга җиткерү — алда торган бурычларның берсе.

**Ә. САБИРОВА,**
**Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивы хезмәткәре.**

# КИТАПХАНӘГӘ 70 ЕЛ

Беренче рус революциясе Россиянең төрле төбәкләрендә яшәгән һәм патша самодержавиесе тырнагы астында гасырлар буе изелеп килгән бик күп милләтләрнең иҗтимагый аңын уятып, азатлык өчен көрәшкә дәртләндерде. Хөррият дулкыннары бик тиз арада Оренбургка да килеп җитә. Монда «Вакыт» газетасы, «Карчыга» журналы, алардан соң ук большевистик «Урал» газетасы чыга башлый. Шәһәрнең алдынгы җәмәгатьчелеге, революцион-демократик рухтагы яшьләр түләүсез җәмәгать китапханәсе оештыру мәсьәләсен кузгаталар. Большевик Хөсәен Ямашев та бу башлангычны беренчеләрдән булып күтәреп ала. Шулай итеп, моннан җитмеш ел элек Оренбургта хәзер Хөсәен Ямашев исемен йөртүче беренче татар китапханәсе ачыла.

Г. Ибраһимов, Ш. Камал, З. Бәшири, талантлы яшь шагыйрьләр Ш. Бабич, Ш. Фидаи, шагыйрә З. Сәгыйдә китапханәнең иң актив укучылары булалар.

Повесть һәм хикәяләре белән революциягә кадәр үк оренбурглыларга яхшы таныш булган каләм остасы Шәриф Камал берничә ел дәвамында китапханәнең мөдире булып эшли. Китап фондын ул, татар авторларының әсәрләреннән тыш, рус әдәбияты классиклары Пушкин, Толстой, Гоголь, Чехов, Горький әсәрләре белән баета, бик күп газета һәм журналлар алдыра.

Егерменче елларда монда трибун шагыйрь Һ. Такташ, ялкынлы комсомол шагыйрь М. Җәлил, булачак атаклы композиторлар С. Сәйдәшев, Җ. Фәйзи еш килеп йөриләр, Кәрван-сарайда укучы студентлар, соңыннан Башкортстанның күренекле әдипләре булып танылган Б. Бикбай, С. Агиш, З. Биишева һәм шәһәребездә яшәгән, укыган, шунда иҗат дәртләре кабынган башка бик күпләр китапханәнең якын дуслары булалар.

Х. Ямашев исемендәге китапханәгә бүген алты меңнән артык укучы йөри, ә әдәби фондында китап һәм журналлар илле өч мең томнан артык исәпләнә.

Китапханәдән барлык шәһәр халкы файдалана. Институт студентларын, техникумнар, музыка һәм педагогия училищесы, мәктәп укучыларын бирәдә аеруча еш очратасың. Китапханә шулай ук өлкәнең Саракташ, Сакмар, Илек һәм башка районнарында яшәүчеләргә дә хезмәт күрсәтә.

Ул күптән инде шәһәрнең культура үзәкләреннән берсенә әверелде. Җәмәгатьчелек тормышындагы һәрбер зур вакыйга китапханә катнашыннан башка узмый. Соң-

гы елларда гына да әдәби түгәрәк членнары белән берлектә күп санлы кичәләр, укучылар конференцияләре, татар һәм башкорт язучылары белән очрашулар үткәрелде.

Китапханәнең 70 еллыгын билгеләп үткәндә, аны чын мәгънәсендә культура учагына әверелдерү өчен жаны-тәне белән тырышып, күңел жылысын биреп эшләгән хезмәткәрләр турында да әйтми мөмкин түгел. Китапханәгә ярты гомерен багышлаган Бибинур Гайнетдинова Бөек Ватан сугышының авыр елларында аның әдәби фондын саклап кала. Ул, шәһәр буенча йөреп, сугыш инвалидларына, эшче һәм хезмәткәрләргә китаплар ташый. Жиһан апа Шәрипова да китапханәдә кырык ел хезмәт итте. Аның фидакарь хезмәте Ватанның мактаулы бүләге — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән билгеләнде.

Хәзер китапханәне иң өлкән хезмәткәрләрдән берсе Наилә Гарипова житәкли, ә уку залын үз эшен сөеп башкаручы Лия Рафиковадан башка күз алдына китерүе дә кыен кебек.

Быел, матур яз аенда, шәһәр жәмәгатьчелеге вәкилләре китапханәнең юбилей кичәсен үткәрделәр. Завод-фабрикалардан, башка хужалык һәм культура оешмаларыннан, уку йортларыннан килгән делегацияләр китапханә хезмәткәрләрен бәйрәм белән жылы котладылар, истәлекле бүләкләр тапшырдылар, аларга киләчәк эшләрендә зур уңышлар теләделәр.

**Ш. РАМИЛ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ҮЗӘКТӘ — ЭШЧЕ ОБРАЗЫ

Июль ае татар әдипләре, бигрәк тә прозаиклар өчен, истәлекле булды. Казанда, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында, «Татар әдәбиятында эшче образы» дигән темага бик җитди һәм файдалы сөйләшү уздырылды. Хәзерге заман әдәбиятының үзәгендә торган бу зур мәсьәлә РСФСР Язучылар союзы каршындагы Проза советының күчмә утырышында тикшерелде.

Күчмә утырышны Проза советы председателе, рус язучысы Сергей Залыгин ачты. Татар прозаикларының эшчеләр тормышын сурәтләгән әсәрләре турында докладлар тыңланды, фикер алышулар булды. М. В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетында совет әдәбияты кафедрасы мөдиренең урынбасары, филология фәннәре кандидаты Роберт Бикмөхәммәтов татар язучыларының кайбер әсәрләрен — соңгы елларда эшче темасына иҗат ителгән романнарны анализлады. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Флүн Мусинның докладына да шул ук темага багышланды.

— Татар әдәбиятының алтмышынчы-җитмешенче еллар прозасына тематик киңлек, төрлелек хас, — диде Мәскәү галиме. — Татар язучылары күп милләтле совет әдәбиятындагы эшче образлары галереясенә үз геройларын — Татарстан нефтьчеләрен, КамАЗ төзүчеләрен, производство новаторларын өстәделәр. Болар — реаль тормыштан алынган бай характерлы геройлар. Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов эшче образлары аша социаль көрәшләрне бөтен киңлегендә колачларга омтылса, Ә. Еники производстводагы кешеләрнең мораль сыйфатларын сурәтли. Э. Касыймов геройларның эшчәнлегенә, укганлыгына игътибар бирә, А. Гыйләҗев белән Ә. Баянов исә бу эшчәнлекне фәлсәфи-художестволы формадагы уйланулар аша ачарга тырышалар. Барысы өчен дә уртак сыйфат та бар: татар язучылары иҗтимагый үсешнең закончалыкларын һәм замандашларыбызның характерларын реаль чынбарлыктагыча — интернациональ бәйләнешләрдә өйрәнәләр, шулай сурәтлиләр. Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнардан килгән традиция, күркәм башлангычлар яши: проза осталары аерым тема кабырчыгына төренеп ятмый. Алар авыл турында да язалар, шәһәр производствосына да үтеп керәләр. Кыскасы, татар язучылары бүгенге тормышны һәр яклап өйрәнәләр. Бу бик күңелле күренеш. Ә эшче сыйныфының бөек эшләрен, героик характерын сурәтләгән проза әсәрләре татар әдәбиятын көчәйтә, баета, аны бөтенсоюз мәйданына чыгара.

Әдәбиятта эшче образы мәсьәләсе — катлаулы проблема. Бу турыда фикер алышуларда Мәскәүдән Проза советы утырышына махсус килгән кунаклар — рус язучылары һәм тәнкыйтьчеләр, тәрҗемә осталары, газета-журнал һәм нәшриятларның җаваплы хезмәткәрләре катнашты. Татар язучылары аларга үз фикерләрен, теләкләрен, тәкъдимнәрен белдерделәр.

Заманында А. М. Горький милли республикаларның язучылары турында: «Аларның берсе дә тик үз халкы өчен генә эшләми, бәлки һәркайсы социалистик республикалар һәм автономияле өлкәләр Союзындагы барлык халыклар өчен иҗат итә. Тарих аларга да, рус язучыларына да, бер үк җаваплылыкны йөкли», дип язган иде. Утырышта татар әдипләренең әсәрләре нәкъ әнә шундый югары таләпләр куеп тикшерелде һәм уңай бәяләнде. Совет кешеләренең тарихи новаторлыгы нәрсәдә? Фәнни-техник революция процесслары татар эшчеләренә нинди йогынты ясый, аларны ничек үзгәртә — татар әдәбияты да шул проблемаларны өйрәнү, анализлау һәм фәлсәфи-художестволы формада чагылдыру юнәлешендә үсә.

## МӘСКӘҮ ЯЗУЧЫЛАРЫ КамАЗда

КамАЗ эшчеләре белән Мәскәүнең «Новый мир» журналы һәм аның авторлары арасында иҗат дуслыгы моннан алты-җиде ел элек башланды. Мәскәү язучылары гигант төзелеш геройлары турында инде шактый күп очерклар, дулкынландыргыч язмалар иҗат иттеләр, алар белән әледән-әле очрашып торалар. Шундый очрашуларның берсенә июль аенда журналның баш редакторы урынбасары, танылган рус шагыйре, безнең милләттәшебез Михаил Львов җитәкчелегендә бер группа язучылар килде. Алар КамАЗ һәм шәһәр төзелеше объектларында булдылар, двигательләр заводы эшчеләре белән очраштылар. Әдәбият сөючеләргә «Энергетик» культура сараенда М. Львов, М. Соболь, В. Боков, Н. Зиновьев һәм башкалар шигырь һәм хикәяләр укыды. Камазлыларга зур шефлык хезмәте күрсәтүдә бик яхшы эшләгәннәре өчен, КПССның Чаллы шәһәр комитеты бюросы карары

белән, аларга «КамАЗ төзелеше ударнигы» исеме бирелде һәм моны раслаучы значоклар тапшырылды. Бу мактаулы исем эшчеләр арасында яшәп уңышлы әсәрләр иҗат иткән татар язучысы Эдуард Касыймовка да бирелде.

## ӘСТЕРХАНДА ҺӘМ ГОРЬКИЙ ӨЛКӘСЕНДӘ

* * *

Әстерхан шәһәрендә һәм өлкә районнарында, Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына багышлап, татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы үткәрелде. Анда бер төркем язучылар, Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры артистлары һәм Казан кинохроника студиясенең иҗат хезмәткәрләре катнашты. Шәһәрнең «Родина», «Призыв», «Октябрь» кинотеатрларында һәм Нариманов районында кинорежиссерлар Ф. Шәрәфиев, Х. Фәхретдинов, операторлар Г. Әмиров, В. Райский күп санлы тамашачылар белән очраштылар, Казан киностудиясенең эшчәнлеге, киләчәккә планнары белән таныштырдылар. Бу студия чыгарган «Тукай», «Җәлил», «Көрәш сәхифәләре», «Туган як моңнары», «Татарстан» киножурналының махсус чыгарылышы һәм башка тасмаларны тамашачылар зур кызыксыну белән карады. Аларга шулай ук Г. Ахунов романы буенча Свердловск киностудиясендә төшерелгән һәм Казан киностудиясендә татарчага тәрҗемә ителгән «Хәзинә» фильмыннан өзекләр дә күрсәтелде.

* * *

Горькийда, өлкә шәһәрләрендә һәм районнарында үткәрелгән совет әдәбияты көннәренә рус язучылары белән берлектә тугандаш республикалардан да әдипләр килде. Татарстаннан анда шагыйрь Зәки Нури катнашты.

## ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЕНДӘ

Мәскәүдәге «Художественная литература» нәшрияты «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясеннән рус телендә «Поэзия народов СССР XIX — начала XX века» («XIX йөздә — XX йөз башында СССР халыклары әдәбияты») дигән күләмле китапны бастырып чыгарды. Гасырдан артыграк чорны эченә алган әлеге басмада, төрле халыкларның шагыйрьләре белән беррәттән, шул заманда яшәгән һәм иҗат иткән күренекле татар шагыйрьләреннән Габделҗаббар Кандалый, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла, Яков Емельянов, Дәрдмәнд, Сагыйть Рәмиев һәм Габдулла Тукай шигырьләре томның күп кенә сәхифәләрен били. Аларны русчага А. Ахматова, С. Маршак, В. Тушнова, С. Липкин, М. Львов, Р. Моран, Я. Хелемский, В. Державин, В. Ганиев һәм башкалар тәрҗемә иткән.

* * *

Куйбышев өлкә китап нәшрияты, Октябрьның 60 еллыгына багышлап, Идел белән Урал арасындагы автономияле республикалар һәм өлкәләрдә яшәүче төрле милләт шагыйрьләренең туган ил, Октябрь, халыклар дуслыгы турындагы иң яхшы шигырьләреннән тупланган «Салават күпере» («Радуга») дигән китап чыгарды. Анда башкорт, мордва, чуваш поэзиясе үрнәкләре, татар шагыйрьләреннән Әнвәр Давыдов, Муса Җәлил, Зәки Нури, Ренат Харис, Мәхмүт Хөсәен, Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Әмир Мәхмүдов шигырьләре Куйбышев шагыйрьләре тәрҗемәсендә бирелә.

* * *

Семипалат шәһәренең Абай исемендәге казакъ театры Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен сәхнәләштергән: режиссеры Е. Тәпенов, баш рольне — талантлы артист Җангырбаев уйный.

Казакъ матбугаты, спектакльгә югары бәя биреп, сәхнәдә татар музыкасының бик уңышлы файдаланылуын, декорацияләрнең отышлы эшләнүен билгели. Театр бу спектакльне, республика башкаласы Алма-Атада күрсәткәннән соң, авыл җирләренә гастрольгә алып чыкты.

## ГАСТРОЛЬЛӘР ҖӘЕ

* * *

Әлмәт татар дәүләт драма театры июль аен Казанда гастрольдә үткәрде. «Нефть башкаласы»ннан килгән артистлар Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнадылар. Казан тамашачылары әлмәтлеләр сәхнәләштергән «Шәмсекамәр» (М. Әблиев), «Сафура бураннары» (Ю. Әминов), «Кар астында кайнар чишмә» (А. Гыйләҗев), «Синнән башка юк тормышым» (С. Шәкүров) спектакльләрен яратып карады.

Театр яшь драматурглар иҗатына да игътибар иткән — репертуарга Фоат Садриевның «Их сез, егетләр!» пьесасы кертелгән. Тамашачылар бу әсәрне җылы каршылады.

Гастроль Ленин премиясе лауреаты Ч. Айтматов әсәре буенча эшләнгән «Анам кыры» спектакле белән тәгәлләнде.

Соңыннан Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегендә коллективның репертуары, сәхнә осталыгы турында кызыклы һәм файдалы сөйләшү булды. Сәхнә сәнгате өлкәсендәге иҗади уңышлары һәм республика хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтүдәге зур эшчәнлеге өчен, Әлмәт театры коллективы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының мактау грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры осталары борынгы шәһәр Владимирда тамашачыларны театр репертуарындагы иң яхшы әсәрләр белән таныштырдылар.

* * *

В. И. Качалов исемендәге Казан рус драма театры Калуга тамашачыларына унлап спектакль күрсәтте.

* * *

Казан тамашачылары Мәскәүнең А. С. Пушкин исемендәге драма театры спектакльләрен зур кызыксыну белән карадылар. «Безнең иҗат коллективы Казанда моннан ике дистә ел элек булган иде,— диде Мәскәү театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты, Дәүләт премиясе лауреаты Борис Никитич Толмазов.— Дөрес, ул чагында артистларыбыз башка иде. Заманнар да, әлбәттә, бүтән иде. Ләкин казанлылар белән очрашу һәр вакыт онытылмас тәэсир калдыра. Татарстан башкаласының тамашачылары бик таләпчән, без моны белеп килдек. Коллективыбыз алар алдында йөз кызартмады. Артистларыбыз һәр спектакльдә бөтен сәләтләрен, көчләрен биреп уйнады».

* * *

Тугандаш Карелия АССРның башкаласы — Петрозаводск дәүләт музыкаль театры артистлары Казанда күрсәткән күңелле опереттәлар, музыкаль комедияләрдән бөек И. Штрауснең «Вена фантазиясе», француз композиторы Ф. Эрвенең «Мадмуазель Нитуш» әсәрләре казанлылар күңеленә аеруча хуш килде. Театр коллективы кечкенә тамашачыларны да истә тоткан: балалар «Золушка» әкиятоперасы белән «Поп һәм аның ялчысы Балда турында әкият»не карадылар.

## ЯЗУЧЫГА ЭШЧЕЛӘР БҮЛӘГЕ

Менделеевск химия заводы эшчеләре язучы Эдуард Касыймовны очрашу кичәсенә чакырдылар. Аның Мәскәүдәге «Современник» нәшриятында русча басылып чыккан «Чулман — река внуков» дигән романы буенча кызыклы сөйләшү булды. Химиклар авторның производствоны белеп язуын, завод кешеләренең характерларын реаль чагылдыруын әйттеләр. Кичәдә завод дирекциясе, парткомы һәм профсоюз оешмасы исеменнән Э. Касыймовка, химиклар тормышын сурәтләгән әсәр язганы өчен, рәхмәт белдерелде. Эшчеләр делегациясе язучыга «Эшче-химик» дигән диплом-адрес һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

## АФРИКАДА — «АУЛАК ӨЙДӘ»

Африка дәүләтләренең берсе — Туниста, аның башкаласына якындагы борынгы Карфаген шәһәренең реставрацияләнгән Рим амфитеатрында дөнья халыклары сәнгатьләренең IX Халыкара фестивале булды. Бу дөньякүләм сәнгать бәйрәмендә Советлар Союзы исеменнән Татарстан АССРның дәүләт җыр һәм бию ансамбле катнашты. Залдагы сигез мең тамашачы безнең сәнгать осталарыбызны озакка сузылган алкышлар белән каршылаган. Бу хакта Тунистан ТАСС хәбәрчесе болай дип яза: «Татарстан АССРның атказанган артистлары Нәфисә Васильева, Гали Ильясов, Эмиль Җәләлетдинов фестивальдә бик уңышлы чыгыш ясадылар. Ансамбльнең «Сарман яшьләре биюе», «Казан кунаклары» дигән фольклор-хореография программасы тамашачыларга бик охшады. «Аулак өйдә» дип исемләнгән вокальхореографик постановка барысын да сокландырды. Егетләр биюе, башка бик күп номерлар алкышлар белән хупланды». Ансамбльнең баш хормейстеры Л. Кустабаева исә Тунис фестивалендәге концертлар турында зур канәгатьләнү белән болай сөйли: «Коллектив бик зур дәрт, тырышлык һәм күтәренкелек белән чыгыш ясады. Без бернинчә шәһәрдә булдык. Халык һәркайда яратып, үз итеп каршылады. Тунис матбугаты Татарстан ансамбле турында бик җылы сүзләр язды».

Карфагенда үткән концертта республикабызның культура министры И. Н. Алеев катнашты. Ул Туниска рәсми визит белән барган иде.

## СӘНГАТЬ ТАРИХ ТА УЛ

Казанның рәссамнар йортында монументалист-художникларның әсәрләрен туплаган күргәзмә Октябрьның 60 еллыгына багышланды. Залларга куелган төрле жанрдагы әсәрләрдә Татарстан республикасының тарихы, татар халкы сәнгатенең үсеше чагыла. И. Халиулловның «Отряд китте», Л. Фәттаховның «Мулланур Вахитов», «Совет властеның беренче елларында» кебек сюжетлы полотноларында граждаңнар сугышы елларының утлы сулышы бөркелеп тора. Ә егерменче елларда Татарстан рәссамнары героик хезмәт темасына зур игътибар бирәләр. П. Радимовның Казан фабрикаларын сурәтләгән картиналары, П. Беньковның «Татар эшчесе», Б. Урманченың «Сепаратор янында» һәм башка әсәрләр шул елларда иҗат ителә. Бөек Ватан сугышы елларының — үз тематикасы: дошманга каршы аяусыз көрәш, ул көрәшнең батырлары. Герой-шагыйрь Муса Җәлил батырлыгы һәм фидакарьлеге бик күп рәссамнарны аеруча рухландырган: Х. Якуповның «Хөкем алдыннан» дигән картинасы, С. Ахун, В. Маликов, Б. Урманче скульптуралары, И. Язынинның график әсәрләре — шул тема әсәрләре. Сугыштан соңгы чорда Татарстан — нефтьле як, КамАЗ төзелгән як. Рәссамнар иҗаты да моны бик яхшы чагылдыра. Х. Якупов, М. Хәйретдинов, Х. Хәйдәров, М. Усманов, В. Попов, Э. Ситдыйков, А. Бурлай картиналары индустриаль республикабызга дан җырлыйлар. Шулар белән янәшәдә колхоз авылының бүгенге матурлыгын, кырлар киңлегендәге хезмәтне гәүдәләндергән рәсемнәр күрсәтелә.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге зур казанышлары өчен, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солисты **Азат Зиннәтович Аббасовка**, СССР Верховный Советы Президиумының 29 июньдә игълан ителгән Указы нигезендә, **СССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның 11 саны Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышлап чыгарыла. Сез аннан республикабызның үткәне, бүгенге көне, халыклар дуслыгы темаларына кагылышлы әсәрләр укырсыз.

Аның беренче бите партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев мәкаләсе белән ачыла. Ул республикабыздагы бөек төзелешләр, киләчәк перспектива, тормышыбызның торган саен матурлана баруы турында сөйли.

Өлкән һәм урта буын шагыйрьләр, яшь шагыйрьләр Олы бәйрәмне шигырь белән тәбрик итәләр.

Мәдинә Маликованың «Язгы такыялар» исемле повесте Бөек Октябрьның хезмәт иясе хатын-кызларына нинди хокуклар бирүен чагылдыра.

М. Рафиковның «Бер дистә Мифтахетдиновлар» очеркы бүгенге хезмәт шатлыгына багышланса, И. Абдуллинның «Х. Ямашев автобиографиясе», Р. Хәйретдиновның «Татарстанда Октябрь тарихыннан», М. Җиһүдиннең «Калининның Татарстанга килүе» дигән хезмәтләре исә Октябрь революциясе тарихына карыйлар.

Бу санда Нури Арсланов «Аяз булсын тирмән», Галимҗан Латыйп «Тополь» дигән шигырь бәйләмнәре белән, Нәби Дәүли «Мадам Клод трагедиясе» дигән шигыре белән катнашалар.

Поэзия сөючеләргә казакъ шагыйре Җ. Мулдагалиев, үзбәк шагыйре М. Мирмухсин шигырьләре тәкъдим ителә.

Н. Морадымовның «Дуслык эзләре», С. Акбиевнең «Татар мәгърифәтчесе таулар илендә», Т. Каххарның «Уйгур-татар мәдәни бәйләнешләре» дигән язмалары да тугандаш әдәбиятлар дуслыгын чагылдыра.

Шушы елның ноябрендә Казан радиосына 50 ел тула. Шул уңайдан Татарстан радиокомитетының элекке дикторы Шәриф Рахманкуловның истәлеге урнаштырыла.

Һәр сандагыча «Китап күзәтү», «Елмаеп та, көлеп тә» бүлекләре файдалы һәм күңелле материаллар тәкъдим итә.

Бу санда укучылардан килгән хатларга да зур урын бирелә.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары басыла.

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Октябрь — газета-журналларга язылу ае. «Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналына Сез илебезнең барлык элемтә бүлекләрендә языла аласыз. Журналыбызга язылу ел буена дәвам итә. Тик аңа вакытында язылып куйсагыз уңайрак булачак. Әгәр бу эштә кыенлыкка очрасагыз, редакциягә мөрәҗәгать итә аласыз.

«Казан утлары» журналының индексы 73210.

Язылу бәясе бер елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210